# КАЗАН УТЛАРЫ

11.1999



ТАТАРСТАН

ЯҢА ГАСЫР — НОВЫЙ ВЕК

Казань

**19 DEKABR'**

**Rossiə Dumasına, Tatarstannıŋ Dəülət
həm cirle Sovetlarına
saylaular kөne**

# Казан утлары
# Qazan utlarь

*1999*

**11**

**(925)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Хәлим Гайнуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Нажар Нәҗми,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова.**

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Барлас КАМАЛОВ. Дөмбер Даниял. *Повесть* ........ 5
Шәүкәт ГАЛИЕВ. Бакырчы җәе. *Шигырьләр* ........ 39
Марат ӘМИРХАНОВ. Тәкъдир. *Роман* ........ 45
Нур ӘХМӘДИЕВ. Сагынудан бүтән зарым юк. *Шигырьләр* ........ 114

НӘКЫЙ ИСӘНБӘТНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Нәкый ИСӘНБӘТ. Мәкальләребез турында ........ 119

ХӘТЕР

Факил САФИН. Кече Укмаска сәяхәт ........ 140
Кадыйр СИБГАТУЛЛИН. Шагыйрь архивыннан. *Шигырьләр* ........ 148
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Онытылмас эшләр калдырып китте. *(Ш. Хөсәеновның тууына 70 ел)* ........ 189

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фаяз ДУНАЙ, Илһам ФӘТТАХОВ. Туксанынчы еллар әдәбияты *(Анкетага җаваплар.)* ........ 153

ПУБЛИЦИСТИКА

Вахит ЮНЫС. «Кызыл кхмер» ........ 157

СӘНГАТЬ

Юныс САФИУЛЛИН. «Әйләнә сәхнә...» ........ 163

ТАРИХ

Алсу КӘРИМОВА. Ике йолдыз яктысы ........ 174
Гаяз ИСХАКЫЙ. Артист Габдулла Кариев ........ 175

ШӘРӘФ МӨДӘРРИСНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Шәрәф МӨДӘРРИС. «Сонетлар бәйләме» циклыннан. *Шигырьләр (Л. Ихсанованың кереш сүзе белән)* ........ 177

КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА

Марс ШАБАЕВ. Бер китап язмышы ........ 181

КИТАП КҮЗӘТҮ

Чулпан ЗАРИПОВА. Шигърият һәм җыр ........ 186
Котлыйбыз! ........ 190
Иҗтимагый—мәдәни тормышыбыздан ........ 191
Тышлыктагы сурәтләр ........ 192

# В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть Б. КАМАЛОВА «Непоседа Даниял»; роман М. Амирханова «Судьба» *(окончание)*; стихи Ш. ГАЛЕЕВА, Н. АХМАДЕЕВА.
«К 100-летию Наки Исанбета»: статья выдающегося писателя и ученого - фольклориста «О пословицах» *(продолжение)*.
«Память»: статья Ф. САФИНА «Путешествие в Малый Укмас»; стихи К. СИБГАТУЛЛИНА; статья Аяза ГИЛЯЗОВА к 70-летию Ш. Хусаинова.
«Литературная критика»: «Татарская литература 90-х годов»—статьи Ф. ДУНАЯ, И.ФАТТАХОВА.
«Публицистика»: статья В. ЮНУСА «Красный кхмер».
«Искусство»: статья Ю. САФИУЛЛИНА посвящена творчеству режиссера Д. Сиразиева.
«История»: А. КАРИМОВА. «Свет двух звезд»; Г. ИСХАКИ. «Артист Габдулла Кариев».
«К 80-летию Ш. Мударриса»: предисловие Л. Ихсановой; стихи поэта.
«К 1000-летию города Казани»: М. ШАБАЕВ. «Судьба одной книги».
«Книжное обозрение »: Ч. ЗАРИПОВА рецензирует книгу К. Миннуллина «Поэзия и песня».
В номере отмечается 70-летие переводчицы Ф. Гайнановой.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Родной язык мой...»—картина художника И. Рафикова; писатель Киям Миннибаев.

# IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": story of B. KAMALOVA «Fidget Daniyl»; novel M. AMIRKHANOVA «Fate» (finishing); verses of SH. GALEEV, N. AKHMADEEV.
"Commemorating the 100 Anniversary of N. Isanbat": article remarkable writer and scientific - folclorman «About proverbs» (continuation).
"Memory": F.SAFIN'S article «A trevel in Little Ukmas»; verses of K. SIBGATULLIN; article of AYAZ GILYZOV for 70th years of Sh. Husainov.
"Literary criticism": «Tatar literature of 90 th years» - article F. DUNAY, I. FATTAKHOV.
"Publicism": V. UNUS'S «Red khmer».
"Art": article of U. SAFIULLIN dedication creative works of producer D. Siraziev.
"History": A. KARIMOVA «Light of two starts»; G. ISKHAKI «Artist's Gabdulla Kariev».
"For 1000 years of Kazan city": M. SHABAEV «The fate certain book».
"Book review": CH. ZARIPOVA criticize K. Minnulin's book «Poetry and song».
In issue mention 70th years of translator F. Gainanova.
The diary of social and cultural life.
In our covers: picture of artist of I. Rafikov; writer of K. Minnibaev.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 29.10.99 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8029 Заказ 3-544
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1999 ел.

## Чәчмә әсәрләр



**Барлас Камал**

# ДӨМБЕР ДАНИЯЛ

ПОВЕСТЬ

Алмасар авылында унганлыгы белән тирә-юньгә мәгълүм механизатор Лотфулла Арукаев көн итә. Хатыны Өммегөлсем дә үзенә тин, гомере буе терлекчелектә эшләп, мактаудан гайре сүз ишеткәне юк. Алар биш бала үстерделәр. Өлкәннәре тырыш, әдәпле булып буй тарттылар да, берәүдән дә ким булмыйча дөнья көтәләр.

Арукаевларнын төпчеге—Даниял гына әллә ниндирәк булып чыкты. Юк, әрәмтамак түгел, хезмәттән посынып йөрми. Бәләкәйдән этисе кул астына керде, жиденче классны тәмамлаган елны ук комбайнчы ярдәмчесе булып эшләде. Махсус укымаган булса да, техниканы биш бармагыдай белә.

Холкы—табышмак. Укытучылары белән бәхәскә керде дә, мөгезен жиргә терәде—унынчыга бармады. Армиягә алынганчы тракторда, комбайнда эшләде.

Малай чактан ук шауберлерәк булды, ягъни бер караганда басынкы-сабыр, икенче баксаң, пружинасы ычкынгандай булып, эчендәге тышында дигән кебек, жилбәзәкләнеп китүчән. Җыр күнелле дә ул үзе, шигырьләр чыгара.

Авыл малайлары таккан кушаматы да холкына сыланып тора. Дөмбер Даниял дип йөртәләр аны. Әлеге атнын кушылуына да үзе сәбәпче.

Икенче класста укыганда микән, көзен ике-өч малай колхознын иске кәнүшние чормасына менәләр. Һәрвакыттагыча, Арукай Лотфулласының житез-жилле төпчеге алдан элдертә һәм... черегән түбә тактасы сынып-жимерелеп эчкә мәтәлә. Бәхетенә, атларга дигән солы өстенә барып төшә. Чуртым да булмады үзенә.

Җаны гел көтелмәгән хәтәрлекләр тансыклап кына йөргән малай бу хәлне илбасарлар, пиратлар, парашюттан сикерүчеләр батырлыгына охшатып кат-кат сөйләүчән булып китә. Сүзен һәрчак «Дөмбер!» дип тәмамлый (ишелде дә төште, янәсе!).

Яратканга ябышкан, диләр ич. «Дөмбер» дигәнең тәки сыланып калды Даниялга. Тик мона ул тырнак очы кадәр дә кимсенмәде, гарьләнмәде. «Дөмбер» ана «атказанган», «аеруча хезмәт күрсәткәне өчен» дигән төслерәк тоела иде, ахрысы.

Сагынганда сабан жигеп, теләгәндә текмә тотып йөрүче Даниял солдаттан кайтканда житдиләнә төшкән иде шикелле. Алай да аны кушаматы каршылады: «Дөмбер кайткан. Бетереп!»

Туган авылга, кендек каны тамган нигезгә исән-имин әйләнеп кайтуның куанычы ни кимәлдә булуын солдат хезмәтен үткән һәркем белә. Даниял да бу шатлыкны татымый калмады. Мәгәр... мәгәр аның сөенеченә кара шәүлә төшергән, сөмсерен сәхрәгә сипкән хәл бар иде. Бу—үзенә күрә бер мәхәббәт тарихы.

Беренче елын бик яхшы хезмәт итеп, бүләк ялына кайткач, Даниял үзе югында авылга килеп эшли башлаган шәфкать туташы Таңсылу белән танышты.

Көзге көннәрнең берсендә яшьләр күңелендә шатлык канат җәйде. Әйтерсең лә елның бу фасылын онытып, кояш язгы иртәдәгечә балкыды, әйтерсең лә баш очында тургай мөнәҗәт сузды, әйтерсең лә ике күңелгә берьюлы сандугач оялады.

Күрешүләренең беренче көнендә үк яшьләр бер-беренә гашыйк булдылар. Дөньяда янә бер мәхәббәт учагы кабынды да, вәгъдә яктысы һәм җылысын бөрки башлады.

Даниялны үз частена озатасы көнне яшьләр, егет демобилизацияләнү белән, туй итәргә сүз куештылар.

Арада хатлар өзелмәде. Хисләр кайнарлыгыннан кәгазь битләренә ничек ут капмый икән диярлек иде.

Танышканда аны-моны сиздермәгән иде, Даниял тезмә юллар белән язарга да һәвәс булып чыкты. Хатларының берсе менә бу юлларны алып килгән иде.

Таң атканда тугангамы,
Таңсылудыр исемең;
Көләч йөзең, тәмле сүзең
Әсир итте хисемне.

Таң суында коендырган
Газиз әнкәең сине;
Шуңа сылу, шуңа зифа
Буй-сыннарың да синең.

Таңда төшкән чык тамчысы
Тамгандыр күңеләңә;
Чык кебек саф, чык кебек пакь
Булып кал гомереңә.

Кыз үзенең җавап хатында һич чытлыкланып түгел, чын-чынлап үпкә катыш фикерен язган иде: «Даниял, дим, мине күкләргә күтәреп, җайсыз хәлгә куйма, оялтма, яме? Күреп киттең бит, белеп киттең, мин буем-сыным, төсем-битем белән дә, башкарган эшем, кылган гамәлләрем белән дә гап-гади авыл кызы. Ә сиңа карата саф та, пакь тә булып каласыма ышан...»

Үзәккә үтәрлек зәмһәрир салкынлы, котырынкы буранлы кыш үтеп, яз килде. Мәгәр бу яз иртәрәк елмайды шикелле, җир өсте дә иртәрәк бизәнде кебек. Яфрак бөреләре кабаланыбрак ачылды, чәчәкләр ашыгыбрак атты бугай.

Апрельнең өченче атнасында әле ерак юл алмаган кыш, яшьлектәге үчен алырга теләгән көнче-хөсетле карт кебек, шәфкатьсез сулышын өрде. Язның яшел ямен кәфендәй ак төс белән томалады.

Күңелләргә шом оялады.

Таңсылу шыгырдап торган кар суыгын, төньяктан искән җилләр зәһәрлеген тоймады да. Керсез мәхәббәт аны мамыклы җылы белән ураган иде.

Гомере беткән барыбер китә. Нәрсәсендер онытып кире кайткан

кыш-карт, күпме генә акшар сипсә дә, яз кызының дәрт кызуына чыдый алмады, табан ялтыратты.

Шул чак шәфкать туташы серенә төшенү авыр булган халәт кичерә башлады. Аның күкрәгенә мәгълүм булмаган хис кереп оялады, җанына исәр уй-ниятләр инде. Яшь күңелнең тыйлыксыз ярсынуы идеме бу, бәгыренең кемгәдер каерылып ачылырга теләвеме, әллә һәммәсе бергә үрелеп, җан-җисеменең ашкынып үз ишен эзләве, даулавымы? Сагынусагыш вә зарыгуданмы, башка нәрсәдәнме—күңеле еш тулышты кызның. Өйдә чакта квартира хуҗасы Сәлимә апасына күрсәтмәскә-сиздермәскә тырышып яшь түгеп тә алгалады.

Менә бүген дә Таңсылу, елап алгач, көзге каршына килде дә, үз чагылышына күз кысып, елмаеп куйды. Аннары төз борыны яфрагындагы ике-өч тары бөртегедәй сипкелләренә кагылды. Гүя елавы шул бөртекләрдән арына алмаудан иде. Аяз күк йөзедәй зәңгәр күзләренә усал караш белән текәлде. Елавына шул зәңгәрлек тә гаепле дип уйларсың. Күзләрен зур ачканда, озын куе керфекләре хәрәкәтсез кала, алар бәләкәй уксөнгеләрне хәтерләтә. Таңсылуның чиядәй иреннәре турсаеп куйган сыман булды. Әйтерсең ул керфекләрнең кара булып, зәңгәр күзләренә күләгә төшерүләреннән риза түгел. Шул канәгатьсезлек тудырган тойгыга бирелеп дип уйларсың, кыз калын чәч толымын калку күкрәге өстеннән алып артка ташлады. Тагын көлемсерәде, тагын көзгедәге шәүләсенә күз кысты һәм, ун кулын күтәреп, нәфис бармакларын кыймылдата-кыймылдата, үзе белән үзе саубуллашты. Тынны кыса башлаган, әллә нишлиселәр килгән мизгелләр үтеп китте...

Кайтырга җыенып, Таңсылу халатын, ак башлыгын, йомшак башмакларын салып, өстенә плащын, аягына затлы туфлиларын киеп, башына кыекча яулыгын япты да урамга чыкты. Аяз көннең саф һавасын күкрәк тутырып сулавы нинди рәхәт! Шәфкать туташының каршысына хат ташучы Халисә апасы килә иде. Ул Таңсылуга ерактан ук елмаеп-балкып эндәште:

—Әйт, сеңелем, сөенчегә ни бирәсен? Сиңа күркәм хәбәр бар.

—Бәйрәм концертында синең исемең белән аталган җырны җырлап бирермен, Халисә апа!

—Вәгъдә—иман, диләр, онытма.—Хат ташучының күңеле тагын да яктыра төште кебек.—Сөенчегә җырлавыңны әйтеп башкарырсың, яме?

—Була ул, Халисә апа! Шартың китерербез...

Хат ташучы Таңсылуга телеграмма тоттырды. Шәфкать туташы өчен телеграмма тексты язылган бу бизәкле открытка очып килеп иненә кунган бәхет кошына тиң иде. Кыз урыныннан кузгалмый гына телеграмманы бер укыды, икенче кат күздән кичерде... Укыган саен тасвирлап бетергесез сөенеч вә ләззәт дулкыны аны ныграк били барды. Кайнар хисләр гүя сулаган сулышы белән бергә агылып керәләр иде.

«Кадерле Таңсылу! Сине яз бәйрәме белән чын күңелдән котлыйм. Гөлләр кебек яшәвеңне телим. Бәхет, олы мәхәббәт сиңа гомерлек юлдаш булсыннар. Дөньяда мин барын онытма. Кайнар сәлам белән Даниял».

Ике көннән Даниялның хаты да килеп житте. Ал өстенә гөл дигәндәй, гаскәри егет фотосурәтен дә җибәргән иде.

Егет сагыну хисләрен бәйнә-бәйнә язган.

Хатта янә ошбу юллар бар:

Сокланырга—Син гүзәл зат,
Рухланырга—илаһи зат,
Уйланырга—табышмак зат,
Сагынырга—дөньяви зат.

—Рәхмәт!—Таңсылуның кәефе килде. Шигырьдәге сыйфатлар бәйләме чыннан да үзендә бардыр дип түгел, Даниялның шул күркәм якларны анарда күрергә теләве өчен...

Хатны кат-кат укыгач, кыз кулына фоторәсемне алды, бик озак

карап торды да күкрәгенә кысты. Фотодан аңа озынча йөзле, киң маңгайлы, дөньяга сокланып баккандай зур ачылган күзле бик сөйкемле егет карап тора. Алай гына да түгел, сурәт телгә килеп: «Онытма мине!»— ди кебек иде...

Апрельнең соңгы көнендә кичен Таңсылу фатирда тора торган Сәлимә апасы өенә укытучы кыз Гөлнур килде. Ул бу авылда икенче елын укыта. Гөлнурга бүген егерме яшь тулган икән. Дусты Таңсылуны туган көн бәйрәменә чакыра килгән...

Сый мул иде. Өстәл тирәләп ике генә пар утырса да, мәҗлес тамадасыз булмый, күрәсең. Бу эшкә колхозның электригы, Гөлнурны бик тә үз итеп йөрүче Ваһап керешә. Сүзгә әллә ни шома түгел ул, шулай да мәгънәле генә кереш әйтеп, шампан шәрабын шартлатып ачты, фужерларга коеп, тост тәкъдим итте. Аннары өчәү, берсен-берсе бүлдереп, юбилярга матур теләкләр теләделәр. Спортчыларча әйтсәк, туган көн бәйрәме старт алды.

Җыр туктап тормады, баян тынмады, җор сүзнең, шаян мәзәкнең чуты булмады. Тостлар әйтелә торды. Таңсылу рюмкасын чәкештерде, ләкин эчмәде.

Колхозның ветфельдшеры баянчы Гыйльман Таңсылуны үз карамагына алгандай итте. Кыстады, сыйлады, уйнаудан туктаган araларда җан эретердәй сүзләргә юмарт булды, мактады. Шулай да чибәркәйнең эчмәве аны үртәндерде, мин-минлегенә сукты. Ул сикереп торды да Таңсылу рюмкасындагы хәмерне юынгыч астындагы чиләккә илтеп түкте.

—Ярамый бит инде бу тикле нәзберекләнергә!—дип сөйләнде ул.— Ихтирам итеп чәкешүнең кадерен җибәрү була, безне санга сукмау килеп чыга... Менә компот салам алайса, һич югы шуны эчәрсең, назлыбыз...

Ул тумбочка өстендәге банкадан компот койды. Аннары күз ачып йомган арада рюмкага нидер салып өлгерде. Моны Гөлнур искәреп тә калды шикелле, тик бу хакта сүз әйтмәде.

Компотлы рюмканы Гыйльман кызга шундый тәкәллеф белән тәкъдим итте, бик сирәк була торган тантаналы йола башкарыла иде дип уйларсың! Шунысы сәеррәк иде, кыз рюмкасын бушатып куйгач та, сыйлаучы, тәүге күргән мәлдәгечә, Таңсылуны байкап утырды.

Кыз җайсызланып-җәберсенеп калды хәтта. Уңайлы минут сайлап сикереп торды да Гөлнурга төбәп шигырь укып китте.

—Гөлнур дустым,—диде ул,—

Сокланырга—Син гүзәл зат,
Рухланырга—илаһи зат,
Уйланырга—табышмак зат,
Сагынырга—дөньяви зат!

Кызның шигъри юллар укуы Гыйльман күзеннән сакланыр калкан эзләве иде.

—Әлеге юлларның авторы—шушы авылның бер егете булыр!— Таңсылу классташының дөньядалыгын Гыйльманның исенә төшерде һәм горур кыяфәткә керде.

—Бик белеп торабыз,—диде Ваһап.—Авторы ерактан сизелә.—Аның авызы хәмер кытыклаудан ерылган иде.—Солдат Арукаев чыгарган бу юлларны...

—Әйдәгез, авылдашыбыз, минем классташым шәрәфенә күтәрик монысын! Без аның белән сабан туйларында көрәшә идек.

Гыйльман циркта гы күз бууучы иллюзионист кебек хәрәкәтләр ясап, башта Таңсылуның рюмкасын кулына бирде, аннары үзенекен күтәрде.

Кабымлыкларга үрелделәр.

Баян янә телгә килде, янә җыр башладылар.

Тәрәзә пәрдәсен ачып, урамга карагач, Ваһап әйтә куйды:

—Таң сызыла, җәмәгать! Һава сулап керәбезме?

Аңа Гөлнур кушылды.

—Әйдәгез!

Гыйльман да килеште.

—Чыннан да, әйдәгез!

Тансылу гына карышты.

—Юк, мин чыкмыйм! Арыдым, әллә нигә алҗып киттем. Гафу кыла күрегез, аз гына ял итим. Гөлнур, кечкенә бүлмәнә керимче... Бигайбә!..

Өчәүләшеп саф һавада кинәнеп йөрделәр. Беравыктан Гыйльман әйләнеп керде һәм песидәй килеп, Тансылу янына ятты.

Кыз нидер сөйләнеп каршылык күрсәтте, үзенә ябырылган нык, таза егетне куллары белән этәреп җибәрмәкче булды, тибенде, кычкырырга итте, аваз чыкмады. Тетрәнүдән аның тавышы качкан иде...

Морадына ирешкән Гыйльман формасы килсенгә генә Тансылуның чәчләреннән сыйпаган, бит очыннан үпкән булды да, янә тышка чыгып китте.

Байтак йөреп керделәр алар.

Рюмкалар тагын мөлдерәмә тулды. Гөлнур бүлмәгә узып, Тансылуны табынга чакырды. Дусты чыгалмасын әйтте.

—Ярар, сулу алсын!—диде Гыйльман. Классташының бәхетеннән күптән көнләшеп йөргән адәм бүген кылган гамәленнән бик канәгать, ләкин азагы ничек булып бетәрен белмичә, нык кына шүрли дә иде.

Ниһаять, өненә килеп, Таңсылу торды һәм акылыннан шашар хәлгә житте. Төпсез упкынга сикерәсе, дөрләп янган утка керәсе, муенына таш тагып, агымсуга батасы, дар элмәгенә керәсе килә иде аның. Шомлы, дәһшәтле кара уйлар ташкыны сытып китәр дигәндә, миенең бер почмагында елдырым уйнап алды: «Тукта, уйлан! Бу хурлыкка төшүеңне фаш итү-итмәү үзеңнән тора бит! Югаласы югалган, ичмаса кешеләр белми калсыннар. Бүген үк авырулар йөз чөерәчәк бит югыйсә үзеңнән. Иң беренче булып Сәлимә апаң өеннән куып чыгарачак... Тукта, ныгытып уйла... Кыз баланың исеме чук өстендә, аннан төшсә чүп өстендә. Уйлан...

Тансылу көч тупларга дип җан атты. Фикер бизмәненә ниләр генә салып карамады! Фәкать үзе генә сакларга тиеш булган хәзинәне ахмакларча югалтуына аптырауның чигенә чыга алмады. Әлбәттә, үз рюмкасындагы шәрабка Гыйльманның ике тапкыр йокы даруы салуын уена да китерә алмый иде ул.

Таңсылу Гөлнурны чакырып алды, артыгын эчтем бугай, кәефем бик начар, кайтып дару кабыйм әле, дип, фатирына кузгалды. Егетләрнең чуерташлары кызган иде, шәфкать туташының чыгып китүен абайламый да калдылар.

Туып килгән көннең алсу сыек яктысында мәсхәрәләнгән кыз авыл урамыннан дарга асылачак кеше сыман узды. Атласа да атлады, атламаса да...

«Язгы ташкыннар да тынып өлгерде, тау-тау кайгымны кайларга агыза алам соң?» Аның башында бернинди карарга да этәрми торган баткаклы, ләпек уй чиләнде. Шул уйны ыра-ера икенче бер фикер баш калкытты: Даниялдан көнләшеп үткән елларының үчен алдымы бу идиот? Даниял танышып киткән айда ук әйткән иде шул: «Без Гыйльман белән дуслар идек, көндәшләргә әйләндек. Унынчы класска күчкән елны авыл сабан туенда көрәшкәндә иң азакка без икәү калдык. Кем—кемне? Озак тартыштык. Ахыр килеп, мин аны аркасына салдым, батыр калдым. Шуннан бирле ул мине өнәми, чагарга гына тора...»

Инде менә зәһәрен чәчеп чакты булып чыга, кызның җанын кара көйдерде. Кемнеңдер хөсетлеге, кара көнләшүе аркасында өзелеп сөйгән өчен җәза бармыни соң җирдә?!

Сәлимә апасы йокы аралаш булса да кызның кәефе кырылганын чамалады, мәгәр һәммәсен хәмер-шәрабка юрады.

—Аракысы да, вино дигәне дә—ирләр ризыгы бит ул. Хатын-кызга төсмени соң?! Ят, ял ит, йоклагач узар,—дип сөйләнде.

Хәмер шаукымы үз хәлен аңлап өлгергән минутта ук юкка чыккан иде. Яшьлек сафлыгын югалтуның әрнүле-үкенечле тойгысы аны каберенә тикле озата барырдыр, мөгаен.

Таңсылу эчтән тынды. Аның вөжданын кара игәү игәүли иде. Намусы каршында Алыптай сорау килеп басты: пычрак фаҗигане Даниялга ничек аңлатасы булыр?

Башында шушы сорау калыпланууга, коточкыч сөземтә дә формалашты: мин Даниял өчен юк бит инде хәзер!

Ике-өч атна буена хат язар өчен кулына кәгазь-каләм тота алмады ул. Егеттән борчулы хат та килде: ни булды, нигә язмыйсың?

Күпме генә сузсаң да очы бер чыгачак иде, үз иңнәренә үзе басып, Таңсылу Даниялга чынбарлыкны ирештерергә булды, алдандым, дип язды, егет чактагы көндәшең Гөлнурның туган көн бәйрәмендә көчләде дип, дөресен хәбәр итте. Бу авылда калмаячагын, Чаллыга яисә Казанга китеп урнашасын әйтте. Гафу сорый алмыйм, кичермәсеңне беләм, диде. Мәңгегә хуш, хыялымда тирбәтеп тә насыйп булмаган ярым, дип тәмамлады.

Җавап хаты озак көттермәде. Ул бик кыска һәм шигъри юлларсыз иде.

«Гыйффәтлелекне саклау һәр кызның да хәленнән килми, күрәсең. Син үз намусыңны пычрату өстенә минем өметләремне дә чәлпәрәмә китердең. Нишләмәк кирәк, ай булмаса, йолдыз калкыр».

Бер нәрсә көн кебек ачык иде: Таңсылуның хыянәте егет бәгыренең асылын сыкты, күңел кыйбласын бутады, холкын сындырды, үземнеке булыр дип йөргән затның пырдымсыз рәвештә йөзенә төкергәндәй итүе Даниялны хатын-кызларга аяусыз һәм нәфрәтле итте. Җанын үч алу теләге биләде. Чынга ашмаган хыял уңалмас җәрәхәт калдыра. Ә яра онытылмый, тиз генә онытыла алмый. Шагыйрь әйткәнчә, аны тән онытса, җан онытмый; җан онытса, кан онытмый; кан онытса, аң онытмый!.. Кешенең хакыйкатьтән курка башлавыннан да яманрак бәхетсезлек юк, диләр...

Солдатка Даниял тугыз класс белем белән генә киткән иде. Урта мәктәпне тәгәлләргә һәм авыл хуҗалыгы институтына керергә дигән ныклы карар белән кайтты ул. Армиядә аны шоферлыкка укыттылар. Хәрби шофер булып алгач, стройда интегүне, җәяү йөрүне белмәде.

Мәктәптә автодело фәне укыта башлаганнар иде. Монысы Даниялга икенче класслы шофер правосын алу өчен трамплин булды. Өлгергәнлек аттестатына имтиханнар арасында район автомәктәбендә икенче класслы йөртүче хокукына да сынау бирде.

Лотфулла Арукаев улының инженер-механик булырга теләвенә бик риза иде. Егет үз юлымнан китә, гомере буе авызы икмәккә тук булыр, чит-ят хозурына баш иеп, тез чүгеп бармас дип фәһемләде. Әнисе Өммегөлсемне әйткән дә юк. Ул да төпчегенең заманча белемле булырга талпынуын ихластан хуплады.

Даниял үзеннән яшьрәкләр белән укый башлады. Ул унынчы класстагы егет-кызлардан буе-сыны, бәдән ныклыгы белән генә түгел, тормыш күргәнлеге белән дә аерылып торды.

Солдат-шәкерт тәгәл фәннәрне бик ярата һәм җиңел үзләштерә иде. Тарих, география белән дә дуслыгы бөтен булды. Рус әдәбиятыннан язма эшләр генә теңкәсенә тиде. Сөйләм теле ярыйсы ук шома иде үзе аның. Солдат еллары бу җәһәттән шактый үтүкләде. Сочинение язарга дигәндә, хәлләр көрчеккә терәлүчән булып кала бирде.

Бәхетенә, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Надежда Сергеевна бик ярдәмчел булды. Иренү-авырсыну белмичә, Даниял белән өстәмә шөгыльләнде. Дәресләрдән соң берүзенә диктантлар яздырды, сочинение өчен темалар биреп, егет өйдә язып килгәннәрне аның янәшәсенә утырып җентекләде, әдәби әсәрләрне күбрәк укырга этәрде. Китапны малай чактан ук үз иткән Даниял рус классик әсәрләрен укып, үзенең тирәлеге

кинәя баруын тойды һәм мона шатланды. Надежда Сергеевна үзе дә Тургенев әсәрләренә чын-чынлап гашыйк иде, укучысына да шушы бөек сүз остасының әсәрләрен тәкъдим итә торды. Мопассан әсәрләрен дә беренче тапкыр рус теле укытучысының китапханәчегеннән алып укыды егет. Укытучысы биргән китапларга чумып, ул чит илләргә дә барып кайтты, китаплар булышлыгы белән кеше күңеленең иң тирәндәге чоңгылларына үтте. Китаплардагы персонажлар белән бергә мәхәббәт газаплары кичерде, сөешү хыянәте ярасына беркадәр дәва да тапты бугай. Тик хыянәт өчен үчешләнүе кимемәде.

Чынлап еласаң сукыр күздән дә яшь чыга диләрме? Уку елы азагына Даниял русча язма җәһәтеннән үзендә азмы-күпме унай үзгәреш сизде. Һәрхәлдә, күңелендә ышаныч яралды: авыл хуҗалыгы институтына керү имтиханнары тапшырганда рус әдәбияты буенча язма эшне канәгатьләнерлек билгегә башкара алачак. Әлбәттә, бәлки кирәге чыгар дигән яшерен өмет белән дистәгә якын сочинение әзерләп куйдылар. Булышлыгы, ярдәме өчен Даниял Надежда Сергеевнага рәхмәт укый иде.

Хәтердән тәмам очып киткәнче әйтеп үтик. Каракның бүреге яна дигәндәй, Таңсылу Даниялга һәммәсен ирештергәндер, ә Арукай Даниялы сдача бирми калучылардан түгел, хәнҗәр белән йөрәкне айкап ыргытуы бар дип шүрләп, ветфельдшер Гыйльман тиз арада күрше Чувашстанга тайды. Андагы бер татар авылында үз һөнәре белән көн итә башлады. Күз күеге булмаска карар кылып дөрес итте бугай ул.

Ә Таңсылу Казанга китте. Өмете болай да өзелгән иде. Авыл урамында очрашкач та Даниялның исәнләшмәве аның күчеп китүен тизләтте.

* * *

Өлкән классларда икенче ел рус теле һәм әдәбиятын укытучы яшь педагог Надежда Сергеевна Даниял Арукаевка карата аңлатуы читен булган мөнәсәбәттә иде. Даниял аның өчен күрергә—күркәм, тотарга куркам дия торган затка әверелде. Укытучы үз укучысына ир-егет итеп карап соклана иде. Чыннан да, сокланмаслыкмыни?! Кара тутлы бу егеткә Табигать һичнине кызганмаган. Озын буй, нык кулбашлары, горур карашлы коңгырт күзләр, куе кашлар, төз борын, ихтыяр көчен күрсәтеп торган ияк, көлгәндә энҗедәй балкып китүчән тигез матур тешләр...

Малай чактан ук физик хезмәт белән мәшгуль булып, спортны үз иткәнгә, көч-куәте ташып тора. Шул көч кытыгы аны сабантуйларында мәйданга бил алышырга чыгара бит инде.

Бер күргәндә Надя Даниялны сулышы-тыны белән үз кочагына суырып алырдай була. Икенче вакытта ул күзләрен «сукыр итә», үзенең алгысуын җинеп, егетне күрмәскә азаплана. Егет аның өчен «юкка чыгып тора». Мәгәр бу хәл озакка бармый. Тиздән Надяның җаны тагын бәргәләнә башлый. Егерме берен тутырган зат рух газабы да, тән ачлыгы да кичерә. Түшәк ялгызлыгы җилкенүнең чиген белмәгән күңеленә шом сала. Йоклаганда төш күреп, үзен баһадир ир-егет кочагында тоя. Бимазаланып, үз-үзен кочаклап өзгәләнә. Сөю-сөешү касәсен төбенә кадәр бушатасы килә аның. Ул бит әле аннан бер генә тапкыр авыз иткән кеше.

Казандагы офицер егет белән бер-берсен татыштылар да, икесе ике якка киттеләр. Дөресрәге, башлап егетнең күңеле бизде. Моны бик тиз төшенгән Надя, әти-әнисенә һични аңлата алмыйча, читтән торып укуга күчте дә, Алмасар мәктәбенә укытырга китте. Беренче мәхәббәт бәрәңге пешергән учакка охшап сүнде, яшь, сәламәт, яшьнәп торган тәннең ир затына ихтыяҗы дөрли бирде. Шашкынлыгына дәваны Надя Даниялда күрде.

Надежда Сергеевнаның үзенә карата әллә ничегрәк, гадәти үк булмаган мөнәсәбәтен Даниял сизми түгел иде. Әмма хисләрне тезгендә тотарга кирәклеген дә төшенде ул.

Четерекле-нәзберек мәсьәлә Май бәйрәме көннәрендә, төгәле—икенче майда чишелде. Спорт залына чираттагы күнегүләргә килгән Даниялның гер күтәрүен, турникта атынуын, алкаларда уйнавын читтән күзәтеп торган һәм егетнең буй-сынына, уйнаклашып торган мускулларына сокланып Надежда Сергеевна, егет кайтырга җыенып киенә башлагач, бер читкәрәк дәшеп алды да, кичке тугызга үз фатирына бәйрәм чәенә чакырды. Гап-гади генә итеп кунакка өндәде.

Даниял сәерсенеп калуын сиздермәскә тырышты, баш тарткан булып кыланмады. Киресенчә, ризалык билгесе булырлык сүзләр тапты:

—Быел яз соңлады бит, Надежда Сергеевна, бүләккә чәчәк тә юк.

—Син үзең чәчәк, Даниял...

Укытучысының шушы сүзләре егетнең күзләрен ачкан кебек итте. «Бу бит...»

Икәүдән-икәү бәйрәм чәе эчтеләр. Татар карчыгы диярсең, Надежда Сергеевна мактый-мактый чәйнеккә Һиндстаннан килгән «Гөлчатай» чәен салып пешерде. Алай гына түгел, Надежда Сергеевнаның өч йолдызлы коньягы да бар икән. Аны да авыз иттеләр. Сержант погоннары тагып кайткан егетнең җимеш суларының мондыен да авыз иткәне бар иде. Кәеф күтәренкелеге кырык градуска үрләде. Радиодан атаклы эстрада җырчысы Ирина Понаровскаяның иҗат концерты язмасын тыңладылар.

Сүз агышы шундыйрак борылыш алды, Надежда Сергеевна шөһрәте дөньяга таралган француз киноактрисасы Катрин Денев әйткәннәрне хәтерләде.

—Люблю жить, чтобы жить, и ненавижу выживать...

Аннары Надя бәйрәм киемнәрен салып ташлады, төнге эчке күлмәктән генә калды да алдан ук җәеп куелган ятакка юнәлде. Көмеш кыңгырау чыңыдай тавыш белән дәште:

—Даниял, сүндер утны, кил яныма!..

Ике гәүдә тоташты. Ике тәнгә ток китте. Надя баллы ыңгырашу белән инрәде, ләззәтле дерелдәү бизгәгенә сапты. Даниял фани дөньяда ук җәннәт бакчасында хозур кыла иде...

Бу хәлләрдән соң алар бер мәл читенсенешеп калгандай булдылар. Мәгәр бу халәт бик тиз үтте. Тирән серле хәлне бүтәннәргә тел белән дә, йөз белән дә сиздермәскә кирәк иде. Сиздермәделәр.

Июнь башы.

Даниял тарихтан имтихан тапшырып, «бишле» алып чыккан иде. Надежда очрап, аны тәбрикләде дә, алар сөйләшә-сөйләшә мәктәп капкасыннан чыгып киттеләр. Сүзгә шул тикле мавыктылар бугай, Даниял укытучысын фатирына кадәр озатып җиткергәнен искәрми дә калды. Надежда Сергеевна егетне өйгә чакырды. Чәй өлгертте. Өстәл янында сүз кузгалгач, яратуын гына расласа бер хәл иде, педагог бу юлы Даниялны өнсез калдырырлык сүз әйтте: «Өйләнешик! Мин яңа уку елыннан Казанда эшли башлыйм. Әти үземә бер бүлмәле фатир алып бирә. Вәгъдә итте, ул сүзендә нык тора».

Егет күңелендә нинди өермә купканны тасвирлау читен. Даниял куәтле магнитка эләккән иде. Укытучысын кочагына алды.

Шашынудан айныгач, наянлыклары өчен орышылган балалар кебек икесе ике урындыкка барып утырдылар. Беренче булып Надежда Сергеевна сүз башлады.

—Йә, җавабың нинди булыр?—диде.

Даниял җавап бирерлек хәлдә түгел иде. Дөресрәге, җавабы юк иде. Шулай да иреннәрен тегеп куйган төсле утырырга ярамаганлыкны чамалап:

—Берни дә әйтә алмыйм әле мин,—диде.—Һич көтелмәгән тәкъдим...

Надежда Сергеевна, урындыгын алып, Даниялның каршысына ук килеп утырды. Тезләре тезгә орынып калды. Егет әллә ниткән читенсенү

тойды, ләкин сер бирмәскә кирәген төшенә иде. Надежда очкынланган күзләре белән Даниялның карашын тотты. Күзгә-күз төбәшеп калдылар.

—Сине нәрсә шикләндерә? Минем татар булмавыммы? Бик азга гына өлкән булуыммы? Укыйсым бар, гаиләгә башымны бәйләп интегермен дип куркасынмы? Әти-әниең каршы килер дисенме? Йә булмаса минем әрсезләнүем, башлап тәкъдим ясавым нәфрәт уяттымы? Әллә боларның һәммәсе бергәме?

Даниял һаман җавапсыз иде. Тик югалып калу халәте узды. Сынын туры тотып, ир-егетләрчә җитди утыра башлады. Укытучысының нинди дә булса җавап ишетми торып тынычланмасын да яхшы аңлый иде. Шуна күрә:

—Мондый чакта җавапны бер селтәнүдә генә биреп була микән?—диде. Шул сүз җитә калды, Надежда Сергеевна фикерен дәвам итте:

—Мина шундый ышаныч каян киләдер, белмим, тик сине бәхетсез итмәсемне сизәм. Укуына комачау булмаячакмын. Монысын өзеп әйтә алам. Мин эшләрмен, минем белгечлегем буенча шәһәрдә дә урын табылачак. Син бик тырышып укырсың. Фатирыбыз үзебезнеке булачак. Ул ягын, әйттем ич, әти көйли...

Бу көнне егет өзеп кенә һични димәде. Тел күтәреп әйтер сүзе юк иде. Аның каруы, миен биләп алган уйлар бихисап иде.

Даниял башында сорау туды: «Изге тамыры» бармы әллә Надежда Сергеевнаның? Минем аңа чын-чынлап гашыйк булып йөрүемне ничек чамалаган? Сихерләнүемне ничек сизенгән? Мин бит аны табигать гүзәллеген яраткан төсле, матурлык өлгесе итеп ярата идем. Өйләнергә уйлап түгел. Хатыным итеп күз алдына китермичә. Нинди дер бер илаһи ярату иде бит ул...

Әгәр Надежда Сергеевна тәкъдим иткән юлны сайласам? Иң беренче булып әти белән әни каршы төшәрләр идеме икән? Төшәрләр иде. Ризалык бирмәсләр иде, юк, бирмәсләр иде... Төпчекләре, юньсезләнеп, үз укытучысына, марҗага өйләнсен әле!..

Дус-ишләр, кордашлар да аңламаслар, начар уйларлар иде. «Өйрәнчеккә—бәрәнчек булып авызланган бу малай, шуннан башын аралый алмаган. Ә тегесенә... кайнар канлы, гайрәтле татар егете кирәк булган. Пешмәгән борчак боткасы булачак боларның тормышлары...» диячәкләр.

«Егетнең башы түгәрәк,—дип мәсхәрәле елмаючылар да табылыр иде.—Степендиягә генә яшәп изаланмаска уйлаган. Укытучы акчасына көн итәргә җыена...»

Имеш-мимешнең, гайбәтнең чиге булмас иде. Монысына шикләнмәскә мөмкин.

Монысы—минем Надежда Сергеевнага өйләнү ихтималына читтән караш. Ә үзем? Үзем бәхетле була алырмынмы? Аның рухи дөньясын түгәрәк итәрлек көч табылырмы миндә? Аны бәхетле итәрлек кодрәткә ияме соң әле мин? Тормыш корып гомер сөрү ләззәтләнешеп алу гына түгел ич...»

Егетнең башы каткан иде, гаиләдә яшен яшьнәп, күк күкрәде. Иртәгә институтка документлар илтергә барасы дигән көннең кичендә Даниялны әтисе җиләк-җимеш бакчасына чакырып алып чыкты. Алмагач төбенә әмәлләп куйган өстәл янына килеп, кара-каршы утырдылар. Лотфулла нык әсәренгән иде. Ул үгезне мөгезеннән алырга булган, һәр сүзенә таш салып торды.

—Синең башыңа, улым, институт кайгысыннан да битәр укытучы марҗа хәсрәте кунаклаган икән бит! Шул нәстәкәй хак булса, син бүгеннән минем улым түгел! Дине башка, теле үзгә, гореф-гадәтләре, йолалары чит-ят кавем белән кан катнаштыру хакында уйларга да рөхсәтем юк. Арукай нәселе йөзенә тизәк сыларга юл куймам мин сиңа! Ни гомерләр татарны изгән милләтне ишәйтергә җыендыңмы? Юк, басам мин стоп-краныңны! Башыңны ихтыяри хәлдә элмәккә тыгып, коллык ярлыгы

алыргамы ниятең? Барып чыкмас! Атаңның соңгы сүзе шул: ул маржа белән мөгамәләнә бүгеннән нокта куясың! Ике әйтмәм, холкымны белеп үстең...

Даниялга акланырга да, аңлатырга да җай калдырмыйча, Лотфулла торып басты һәм эре-эре атлап өйгә кереп китте. Даниял бермәл алмагачка сөялеп торды да бакчадан чыкты...

Институтның кабул итү комиссиясенә документларын биргәч, Даниял Алмасарга кайтмады, имтиханнарга әзерләнде, нужа куучыларга кушылып баржа бушатты, вагон төяде, көнлек ихтыяҗларының очын-очка ялгап барырлык акча эшләде. Тулай торакта урын били алуына бик шат иде ул.

Керү имтиханнары аның алдында сират күпере булып тоелды. Кылдан нечкә, кылычтан үткен. Шуны үтеп чыга алсаң, син—студент, югары белем кыяларына үрләргә хокуклы адәм. Мәтәлсәң—бетте! Яшәешнең тәмугына очтың дигәнең шул була. Хурлыгыңнан хет асылын! «Кереп булмады шул!»—дип Алмасарга кайтып мескенләнергәме? Һай юк инде, юк! Бу кадәресе Даниял Арукаев өлешенә тигән көмеш булырга тиеш түгел!

Бик курыккан эшнең азагы хәерле була, дигән сүз бар. Хактыр ул, мөгаен. Хаклыгы шуннан гыйбарәт булса кирәк: хыялларым пыран-заран килеп, ярык тагарак янында калмыйм дип, кеше барлык акыл көчен, барча энергиясен алдына куйган максатны чынга ашыруга туплый.

Даниял өчен дәһшәт, билгеле инде, рус әдәбиятыннан язма эш иде. Хак тәгаләгә мең шөкерләр, күк капусын ачты бит! Имтиханда тәкъдим ителгән темалар арасында Надежда Сергеевна биреп яздырганы да бар иде.

Даниял Арукаевның язма эше унай бәя алды. Калган фәннәрдән имтихан тоту егетне ул тикле өркетми иде инде.

Үзенең исем-фамилиясен беренче курс студентлары исемлегендә күргәндә, егет күнеле белән күкнең җиденче катында йөзде. Алда үтәсе юллар авырлыгыннан өрки белми иде әле ул.

Августның егермеләре тирәсе. Көтмәгәндә-юрамаганда Даниял Бауман урамында Надежда Сергеевнаны очратты. Чак кына маңгайга-маңгай килеп бәрелмәделәр. Күтәрелеп бер-берсенә карагач, икесе дә көлеп җибәрде. Аннары гына кул биреп исәнләштеләр.

Университет урамы чатына борылып байтак сөйләшеп тордылар. Даниял сагынуга якын тойгы кичереп кинәнеп гапләште, мәгәр миендә өрәзлексез кечкенә кызыл лампочка янып торды: әтисенең катгый сүзләре кабызган ут иде ул. «Кара аны, малай!..»

Надежда Сергеевнаның әтисе сүзендә торган, кызына борынгы йортлар арасында калкып чыккан күпкатлы йорттан бер бүлмәле фатир алган. Әйтерең бармы, төзелеш тресты начальнигы шул! Надяның күченеп яши башлаганына әле бер атна чамасы гына икән. «Бүген кунакка чакыра алмыйм, гафу ит, беренче сентябрьдә кичләтеп көтәрмен!»—дип китте саубуллашканда. Эш урыны да шундагы бер мәктәптә икән. Транспортка утырып интекмәскә дә мөмкин. Чирек сәгать алданрак чыксаң, кичегүсез килеп җитә торган.

Даниял укытучысының яңа торагына киләсе булып саубуллашты. Тулай торакка кайту юлында ул бер карарга килде: укулар башланганчы елга портында бер атна ныгытып эшләп алырга! Сыгылсам сыгылырмын, аның каруы Надежда Сергеевна янына буш кул белән бармам, дип уена беркетеп куйды.

Беренче сентябрь мәктәпләрдә дә, техникум һәм институтларда да шундый бер көн инде ул, үзенчәлекле бәйрәм төсен ала. Җәй буе күрешмәгән классташлар, курсташлар очраша. Беренче курска килүчеләр яңа күмәклеккә күнегә башлыйлар. Яңа танышлар шул көнне игътибарны җәлеп итүчән була. Шул көнне яңа мәхәббәт бөреләре уянгалап куйган очраклар да аз түгел...

Авыл хуҗалыгы институтында барлык факультетларның беренче

курска кергән студентларын бергә җыеп сөйләштеләр. Югары уку йортында уку дигәнең шул рәвешле башланды.

Күзгә ташланганы бу иде: монда килгәннәрнең барысы да диярлек авыл егетләре һәм кызлары. «Без—авылныкы!» дип кычкырып торалар. Үз-үзләрен тотышлары, кием-салымнары, сөйләшү манералары... Бер-ике ел үтәр, аларның бер ишесе танымаслык булып үзгәрер, шәһәрнекеләр булып китәрләр. Телгә дә остарырлар, күзне-кашны, килешкилбәтне дә шәһәрчә итәрләр, костюмнар да сан-савырга сыланып тора башлар. Иң мөһиме—аларның уй сөрешләре, фикерләү рәвешләре шактый үзгәрер. Икенче берәүләре «Кубань казаклары» булып калырлар, «Каким ты был, таким и остался...» Шәһәр тимерчелеге андыйларны үзгәртеп чүки алмый...

* * *

Даниял агрономия факультетына килгән бер чибәргә дикъкать итте. Актлар залына керер алдыннан бер төркем кызлар белән читтәрәк сөйләшеп тора иде ул. Моннан атна-ун көн элек кенә студент булу бәхетенә ирешкән яшь кызлар, табигый, әле кыюсызлык кичерәләр һәм зур залга беренчеләр булып керергә батырчылык итмиләр иде.

Даниял бу кызга Гөлфия дип эндәшкәннәрен үткер колагына салып куйды.

Ректорат вәкиле беренче курска кабул ителгәннәрнең һәммәсен залга өндәгәч, теге кызлар да кузгалдылар, барысы бергә өченчеме-дүртенчеме рәткә барып утырдылар. Даниял алар артындагы рәткә теркәлде. Кызны кыеклап кына күзәтергә бик җайлы иде.

Гөлфия, халык җырындагыча, йомарлаган май кебек, урта буйлы, хатын-кыз өчен Алла сөеп биргән буй-сын иясе иде. Гәүдәсен скульпторның булдыклысы иҗат иткән диярсең. Йөзе айның унбишенче кичәседәй табак-түгәрәк тә түгел, озаеп-очланып та китмәгән, шул хәтле килешле кимәлдә, шикләнми әйтергә мөмкин, күпләрне ымсындырырлык. Акыл нуры сирпеп торган шомырт кара күзләрен яман карашлардан сакларга теләгән кебек озын куе керфекләр каймалаган. Карлыгач канаты төсле кашлары бөтен чыраена ямь өсти. Төз борын, пешүе килгән чиядәй юка иреннәре «Сөбханалла!» диярлек. Бит урталарына әнис алма алсулыгы иңгән. Болар өстенә чигәләрендәге кара бөдрәләрне дә кушсаң, тасвирлап туймаслык матурлык килеп чыга. Матурлык эталоны дияргә дә ярыйдыр, билләһи! Ымсынганга ымсын ашы инде менә! Акылы-фигыле дә начар була алмас бу затның. Бик әдәпле күренә. Эшчәндәдер. Үз гомерендә агрономнар күреп үскән бит инде ул, иренчәк булса, агроном хезмәтенә җигелергә карар кылмаган булыр иде...

Даниял чамасы җиткән кадәр кызның киенү зәвыгын да бәяләмәк булды. Чибәркәй өстенә ак кофта, чем-кара итәк, аякларына үкчәле кара туфлилар кигән. Йомры күкрәкләре өстенә төшәргә генә торган калын толымын әледән-әле артка ташлый. Ул толым кызга сихри бер төсмер өсти.

Алмасар егете уеннан бер фикер сызылып узды: күп тә үтмәс, Гөлфиягә бу нәфис, күркәм толым артык тоелыр һәм студентка кырыкмыш тай төсле йөрүне тансыклап кычына башлар. Аһ юк, бу чибәрне муен чокырыннан калдырып кистергәч чәч белән күрәсе килми. Бүген үк, гафу сорап, гүзәлнең янәшәсенә килер дә, килешми дип тормас, Даниял үзенең кинәшен бирер. «Сезнем,—дияр,—йөз проценттан арткан матурлыгыгызның бер өлеше булган толымыгыздан һичкайчан ваз кичә күрмәгез. Югыйсә сез зур гөнаһ кылган булырсыз»,—дияр.

Түр сәхнәдәге президиум өстәле артына менеп утырган галимгоmembers әмә арасыннан мәһабәт гәүдәле бер агай күтәрелеп, залның гөҗләүдән туктавын сорады. Очрашу башлана иде.

Торып баскан абзый институтның ректоры икән. Профессор. Ул бик кыска гына итеп югары уку йортының тарихына тукталды, нинди белгечләр хәзерләгәнлекне әйтте, перспективаданиләр буласын фараз кылды, бүген ничә кеше укуын телгә алды.

Профессор фикеренчә, авыл хуҗалыгы институты—ВУЗларның да ВУЗы иде. Ул, инанган фикерен ныгытып, болай дип дәвам итте:

—Без җир белгечләре тәрбиялибез. Агрономнар да, инженер-механиклар да, бакчачылар да—һәммәсе туклык тәэмин итүче җир осталары.

Кайчак уйлап куясың: кешеләр кайчан да булса «ҖИР» һәм «ИКМӘК» дигән сүзләргә мәгънәсе белән тиң берәр сүз таба алырлармы икән? Фәкать «АНА» дигән сүз генә алар янәшәсендә торырга хаклы. Бүтән бер сүзнең, бер төшенчәнең дә моңа хакы юк! Менә без шушы илаһи төшенчәләр булган кыйммәтләр белән турыдан-туры бәйләнештә булачак осталар укытып чыгарабыз...

Җыешлыштан соң Даниял, тартыну-читенсенүне бер читкә болгап, баягы кыз янына барды һәм:

—Исәнмесез, Гөлфия! Мин Даниял Арукаев дигән кеше булам. Очрашу башланганчы ук сөйләшмәкче идем дә, Сез кызлар белән онытылып китеп чүкердәшә идегез,—диде.

Кыз җайсызланып калды.

—Исәнмесез! Сез мине каян беләсез?—дип гаҗәпсенде.

—Беләм дип, бар белгәнем әлегә исемегез генә. Якыннанрак танышасым килә. Мин үзем Зөя буеннан. Даниял дидем инде. Урта мәктәпне солдаттан кайткач тәмамладым. Колхозда тракторчы да, комбайнчы да булып эшләгән малай. Инженер-механик булырга теләк зур. Шуңа дип килдем. Сораулар юкмы?—Егет күңелле көлемсерәде.—Инде Сезне тыңлыйк. Сез Чүпрәледән түгелме? Әллә Чистай, Аксубай якларыннанмы?

—Нигә дип әле ул районнарны атадыгыз?—Кыз гаҗәпсенә бирә иде.

—Сөйләшүегез мишәрчәгә бик тартым. Шуңардан чамалап әйтүем...

—Багучы була алмыйсыз икән.

—Тамырларымда чегән каны ага дип мактаныр хәлем юк, Гөлфия. Бик зур сер булмаса, үзегез әйтегез инде?

—Чувашиядән мин. Фәтхи Бурнаш туган авыл күршесеннән. Унынчыны былтыр бетергән идем. Бер ел участок орлыкчылык лабораториясендә лаборантка булып эшләдем. Менә укырга килдем. Әти-әни дә укы дип торалар...

—Алар кем инде, әлеге дә баягы сер булмаса?

—Әти җирле хакимият башлыгы, әнием—укытучы.

—Алай икән. Минем карт—гомерлек механизатор. Әни кешем терлекчелектә. Хәзер дә эшлиләр әле...

—Менә, анкеталарны тутырып бетердек,—дип көлде Гөлфия.

—Сез тулай торакка урнаштыгызмы?—егет шулай сорарга булды. Тешләгән җирдән өзәргә җыена иде.

—Юк.—Кыз, һәммәсен сөйләп тору кирәк микән соң дигәндәй, беравык сүзсез торды да, әйтергә булды.—Мин әтиемнең өлкән апасында торам. Ул күптән, бик күптән инде Казан кешесенә чыккан булган, үз йорты белән Яңа бистәдә яши. Байтактан пенсиядә...

—Аңлашыла язды. Рөхсәт итсәгез, озатып куйыйм, Гөлфия? Якыннанрак танышырбыз да. Вакытыгыз булса, фильм карап чыгарбыз. Юл уңаенда кинотеатр, шагыйрь исемендәгесе, беләсездер?

—Беләм. Шулай да миңа кайтырга кирәк.

—Алайса, әйдәгез, озатып куйыйм.

«Балалар универмагы»на кадәр җәяү килделәр.

—Беләсезме, Гөлфия,—диде Даниял,—сез игътибарны беренче нәүбәттә ни белән җәлеп итәсез?

Кыз башын борып, Даниялга текәлде. Сорау бирмәде. Җавапны егет үзе әйтте.

—Бик матур толымыгыз белән. Мин очрашуда утырганда бу унайдан дүртьюллык чыгардым. Укыйммы?

—Йәгез сон...

Даниял үз стихиясенә кереп бара иде. Такмаклап китте.

Кызлар күрке—озын толым,
Урала кунелләргә.
Саклагыз ул хәзинәне,
Кисмәгез гомердә дә...

—Кинәшегезгә рәхмәт! Мин әниемнән узып андый эшкә батырчылык итмәячәкмен. Әни чәч кистерергә беркайчан да рөхсәт бирмәячәк. Анын үзенен толымнары минеке кебек генәме!

—Акыллы апа икән!—Даниял бу темага шунда нокта куйды.—Тагын бер куплет укыйммы?

—Толым турындамы?

—Түгел. Йөрәк давылы турында.

—Укыгыз сон...

Күнелемә сандугачтай керден,
Хәерлегә булсын диикме?
Текәдер дип тормый, тәвәккәлләп,
Сөю тауларына меникме?

Бер очтан дәвам итәсе булды Даниял.

Ихтимал, шик-шомлы уйлар
Яннан җилләнеп узар,
Тик йөрәк алгысып туймас,
Назлану юксынып тузар...

Гөлфия салмак кына атлап барган җирдән туктады да Даниялга сорау куйды.

—Боларны конкрет мина адреслап укуыгыз түгелдер ич?

—Әлбәттә, сезгә, Гөлфия.

—Ашыгып төштем, утка пештем, дип уйламыйсызмы? Мине бөтенләй белмисез бит әле. Очраган бер кешегә йөрәк серегезне түгә башласагыз, кая китә ул?!

—Ә сез очраклы кеше түгел. Мона минем иманым камил. Мин ничә ел эзләгән кешемне таптым. Сез минем төшләремә керә килдегез. Төсегез, кыяфәтегез, буегыз-сыныгыз, сөйләшүегез нәкъ тормыштагыча итеп күрә идем төшләремдә...

—Сез Даниял, аферистмы, әллә балаларча беркатлы кешеме? Гафу итегез, мин сезне анлаудан ерак торам... Беренче күрешүдән шул тикле ачылып китү нәрсә галәмәте?

—Ихласлык. Бер-беребезне якыннан, бик якыннан белербез әле, Гөлфия. Биш ел бергә укыйсы бар. Бүген безнен хисләр берегер дип санийк, яме?

—Җиде кат үлчәргә кирәк.

—Унҗиде үлчәсәгез дә риза-бәхил мин. Тик мина унай җавап кына бирегез, Гөлфия...

Ниһаять, алтынчы трамвайга утырып, Яна бистәгә киттеләр.

Курсташын озатып кайтышлый Даниял гастрономга керде. Надежда Сергеевна янына барырга дип кучтәнәчләр алды, аннары чәчәк букеты эзләп китте. Шул чагында аны кемдер якасыннан тотып алгандай тәэсир туды. Беркем дә юк иде, әлбәттә. Теге көнне әтисенен үгет-нәсихәт һәм янау сүзләре рухи тукмый иде аны...

* * *

Надяның өченче каттагы бер бүлмәле квартирасы Даниял килгәндә көлеп тора иде. Тыйнак кына җиһазланган, соклангыч чисталык. Мебельдән, тәрәзәләргә элгән пәрдәләрдән, түр өстәлдәге сыйнигъмәттән нindидер җылылык бөркелеп тора иде. Хуҗасы җан җылылы кеше булганга шулай тоела торгандыр, күрәсең.

Кабарып торган сумка һәм чәчәкләр тотып килеп кергән Даниялны, алып килгән күчтәнәч һәм бүләкләрен куеп та өлгермәде, Надежда Сергеевна кайнар кочагына алды.

—Сагындырдың, татар егете! Зарыктым!..

—Сабыр, сабыр, Надежда Сергеевна! Муенны сындыра күрмәгез!..

Сизелер-сизелмәслек итеп кенә бизәнеп-төзәнеп алган, өстенә өрңяңа күлмәк кигән, изүенә асыл ташлы брошь таккан хуҗабикә егетне кочагыннан ычкындырды да, дәрес биргәндәгечә рәсми төскә кергән булып, сөйләп китте.

—Шуны зиһенегезгә киртләп куегыз, Даниял Лотфуллович, бүгеннән миңа Надя дип кенә эндәшәчәксез. Укытучы һәм укучы мөнәсәбәтләре теплоход койрыгындагы дулкыннарда калдылар. Без хәзер бер-беребезне ихтирам итүче якын кешеләр. Ир белән хатын дип әйтеп сине куркытасым килми, фактта исә шулай дияргә дә урын бар... Бу—бер. Икенчедән, сиңа янә бер шелтә. Кем сорады, яисә кем кушты сиңа, Даниял Лотфуллович, сумка тутырып ризык һәм хәмер-шәраб төяп килергә? Сине кунак итәрлек мөмкинлегем барын беләсең. Киләчәктә дә булыр. Бүтән мәшәкатьләнәсе түгел! Ишетсен колагың! Инде күтәренеп килгәнсең икән, әйдә, бушатыйк күчтәнәчләреңне... Чәчәкләрең өчен чын күңелдән рәхмәт менә! Букет сайлый беләсең икән...

—Беләсең дип... Күңелгә ятканын алдым инде, Наденька!

—Шулай диген, шулай колакка ятышлы. Якынлык сизелеп тора шулай эндәшүдән... Ә хәзер бар, кулларыңны юып кил дә, консерваларны ачарсың, шешәләрне...

Икәүдән-икәү генә чөкердәшеп утырудан да мәгънәлерәк мәҗлес бармы икән? Серләр килешкәндә, фикер уртаклыгы булганда, ике затның хисләре бер учак булып дөрләгәндә адәм баласының җаны рәхәт чигә, акылы зирәкләнә, тойгылары тирәнәя бугай ул...

Даниял алып килгән коньяк тәэсире Надяны бермә-бер дәртләндереп җибәрде, аның тәнендәге һәммә күзәнәк бар егәренә тернәкләнә иде.

—Яңа урында эшләр ничегрәк булырга охшый соң, Надя?

—Кайда да эшнең шеше бар инде ул. Укытучы хезмәте Алла каргаган бер шөгыль дигән фикер яралып килә күңелемдә. Кырык ата баласын тезгенлә дә белем-тәрбия бир, имеш! Шәһәр мәктәпләрендә тәртип ягы хөрти. Мине бишенче класс җитәкчесе иттеләр. Быелга түзәрлек булыр дип уйлыйм. Җилкәдә тагын бер йөк бар бит әле. Читтән торып укып, дүрт курска нокта куйдым. Алда тагын ике еллык зур мәшәкать тора. Тешне кысып булса да чыдарга кирәк. Ярты юлда калырга һич ярамый!..

Бәллүр рюмкаларны өченче тапкыр түнтәреп куйгач, Надя Даниялның беләгенә ябышып, күзләренә чекерәеп карады да:

—Хәзер мин сиңа ике генә юл шигырь укыйм. Авторын әйтә алырсыңмы?—диде һәм яттан укып китте.

Мою любовь, широкое море,
Вместить не могут жизни берега...

—Мин мәхәббәт җырчыларыннан русча Степан Щипачев шигырьләрен генә аз-маз беләм, бу юлларны кем язганын һич әйтә алмыйм,—дип, Даниял кулларын күтәрде.

—Белмәвең гаҗәп түгел...—Надя урыныннан күтәрелеп, Даниял урындыгының артына чыкты һәм егетне кочаклап алды.—Бу юлларны Толстой язган. Лев Николаевич түгел. А. К. Толстой. Аның «Слезы

дрожат в твоем ревнивом взоре» дип башланган шигыреннән бу... Йә, ярарсана! Әдәбият дәресемени соң монда? Әйдә, ял итеп алабыз! Аннары янә сыйланырбыз. Сентябрь төне безнен карамакта лабаса.—Ул Даниялны шулай арбады. Ә арбавын белсән, елан да карышмый, диләр. Егет өстәл яныннан торды.

Утны сүндереп тә тормастан иркәләнештеләр. Ярсынган, тынына капкан Даниял байтак сүзсез ятты.

Жан тынычланып, тән бушанып калгач кәефләре янә ямьләнде. Аппетитлап ашап-эчтеләр. Бер темадан икенчесенә сикерә-күчә озак сөйләштеләр. Аннары телевизорга күз салырга булдылар. Казан тапшырулары тәмамланган иде, Мәскәүдән яңалыклар тыңладылар.

Даниял бик иртә уянды. Стенадагы сәгать бишенче унбиш минутны күрсәтә иде.

—Надя, сәхәргә торасыңмы?—диде ул, шаяртырга исәп тотып.

—А что такое сэхэр?

Даниял булдыра алганча аңлатты. Ә хужабикәнең бик аңлыйсы да килми иде бугай, борылып ятты, ак җәймәне өстенә ипләбрәк япты.

—Мине Казан радиосы гимн уйный башлагач уятырсың, яме. Чәй куй, ашарыңа җылыт.

Егет сөяркәсе кушканча эшләде.

Җиде тулгач, чыгып киттеләр. Надежда Сергеевна—мәктәпкә, Даниял институтка.

Якшәмбедә очрашырга булып саубуллаштылар.

* * *

Профкомның культсектор әһелләре беренче курс студентлары арасында еш була башладылар, талантлар эзләделәр. Үзешчән сәхнә шаукымы кагылган Даниял тыйнакланып тормады, профкомнан килгән туташка (өченче курс студенткасы Гөлнара икән) : «Мин җыр текстлары, шигырьләр язуда үземне сынап карауч кеше, кирәге чыкса, җырлыйм да»,—диде.

Гөлнара самородок алтын тапкан кеше шикелле сөенде. Даниялның исем-фамилиясен кечкенә куен дәфтәренә язып алды. Аннары бишенче сентябрьдә кичен сәгать алтыга профкомга килергә кушты. Үзешчән сәнгать һәвәскәрләре шунда җыеласылар икән.

—Җидесендә чыгарылыш курсындагылардан кала барлык студентлар колхозга булышырга китәсе. Агитбригадага алынганнар бу эштән азат ителә,—диде Гөлнара.—Без шефлыктагы колхозларда концертлар куячакбыз.

Билгеләнгән вакытка килгәч, Даниял профкомда Гөлфияне очратты. Кызык булып китте ана.

—Мобилизациягә сез дә эләктегезмени?—диде ул көлеп. Монда очрашуга сөенүен яшереп тә тормады.

—Мин азрак җырлаштыргалыйм, шуңа үзешчәннәр белән буласым килә,—диде Гөлфия тыйнак кына итеп.

Репетицияләр залына чыктылар. Беренче курс һәвәскәрләренең осталыкларын карадылар. Нинди әсәрне, нинди көйне әйтсәң, шуны уйнарга сәләтле баянчылары бар икән. Профком яллаган филармония музыканты.

Гөлфия «Әллүки»не җырлаганда Даниял гына түгел, залдагы барчасы тын калып, тирән кичерешләргә чумып утырдылар. Җанны иркәли торган йомшак, ләкин көчле милли моң белән мөлдерәмә өретелгән тавыш теләсә кемне әсир итәрлек иде. Шушы аһән-моң бәгырь кылларының иң нечкә-нәзберекләренә килеп кагыла да, күңел чоңгылына юл ала. Җырдан егет тәэсирләнеп туя алмады.

Гөлфия җырны тәмамлагач, осталык сынарга җыелган әһелләр дә,

үзенчәлекле имтихан тотарга чакырылган яшь студентлар да, сихерләп тораташ иткәннәр диярсең, беравык тып-тын тордылар. Аннары, әйтерсең нидер шартлады, кубарылып кул чаба башладылар, тамаша залы түгеллеге онытылды. Гөлфия болай ук кабул итүне көтмәгән иде бугай, сизелер-сизелмәс кенә баш иде дә бер читкә китеп басты.

Институтта татар халык театрын җитәкләүче мәшһүр артист Гөлфиянең кулын кысты, сабыйны назлаган төсле аркасыннан сөйде. Кыз уңайсызлана калды хәтта.

—Күз генә тимәсен, сеңелем. Бер үк саклый күр тавышыңны!— Халык артисты үзен алкышлагандагы кебек дулкынланган иде.

Даниял икеләнә калды. Җырлап карарга соң? Әллә кирәкмәсме? Чувашстан кызыннан соң бүтәннәргә маташыр җай калмады түгелме?

Мәгәр шундук профком культсекторы әгъзасы Гөлнара алдында кыюлануын искә төшерде. Посынырга ярамый, егетләрчә булмый!.. Ул «Таң атканда»ны сузды. Онытылып тыңладылар. Репетиция залындагылар хыялында тылсымлы таң аттырды егет. Үзе дә тыңлаучылар хозурына таң алсулыгында бүтән шәхес буларак килеп басты шикелле.

...Тиң булып безнең елларга,
Балкысын гомер юлы.

Аны да кул чабып тәбрикләделәр. Залның аргы почмагыннан килеп беренче кул кысучы Гөлфия булды.

—Сихерләдегез, Даниял. Рәхмәт!

—Сезнең бәядән зуррагы кирәкми, Гөлфия!

Тагын ике студентка җырлады.

Бу көнне институт җәмәгатьчелеге каршында сынау узучыларның һәммәсен сәнгать коллективына алырга дигән карарга килделәр. Алар да шефлыктагы хуҗалыкларга гастрольгә чыгачаклар, диелде.

Таралышыр алдыннан, академия театрыннан килеп халык театрын җитәкләүче актер мондый нәтиҗә-тәкъдим ясады:

—Гөлфия Низамова да, Даниял Арукаев та, әлбәттә, соло җырларга тиешләр. Шуның белән бергә, мин аларның дуэт башкаруларын да бик теләр идем. Күпләр көнләшерлек парлы җыр килеп чыгачак. Мин моңа шикләнмим...

Сөенешкән яшьләр кайтырга кузгалдылар. Даниял Гөлфияне озата китте. Бу көнне алар бер-берсенә гади итеп «син» дип кенә эндәшергә килештеләр.

Тулай торакка кайтып ирешкәч, Даниял Арукаевны бүлмәдәше Гата керпеләнеп каршылады.

—Кайда йөрисең син, ә? Авылыгыздан әтиең килгән иде, беравык көтеп тә торды,—диде ул карлыккан тавыш белән.—Шәйхелислам абыйларына барсын. Итне дә, бәрәңгене дә шуларда калдырдым. Акча да Шәйхелисламда, диде. Запчастьлар юллап килгән булганнар. Бүген китәбез дә, диде.

Даниялга читен булып китте. Әтисенең кәефе кырылгандыр инде. Күралмый кайттым дигәч, әнисе дә күңелсезләнер... Тик ни хәл итәсең, профкомга да бармый булмый иде бит...

* * *

Институт шефлык итә торган хуҗалыкларның берсе Чулман буендагы зур авыл икән.

Студентларның сәнгать коллективын монда әйбәт беләләр булып чыкты. Шуна күрә үз итеп, көтелгән кунаклар кебек каршыладылар. Кичен авыл культура йорты тамашачы белән шыгырым тулды.

Элек тә монда чыгыш ясаган өлкән курс студентларына залның мөнәсәбәте гаҗәп җылы иде. Алкышлар тынып тормады.

Чират колхозчылар өчен таныш түгел башкаручыларга житте. Залда ниндидер сагаю туган төсле булды. «Йәле, йәле, карап карыйк әле, ниндирәк икән сез кемсәләр?»

Бригада житәкчесе—конферансье концертка ноктаны Гөлфия куярга тиеш дип санады, аны «саубуллашу фейерверкы» дип атады.

Гөлфия концерт азагына нокта гына түгел, өндәү билгесе куйды. Аны сәхнәдән озак чыгармадылар. Илаһи дип әйтерлек тавыш культура учагына жыелган авыл кешеләрен гүя күк гөмбәзенә чөйде, дәрьялар тирәнлегенә чумырды, кыйбла тарафына ерак офыкларга алып китте. Кая гына илтмәсен, ул аһәң мәхәббәт хакында сөйләде. Газиз анаңа, сөйгән ярыңа, туган төбәгенә мәхәббәт хакында...

Соныннан кечкенә мәжлес. Әмма Гөлфияне сагайтканы шул булды: Даниял анда катнашмады, тылсымлы балдак төсле юкка чыкты. Жырчы кыз төшенде, егетнең көне буе диярлек китапханәче яшь хатын янында уралуы тикмәгә булмаган... Шуңа микән, Даниял жырындагы сүзләрне Гөлфия үзенә кабул итә язып калды.

Таң алдыннан төшкә керден,
Борчуларың бар сыман.
Таң нурлары сиңа миннән
Сәлам булып барсыннар!

Юк ла, юк, ни дип борчылсын Гөлфия?! Кем аңа Даниял? Шулай да таң нурларын керфеккә керфек тә ормый каршылады бит менә! Аңламассың бу йөрәк дигәнеңне. Кеше үзе дә төшенә алмаслык табышмаклар биреп, сәер хис-тойгылар уятып тибә ул.

Кайтырга дип автобуска утырганда килеп житкән Даниялдан житәкчеләре төксе генә сорап куйды:

—Кая олактың син, егет? Әйтү юк, сорау юк, тот та парга әйлән!

Даниял бүтән иптәшләренең дә карашларында өнәп бетермәүне күреп, коңгырт күзләренә, бөтен йөзенә кичерү сорау галәмәте чыгарырга тырышты һәм аңлатырга кереште.

—Армиядә бергә хезмәт иткән дустым белән күрештек тә, аларга киттек,—диде.

Даниял белән моннан өч кенә минут элек очрашкан егет көлемсерәп торды: «Бар бит шома адәмнәр! Ябыштырып кына куялар ялганны!».

Даниялның житәкчегә сөйләгәннәре Гөлфия күңелендә чуерташка әйләнеп барган үпкә, ачу, каһәрләү хисләрен эретте дә жибәрде. «Нигә мин кеше турында начар уйларга ашыгам соң?»—дип үзен битәрләде ул хәтта.

Автобуста янәшә утырып кайтканда, кыз күңелендә күк аязлыгы иде инде.

* * *

Октябрьдә лекцияләр беренче семестрга планлаштырылган барлык фәннәр буенча да укыла башлады. Өчәр-дүртәр пар лекция, мәктәптәгечә әйтсәң, алты-сигез сәгать дәрес. Әмма моңа чыдарга була. Ник дигәндә, мәктәптәге кебек дәрес сорамыйлар. Студент халкы моннан бик канәгать. «Сессия житкәч, күз күрер әле» дип йөри берәләр.

Ләкин... ләкин студент дигән тезгенсез кавемне тышаулый торган бер предмет бар. Ул—чит тел. Аның практик дәресләреннән дә, аудиториядән тыш тәржемәләреннән дә һич кая качып котыла алмыйсың.

ВУЗда чит тел укытучылар сизәләр: шәкерт халкы бу фәнгә арбаның бишенче көпчәге дип карый, ике еллык мәжбүри хезмәткә саный. Шуңа күрә чит тел өйрәтүче мөгаллимәләр аяу һәм миһербан белмиләр. Белә ич алар: чит телдән имтихан тапшырмый торып, берәү дә диплом алу бәхетенә ирешмәячәк. Бу фәннән имтихан «койрык» булып озак сөйрәлә калса, институттан куу турында ректор приказына да ерак түгел.

Даниял Арукаев немец теле дигән рәхимсез эскәнҗәгә килеп кысылгач, бер мәлгә тәмам мингерәп калды. Аннары таләп катгый буласын төшенде. Җиң сызганмый котылмаячагы ачык иде. Урта мәктәптә килделе-киттеле генә укыттылар немец телен, рәте-чираты булмады. Монда якадан алалар.

Группаны икегә бүлделәр. Арукаев Зәмирә Әсгатовна Бикташева дигән укытучыга эләкте. Мөгаллимә педагогия институтының чит телләр факультетын моннан дүрт ел элек тәмамлап килгән икән. Карт кыз, диделәр. Шуңа явыз. Димәк, гомеренең ярты-йорты үткәненә җаны сызлый.

Карап торуга һич кенә дә канәчкеч вампирга охшамаган ул үзе. Мөлаем гына, ягымлы күренә. Сүзен өздереп сөйли. Карашы үткер. Уйларыңны укыйдыр төсле.

Даниялны төркемнең старостасы иттеләр.

Беренче дәрестә, үз төркемендәге студентларның чамасын тәгаенләр өчен, укытучы немецча төрле чыганаклардан өзекләр таратты. Бер сәгать вакыт бирде. Аннары һәммәсенең тәрҗемәләү сәләтен тикшерде.

Зәмирә Әсгатовна янына килә-килә үк Даниял зар түгә башлады.

—Бер фигыльнең русчасын табалмадым. Өч сүзлекнең берсендә юк. «Леониерен»...

Зәмирә көлеп куйды.

—Димәк, Арукаев, текстның беренче абзацына күз дә салмагансыз. Анда космонавт Леонов немец газетасында басылган мәкаләдәге бу сүзнең тәрҗемәсен эзләве турында сөйли. Хикмәт шунда, немец журналистлары «ачык космоска чыга» дигәнне космонавт фамилиясеннән фигыль ясап аңлатканнар... Ярый, анысы бәла түгел. Утырыгыз, тәрҗемәләгез, тыңлагыз...

Җиде-сигез минутта Бикташева фикерен кистереп әйтте.

—Ташны тишәр тамчыга әйләнмәсәгез, бик авыр булыр сезгә, Арукаев. Вакыт дигән хәзинәне йокыгыздан, ялыгыздан урлап шөгыльләнергә туры килер...

Даниял җил уңаена бөгелүне кулай күрде.

—Нәрсә бәрабәренә генә булса да тырышырга инде, Зәмирә Әсгатовна,—диде.

Шул рәвешле, берникадәр вакытка Надежда Сергеевна арткы сызыкка чигенде, хәтта Гөлфия белән күрешүләр дә сирәгәйде. Хәер, Гөлфия үзе дә дәреслекләргә теш-тырнагы белән ябышырга мәҗбүр иде.

Шөпшә кебек, чәчәктән-чәчәккә күчеп, ширбәт суырырга күнегеп барган Даниял егетлеген саклап көн итә алмый иде инде. Тиздән Надежда Сергеевнага визитларын кабат яңартты. Гөлфияне дә кулдан ычкындырмаска дигән нияте дә бар иде. Ни хәл итсен, дәрте кайный, каны ыргып ага, җаны сикерәнә, йөрәк магниты Табигатьнең энҗеле калфагы булган хатын-кызларга тыелгысыз тартыла бирде.

Вакыт пресс астына куеп кыскан төсле тыгызланды. Нинди генә өлгер булсаң да, барысына җитешүе ансат түгел. Шулай муеннан мәшгуль көннәрнең берсендә, ноябрь ахыры иде шикелле, Даниял Арукаевны институтта татарча көрәш секциясен җитәкләүче тренер чакырып алды. Сәламләшкәч, танышкач, оста:

—Сине шәп көрәшә, диләр. Секциягә йөрергә ниятең юкмы?—дип кызыксынды.

—Кем мактагандыр, белмим, только арттырган. Авыл сабан туе батырыннан узганым юк.—Даниял остага ихтирам белән текәлеп, шулай диде. Бу тренер турында ишеткәне дә, укыганы да бар аның. Институт егетләренең ничәсен милли көрәш серләренә өйрәткән кеше.—Секциягә йөрер идем, абый. Спорт белән мавыкмасаң, борынгы мәдрәсә шәкерте төсле саргаеп кибәрсең. Йөрим секциягә!..

—Килештек алайса. Күнегүләр һәр атнада. Сессияләр вакытында гына тукталып торабыз.

Даниял көрәшкә йөри башлады. Ә көрәш дигәнең көчне суырыпмы-суыра, аппетитны бик нык ача. Шул сәбәпле, Алмасардан кемнәрдер артыннан җибәргәнне көтеп ятмыйча, ике атнага бер дигәндәй, ризыкнигъмәт алырга авылга үзе кайтучан булып китте. Шөкер, әти-әнисе барлык белән, мул яшиләр...

Соңгы кайтуында байтак итеп яңа суелган тана ите алып килде. Шуны күтәреп Надежда Сергеевна янына китте.

—Пилмән тансыкладым, Надя. Пешер әле күп итеп,—диде ул, тырнак очы кадәр дә рияланмыйча. Пилмән астына бирәр нәрсә чамаларбыз.

Даниялнең онытып бетермәвенә шатланганын яшерергә теләмәгән Надя ай-кояштай балкыды.

—Анысы бар,—диде.—Ит турагычны көйлә дә, чыгара башла. Мин камырга тотынам.

Пилмәнле төндә Даниял тулай торакка кайтып йөрмәде. Шундый көнне, үч иткәндәй, кичләтеп, нindidер йомышы төшеп, тулай торакка Гөлфия килеп чыккан. Арукаевның бүлмәдәше Гата аңа:

—Шәйхелислам абыйларына китте ул. Алар үз йортлары белән торалар. Менә дигән мунчалары бар. Көрәшче егет чабынырга бик ярата,—дип аңлаткан. Сайрый белгән ахириләр бәладан йола торалар шул...

Офыкта зачетлар баш калкытты. Беренче семестрда дүрт зачет, өч имтихан тапшырасы. Әүвәл зачетлар белән араны өзәсе була. Шулай да зачет-зачет инде ул, имтихан ук түгел. Хәтәре берәү генә—немец теле.

Зәмирә Әсгатовнаның таләбе катгый. Мөгаллимә тәрҗемә текстының шактый зур, вакытның чикләнгән булуын кисәтеп куйды.

Зачет көне җиткәндә, Зәмирә Әсгатовна сырхап китте. Деканатка өеннән шылтыратып, секретарь Суфиягә әйткән:

—Беренче курстагы группа өчен тәрҗемә текстлар әзерләп куйдым. Арукаев килеп алсын, хәзерләнә торсыннар, дигән, адресын бирергә кушкан.

Шәкерт халкы мона шатланышты.

—Кемгә кайсы икәнен дә тәгаенләп әйтмәс микән?

—Тот капчыгыңны! Көйлә итәгеңне! Син тагын үзе үк тәрҗемәләп тә бирсәң диярсең...

Зәмирә Бикташева Мусин урамындагы мәчет тирәсендәге күпкатлы йортларның берсендә яши икән. Хода йорты биек ташпулатлар арасында югалып калган. Ислам дине кануннары буенча манара тирә-юнь корылмалардан иң биеге булырга тиештер дә инде ул, хәзерге заман каласы шартларында ни хәл итәсең?!

Зәмирә Әсгатовна өч бүлмәле квартираның бер бүлмәсен үз «резиденциясе» иткән. Тегe якларда зал һәм әти-әнисенең бүлмәсе булып чыга. Әтисе кайчандыр министр урынбасары булган, диләр. Күптән пенсиядә икән. Әнисе кырык елга якын мәктәптә укытып ялга чыккан карчык, ди.

Студентларча әйтсәң, «немка» читенсенебрәк килеп кергән Даниял Арукаевны бик ачык каршылады. Аудиториядәге кырыслыгы бөтенләй юкка чыккан иде.

—Нәзберeклек чиктән ашты бугай, беренче суыклар ук куырып алды,—дип зар түкте.—Урак өсте җиткәч больничныйда ят инде...

Укытучысы Даниялны түргә узып утырырга өндәде.

—Хәзер чәйләп алабыз,—диде.

—Юк, юк, Зәмирә Әсгатовна, чәйләп тормыйм, текстларны бирегез дә китим...—Бүтән чакта чаялана белгән Даниял чын-чынлап тартыну кичерде.

—Сез солдат булган егет бит, Арукаев. Бәләкәй балалар кебек кыенсынып тормагыз!—Зәмирә Әсгатовна күңелле елмаеп кухняга чыкты.

Студент «немка»ның бүлмәсен күздән кичерде. Пөхтәлек. Күзгә беренче ташланганы шул. Җиһаз затлылыгы. Китаплар. Аларның күпчелеге

чит телләрдә бугай. Зәмирә Әсгатовнаны немец һәм инглиз телләрендә иркен сөйләшә, ул илләрнең язучыларын оригиналда гына укый, диләр.

Чәй янында Даниял үзен шуклыгы өчен почмакка бастырылган малай сыманрак сизде. Бу сиңа кырдагы механизаторлар табыны да, солдат ашханәсе дә, студент общагасы да түгел, бу—институт укытучысы хәстәрләгән өстәл, чит тел мөгаллимәсе табыны. Чынаяклары, балкалаклары, чәнечкеләре дә башкача монда.

Бер чынаяк чәй эчеп, рәхмәт әйтте дә, студент егет кузгалмак булып калкынды. Зәмирә Әсгатовна исә немец телендәге журнал һәм брошюраларны туплап биргәч тә, аның белән сүзен дәвам итте.

—Сез машина йөртәсезме, Даниял?—Әлегәчә гел фамилиясе белән генә эндәшүчән укытучының бу юлы исеме белән мөрәҗәгать итүе егеткә кызык тоелды. Мөгаллимәсенә болай эндәшкәне өчен рәхмәт әйтәсе килде хәтта. Ә соравына күкрәк киереп җавап бирә алачагына сөенеп бетә алмый иде.

—Мин—икенче класслы шофер, Зәмирә Әсгатовна.

—Шулаймыни? Сезнең яшьтә бик тиз түгелме соң?—Мөгаллимә күбәләк мыеклары шикелле озын керфекле зәңгәр күзләрен Даниялга текәгән иде. Егет карашын читкә алды.

—Тиз дип... башлап армиядә укыттылар. Ике ел рульдә булдым. Кайткач, икенче класска тапшырдым.

—Алай икән... Каникулга ниләр планлаштырасыз?

—Әллә ниткән ниятләр юк болай. Авылга кайтып киләсе була инде. Картлар янына...

—Алай икән...—Укытучысының бу сүзләрне еш кабатлаганын Даниялның искәргәне юк иде әле. Мәзәк булып китте. Зәмирә Әсгатовна исә фикерен төенләп куйды.

—Мине туганнарым күптәннән Чистайга чакыралар. Әтинең энеләре, сеңелләре. Үз «Волга»ң белән кайт, Гадельшага да барып килербез, диләр. Әтинең туган авылына. Ерак юлга үзем руль тотып чыгарга куркам. Бәлки сез алып барып кайтырсыз?

Ризалык белдерәсе урында Даниял, гаҗәпләнүен яшереп кала алмыйча, сорау бирде:

—«Волга»гыз бармыни, Зәмирә Әсгатовна? Вот это—да—а!..

Шул рәвешле, Даниял малаизмны тезгенли алмады. Мөгаллимәсе аны аңлый иде.

—Гаҗәпсенүегезне бераз төшенәм, Даниял. Шуңа ул машинаның тарихын әйтим.—Чит тел укытучысы ул тарихны бик кыска аңлатты.—Үз акчама алган автомобиль түгел ул. Моның өчен безнең шартларда миңа ашамый-эчми, киенми-төренми дистә ел эшләргә кирәгер иде. Америкада яшәүче туганым бүләк итте. Өченче ел ул Казанга килгән иде. Әнинен әтисе белән аның бабасы бертуганнар... Безнең нәселдә ике-өч буында гел ир балалар...

Абый әйтте: «Бердәнбер сеңелебезгә машина бүләк итеп китим әле!»—диде. Гараж да сатып алып бирде.

Даниялга бу сүзләр әкияти тәэсир итте. Бик үк килешкән булмаса да, «Эх-ма!» дигәнен абайламый ук калды бугай. Юк, моның шөкәтсез чыгуын искәреп өлгерде һәм, шул тәэсирне юарга теләгәндәй, сәфәр чыгарга ризалыгын бирергә ашыкты.

—Кышкы ялда буш мин, Зәмирә Әсгатовна. Барам Чистайга, кинәнеп алып барып кайтам үзегезне,—диде.

—Ә җәйге ялда ниләр майтарырга җыенасыз?

—Җәен механизаторның урыны уракта инде. Комбайнда эшләячәкмен.

—Алай икән...

—Колхозга булышлык, үземә—ярдәм.—Егет көлеп куйды. Студентка еллык дым тупларга кирәк ич!

—Комбайнда урдырасызмы?

—Мин алтынчы классны тәмамлаганнан бирле әтинен ярдәмчесе булдым, Зәмирә Әсгатовна. Җәйгә үземә комбайн бирәчәкләр.

—Алай икән! Бик яхшы. Механизаторлыкны нечкәләп өйрәнәсез дигән сүз. Ир-егетне беренче чиратта үз эшенең остасы булу бизи...

Немец теле укытучысының квартирасыннан саубуллашып чыгып киткәндә, Даниял Арукаевның күңел гөмбәзен салават күпере инләгән иде. Дәресләрдә шактый кырыс күренгән Зәмирә Әсгатовна бик кече күңелле, кешелекле күренде. Даниял шуның белән бергә, җанында сурәтләп бетереп булмастай хис-тойгылар да уйнаклап алды. Ялгызына күңелсездер аның, ямансудыр. Әти-әнисе янәшәдә дә соң, ләкин ул мондый янәшәлек белән канәгать яшәү чорыннан узган бит инде. Сынар канатлылык газаплыйдыр аны, башкача булмас... Чибәр генә, акыллы, белемле, ә бер үзе...

Бу сәгатьләрдә Даниял үзен укытучысы урынына куеп та, аңа теләктәш зат булып та уйланды. Шул уйлар аңа житдилек сулышы өргәндәй итте...

Гомумән, житдиләнер көннәр житте. Студент халкы басынкыланып калды. Тезгенсезләнеп, авызлык тешләп дигәндәй пырдымсызланган егетләр казый хозурындагы шәкертләр сыман шым булдылар, китапларга, лекцияләр язылган дәфтәрләргә ябыштылар. Тырыша-тырмаша океан арты биюләрен өйрәнергә дәртләнгән кызлар да джаз музыкасыннан читтәрәк торырга мәжбүр булдылар. Югары билгеләргә тапшырган имтиханнар студентның яшәү чишмәсенең чылтыравын дәвам иттерәчәк иде. Стипендияле булу өчен ял һәм йокы дигәннәреннән өлешчә ваз кичәргә туры килде.

Аның каруы семестр дәвамында кирәгенчә укыган, тиешенчә хәзерләнгән студентның күңелендә һәр фәннән сынауны кичеп чыккан саен тантана була иде: «Өстән тагын бер тау төште!»

Даниял ике имтиханын—«яхшы»га, ә берсен «отлично»га тапшыра алды. Шул казаныш анарда үз-үзенә ышаныч арттырды, тез буыннарын ныгытты. Күңеле ирәйде. Авылына кайтып күренергә дә, чит тел укытучысы белән янәшә утырып сәфәр чыгарга да йөзе ак иде аның.

Соңгы имтиханны уңышлы тапшырсам, Гөлфия белән Камал театрына барабыз дип уена беркеткән һәм «Гөргери кияүләре»н карарга билетлар да алып куйган иде.

Яшьләрнең монда—жәннәт почмагыдай ымсындырып торган сәнгать йорты—академия театрында—беренче тапкыр булулары иде. Күпме халыклар теленә кергән, әдәби әсәрләрдә, халык жырларында тасвир тапкан Кабан күле ярына салынган тамаша бинасы тышкы яктан ук ниндидер серлелек белән үзенә жәлеп итә. Эченә узгач, яшьләр күңелендә татлы жилкендерүле хисләр уянды. Сәнгать сарае!

Тамашадан алган жан жылысы өстенә, үзенә бәйрәм булдырганы өчен чын күңелдән рәхмәт әйткән Гөлфия сүзләре Даниялны каядыр югарыга, мамыклы жылы канат каккан бер почмакка алып китте. Нидән, нилектән икәнен тәгаен әйтә алмас иде, бу сәгатьләрдә ул үзен гадәттәгедән әйбәтрәк хис кылды, Гөлфияне дә салават күперенең сихри төсләренә манып күрде.

Гөлфияне тулаиләре өенә озатып куйганда, егет кышкы каникул көннәрендә Зәмирә Әсгатовна Бикташеваны аның үз машинасында Чистайга алып барып кайтачагын әйтте. Моны хәбәр иткән минутларда егет Чуашстан чибәренең йөзенә кадалып карады. Ниндирәк тәэсир ярылыр бу хәбәрдән? Берәр төрле реакция-фәлән булырмы? Әллә шоп-шома гына колак яныннан узып китәрме? Юк, узмады. Гөлфия Даниял дигән студентның кайчан ниләр кылуына, ни гамәлләр башкарасына бөтенләй үк битараф түгел икән. Аның күңеленә вәсвәсә сырылып өлгергән иде.

Гөлфия... Кызларга хас турылыгын яшерә алмыйча, ләкин кызларга хас дипломатия бөркәнчегенә төренергә маташып, сорау бирде:

—Күңелең бик киңмени соң синең? Гафу ит, укытучыларыңның барсына да кучер булып бетә алырсыңмы икән?

Карасана, кара! Рәнжетергә, кыерсытырга дигәндә, бу гүзәл дә тел чарлый белә икән бит. «Шофер» түгел, «кучер!» Авыл Советы рәисе кызы шул. Атасыннан киберлек күчми булмагандыр. Кулыннан килгәнне булышу

гап-гади лакейга әверелүмени соң? «Кучерлыкмы?»

Әле ничә минут элек кенә аллы-гөлле буяуларга манылып, җанга рәхәтлек өстәгән бәйрәм рухы чәлпәрәмә килде. Кәефләре кырылды. Булдыксыз малай төсле, телсезгә охшап кайтып китмәс өчен генә Даниял әңгәмә резинкасын сузмак булып, сорау бирде.

—Авылга кайчан китәсең, Гөлфия?

Кыз эндәшмәде. Туфли башы белән җирне тырнаштыргалап тора бирде.

—Авылыгызга кайчан кайтасың, дим?..

Егетнең тавышы имәндергеч чыкты бугай, Гөлфия сискәнеп китте шикелле.

—Шушы көннәрдә әти киләсе,—диде аннары теләр-теләмәс кенә.—Үзем алып кайтырмын дип язган иде.

—Әйбәт алайса!—Даниял хуплап куйды.—Каникулдан соң күрешербез инде. Әйбәт ял ит!

—Рәхмәт! Сау булып тор!

Кыз кереп китте. Саубуллашу барып чыкмады. Даниял Арукаев сөмсере коелып, трамвайга юл тотты. Үртәлгән иде ул, кыерсытылган иде. Тиктомалга «кучер» итте бит әле бу кызый аны. Аңламассың...

Атлый торгач, гарьлек биштәре җиңеләя төште сыман.

—Э-э-эх! Каян килеп, кая китмәгән! Җиде чатта җирән башлы маңка малайларым елап утырмый әле... Киттем Надя янына!

Надежда Сергеевнаның түр тәрәзәсендә ут юк иде. «Өйдә юк микәнни? Әти-әниләренә киткәнме? Мәктәптә берәр чара булып тоткарландымы? Әллә иртәләп йокыга ятуымы?»

Бик аз гына уйланып торгач, Даниял каты итеп кыңгырау төймәсенә басты. Көтте. Түр якта ут кабынды.

Хуҗабикә бусага буена килде.

—Кем шулай соңлап йөри?

—Мин идем, Надя. Даниял дигән студент.

—Кайларда кәефләнгәч киләсе иттең?—Надежда Сергеевна ишекне сөйләнә-сөйләнә ачты да Арукаевны эчкә уздырды.—Мин синең дөньяда барлыгыңа икеләнә башлаган идем инде.

—Имтиханнар эскәнҗәгә кысты бит, Наденька, беләсең. Менә шул бөкреләрне иңемнән төшердем дә бушандым. Группа белән театрга культпоход ясадык. Илдән аерылып каласы итмәдем инде... Болай да «Син иптәшләреңне коллектив итеп санамыйсың»,—дип энәләнергә генә торалар... Йә, нихәлләрдә ятасың?

—Бер көе, мәктәпнекен беләсең... Каникул үтеп китте. Иң озын чирекне башлыйбыз. Ярты елны ярыйсы түгәрәкләдек... Ашарга җылытыйммы?

—Тамак тук диярлек. Чылату мөмкинлеге булса...

Надежда саран гына елмайды.

—Бик көттереп, ялындырып кына килгән кешегә бик аз гына тапмый ярамас.

Хуҗабикә чәй әзерләде. Хәмер чыкты. Сагынышканнар иде.

—Юынып чыгып яткан гына идем. Әйдә, с легким паром дип мин дә тотыйм инде...—Надежда Сергеевна үзенә аз гына салды.

—Сихәтле пар унаеннан булсын, алайса. Во парочка: бутылка да гарочка. Исән була күр!—диде Даниял.

Хәмер, шәраб—сүз җилеме. Сөйләшеп киттеләр. Надежда Сергеевна шушы араларда гына элекке классташы, хәзер отпускага кайткан капитан егетнең килеп чыгуын әйтте. Мәктәп елларын хәтерләп утырдык, диде. Виталий шактый олыгайган, сабыр-салмак ир булган, дип тә өстәде.

Офицер классташы хакындагы мәгълүматлар Арукаев өчен ноль бөтен уннан ноль дәрәҗәдә тансык иде, тик боларны миңа ник сөйлисең дип булмый бит инде. Турысын әйткәндә, хуҗабикә максатына ирешә. Ул—Арукаев дигән татар күңеленә шик-шөбһә, көнчелек кырмыскалары җибәреп

карау иде. Артыгын һаваланып китмәсен, янәсе, дөньяның кендеге Алмасар Арукаевы гына түгел...

—Бик күңелле очрашу булган икән!—Даниял кырысланып куйды, аннары мона хакы югын чамалап алды да елмайгандай итте.

—Үткәнне сагынып искә алу күңелле дә, моңсу да инде ул, Даниял Лотфуллович.—Рәсмигә охшаган эндәш сүз егетнең сырт йонын кабарта язуга җавап иде.

Гашыйклар хәле мәчеләрчәрәк диләрме? Ике мәче талаша, берсен-берсе ялаша... Болар да шулай, бер-берсен әле чеметкәләп, әле назлап төн уртасын җиткерделәр.

—Мин общагага кайтып тормамдыр инде, Надя.

—Ихтыярың.

Даниял битараф кына бу сүзне үз итә алмады.

—Башка вакытта болай дими идең, Надежда Сергеевна. Кал дип өзеп әйтә идең.

—Әмер булып ишетелмәсен диюем...

Бу сүзгә шунда нокта куелды.

Даниял иртәгесен иртүк ваннада юынып чыкты. Зәмирә Әсгатовна янына барырга кирәк иде.

Чит тел мөгаллимәсе ишекне үзе ачты. Әти-әнисе белән өчәүләп чәй янында утырган чаклары икән. Студент егетне өстәл янына кыстый башладылар. Даниял кайчан кузгалабыз дигәнне генә белешергә керүен, бик тиз барып җитәсе җире барын әйтте, рәхмәт диде.

—Иртәгә иртүк тәвәккәлләсәк, хәерле булырын өметләник,—диде Зәмирә Әсгатовна.

—Мин алтыда килеп җитәрмен!

Кышкы иртәдә алар Чистай каласына сәфәр чыктылар. Көн аяз булырга өметләндерә иде. Суыгы да зар түгәрлек түгел, термометр нольдән нибары тугыз-ун градус түбән күрсәтә иде.

Юл кешеләре иртә кузгалучан. Олы юлда хәрәкәт зур иде инде. Яна «Волга» бәйгегә ярсып торган чабышкы кебек бик җай юыртты. Байтактан машина руле артына утырмаган Даниял күңеле бәйрәм итә иде. Мөгаллимәсе дә, егетнең җитез хәрәкәтләрен күзәтеп, бик канәгать барды. Әкияттәгечә, нәкъ сәгать җиденчә кузгалып, каладан елга ярына җиткәнче җитмеш җиде чакрым юл үттеләр. Машинасы да гөрләп чапкач, Зәмирә Әсгатовнаны тынлый-тынлый Камага килеп җиткәнен тоймый да калды Даниял. Чит телләргә бала чагыннан ук кызыгып үсүен, урта мәктәпне тәмамлаганда бары тик инфакка гына керергә каттый карар кылганлыгын, күңел биреп, бик теләп-яратып укыгач, чит телләр үзләштерү газабын чагыштырмача ансат аралавын сөйләде укытучы. Сүзгә-сүз ялганып, диплом алмый бер кая да кузгалмаска ант итүен, шуның аркасында яраткан кешесен югалтуын да әйтми калмады. «Диплом алдым, егетемне югалттым»,—диде ул, уенынчынын бергә үреп. Үз мәктәпләрендә Зәмирәдән ике класска өлкән укыган, аннары хәрби училище тәмамлаган егет Зәмирә өченче курста чакта ук өйләнмәкче һәм яшь киленне үзе хезмәт иткән җиргә—Германиягә алып китмәкче булган.

—Мин чит илләргә туристик сәяхәткә барырга, анда үзем өйрәнгән телләрдә сөйләшеп тәпле күнекмәләр алырга дүрт куллап риза,—дип сөйләде Зәмирә Әсгатовна.—Дөнья күрәсең, тел шомартасың, яшәешкә карашың киңәя. Әмма чит мәмләкәттә яшәргә күңелем тартмый. Һич! Аннары укуымны да өзәсем килмәде. Һич! Факультетның күз өстендә кашы булып укып барганда, югары уку йортын ташлап кит, имеш! Булмаганны! Бу хакта үз дип йөргәнемә туп-туры әйттем. Аның кәефе бик нык китте. Каты үпкәләде, рәнҗеде хәтта. «Читтән торып тәмамларсың укуыңны!» дип тә карады. Әйткәнем сүз иде! Шунысы да бар—әтием, әнием дә мона юл куймаслар иде. Ленин стипендиаткасы булып укы да, ярты юлда белем алуыңны өзеп куймы? Булмаганны!..

Менә шул рәвешле юллары аерылышкан аларның. Зәмирәгә үч итеп,

офицер егет кире җавап алганның иртәгесендә үк бүтән бер кызга, медицина институтының соңгы курсындагы Казан чибәренә өйләнгән дә, аны алман иленә алып киткән. Өч елдан алар Союзга кайтканнар, егет туган шәһәренә билгеләнү алуга ирешкән. Хәзер Казанда яшиләр икән.

—Кайчакта кала урамында очрашкалыйбыз. Бик матур малайлары үсеп килә. Сәламләшеп узабыз. Хатынына минем хакта сөйләгәндер дип беләм,—диде Зәмирә Әсгатовна.

Урынсыз булды бугай да, ләкин Даниял әйтеп куйды бит: «Сезгә насыйбы чыгар әле, Зәмирә Әсгатовна!»—диде. Мөгаллимә бу беркатлы юатудан кинәнеп көлеп куйды.

—Кайгым анда түгел, Даниял. Килде-киттесенә, ни життесенә дип әйтүем, чыгарга жыенмыйм. Минем күнелне жилкендерерлекләре яшьрәкләрне карыйлар... Хәзергә уем бүтәндә. Мин кандидатлык минимумын тапшырып, диссертация язган идем. Шул хезмәтемне бүгеннәрдә, соңгы араларда дип әйтүем, Мәскәүдәге чит телләр институты галимнәре тикшерәләр. Оппонетларым шуннан булачак. Тиздән Мәскәүгә диссертация якларга барырга туры килердер, мөгаен...—Боларын бик җитди әйтте дә, сүзне тагын шаяруга борды.—Карт кызларның бердәнбер юанычы диссертация язу, шуны яклап, кандидатлык дәрәҗәсе алу була бит ул... Бала үстерә алмагач, фәнне үстерешик дип тырышкан булалар. Ә фән, бик кире беткән, үҗәт нәрсә, теләсә кем килеп тыгылганны өнәми, аларга баш бирми. Аңа бөтен гомеренне багышларга кирәк...

Даниял, урынлымы-урынсызмы икәнен азаккача чамалап бетермәстән, сүз кыстырды:

—Мин үзәк газеталарның кайсыннандыр укыдым, аннары телевизордан да күрсәттеләр, Балтик буе республикаларының берсендә бер ханым ун бала тәрбияләп үстергән һәм докторлык диссертациясе яклап, профессор булган...

—Андый уникумнар бик сирәк очрый, ләкин бар алар, бар. Ул ханым икеләтә герой!..

Даниял үзенең укытучысының тулы гәүдәләнешен күргәндәй булды. Яхшы мәгънәсендә үҗәт кеше икән шул Зәмирә Әсгатовна. Әйткәнен эшләргә, башкарып чыгарга җиң сызганган зат икән. Мондыйлар ярты юлда калмыйлар, читенлекләрдән өркеп котлары алынмый. Ихтыяр көче дигәндә, әҗәткә алучылар түгел, димәк. Тормышның, дөньяда яшәүнең мәгънәсен тирәнтен анлыйлар булып чыга... Алыйм дисән, гыйбрәтләр бар дөньяда!..

Чулманны кичкәч, Зәмирә ерак-еректан уратып, читләтеп, кыеклатып кына Даниялнең йөрәк серләрен дә белергә теләгән сыман сораштыргалап карады. Укытучысы алдында бу темага ачылып китүе бик җайсыз иде, Даниял кыска-кыска гына җаваплар биреп, сүзне бүтәнгә борырга тырышты.

—Минем күнел—бүлмәгән чалу әле, Зәмирә Әсгатовна,—дигән булды егет.—Бер янып сүнгән булды булуын...

—Шулаймы? Күңелегез җәрәхәтләнеп калгандыр алайса?

—Гарьләндерде дә, ямансылатты да... Булды инде...

—Аңа карап кына явызланырга гына кирәкми, Даниял. Яшьлектә күпләрдә була торган хәл. Баштарак дөньяның асты өскә килгәндәй тоелса да, тора-бара үтә ул, үтә. Иң яхшы табиб—вакыт, диләр бит. Борынгылар сүзендә олы хаклык бар...

Болар да юату сүзләре иде. Тик нигәдер мөгаллимәнең әйткәннәре Даниялга сихәтле булып ирешмәде, күнел кутырын куптарды гына кебек.

—Кызларга ышанычны җуюы бик тиз икән ул, Зәмирә Әсгатовна,—диде рульдәге егет. Тансылу хыянәтенә үч итеп, хатын-кыз кавеме белән кәнфитләнеп тормаска карар кылганын әйтмәде, әлбәттә.

—Аерым кешегә карата ышанычсызлыкны, гомумән ышанычтан бизү белән бутарга кирәкми. Шуны онытмаган хәерле, Даниял. Мәхәббәт еркараны өнәми. Аның төп шарты—тугрылык...

* * *

Чистай сәфәреннән кайтуга ук, иртәнге поезд белән Даниял Арукаев Алмасарга юл тотты. Анда ял итте егет, туйганчы йоклады, каралтыкура тирәсендә кайнашты. Буранлап, ишерелеп яуган карны көрәп мускулларын уйнатты.

Егет әнисе хәстәрләгән ризык белән кинәнеп сыйланды. Таба ашларын, бигрәк тә гөбәдияне яратты. Туган йортында газиз кешен пешергән ашсуга ни житә?! Әнкәсенә чиксез рәхмәтле иде ул.

—Әнкәй, син пешергән ризыклар белән Мәскәүдәге ил башлыкларын сыйларга иде, ә?—диде. Фермада алган орденың янына тагын да кәттәрәген тагып жибәрерләр иде.

—Сайра, улым, сайра,—дип елмайды Өммегөлсем.—Салам мина көлтәсе белән сыя. Ие, беткән иде, ди, Мәскәү тикле калада аш-су осталары, бер татар хатыны гына житми, ди...

Сөт-катыкка да кинәнде студент. Тулай торакта көн саен иртәләрен сөт ризыгы юллап чыгулар юк. Аннары каладагы сөтне бер читкә куй инде син аны. Бүлмәдәше Гата әйтмешли, шешәсен юып та торасы юк. Сөт өсте ялгышып та йокмаган...

Даниял кичләрен авыл культура йортына чыккалады. Кордашлары белән булды. Мәгәр андагы кичәләр аның өчен ничектер төс жуйганнар иде инде. Ул гына да түгел, алар Даниял Арукаевның яшьлек таңында төшкән аяусыз кырауны искә төшерәләр иде.

Жыр-биюле кичәләрдән тиз генә кайтып, Зәмирә Әсгатовна тәкъдим иткән китапны укыды ул. Бу әсәр малай чакта ук укылырга тиеш булып та, егетнең кулы тими калган повесть иде. Лев Кассильнын «Великое противостояние» повесте.

Даниял бермәл сәерсенде: ни дип әле немка түти мина бала-чага әсәрен тәкъдим итә? Жентекләп укып чыккач, кайта-кайта фикерли торгач, анлады: юкәдә икән чикләвек! Әлеге әсәрдәге героиняның—«Мужик сердитый» кинофильмында Устя ролен уйнаган укучы кыз Сима (Серафима) Крупицынаның эчкерсез мәхәббәте сурәтләнгән. Шуның белән бергә, Романның тыенкы-тыйнак мәхәббәт тота белүе дә тасвирланган. Зәмирә Әсгатовнаның «Роман Каштанны үзенә өлге итә алсаң, ялгышмассың!» дию булгандыр, күрәсең. Менә бит! Педагог һәркайчан педагог...

Повестьта кызыл карандаш белән тамгаланган бердәнбер абзац бар. Даниял шул хакта уйлана калды. Бу «чәүкә» элек үк булдымы икән, әллә мөгаллимә китапны студент егеткә бирер алдыннан гына билгеләп куйганмы? Менә ул өзек:

«Какая же вы звезда? Вы в лучшем случае планета... Планета. Своего сияния у вас нет, попали в хорошую систему—засверкали и давали хороший, ровный, честный свет. А теперь вам надо учиться, своими руками загребать жар, чтобы потом греть и освещать то дело, которое будет в вашей жизни главным делом, а не случайным».

Галәмгә нур сибүче йолдыз һәм аңардан якты алучы планета... Уңган, булдыклы, талантлы шәхесләр һәм кеше ярдәме белән дә мукәләргә генә сәләтле жан иясе... Укытучысының шулай дию еме, теге абзацны билгеләп куеп?

Уйларын кылыч белән турап ыргытырга ниятләгәндәй, кулын селтәде дә, Даниял китапны диванга ташлады. Уйларбыз, уйланырбыз, иптәш Бикташева! Үзегез дә һәммәсен кирәгенчә уйлап житкермәгәнсез түгелме? Дипломлы булдым, кияүсез калдым дисез ич. Менә бит! Бик акыллы булгач, сарыкны да исән, бүрене дә тук итәсегез бар иде. Менә бит! Әйе, офицер егет югалып калмаган. Менә бит!..

Укытучысын күз алдына китереп, аның белән читтән торып бәхәсләшеп маташуы үзенә дә мәгънәсезлек булып тоелды бугай, ул, уйларыннан посарга ниятләп, бүлмәдә арлы-бирле йөренде дә, миенә килеп сарылган бәйләнчек фикерләрдән арына алмагач, киенеп урамга чыкты. Юкка чәбәләнү

иде бу! Уйлардан алай гына арынып булса, башларына уй төшкән адәм балалары Каф тау артына гына түгел, чит-ят кыйтгаларга чыгып качарлар иде...

—Бәхетленең төне житми, бәхетсезнең көне үтми дигәндәй, саф һавада да тынгы табалмады Даниял.

Казанга китәр көн житте. Кичке поезд белән юлга чыгасы көнне, әтисе ремонт мастерскоеннан төшке ашка кайткач, жәйне ничек үткәрү турында кирәзәлек итеп алдылар.

—Комбайнда эшләүне кире уйламагансыңдыр бит, улым?—диде Лотфулла.

Бу сорау Даниялны сискәндерә калды. Ни дип капыл гына болай сорады әле әти кеше?

—Иске авыздан яна сүз дип әйтимме, бу соравың нидән ярадды әле, әткәй?—Егет әтисенә төбәлде.

Лотфулла бик тыныч кала бирде.

—Нидән дип... иллә дә битараф йөрүеңә күрә әйтүем. Ничә көн туган авылыңда булып, мастерскойга аяк басмадың, илне-көнне тук итүче кешеләрне күрмәдең. Шуңа да фәһемләп куйдым, бу егетнең башында бүтән планнармы әллә, дим. Жәен дә калада мәшгульләнмәкчеме улыбыз, дим. Белмәссең...

Даниял әтисенең әйткәннәре—телендәгесе, әйтеп бетермәгәнне күңелендәгесе икәнен сизенә иде. Әтисе теге чактагы кебек «маржа» дигәнне чәчрәп телгә алмаса да, шул жәһәттән шиге таралып житмәве аңлашылып тора лабаса.

—Икеле-микеле кыланырга мин детсад малае түгел бит, әткәй, ирегет сүзе бер булыр. Уракка авылга кайтам. Председательнең яна комбайн бирербез дигән вәгъдәсе дә көчендә калса, шәп булыр иде.

—Безнең Зөфәр ике сөйләшми,—диде Лотфулла.—Ике әйтми. Район башлыклары да сүзен жилгә жибәрмәгән өчен олылыйлар аны, Зөфәр Галләмович дип кенә торалар. Гозерен дә екмыйлар.

—Уракка кайтам, әткәй, һичсүзсез кайтам! Үземә—практика, ашарга икмәк, тотарыма акча дигән сүз бит... Син минем хакта борчылма, яме. Үзең әйтмешли, башым урынында...

Ризык-нигъмәт төяп китте Даниял. Ярмасын да, итен-маен да мулдан куйдылар. Әтисе әнисеннән сорап алып акча да бирде.

—Укы, сынатма. Кемнеке—аларныкы...—Лотфулла улына горурланып та, өметләнеп тә карады. Мондый караш аталарда гына була.

—Ходай саулык бирсен, акыл-зиһен бирсен, тел ачкычы бирсен,—дип тезеп китте Өммегөлсем.—Бәхет-тәүфыйктан аермасын улым...

* * *

Алмасардан бу килүендә түтәрәме белән ит күтәреп Недежда Сергеевна фатирына ашыкмады студент. Читтән әйткән кирә бит ул, ни генә дисәң дә. Чистай юлында Зәмирә Әсгатовна сөйләгәннәр дә, әтиәнисенең үгет-нәсихәте дә күңел уйдыгына жыела барды. Дөрес әйтәләр инде алар, яхшылык теләп сөйлиләр. Мәгәр яшьлек тыелгысызлыгы да бар ич, бар! Даниялның тамырларында да егет каны ага. Аның каны-сүле эчендә, күзе матурны күрә. Тышаулап куя торган чак булса, аны яшьлек димәсләр дә иде. «Яшьлегем—рәхәт чагым, очар кошлар түгел бит ул, әйләнеп кайтмас тагын», «Болыт килер, явар янгыр, буразнада дым булыр; Болыт китәр, яшьлек үтәр, үкенерсең, соң булыр...» Әнә, жырлар ни диләр!

Шул рәвешле, Даниял үз-үзенә дәрт-дәрман өстәмәк иде. Әмма күпме генә ирәймәсен, каяндыр томан артыннан Зәмирә Әсгатовнаның бармак янап торуын шәйләгән кебек булды, әтисе дә «матри, малай!» дип кисәтәдер кебек тоелды.

Факультетлар өчен уртак лекциягә килгәч, Гөлфияне күреп, Даниял

ялкынланып китте. Сагынганлыгын шул минутта ап-ачык аңлады егет. Юк, Надежда Сергеевна гына түгел бу зат Даниял өчен. Гөлфия—бүтән, Гөлфия—киләчәкле... Гөлфияне хатыны итеп, балаларының әнисе буларак күз алдына китереп караганы да булды егетнең. Татлы, сихерле иде бу күзаллау. Моңа ирешү өчен институтны тәмамлыйсы бар әле, әлбәттә. Һич югы соңгы курска житәсе. Эшкә бергә билгеләнәсе, бергә китәсе... Анарчы ничәмә-ничә кат имтихан дигән салават күперен имин кичәсе... Булса ни, ул күперне кемнәр генә кичмәгән! Без дә кичәрбез, бездән соң да табылыр андыйлар... Кыз гына читкә тайпылмасын, язмыш аны ягага тибәрә күрмәсен! Ул тиклесе булмасын инде, моңа юл куярга ярамый! Гөлфия бит «алма түгел, бүлешергә күршең белән...»

Лекциядән егет беренчеләрдән булып чыкты һәм аудитория ишеге төбендә Гөлфияне көтеп алды. Күрешү шатлыгыннан Даниял тулган ай булып балкый иде. Гөлфия дә елмаеп күреште. Егет өчен күк капусы ачылгандай булды. Ә ул капка артында җан җәннәте!

Читкәрәк тайпылдылар. Бер-берсен бүлдерә-бүлдерә хәл белештеләр. Гөлфия Даниялны кичкә үзләренә чакырды, сөйләшеп утырырбыз, диде. Хужабикә түтие Северный поселогындагы кардәшләренә кунакка китәсе икән.

Даниялның Гөлфияне бу йорт капкасына кадәр ничә озатканы бар, өйгә үткәне юк иде. Бусаганы беренче атлап керүе булачак. Буш кул белән бару килешмәячәк. Алмасар егете шәһәр үзәгендәге шәраб кибетенә керде. Сатучы кызга сүз кушып: «Хәзинәгездәге иң әгъла шәрабны сайлап бирегез әле, матуркай. Бәйрәмнәрдә үзегез авыз итә торганын. Сеңелемнең туган көн бәйрәме өстәленә куйганда комачка батарлык булмасын иде»,—диде. Сатучы кыз елмайды:

—Бу хәтле татлы тел күрсәткәч, үтенечегезне кире кагып булмас инде,—дип, бик матур шешәле шәрабны йомшак кәгазьгә төреп Даниялга сузды.

Гөлфия аны сулышы белән тартып алгандай каршылады. Кызый сагынуын яшерер хәлдә түгел иде. Ул сан-савырының төзлеген сөйләп торырлык яңа күлмәк кигән, аягына да монарчы Даниял күзенә чалынмаган затлы туфлиләр элеп алган. Шомырт кара күзләрендә җан җәлеп итеп очкыннар уйнаша, карлыгач кашлары бүген аерата сөйкемле күренә. Бит урталарындагы алсулык та үзәк өзәрдәй булып яна иде. Чигәләрендәге кара бөдрәләр дә Даниял шәрәфенә генә бөтеркәләнеп тора диярсең!

—Чишен, уз! Түргә үт, өстәлем әзер. Өйдән килгән ризыклар белән сыйланып чәй эчәрбез,—диде сөйкемлелегенә чик булмаган Гөлфия.

—Рәхмәт! Килгәч-кергәч, чишенәбез дә чәйлибез дә инде, Гөлфиякәй! Сагыныпмы сагындым үзеңне. Әллә ничә мәртәбә төшемә кердең, акыллым. Тик берсен дә рәткә-чиратка салып сөйли алмамдыр... Уянып киткәч, ямансу була иде...

—Мин андый төшләр күрмәдем,—диде кыз, бәгырь жылытырлык елмая биреп.—Аның каруы өнемдә исемнән чыкмадың. Чистайда нинди мажараларга тардылар икән дип тә уйлап куйдым хәтта...

—Йә, йә, Гөлфия, минем чәчәк түтәлемә таш ыргытмый гына сөйләш әле. Чистай нәрсә?! Мөгаллимәне алып бардым, алып кайттым.

Чишенгәч, Даниял ишек буенда калдырган портфелен алып килде.

—Минем дә күчтәнәчем бар. Синең өчен дип махсус гозерләп алдым.—Даниял шәраб шешәсен кәгазьләреннән арындырып өстәлгә утыртты.—Сак белән Сок булып торганнан соң күрешү шәрәфенә авыз итү гөнаһ булмас.

Шәраб, чыннан да, мактарлык иде. Кечкенә рюмкалар берничә йөреш ясап алгач, сүз үзегенә төшеп куерды.

Гөлфия авылдагы мәктәпләренә баруын, укытучылары белән күрешүдән бик канәгать калуын сөйләде. Әти-әнисе аның имтиханнарын бик яхшы билгеләренә генә тапшыруына сөенеп бетә алмаганнар. Энекәше Гөлфиянең каникулга кайтуына фоторәсеменнән күчереп, апасының зур рәсемен ясап куйган икән, шуны бүләк иткән. Энесе быел тугызынчы сыйныфта белем

ала, урта мәктәптән соң ветеринария академиясенә керергә дип хәзердән үк җиң сызгана башлаган. Мал-туар дигәндә, жаны фида. Атларга мөкиббән. Җиденче классны тәмамлагач ук, өлкәннәргә ияреп, төннәрен колхоз атларын көткән. Хәзер дә, буш вакыт чыктымы, шулар янында. Колхоз ветеринария табибының түләүсез ярдәмчесе.

—Әтиең ни ди соң?

—Әти—демократ безнең. Бара торган атның башына сукмыйлар, ди. Кем белә, аңардан бәлки менә дигән ветеринар чыгар, дип өметләнә...

Даниял да авыл хәлләрен телгә алды, тик барыбер Казан тарта дигәнне аңлатты, «Казанда син яшисең ич, Гөлфия!» диюдән тартынмады.

Тау агы шәрабы кимеп калгач, азмы-күпме базынып өлгергән егет янә портфелен ачты. Анда тулай торакта ук кереп оялаган хәмер бар иде.

—Абау! Кирәкми анысы, кирәкми, хаҗәте юк!—Кыз чыраен сытты.

Даниял көлде, мәҗлестәшен юатты:

—Сиңа түгел, Гөлфия, түгел. Үзем генә авыз итәрмен. Ир-егет кавеменнән лә мин!

Ул маһирларча сугып, шешәнең бөкесен ачты, үз рюмкасына аракы койды, эчеп җибәрде. Аның озынча йөзе чытылды. Аннары ул кин мангаен җыерып, зур күзләрен ачалак-йомалак китереп торды да, әллә нәрсәне исенә төшергән кебек, кабаланып минераль су уртлады.

—Җимеш суын макта, ак даруны капла, дигәннәрме, Гөлфия? Дөрес әйткәннәрдер, пожалуй. Агы бүтән инде аның, бүтән.

Шешәне алдымнан алып куймасын бу чибәркәй дип шикләнә калган кеше төсле, ул тагын берне түнтәрде. Эчкәч тә башын арткарак ташлап, түшәмгә карап торды. Күңелдән нидер ятлый иде диярсең. Шуннары:

—Булды! Точка!—дип урындыгыннан күтәрелде, ике-өч адым алга, ике-өч атлам артка йөренеп алды. Аның сүз кытыгы кузгалды.

—Чистайда Зәмирә Әсгатовнаның бер энесе бар, абыйсының улы, Гөлфия. Тыңлыйсыңмы?

—Тыңлыйм, Даниял. Исерә күрмә, яме?

—Юк ла, исермим. Шуның белән дә мәлҗерәсән... Әйе, шул энесе, Әбелкасыйм, аңа Касыйм гына диләр, мәзәк сөйләшә. «Салкын» диясене «Фалкын» ди, «Сабыр ит» диясе урында «Фабыр ит» дип куя. Җырлаганда да «С»ны «Ф»га алыштыра.

«Фин фин генә, фин бер генә
ФФФР илләрендә»,—дип җырлый.

Гөлфиягә бу аз гына да мәзәк тоелмады. Киресенчә, күз күрмәгән әлеге җиде ятны кызганды ул.

—Нишлисең, тел кимчелеге,—диде.

Даниял кызның кәефсезләнә башлавын чамалады һәм аның кулыннан сак кына тотарга тырышып, үзе янына диванга утыртты.

—Сөмсерең коеламы, матурым? Кирәкмәс! Йәле башыңны югары күтәр дә елмай әле бер! Йәле, йәле... Синең елмаюың сырхауны аруландыра, кайгылыны шат итә бит, Гөлфиям...—Ул кызны кочагына алды, үбәргә үрелде. Кыз аны читкә этәрде.

—Кыланма әле, Даниял! Тик кенә утыра аласыңдыр бит?—Кызның киермә кашлары җыерылды. Ул җаны тарсынудан бусарынды, суыксынгандай тәне бөрешТе.

Дөмбер Даниял тәкатьсезләнгән иде. Әлеге минутларда аның күкрәгенә тыелгысыз дәрт инде, җанына исәр, ашкын ду тулды. Шомакай егет, батыраеп китеп, бичаралыктан гәүдәсе тетрәнгән, тыны сикергән, тамак төбе ябышкан кызны диванга яткырмак булды.

Авыр күтәргән ачы кычкырган, диләр. Рас шулай. Хәлкылгыч мизгелдә Гөлфиягә дә гайре табигый көч килде. Ул бар куәтенә Дөмберне тибеп җибәрде. Хәмер парына әсир төшкән егет чайкалып артка чигенде, мәгәр сынын бик тиз турайтты, кулларын киң җәеп Гөлфиягә ябырылды. Кимсетүдән тәмам ярсып, зәһәре кайнаган кыз алагаемга Даниялның

янагына чалтыратты. Әрсезлеге чик-чамадан ашкан студент моны һич көтмәгән иде, беравыкка тораташ булып калды.

Чырае качкан, йөзе ямьсезләнеп-кыйшаеп киткән Гөлфия артыгын базуланган курсташының күз ачып йомган мәлгә аңгыраеп калуыннан файдаланып, өс-башына да кимичә өйдән чыгып йөгерде.

Даниял айнып китте, чоланга чыкты, болдырга узды. Тавышын күтәрми генә төнге тынлыкка эндәште.

—Гөлфия! Кая киттен, Гөлфия? Кер, туңасың! Кер, авырып китәрсең. Шаяруны да аңламаска инде... Гөлфия! Йә, бала-чага булма, кер! Мин китәм...

Эндәшүче булмады. Даниял борсаланып кире керде. Киенә башлады. Башына берсеннән-берсе шөкәтсезрәк уйлар ябырылды. Күршеләрне алып керсә? Милициягә үк китеп барган булса? Неужели шул хәтле үчләнер? Хөкем иләре каршында түбәнсенәселәр бар микәнни?!

Даниял Арукаев чыгып китте, туп-туры тулай торакка кайтырга ниятләде. Өй ишеге биксез генә калды.

Гөлфия өйдән качып чыккач, утын сараена кереп бикләнгән иде. Утырыр урын булмады. Кара мунчаныкы кадәр генә тәрәзәчектән болдыр буен күзәтте кыз. Даниялнын үзен эзли чыгуын күреп торды, чакыруын ишетте. Аның янына чыгу хакында уйламады гына түгел, килеп тапмаса гына ярар иде, Раббым, дип кан калтырап торды. Даниял киенеп чыгып киткәч тә, бөтенләйгә кузгалуы булдымы дип, байтак торды. Аннары гына өйгә керде.

Беренче эш итеп түр өстәлне җыештырды. Даниялдан калган аракы шешәсен юынтык су бидрәсенә салып чүплеккә чыгарып түкте.

Кергәч, ишек буе идәнне юып корытты. Күкрәк киереп тирән сулыш алды. Азрак тынычланган кебек булды. Ишекләрне ныгытып бикләде, урын салды, утларны сүндереп ятакка чумды.

Сарайда яланөс басып торганда эченә суык үткәнен тоемлаган иде, тән температурасы күтәрелүен абайлады. Йокы алмады. Аның каруы уйлары ишерелде.

Даниял аның фикерендә берьюлы ике зат булып гәүдәләнде. Унда—берсе. Әдәпле, игътибарлы, ярдәмле. Шигырьләп, бизәкләп сөйләргә яратучан егет. Эш авырлыгыннан курыкмаганы күренеп тора. Сулда—икенче адәм. Муллыкта, пар канат астында үсеп азына башлаган, җиледән чыккан, ни теләсәм шуны булдырам диебрәк санаучы, үзен бик яратучы зат. Әтисен бик коры кеше, каты куллы дип сөйләгәне бар, ә үзе муенчакны иртә өзгән. Утлы суны ярата. Шайтан селәгәе холкын үзгәртә икән шул. Шуны чөмергәч, аңа дингез тубыктан була башлый. Сәрхүшләнгәч, хак белән нахак, ак белән кара, чын белән ялган, тугърылык белән хыянәт арасындагы чикне бар дип тә белми. Шулай булмаса, яратам дип йөргән кызның намусына тукынырга алгысыр идеме? Гыйффәтле кыз баланың иң зур хәзинәсенә кагылырга ымсынып идеме?

Юньле ата-ана баласы да баш атып, юньсезләнеп йөрмәсә, бу дөньяда шакшы җаннар азмы? Алар буа буарлык! Алдакчысы, аферисты, мал буры, мәхәббәт карагы, денен акчага сатканы, баласын ташлап качканы, иманын салып таптаганы, ата-анасыннан йөз чөергәне, үз мәнфәгатен барысыннан да алга сөреп, җинаятькә чумганы, кеше гомерен өзүчеләре, тагын әллә кемнәр!..

Шөкер әле, гадел кешеләр бар! Алар аз түгел! Ил-көн алар иңендә. Яшәешебездә азмы-күпме алгарыш чишмәсе тибә икән, ул—гадел, тырыш, булдыклы, зирәк, ярдәмчел, хөсетсез, хәрәмсез ватандашлар эшчәнлегенең җимеше.

Андыйлар гаиләдә дә, мәхәббәттә дә тугърылардыр, яратышуның илаһилыгын, кадерен беләләрдер.

Әнә бит, бер-беренә мәхәббәт тоту турында әдип ниләр дигән (Гөлфия моны яттан белә): «Яратышу нинди зур бәхет! Күңелдә нинди рәхәтлек! Син икенче кешенең, бөтенләй башка җан иясенең йөрәгендә яшисең.

Синең мәхәббәтең анын йөрәк тартмасында. Ул йөрәктән сина, кайтаваз шикелле, аның мәхәббәте ишетелә...»*

Даниял да аның янына беренче килүләрендә гел күркәм була иде ич. Факультетара лекцияләрнең берсендә ул Гөлфияләр артына килеп утырган иде. Доцентны тынлап, ул сөйләгәннәрнең сөземтәсен дәфтәренә теркәп барасы урында Арукаев дигән студент рифма-ритм сайлап изаланган икән. Җилкәсенә сак кына кагылып, ул Гөлфиягә дүрткә бөкләнгән дәфтәр бите сузды. Кыз укымый булдыра алмады.

«Туган телемдә ике сүз
Багышладым үзенә—
Сандугач та Син, былбыл да,
Тик тимәсен күз генә!

Җырчыны данлау—мәртәбә,
Ихластан мактыйм әле:
Башкортның һандугаскае,
Урысның соловушкасы,
Алманның нахтигале.

Сине тасвирларга, дускай,
Кирәк илаһи сүзләр.
Фәрештәм Син, алиһәм Син,
Кыйгач каш, сихри күзләр...»

Гөлфия рәхмәт әйткән иде дә лекторны тынларга кушкан иде...

Көннәр үткәч, көтелмәгән адым...

Гөлфия авырып ятып өч көн лекциягә бара алмады. Хуҗабикә түти аны ничекләр итеп кенә дәваларга да белми йөдәде. Даруханәгә барып, ике-өч төрле дару алып кайтты, кат-кат сөт кайнатып эчерде. Кызның ютәле бетсен дип җан атты. Җан шифасы гына бирә алмады.

Карчык көндәлек мәшәкатьләр белән матавыкланып, кибеткә йә базарга киткәндә, кызны өстеннән биклэп чыгучан булды.

Хуҗабикә өйдә юк чакларның берсендә ишеккә Даниял килеп китте. Йозак күргәчтер, ишегалды ягы тәрәзәләренең берсен чиртеп бакты. «Гөлфия! Син өйдә түгелме?» дип тавыш биреп тә карады. Гөлфия, әлбәттә, тын да чыгармады.

Хуҗабикә кайткач, ишеккә кыстырып калдырган язуны алып кереп бирде. Әлеге кәгазь кисәген кыз теләр-теләмәс кенә, фатир хуҗасына һични сиздермәс өчен генә алды.

*«Сәламнәр сиңа, Гөлфия!*

*Институтка килмәвеңә өченче көн. Мин ни хәлләрең барын белмим. Авырмыйсыңмы?*

*Үзеңне күреп, тупаслыгым өчен гафу итүеңне сорармын дип килгән идем. Ишегегездә йозак булып чыкты.*

*Син мине гафу ит инде. Әллә кайларга хәбәр салмассың дип ышанам. Дуслык хакына, киләчәктә дә якын кешеләр булу хакына гафу ит.*

*Сәлам белән: Даниял».*

Гөлфия боламык холыклы кыз түгел иде.

Институтта очрашкач та сүз җилеме табылмады. Даниял бик сырпаланып маташкан иде, Гөлфия ачык чырай күрсәтә алмады, кырыслыгы эремәде. Сүзне озакка сузмас өчен кистереп әйтте.

—Намус карагы булырга батырайсаң да, куркак икәнсең син,—диде.— Милициягә хәбәр итәр, ректоратка жалулап барыр дип шүрләп калгансың. Шыр җибәрмә! Беркемгә дә бер сүз дә әйтмәм... Сине кызганып түгел, үз исемемне шакшыга буямас өчен. Синең белән арам өзек!

Кәефсезләнүләр, тәмсезләнүләр узар, мөнәсәбәтләр әүвәлге эзенә төшәр дип көткән Даниял Арукаевның өмете күгелҗем сабын куыгы булып

*Шәриф Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы» повестеннан.

шартлады. Моны анына кабул күрү егет өчен жан жәзасына әверелде. Кетәктәш әтәч белән сугышырга тансыклап йөргән кикерикбай сыман тулышып-кабарынып торган гаярь егет кыртлап тенкәгә тигәне өчен салкын суга утыртып, кычыткан белән өтәләгән тавык хәлендә калды. Гөлфия анын кулына көзге тоттырды булып чыга: «Кара, күр үзенне! Кемлегенне чамала!»

Кемгәдер сөйләп эченне бушатырлык та түгел бит. Болай да өнәп бетермәгәннәр сизенә калса, каһкаһәләп көләчәкләр, «Сакал тектеләрме, товарищ, үзенә?»—диячәкләр...

* * *

Мәхәббәтнен «янар тавы» атып, Даниялны «имгәткәнгә» берничә көн узган иде инде. Студент һәвәскәрләр 8 март бәйрәменә хәстәрлек башладылар, яна программа әзерләргә керештеләр. Институтта булачак тантаналы утырыштан сон зур концерт куярга, шуны ук шефка алынган колхозда да күрсәтергә тиеш буласылар иде.

Репетициягә Гөлфия дә килде, тик Даниялны ул бар дип тә белмәде, сәламен һәммәсенә берьюлы бирү белән чикләнде.

Егетне сары сагыш басканы күренеп тора. Ул үрсәләнә, сыкраулардан арыну әмәлен таба алмый иде. Дөрес, көрәш секциясенә йөреп, аннан шактый сыгылып кайткач, тәмләп йоклаганнары булды. Югыйсә бит гомер кышына кереп барган карт-коры кебек, төннәрен йокысыз уздыргалады. Һәм бу бит егерме икене тутырып узганда!

Көннәрдән бер көнне Даниял тимер юл вокзалында товар-йөк складында эшләүче Люба белән танышты. Анысы болай булды.

Институт доценты Әфләтүнов студент егетләрдән контейнер белән килгән әйберләрен алып кайтуны үтенде. Егетләр, йөк машинасына төялеп, станциягә төштеләр. Контейнерны алу документлары Даниял кулында иде. Шуларны биреп, контейнерны алганда танышып киттеләр алар.

Чәчен кыска итеп кистергән бөтерчектәй бу яшь хатын керфегенә кунардай чая, озын керфекле конгырт күзләре каракошныкы сыман очкын чәчәләр кебек. Килешле төз борынлы, юка иреннәре назга тилмергәндер төсле, ул аякларны әйткән дә юк. Сәнгать әсәрләре. Гәүдәгә көзге көртлектәй тулы.

Энжедәй тешләрен күрсәтеп елмайса, таш булсан да эрерсен. Тавышы... тавышы әллә ни матур түгел. Аһәнендә көмеш чыны юк. Анын каруы теле бал инде, бал, юкә балы!

—Нәрсә, егетем, контейнер алырга дип килүегезме? Бирегез әле, бөркетем, кәгазьләрегезне. Әйе, әһе... Әйдәгез күрсәтимче кайсы икәнен... Чакырыгыз егетләрегезне... Исемегез ничек, бригадир булып килгән егет? Даниял! Матур исем. Даны да бар, ялы да бар. Ялы булу егет солтаны дигән сүз инде ул...

—Ә сезнен исемегез?

—Минем исемем икәү,—диде багаж бүлеге башлыгы.—Люба, Любовь. Монысы—әнием өчен. Ул—маржа. Ләбибә дигәне—әтием өчен. Ул—мөселман татары. Хәниф атлы. Хәниф Галиәхмәтович Бикмуллин. Мин паспортта Ләбибә Хәнифовна Бикмуллина. Монда эштә—Люба...

Контейнер янына житәрәк Даниял, кысырыграк арадан чыгуны сылтау итебрәк, Ләбибәгә сыланып диярлек калды. Хатын-кыз мондый мескен хәйләне сизмиме? Тот капчыгынны! Ничек кенә сизә әле! Кайчак эндәшми кала, шул гына. Ә Ләбибә Бикмуллина тыелып бетмәде.

—Сез, егетем,—диде ул, көлә-көлә,—тән якынын бик тоясыгыз килсә, мина кунакка рәхим итегез.

Даниял, жинүне жинел яулыйм дип, масаясы итте бугай. Шундук Ләбибәнен адресын сорады. «Сер булмаса...» дип тә кыланды.

—Анын нәрсәсе сер булсын?! Автовокзалны беләсезме?

—Белмәскә! Сез бигрәк тагын!..—Егет үпкәле көлеп куйды.

—Менә шуңа сыланып кына тора безнен ташпулат. Елга порты да кул сузымында. Татарстан урамы, йорт... квартир...

—Кайчангарак килергә рөхсәт?

—Туасы атнаның дүшәмбесеннән мин беренче сменада булам. Кичке жидегә.

—Мине гөрзи белән кем каршылаячак?

—Беркем дә. Мин ялгызым гына яшим. Кооператив фатир. Үз болыным, үз чабыным.

—Күчтәнәчкә нәрсә алып килсәм, Ләбибә туташның зәвыгына туры килер икән?

—Сездәй егетләр—үзләре күчтәнәч. Һични эзләп мәшәкать чикмәгез. Сезне сыйларлык кына хәлем бар.

—Алайса килештек.

—Вәгъдә—иман, диләрме?..

Дүшәмбедә Даниял Любовь-Ләбибә Бикмуллина квартирасына, чыннан да, килде. Кулында ризык-нигъмәт, тәм-том түгел, чәчәкләр иде. Бу тиклесе Ләбибә күнеленә бик хуш булды. Болай да елмаерга әзер торган йөзе балкып китте.

—Рәхмәтләрнен зурысы булсын сезгә! Мен бәладән йолсыннар!

Даниял туфлиларын салып та өлгермәде, Ләбибә анын аяк астына йомшак киез башмаклар китереп куйды.

—Түргә рәхим итегез!

—Рәхмәт! Әрсезләнеп килгәч, узабыз инде.—Студент түр якка чыкты һәм карашы белән бүлмәне капшап узды. Житешлек, зәвык һәм чисталык күзгә кереп тора иде. Стенада гына түгел, идәндә дә келәмнәр. Тәрәзә пәрдәләренең эчкеләре дә, тышкылары да күз явыңны алырлык. Галәмәт матур эшләнгән люстра да, буфеттагы бокал һәм рюмкалар да бәллүр. Ишек буендагы көзге идәннән түшәмгә кадәр, комод өстендәгесе—трельяж—ике канатлы. Кием шкафлары эчке бүлмәдә булса кирәк. Төсле телевизор да анда. Тылсымлы тартма эшләп тора—Казан дикторларының таныш тавышлары ишетелә.

Түр якның урамга караган диварында зурайтылган ике портрет. «Әнисе белән әтисе...»—Даниял шундый фикергә килде.

Барысы да бар, тик китаплар юк иде. Хәлле кешеләр, гомерләрендә бер томны ачып карамасалар да, рәвешкә-фасонга китереп, китап жыючан булалар. Любовь-Ләбибә рияланып маташучылардан түгел, күрәсен. Укымый икән—укымый, бетте-китте! Укымагач, китап жыеп кыланмый...

—Күз хөкеме төгәлләндеме?—Любовь-Ләбибә көлеп куйды. Даниял квартираны күздән кичергәндә, хужабикә аны энә күзеннән үткәзеп торган икән.—Әйдәгез, кулларыгызны юып алыгыз да өстәл янына рәхим итегез. Студент халкы төшке ашны да аягүрә генә капкалап чабучан була бит ул.

—Үз тәжрибәгездән чыгып әйтүегезме? Гафу итә күрегез, сез нинди уку йортын тәмамладыгыз?

—Әйтми булмас, югыйсә сез чамалый алмассыз... Мин елга техникумының яр буе хезмәте бүлеген тәмамлаган идем. Әвәрәләнә торгач, тимер юл дөньясына килеп чыктым. Дүрт ел инде шунда.

—Елга яры ошамадымы?

—Аннан китүнең сәбәпләре бар инде...

Артыгын төпченү килешмәгәнен анлый иде студент.

Мул хәстәрләнгән өстәл янына утырдылар. Ләбибә сый-нигъмәт өстенә япкан жете ак тастымалларны ачты.

—Шампанскийдан башлыйбызмы?

—Анысы—хужа эше инде. Яна ел түгел, никах туе түгел, салютсыз гына ярамыймы, Ләбибә Хәнифовна?

Ләбибә матур итеп көлде.

—Алай эндәшеп мине олыгайтып жибәрмәгез әле. Яшьлек белән бәхилләшәсем килми.

—Ничек дип эндәшергә боерасыз?

—Боеру түгел, кинәш кенә. Гозер хәтта. Просто Ләбибә диегез. Ләби-бә!

—Булды! Килештек.

Шампан шәрабы суыткычта утыра калды. Ләбибә Даниял кулына «Башкала» аракысы шешәсен бирде.

—Ачсагыз икән дә, рюмкаларга койсагыз икән.

—Эшләп ашарга дисез инде?—Эх, бу гыйбадлык! Ефәккә төрсән дә ертып чыга, таш белән бастырсан, ташны читкә тәгәрәтеп шөкәтсез чыраен алга суза. Бүтәнчәрәк сүз беткәнмени сон?!

—Гафу итегез, Даниял, кешеләр кунакта эшләми генә сыйланырга хаклы. Ник дигәндә, алар чакырулы, өндәүле булалар. Кунакка өндәү—ихтирам билгесе...

Менә тик кенә утыра белмәсән! Йөк склады эшчесе профессорларын өйрәтмәгәнне әйттеме? Ә син, шәкерт, югары уку йортында лабаса! Мокытлыкнын да бер чиге булырга тиештер лә...

Ярый әле тәртәне бик тиз борып ала белде.

—Мин дә гафу сорыйм, Ләбибә. Гомеремә кеше төсле шаяра алмадым. Әйдәгез, саулык теләшеп тотыйк! Мине гафу итү дә шул булсын иде.

—Килештем.—Мактану юлында сер сынатмаска жан аткан яшь хатын вәкарь белән шулай диде.

Бәллүр чәркәләр төбенә тикле бушатылды. Мәжлестәшләр чәнечкеләре белән салат тәлинкәсенә үрелделәр.

Озакламыйча телләр бермә-бер жорланды. Хәтердә мәзәк хәлләр янарды, анекдотларнын тозлы-борычлылары искә төште.

Чәркәләр бушый торды. Любовь-Ләбибә кунагыннан калышмый иде. Мондый нык хатыннар сирәк була. Гүзәлләрнен бер ишесе мәжлестәгеләр артыгын сагызланмасын өчен генә ирен тидереп куя, бер ишесе тәкъдим иткәнне рәттән сыпыра да тоякта төшә, мәлжери, укшый башлый, косарга азаплана. Ләбибә каты каккан казык сыман утыра. Фикере буталмый, чәчәләнми, хатын-кыз чыгымчысы күрсәтми. Әйтерсен куе чәй генә эчкән!

Чәркәләрне янә мөлдерәмә тутырдылар. Ләбибә әйтте:

—Боларын, Даниял, ял итеп алгач эчәрбез, яме,—диде...

Ике-өч сәгать узгандыр, Даниял кайтырга дип киенә башлады.

Ләбибә канәгатьсезлеген пәрәнжәләп тормастан сорады:

—Син нәрсә, китәсен дәмени?

—Булды, житте! Калакланып торып булмас.

—Монысы ни дигән сүз?—Әле генә гөлләр кебек булган Ләбибәнен ачуы чыкты.—Сабыр ит,—диде ул, әмергә якын тон белән.—Сөйләшәселәр бар, Даниял иптәш...

Даниял пальтосын элгечкә кире элде.

—Сина йомышым бар минем...—Ләбибәнен тавышыннан кырыслык качкан иде инде.—Мина булыш әле, зинһар. Миндә япон телевизорлары бар. Икәү. Өр-яналар. Шуларны аткарырга кирәк. Комиссионкагамы, алырга кыбырсыган бәндәләргәме?.. Ин яхшысы—комиссионкага... берәм-берәм... Паспортын чиста. Кемдер бүләк иткән иде, студент кешегә акчасы кирәк, фәлән-фәсмәтән... Жәен эшләдем, дисен. Акча алган урынын билгеле. Шул акчага алган булгансын... Унышлы аткарсан, өлешсез калмассын. Ризамы?

Даниял уйлана иде әле. Башына шөбһәле уй төште анын. «Бу Ләбибә туры юлда түгел бугай...»

—Посынма, шүрләмә! Гренадердай егет бит син! Монысын аткаруны ерып чыга алсан, иномарка урнаштыруда булышырсын...

Студент дертләп куюын чак-чак яшерде. Кара син монын колачын!

Любовь-Ләбибә егеткә тын алырга бирмичә психик һөжүмгә ташланды.

—Иномарканы урнаштырышсан, әжере еллык стипендиян генә булмас... Кыскасы, син кирәк мина. Әлегә корым-сөремнән хали кеше буларак кирәк.

Сантый Сандр булып утырыр хәл юк иде, йә ак диярга, йә кара дип әйтергә кирәк иде.

—Уйлап карармын,—диде Даниял. Аның кыюлыгы, җорлыгы, тәвәккәл кыланышлары кул белән сыпырып төшергән төсле югалган иде.

Любовь-Ләбибә дә аның җебеп калуын аңлады, тик сер пәрдәсенең бер читен ачкач бу бәндәне нygытып кисәтмичә генә озату ярамаганын да белә иде.

—Мин сине тоткарламыйм, студент. Дөнья сиңа гына терәлеп калмаган. Шулай да минем кулдан ансат кына шуарга ниятләмә... Бүгенге сөйләшү турында ялгышып кына кемгәдер авыз ачасы булсаң, кабер алды догаларыңны укып йөр! Синнән ычкынган бер сүз миңа кайтып житүгә, маңгаеңа тугыз грамм кургаш. Алай гына түгел, авылыгыздагы атаң йортының көле күккә очачак, бөркеткәем! Контейнер алганда, доверенность белән пасторыңны биргән идеңме? Туган-үскән җирең адресы бик хәтердә. Кинопленкадагы кебек... Теш агартып, тел озайта калсаң, якты дөнья синең өчен түгел! Хәзер кил әле бирегә!—Ләбибә түр тәрәзә буена атлады. Даниял да, гипноз тәэсиренә эләккән кеше төсле, аның янәшәсенә барып басты.

—Күрәсеңме?

Урамда, башында электр лампочкасы янган багана янында, әзмәвердәй өч ир-ат тәмәке көйрәтәләр иде.

—Безнең гвардия!—Ләбибә тавышына базыну катыш мактану йоккан иде.—Исәнләшеп уз үзләре белән!.. Инде бар, юлыңа ак җәймә! Уйлан, төгәл бер атнадан кичен минем ишеккә килерсең. Кыска-кыска дүрт звонок. Дүрт! Килми калырга рөхсәт юк.

—Ләбибә мендәре астындагы пистолетын Даниял күрерлек итеп капшап куйды...

Артына типсәләр дә бу чама хурлык булмас иде, билләһи! Кызлардан кайсысының каргышы төште? Кайсының бәддогасы бандит кочагына китереп ташлады? Каргыш җимешедер бу, каргыш сыедыр!..

Даниялның уйлары чәбәләнеп, кырык төенле булып беткән иде. Инде кая барырга? Тулай торакка бу хәлдә кайту чөй өстенә тукмакка әйләнмәгәе...

Студент күнеленнән моңарчы күргән-күрешкән, наз татыган хатыннарын барлап чыкты. Берсе дә кочагын ачып кабул итмәячәк иде. Кара көнгә дип чын дустын булдыра алмады шул! Юллар киселгән, күперләр янган... Бәлки Надя, Надежда Сергеевна кертер?

Ишек кыңгыравы төймәсенә икенче кат баскач кына килде Надя бусага төбенә.

—Кем йөри бу вакытта?

—Даниял иде.

—Сагынганда сабан җигеп йөрүче шулдыр дигән идем... Юк, ача алмыйм, кешем бар.

—Шаяртма, Надя!

—Җитди әйтәм, кешем бар. Үз милләтемнән. Кит, күршеләр уянып чыгачак...

Менә тагын бер хурлык бәлеше!

Китте. Асфальттан түгел, гүя чәнечкеле тимер чыбык өстеннән атлап китте.

«Кешем бар, үз милләтемнән...»

«Сезденме, мокыт, нинди кукиш күрсәттеләр үзеңә?!—Ул янәшәсендә кеше бар төсле сөйләнә иде.—Аңладыңмы? Мунча ташы кызганда татар егете бик тансык иде, җае чыккач, үз милләтенеке кадерлегә әйләнгән. Гаҗәбе юк...

Колларның сакалларын утта өтү заманы күптән узган булса да, безгә татар малайларына, бозау муенчагы кидерә бирәләр. Кирәгендә тартып китерәләр, кирәгең беткәч—артыңа тибәләр. Типтермәгәннәре дә бар аның барын...»

Таң озак атмады.

*22. XII. 1997.*
*Казан каласы.*

# ШИГЪРИЯТ



## Шәүкәт Галиев

БАКЫРЧЫ ҖӘЕ

### Ниндидер көч

Биек тауда тойганыгыз бардыр:
Иксез-чиксез киңлекләрне күреп,
Ниндидер көч сине күккә тарта—
Кинәттән очып китәрсең кебек!..

Чак тыелып торам, тик бер адым—
Очам диеп, сикереп аласы...
Канатларың синең—күңелеңдә,
Оча беләсең, адәм баласы!

... Ак кәгазьгә карыйм, охшаш тойгы
Минем күңелемне гел сихерли—
Иксез-чиксез монда мөмкинлекләр,
Икеләнеп тә торма, сикер! ди.

Түзә алмадым тарту көченә,
Дәште упкын—шунда мин атладым...
Нинди хозур мизгел кичердем бит—
Ачылды да китте канатларым!

Күңелемнең бәргәләнгән чагы
Хыял чоңгылына гел китерә—
Бу юлы да канат булыр микән?—
Белмим әле, әмма мин сикерәм!

## Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Шаян, көләч ролен уйнап йөрим,
Армас-талмас булып узамын.
Бәйрәмдә дә вәйран минем халәт—
Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Төшенкелек упкынынннан йолып
Тыеп кына тора үз аңым.
Ирешкәнем шөкер итәрлектер,
Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Кешеләргә гел ышаныч өстәп,
Дәртләндереп кулым сузамын.
Карап торсаң, мин оптимист инде,
Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Ятим еллар, төшләремә кереп,
Эзәрлекләп канны бозамы,
Без белмәгән авырлыклар булмас,
Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Тыштан балкып йөргән чакларда да
Эчтән янып, ахры, тузамын.
Уйсыз-гамьсез яшәгәнем юк бит—
Тынгы белми һаман бу җаным,
Ник тынгысыз икән бу җаным?

## Олы Бакырчыда очраштык

*А. С. Пушкинның тууына 200 ел тулу уңаеннан*

Болдинода—синең мәшһүр көзең,
Миндә менә Бакырчы җәе.
Пушкин елы быел—шигъриятькә
Килеп кенә тора бит җае.

... Бик исемдә утыз җиденче ел...
Үлгәннәргә «почет» булганмы—
Бәйрәм итеп шаулаганнар иде
Вафатыңа йөз ел тулганны.

Урман арасында ерак авыл,
Без икенче генә сыйныфта.
Ул чак әле синең даһилыгың
Аңыбызга бетмәс сыеп та...

Күңел тарткан, үз иткәнбез икән,
Саф татарча иде язганың:
Тукай теле якынайткан сине,
Икегезне бергә кызгану...

... Шигырьләрең һаман телгә килә,
Татарча һәм русча ятладым.
Тукайны да, шигъриятне дә син
Яңа Дантеслардан сакладың.

Ике йөз ел тулды бу көннәрдә—
Бусы инде туу бәйрәмең,
Яратуыбызны яңарттың син—
Бөтен татар җирен әйләндең.

Күргән идем Олы Бакырчымда,
Үзгәрмәгән, шул ук сурәтең.
Уртак дога итеп кабатлыйбыз
Син зурлаган Коръән сүрәсен.

## Авыл

Авыл... Күпме мохтаҗлыклар
Аны камаламаган—
Казанны алган Явыз да
Авылны алалмаган!

Күп булды, ипиен чәйнәп,
Аңа тел тидергәннәр,
Кәперәйде дә очты бит—
Тынды тел-тегермәннәр.

Җир хисабына төзәлә
Илдә һәрбер ялгышкан.
Яши авыл, мәңгелек ул—
Тамыр тирәнябышкан.

Шәһәр эш тә ташлый ала
Ахыр чиккә җиткәчтен.
Тик авыл—Аллам сакласын—
Ачлык игълан итмәсен...

## Эрозия

Үзгәргәннәр таныш урамнар,
Бигрәк тирән үткән ерымнар,
Язгы сулар ярны ашаган—
Ераkларга илтеп ташлаган.
Туган ягым кими башлаган...
Ә бит читкә агып киткәнбез—
Без дә эрозия икәнбез...

## Онытылган төш

Елмаеп уяндым—айлы төн,
Күңелгә мөлаем—җайлы төн.
Ак төннәр таныш шул күптәннән—
Яктысы төшә күк үткәннән.

Елмаеп уяндым—сөендем,
Ник әле рәхәткә тиендем?
Ай гына микән соң сәбәбе—
Тиктомал ник кәеф шәп әле?

Елмаеп уяндым—төшендем,
Хикмәте ахрысы—төшемдер...
Сүттем мин ак тойгы йомгагын,
Бик озак күземне йоммадым.

Елмаеп уяндым, татлы да,
Тулы ай сыман ул якты да,
Рәхәте җанымны иркәли—
Күргәнмен илаһи иркәне...

Елмаеп уяндым, сурәтен
Килә дә ачыклап беләсем,
Сагынган, үкенгән бер икән,
Кешегә, үземә сер икән...

Елмаеп уяндым—юрыйсы,
Юк аны кемнән дә сорыйсы:
Ахры, Ай, яшьлектән урыйсың—
Уяткан мәхәббәт тойгысы...

## Арча кызына

Матур иде
Толымнарың,
Мин аларга
Орынмадым.

Сыйпадым тик
Күзем белән,
«Шигырь бу!» дип,
Сүзем белән.

Әйткән-беткән,
Очкан киткән,
Ә бит күңлең
Көткән икән!

Еллар үткәч
Син очрадың,
«Яздыңмы?» дип
Ник сорадың—

Юк бит инде
Толымнарың,
Мин аларга
Орынмадым.

Хисләр шулай
Киселгәндер,
Киселгәнгә
Исеңдәдер?

... Шигырьне ул
Язып булыр.
Соң шул инде...
Язык булыр...

## Җилләр

Чәчләреңне җилләр тарый—
Мин түгел лә,
Керфегеңә кунып карый—
Мин түгел лә...

Изүеңне җилләр ача—
Мин түгел лә,
Куеныңа җилләр кача—
Мин түгел лә...

Җилләр кочаклап та кайта—
Мин түгел лә,
Итәгеңне җилләр тарта—
Мин түгел лә...

## Сынау–сынатмау

Тормыш дигәнең әллә бик
Рөхсәтләр сорап тора—
Төрле хәлләргә куеп ул
Гел сине сынап тора.

Үзең дә кеше сыныйсың,
Таләбең зурдан була.
Барыбызны да сыныйлар—
Үлчәве вөҗдан була.

Узган чагың да буладыр
«Ярый», «ярамый» чиген...
Бүтәннәрне сынау җиңел,
Үзең сынатмау читен.

## Пароход

Пароходның борынында,
Күренекле урынында
Алга карап егет бара,
Канатланган кебек бара.
Көлтә чәчләр тузып бара,
Киләчәккә узып бара.
Омтылыш, дәрт тоеп бара.
Бөтен гомер алда, алда—
Хыялыңнан артка калма!

... Койрыгында пароходның
Бабайның да эшләр хутлы:
Җилләр бәрми, монда ышык,
Ерагая киткән офык...
Су өсләре күбек кенә,
Үткән гомер кебек кенә...
Кала, кала, еллар кала,
Ни бар булган—шулар кала...

... Бабай белән оныкбара...
Син уртадан торып кара:
Бу пароход кая бара?

## Бер көн

Кайда бүген илһам—уйнак,—
Хис битараф, булмый уйлап...
Онытылыр, бу көнем—буш,
Үз ишләре янына куш.
Кемнең гомер үтә оеп,
Менә шундый халәт тоеп.

Мәңгелеккә көнем тамды,
Санаулысы кимеп калды.
Югалтуың әсесез үтмәс—
Бик кирәктә шул көн җитмәс...

## Ниләр бар икән күңелдә?

Ниләр бар икән ул күңелдә,
Күңелнең иң-иң-иң түрендә,
Түренең иң-иң-иң төбендә,
Уй җитмәс урында—тегендә?
Тоясың—белмисең үзең дә.

Буй җитми төшәргә серенә,
Кайчакта каләмең үрелә—
Илаһи балкышлар күренә...
Хис белән, төс белән, ис белән
Укмашкан уй белән, көч белән.

Ниләр бар икән ул күңелдә—
Кайчакта хикмәте күренгән?
Үткәнне—килерне тойганы,
Гомергә бөртекләп җыйганы—
Бер нокта эченә сыйганы?

Гел генә белмәслек түгел лә—
Илһамым чәчелмә, түгелмә:
Җан тыныч, рух уяу булсын да,
Намусың чирүдә торсын да...
Барыбер җитмәслек барсына—
Ниләр бар икән ул күңелдә?

## Илһам капусы

Күк капусы ачылганда
Әгәр өлгерсәң,
Теләкләрең кабул була
Күккә белдерсәң.

Күз ачып йомган арада
Нәрсә теләрмен?
«Сугыш бетсен! Әткәй кайтсын!
Тизрәк!»—диярмен.

Йолдызлы зәңгәр төннәрдә
Сагалап көттем,
Серлелеген, матурлыгын
Күрдем мин күкнең.

Кай арада балкып алды
Нурлы капусы,
Сокландым, сүз әйтәлмәдем,
Ихлас, хак бусы...

Булмады... сугыш бетмәде,
Әткәй кайтмады,
Ятим күңел ул елларның
Моңын ятлады.

Әй шулай да могҗиза бар—
Шулай дип саныйм,
Әле һаман да ышана
Күптәнге сабый:

Ачылды илһам капусы
Якты төннәрдә—
Өлгердем сезгә, үземә
Бәхет теләргә.

Мин теләдем, чынга ашу
Үзеңә кала—
Булмас, димә, булыр әле,
Тырышып кара!

*Олы Бакырчы авылы.*
*Июнь, 1999.*

*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Марат Әмирханов

# ТӘКЪДИР

РОМАН

* * *

Хастаханәдән чыккач, Җәмилә үзен читлектән котылган кош кебек хис итте. Яшәүнең тәмен, тормышның нинди зур ләззәт вә бәхет булуын бөтен тулылыгы белән тоемлыйм дисәң, бераз вакыт ябылуда тор икән. Дөньяны бөтенләй башкача күрә башлыйсың. Каты-коты такта ятак та туй түшәгедәй йомшак тоела.

Хастаханәдә телисенме-теләмисенме, һаман чир турында уйланасың, анда сине барысы да шул эзгә төшерә, шуңа мәҗбүр итә. Тормыш исә сырхаулыкны танымый. Сырхау кешене эштә дә өнәмиләр, өйдә дә. Хәтта яраткан, язмышыңны ана ышанып тапшырган ин якын кешең дә тора-бара йөз чөерә башлый.

Җәмиләнең исә чир турында уйларга вакыты юк иде. Уку елы азагы бит. Мәктәп таяк белән тузгыткан шөпшә оясы сыман мыж килә. Кемнең кая барып бәрелгәнен дә абайламыйсың. Директор югары өлгереш таләп итә, чөнки мәктәпнең эшенә шуннан чыгып бәя бирелә. Укытучы сандал белән чүкеч арасында. Директорның сүзен читкә этәрә алмый укытучы. Чөнки аның үзенең язмышы да шул каһәрле процентларга бәйле. Шул ук вакытта аяк терәп, укудан баш тартучы кире беткән ялкау балаларга күрәләтә унай билге дә куясы килми. “Классыңда утыртып калдырам”,—дип күпме яный ул аларга ел барышында. Икеләне шартлатып чәпәр иде дә бит, кулы кыска, баш очында Процент Газраилнын үткен чалгысы.

Шушы мәсхәрәле, түбән халәттән үзенең шәхси горурлыгын җуймыйча чыгу юлын табарга тырышып чәбәләнә укытучы. Әлифне таяк дип белмәгән укучылар белән өстәмә дәресләр уздыра, биремнәр бирә, таләпчәнлек күрсәтә, янәсе.

Җәмиләдә дә бар андый ташбашлар. Әнә, каршысында Тимерхан исемле малай. Әнә өстендә утырамыни, боргаланыпмы-боргалана. Бүләк исемле бер кечкенә авылдан йөреп укый ул. Өченче ел инде тартып-сузып класстан класска күчерәләр. Чәчләре гарәп комганы шикелле бакыр төстә. Йөзендә дә шундый ук сипкелләр. Үзе эре сөякле. Ә тавышы ләнкә этнеке кебек чәр дә чәр.

Беренче дәрестә, беренче очрашуда ук киреләгән күрсәтте Тимерхан. Яна килгән укучыларның әзерлек дәрәҗәсен ачыклау максатыннан,

---

Ахыры. Башы журналыбызның 10 нчы санында.

Җәмилә уртача авырлыктагы бер мәсьәлә тәкъдим итте. Борыннарын тарткалый-тарткалый эшкә тотындылар. Бакыр чәчле малай гына ашыкмый, тәрәзәдән нидер күзәтә.

—Тимерхан, вакыт уза, соңаруың бар,—дип Җәмилә аның аркасыннан какты.

—Китәле, нигә сугасың,—дип сикереп торды малай,—тегендә бөкересе чеметә ие...

Бөкере дигәне үз авылларындагы Рамазан исемле укытучы, яшьли гарип, аркасы уалы.

Әйтерсең лә, искәрмәстән Җәмиләнең яңагына китереп чәпәделәр, колаклары чынлап китте. Тимерханны класстан типкәләп куып чыгарудан үзен-үзе чеметеп кенә тыелып калды. Әмма бу тискәре малайны шушы беренче дәрестә үк кулга алырга тиеш ул. Югыйсә, йөгәнле алмаячак. Әнә, башкалар да кемнең сүзе өскә чыгар, дип астыртын гына күзәтәләр.

—Эшкә тотын,—диде Җәмилә, тавышына булдыра алганча катгыйлык төсмере бирергә тырышып.

—Ручканы онытканмын,—дип Җәмиләгә җилкәсе белән борылып утырды Тимерхан.

—Мә, минеке белән яз.

—Нәрсәгә миңа кеше калдыгы...

Сизелеп тора, малай Җәмиләне чыгырыннан чыгарырга омтыла. Вожак булмакчы. Яңа класста андый хәлләр элек тә күзәтелә иде. Әгәр ул хәзер кычкырына, җикеренә башласа, абруе калмый дигән сүз. Бу инде көчсезлек билгесе.

—Ярар соң, дәрестән соң калып чишәрсең мәсьәләнне,—диде Җәмилә тыныч кына. Шуннан ары ул аңа таба борылып та карамады. Күз уңыннан төшеп калгач, аңа карата игътибар беткәч, ниһаять, Тимерхан да биременә кадалды. Ручкасы да бар икән, онытып калдырганмын дип алдашкан гына.

Алар арасында мөнәсәбәт барыбер яхшырмады. Гаеп Җәмиләнең үзендә дә бар. Бервакыт әтисен очратып, улын яманлаган иде. Тегесе кайткач, гадәттәгечә, "тәрбия дәресе" үткәргән. Тимерхан атна буе күгәргән күз белән йөрде.

Әле хәзер дә сөзгәк үгез кебек күзләрен тондырган.

—Менә бу мәсьәләне укып чык әле башта,—диде Җәмилә,—аннан соң бергәләп аңлашырбыз.

—Башкалар әллә кайчан өйләренә кайтып китте, мин нәрсә... каныкты тәки...

Ишектән класс житәкчесе башын тыгып карады. Борчыла. Процент тынгы бирми.

—Җә, ничек? — диде ул.

—Менә карашып утырабыз әле...

Тимерхан теләр-теләмәс кенә дәреслекне алдынарак тартып куйгандай итте.

—Бу кире беткәнгә икеле генә куям,—диде Җәмилә,—ботыннан тотып селексәң дә рәт чыгарлык түгел, азаплансын тагын берәр ел жиденче класста. Хурлык бит. Телләшмәсә бер хәл иде.

—Җиденчедә ун ел утыртсаң да файдасы тимәячәк, Җәмилә Нурулловна,—диде класс житәкчесе.—Әнисе кызганыч. Чирләшкә бит. Һич тернәкләнә алмый мескенем. Әтисе салырга ярата. Өйдә тагын берсеннән-берсе кече өч бала. Күзәтү дә, тәрбия дә житми. Тимерханга тормышында квадрат тамыр алулар кирәк булмас, дип уйлыйм, акча саный белсә, шул житкән.

Чирләшкә дигән сүз Җәмиләне сискәндереп җибәрде. Шушы ук мизгелдә әлеге авыру хатын белән ике арада ниндидер серле җеп сузылгандай булды. Күреп сөйләшсе, хәлен беләсе килеп китте. Теләктәшлек хисе уянды. Үзе дә шул хәлдә ич ул...

Аңа инде Тимерхан да ул кадәр үк сөймәс сөяк кебек күренми иде.

—Менә бу дәфтәрдә барысы да язылган,—дип пышылдады ул класс житәкчесенә,—үзегез жайлаштырыгыз, ә мин чыгып торам.

Тормышта барысы да бергә йөри. Шатлыгы да, борчулары да, уенкөлкеләре дә. Шулар тотырып тора да инде аның чиләген. Бер мәшәкать икенчесен алыштыра, алдагысы үткәнен юып ташлый. Тормыш арбасы алны-ялны белми, тәгәри дә тәгәри.

Беркөнне кичләтеп кенә Әлмәттән апасы Мәгъсүмә шалтыратты. Тыны-көне беткән, сулышын да көч-хәл белән генә ала.

—Сенлем, әти югалган,—дип мышык-мышык еларга ук тотынды.

Жәмилә апасының энәдән дөя ясый торган гадәтен бик яхшы белә, үз башыннан үткәрде. Шуңа ышанып та бетми.

—Апа, аңлатыбрак сөйлә әле, кайчан югалган, ничек?

—Сыерны базарга житәкләп киткән дә... инде бер атна ди...

—Кем әйтте?

—Авылдан килгәннәр иде, әни бик борчыла, ди.

—Теге маржасындадыр, бәлки?

—Шунда инде, шунда булмыйча...

—Нигә соң алайса, югалган дип оран саласың?

—И, сенлем, мине беләсең инде, әнигә авыр бит. Машинагызга утырып кияү белән янына барып килмәссезме, диюем. Сез укыган кешеләр бит, бәлки тыңлар. Кеше арасында хурлык бит.

Нурулланың колхоз рәисе булып эшләгәндә чуалып йөргән яшь нәмәстәсе бар иде. Шуны һаман ташлап бетерә алмый, барып-барып кайткалый. Атна-ун көннән туйда йөргән ата мәче кебек сөйрәлеп кайтып керә аннарысы. Шундук хатынын кыздыра башлый. Нигә монысы болай, нигә тегесе тегеләй, авыз да ачтырмый. "Жәүһәрияне дугалы атта гына зур итеп төшердем, канәт, кыңгырау тавышы әле дә колакта тора,—дип сөйләгәне бар Мансурга—элек киленнәр хәзергесе күек ир рәтенә туйда кәеф-сафа корып йөрмиләр иде, дварга керүгә эшкә тотына иде. Әбиеннең әле матур, яшь цагы, унбише дә тулмаган. Бераз капкалап алуга малтуар янына цыгып китте бу. Мин дә келәт поцмагында посып кына күзәтәм моны, кулы эшкә ятамы, әти-әни алдында йөзгә кызыллык китермәсме? Килен килде, киле саптай теле килде, кече сәкегә пире килде, дип мыскылламасалармы?

Багам шулай, канәт, сәнәк-көрәк тотарга ашыкмый, як-ягына карана, аң-саң этә. Урамнан кемдер узып бара иде, йөгереп барып капка ярыгына капланды. Үзеннән-үзе кулларым цыбыркыга үрелде. Тавышсыз-тынсыз гына бер-икене сыдырып та алдым моңа.

Шуннан соң әбиең майлаган күек булды, канәт. Катыннарны узындырырга ярамый, вакытында кулга алырга кирәк".

Федоровка исемле бу авылның авыл диярлеге дә калмаган иде. Яу узган сыман. Кая карасаң, шунда жимерек. Койма-капкалары авыптүнеп беткән. Ташландык өйләр хәтсез. Яшьләр нефть эшендә, шәһәрләргә күченеп беткәннәр. Авылда башлыча карт-карчыклар гына торып калган. Алар инде яшәсен яшәгән, дөнья мәшәкатьләреннән дә гарык.

Мария түтәйнең өе яныннан гына инеш ага. Сай, пычрак инеш. Каз-үрдәк шунда мәш килә.

—Син генә кереп сөйләш әле, Мансур, мин гәрләнәм,—диде Жәмилә. —Мин машинада көтеп торам.

Авылның фәкыйрьлеге, шыксызлыгы Мансурга авыр тәэсир итте. Курчак өе кебек йорт-жирен калдырып нишләп жүләрләнеп йөри инде бу карт бүре, дип бабасын сүгеп ташлады. Мөгаен, маржасы бозгандыр, алар андый гамәлгә бик маһир.

Машинаны күреп булса кирәк, өйалды басмасында узган гасыр картиналарында тасвирланган купшы купчихаларны хәтерләтүче зур гәүдәле хатын чыгып басты. Күкрәкләре ат башы чаклы, ботлары юан. Йөзе яныл тора. Менә ни өчен арына алмыйсың икән, бабакай, дип көлемсерәп куйды Мансур.

—Сезгә кем кирәк, кемне эзлисез?—диде хатын.

—Нурулла агайны күрәсе бар иде.

—Рәхим итеп, өйгә узыгыз.

Бабасы имезлек белән бер яшь бозауга сөт имезә иде. Мансурны күргәч тә шөгыленнән туктамады.

—Цуаркай бозаулады бит әле, канәт, кара нинди баһадир.

Мансур бозауны баһадир ук дип әйтмәс иде. Эт чаклы гына бер нәмәстәкәй шунда. Чуар. Әнисенә ошаган. Тере күренә. Сөтне шешәсение белән йотып җибәрер иде.

—Бер-ике көн өйдә торсын әле,—диде Нурулла кияве бирәчәк сорауны алдан ук шәйләп.—Ныгысын, дим.

—Кунакта ошап киткән сиңа, бабай, аш төрләндерәсең, ә?

—И, канәт, бозау тота. Цибәр цукынмыш. Кышлыкка калдырырга исәп. Әнкәсен сатып җибәрергә була аннары. Расхудлар зур.

Нурулла никадәр генә ваемсыз күренергә тырышса да, киявенә күтәрелеп карарга кыймады. Үзе дә белеп тора, бу сәяхәте озаккарак сузылды. Гайбәте кызларына да барып ирешкән икән инде. Ыштырны урарга вакыт житкән. Вәләкин маржаны да үпкәләтергә ярамый. Араны өзәргә җыенганы юк әле аның.

Мария аларның сүзенә кушылмый, тавыш-тынсыз гына табын хәзерләп йөри. Кунакчыл да икән әле, каһәр. Ә Мансурга озакларга ярамый. Җәмилә килеп керсә, җәнҗал кубачак. Аңа ничек тә бабасын бу тозактан кычкырыш-талашсыз гына йолкып алырга кирәк. Бу араларда нишләптер гел шундый киеренке хәлләргә юлыга. Теге вакытта ГАИ офицерын юмаларга туры килгән иде. Аннан Җәмилә. Хәзер менә бабасы...

Мансур Нурулла имезлек шешәсенең сөтен алыштырган арада бозауны күтәреп алды да, урамга чыгып йөгерде. Җәт кенә аны машинасының арткы утыргычына яткырып, кузгалып та китте.

—Нинди бозау бу, нишләвең синең? Әти кайда? — дип, Җәмилә сорау артыннан сорау яудырды.

—Барысы да соңыннан, ә хәзер бозау янына күченеп утыр әле, дулап тәрәзәләрне ватуы бар,—диде Мансур.—Анда, әнә, халат бар, астына шуны җәй.

—Әти кайда соң?—дип төпченүендә булды Җәмилә.

—Борчылма, озакламас, магнитлы бозау бу.

Чыннан да, бер-ике сәгатьтән Нурулла, атына чуаркаен тагып, кайтып та житте.

* * *

Казан аларны сөрсү, тынчу һавасы белән каршы алды. Көн ифрат дәрәҗәдә эссе иде. Асфальт камырга әйләнгән, баскан саен изелеп-изелеп китә. Өстәвенә, аэропорт алдындагы мәйданны төзекләндереп, сурәтен үзгәртәләр икән. Биниһая зур кара чанда гудрон кайный, электр төрткече белән юл өстен кубаралар. Борынны ярып сасы ис керә. Шау-шудан колак элпәләре ярылып китәр сыман.

Троллейбус тукталышында да кеше күп.

—Такси тот, тизрәк китик моннан,—диде Җәмилә үртәлеп. Кәефе шәптән түгел иде. Аны моңа кадәр уку елын тәгәлләүгә кагылышлы мәшәкатьләр, имтиханнар кысада тота иде. Инде алар артта. Хәзер ул авыру-борчулары белән күзгә-күз торып калды. Иртән дә, кич тә, көнен дә, төнен дә шул борчуларның шәфкатьсез кочагында. Ярый ла, Шарон Моисеевич әйткәннәр раска килсә? Әгәр килмәсә? Бик хәйләкәр шимбә, юмалый-юмалый тәки Казанга озатты бит. Алай черки тешләгән кебек кенә булса, үзе алыныр иде...

Такси эчендә дә бөркү иде. Шофер үзе ягындагы тәрәзәне яртылаш ачкан, башкаларына тотындырмый, җәйге үтәли җил бик куркыныч була, ди. Җәмиләнең моңа да җене кузгалды. Ярты юлда төшеп калдылар.

—Әйдә, елга портына эллертәбез, анда, мөгаен, җиләстер,—дип Мансур көтелмәгән тәкъдим кертте. Хәер, моны көтелмәгән дип әйтеп тә булмый, киресенчә, төптән уйланылган тәкъдим. Алар Казанга килгән саен Идел буенда мәхәббәт хатирәләрен янарталар иде. Пароход Җәмилә өчен гаилә талисманына әверелгән иде инде. Тик бу юлы хәлләр бөтенләй башка. Әнә бит, юкка-барга да көйсезләнә.

—Мина барыбер,—диде Җәмилә. Әмма үзенең күзләрендә җанлану чаткылары кабынып китте. Мансурның эченә җылы йөгерде. Бу форсатны кулдан ычкындырырга ярыймы соң? Озак та үтми алар универмаг янындагы тукталышта 6 нчы трамвайга утырдылар.

—Трамвайда дыңгыр-дыңгыр йөрүне җаным сөйми,—дип сукранды Җәмилә,—троллейбуска утырасы калган.

Мансур дәшмәде, хатынының сүзләрен колак очыннан гына очырып җибәрде. Ул Җәмилә ныклап торып кәҗәләнә башлаганчы вокзалга барып җитү турында гына кайгыра иде. Алай да хәвеф-хәтәрсез килеп җиттеләр.

Монда, гадәттәгечә, ыгы-зыгылы тормыш кайный иде. Кеше өстендә кеше. Кайсы китә, кайсы кайта, кемдер якыннарын каршы ала, кемдер озата. Ләкин бу шау-шу тынны кысмый, күңелгә тими. Көмештәй җәйрәп яткан Идел, Ослан ягындагы таулар аны үзләренә йота иде, күрәсең.

Җәмиләнең дә кәефе күтәрелеп китте. Мансур тиз генә рестораннан ике шешә сыра алып килде.

—Сырасы шәп,—диде ул бераз авыз иткәч,—Чехлар кайната беләләр, каһәр.

—Әйе,—дип килеште аның белән Җәмилә.

—Шарон Моисеевич тәҗрибәле табиб, мин үзем дә белештем, гап-гади операция диләр...

Җәмилә су читенә ипи кисәкләре ыргытты. Чыр-чыр килеп аларга акчарлаклар ташланды.

—Менә күрерсең,—дип дәвам итте сүзен Мансур,—армиядә минем дә сукыр эчәгемә операция ясаганнар иде, сизмәдем дә, тундыралар бит аны...

Җәмилә битараф килеш кала бирде.

—Галимнең хатыны гинеколог. Ул да булышырга әзер. Бүген үк очрашачакбыз. Әйтеп куйдым. Телефоннан.

—Операциядән соң безнең белән ни-нәрсә була инде,—диде Җәмилә, ниһаять.

—Барысы да әйбәт булыр, күрерсең.

—Әгәр мин ясатмасам?

Җәмилә Мансурга сынаулы караш ташлады.

—Әйттем ич инде, гап-гади операция...

—Әгәр мин үлсәм?

Җәмилә, үксеп, Мансурның күкрәгенә ауды. Берара тып-тын утырдылар. Баш түбәсендә акчарлаклар чыелдаша. Идел өстендә "Метеор"лар, "Ракета"лар тыз-быз килә.

—Син мине элеккечә яратырсыңмы?—диде Җәмилә яшь аралаш.

—Яратканымны беләсең ич инде.

—Алдагысын белмим шул менә... Ләйсәнне кага күрмәгез...

Мансур кабынып китеп, сыра шешәсен җиргә бәрде. Ул челпәрәмә килеп ватылды.

—Нинди сүз инде бу, Җәмилә? Ләйсәнне кагу турында нинди сүз булырга мөмкин? Ничек шундый мәрхәмәтсез сүзләрне әйтә аласың?

—Исемә төште дә, әйттем,—диде Җәмилә тәккәлефсез генә. Ул янә су читенә ипи кисәкләре ыргытты. Баягы кебек үк аларга акчарлаклар ябырылды. Сорыкорт акчарлаклар. Аздырып бетергәннәр үзләрен, әзер ризыкка күнгәннәр. Болар инде бервакытта да үз асылларына кайтмаячак.

Җәмилә аларга кызганып карап торды. Ул үзе дә шулар хәлендә

иде. Пычак тәннең дә, жанның да табигыйлыгын боза инде ул. Хәерлегә генә булсын.

Мансур үзенчә борчылып утыра. Вәйт, аңгыра. Ул соң монда Җәмиләне шик-шөбһәләрдән арындырырга алып килгән иде ләбаса! Теленә тилчә чыккыры, үзе үк операция турында сүз кузгатты. Җәмилә чирен җиңәчәк, моңа иманы камил. Күнел төшенкелегенә генә бирелмәсен.

—Безне Рәшидәләр көтәдер, җанаш,—диде ул,—кузгалыйкмы әллә?

Җәмилә урыныннан торып басты.

Рәшидә Җәмиләнең бертуган сеңлесе. Ике бүлмәле фатирда яшиләр. Үзе бухгалтер, ире—инженер. Айдар исемле.

Мансур Рәшидәнең булышлыгына да исәп тота иде, билгеле. Туган туганның хәленә керми калмас, йомшак күңелле хатын ул. Үзләре генә этле-мәчеле яшиләр бугай. Аның шулай буласын алдан ук юрарга мөмкин иде инде. Рәшидә апасы шикелле зифа буйлы, озынчарак йөзле чибәр хатын. Чирмешән таулары арасында ямьшәеп утырган ерак мишәр авылы кызына бөтенләй охшамаган. Айдары да бик булдыклы, тәвәккәл егет. Кешеләр белән уртак тел таба белә, аралашучан, ярдәмчел. Әмма Ходай аңа сәламәтлек бирмәгән. Тумыштан гарип—аксак. Шуңа кимсенә, күрәсең. Ә ким кеше көнләшүчән, бәйләнчек була. Тавыш-гауга да шул сәбәпле чыгадыр, мөгаен.

Рәшидә ышанычны акламады. Кая юату? Йокы бүлмәсенә бикләнеп апалы-сеңелле елашырга тотындылар. Айдар кухняда Мансурны сыйлый, якасыннан гына коймый. Йөрәк януын басмасмы, дип Мансур хәтта карышып та азапланмый. Тик хәмер генә алмый.

Бер бүлмәдә мәҗлес, икенчесендә—матәм.

Иң зур ярдәм Лилиядән килде. Чир-сырхау белән бәйле булса да, аны хәтта бәхет дип әйтергә дә була иде. Лилияне шәфкатьле зат дип әйтү генә аз. Ул үзе шәфкать. Шәфкать белән изелгән, шәфкать белән басылган. Галимнең дә: “Мин әсир”,—дигән сүзләре мактану, горурлану гына икән.

Лилия тиз генә чишенеп киемен элгечкә элде дә, хатыннар янына ашыкты. Мансур да аңа иярмәкче булган иде дә, “Мин үзем генә”,—дип, аны да кире борды.

Лилия белән Җәмилә бер-берсен күреп белмиләр, ирләре аша гына танышлар.

—О-о, Ямилә мин күз алдына китергәннән дә сылурак икән син, —дип, Лилия Җәмиләне кочаклап алды.—Бусысы сеңлен энде, әйеме, бик охшашкансыз.

Лилия хатыннарның шешенеп беткән күзләренә игътибар да итми, күптәнге дуслары кебек сөйләнә дә сөйләнә. Ул рус мәктәбендә укыган, шуңа күрә кайбер авазларны үзенчәрәк әйтә. Һәм ул аңа нindидер серлелек биреп тора.

—Еедә генә ебәрделәр, бүген эш күп булды,—дип такылдады ул.—Эш тә эш инде, эштә дә эш, өйгә кайткач та эш. Театрга бармаганыбызга да бер-ике ай була бугай енде. Бу арада яна спектакльләр күренми. Шәриф Хөсәеновның “Әни килде”сен яратам мин. Галимә апа Ибраһимова башкаруында әни искитәрлек. Галимә апа белән махсус барып таныштым. Тормышта да бик мөлаем, нечкә күңелле кеше икән. Сара апа матур-матур ерлар яза.

Күктә кояш, ердә гөлләр,
Алда юллар, юлда мин.
Күктә елдыз, ердә ярым,
Дөнья матур, дөнья кин!

Әйбәт бит, әемегез. Уфадан Фәридә Кудашева килгәч, мәҗлес үткәргән едек. Сабыйлар енде. Көлешәләр, шаярышалар, елашалар. Сәнгать әхелләре шулай бит ул. Фәридә апаның “Дранча”сы бик ошый. Бик

халыкчан. Автограф белән пластинкасын да бүләк етте...

Акрынлап Җәмиләнең яшьләре кипте. Ул инде үзеннән үзе оялып утыра иде. Күр, нинди тулы канлы тормыш белән яши кеше. Ә ул чебен тимәс чер итәр...

— Күптән түгел генә Галимә апага да медицина тикшерүе үткәрдек. Күкрәгендә аның да киста. Операциягә ятарга туры киләчәк. Бик көчле характерлы, ьһ та етмәде, ризалашты...

Лилиянең акрын-акрын Җәмиләне көйгә китерүе иде бу. Җәмилә дә тураеп китте, күзләре уянды.

— Син, сенлем, чыгып чәй хәстәрли тор,—диде Лилия карават читендә канаты каерылган чәүкә кебек бөкшәеп утырган Рәшидәгә, — теге егетләргә дә күз-колак бул, арттырып ебәрмәсеннәр. Ә без Ямилә белән серләшеп алыйк.

— Йә, чишен әле, Ямилә,—диде Лилия Рәшидә артыннан ишек ябылуга, — Галим сине бик уенчак, шат күнелле, көчле рухлы кеше, дип сөйли еде. Сина хәзер нәкъ менә шул сыйфатлар зарур, Ямилә. Мондый күмәк елашып утыруларга чик куярга кирәк.

Лилиянең теле дә, куллары да берьюлы эшли.—Яле, яле... менә шулай, тынычлан, тәненне йомшарт. Булдымы? Булды. Молодец. Мансур сине өрмәгән урынга утыртмыйдыр да, дип беләм, гәүдән Софи Лоренныкы кебек. Тьфү, тьфү, күз тимәсен. Енде мина артын белән борыл да, кулларынны югары күтәр. Кытыгын киләдер, әйеме? Сылу хатыннар көнчел була. Дөресме? Дөрес. Әлбәттә, дөрес. Култык асты бизен авыртмыймы, Юк. Бик яхшы. Хәзер сул як күкрәгенә басам. Сизеләме? Мин дә сизәм. Кечкенә төер оешып килә. Ярый, вакытында абайлап өлгергәннәр. Бу харам нәмәстә. Аннан тизрәк котылырга кирәк. Организмны агулап ятмасын.

Юлламан бишенче хастаханәгә икән. Анда минем әнием эшләгән иде. Дуслары калгандыр, сораштырырмын. Операциядә үзем дә катнашырга тырышырмын. Енде киен. Эчке күлмәген бик затлы икән. Әллә Франциядә эшләнгән енде? Мансур Мәскәүдән алып кайтты дисенме? Галимгә әйтсән, бот чабып көләр. Нигә дип, шулай енде ул. Авылча хөкем ертә. Алай дисән, Мансур да шәхәрдә тумаган анысы... Бик матур ерлый ул синен Мансурын. Бер Казанга килгәч, ерлашып утырган едек. Бүген дә ерлатсак, каршы килмәссенме? Мин үзем ер-монга, сәнгатькә гашыйк енде шулай. Ходай сәләт кенә бирмәгән. Безнен нәселебез табиблар нәселе.

* * *

Сырхауханәнең хирургия бүлеге өченче катта урнашкан иде. Сонга калмыйк дип, баскычтан йөгерә-атлый менделәр. Ләкин бу ашыгуның файдасы гына тимәде. Профессорга кергәнче кәгазь-документлар белән бәйле рәсми эшләр беткәнен шактый вакыт көтеп утырырга туры килде.

Җәмиләнең төсләре үзгәрде. Ничекләр итеп тынычландырырга сон аны, жанына нинди жим бирергә? Мансур аның борчуларын бик теләп үзенә алыр иде дә бит, юк, бу мөмкин түгел. Хәзер бөтен ышаныч Җәмиләнең үзендә. Бу гаделсез сынауны жинсә, үзе генә жинеп чыга ала.

Профессор Кәримов янына алар икәүләшеп керделәр. Тукайның Карәхмәте кебек таза, мул гәүдәле кеше икән. Бөтен бүлмәне тутырып утыра.

—Нишләп әле Шарон Моисеевич үзенең пациентларын монда жибәрә, әллә кулы киткәнме?—диде ул Җәмиләне баштанаяк күзеннән кичереп. Аннан сон Мансурга мөрәжәгать итеп: "Атакай, гафу итегез, без чаршау эченә керәбез",—диде.

Җәмиләне бик жентекләп карады профессор, күкрәкләрен сыта-сыта авырттырып бетерде. Җәмилә мәрхәмәт көтеп судьяга баккан

гаепләнүче шикелле Кәримовка текәлде. Өметле сүз көтте. Бәлки операциянең дә кирәге юктыр әле? Терапия дә җитәдер?

—Сезгә, чибәркәй, операцияне үзем ясыйм, бүгеннән хәзерли башлыйбыз,—диде профессор бик шатлыклы хәбәр җиткергәндәй.

Җәмиләнең соңгы ышаныч җебе дә шартлап өзелде. Инде язмышка буйсынасы гына калды.

Аны ике кешелек палатага яткырдылар. Палата чиста, пөхтә иде. Лилия барысын да җайлаган, көйләгән булып чыкты.

Күршесе йомры сөякле, хәтта матур дип тә әйтергә булыр иде, әмма килеш-килбәтен мыегы боза. Кытай картларыныкы шикелле сирәк төкле мыек. Үзе бик җор. Авызы тулы мәзәк, мәкаль-әйтемнәр, теле телгә йокмый.

Җәмиләне ул күптәнге танышы шикелле кочак җәеп каршы алды.

—Үзебезнең халык икәнсең, рәхмәт, марҗа кертерләр дип шикләнеп тора идем,—диде ул шомырттай кара түгәрәк күзләрен уйнаткалап.—Берсе белән бик интектем, чыгып качар хәлләргә җиттем, арт ягы шарт та шорт, хет противогаз ки. Синең дә шөрефләрең бушамагандыр бит?

Хатынның итләч ияк ләре дерелдәп алды.

—Бушатсалар, монда бушатырлар инде,—дип көлемсерәде Җәмилә.

—Гафу ит, шаяртам гына. Шундый агач авыз, балта тел инде мин. Танышыйк, әйдә, исемем—Хәдичә.

—Мин Җәмилә булам.

Бу телбистәсе чир турында төпченә башлый инде хәзер, дип куркынып көткән иде Җәмилә. Юравы рас килмәде. Шуңа бик сөенде. Чөнки аның сырхавы турында чит кеше белән сөйләшәсе килми иде.

Хәдичә танышкан арада тумбочкасыннан төргәк-төргәк ризык алып, янындагы өстәл өстенә тезде. Ит, сыр, йомырка, уылдык...

Җәмилә кыстамаса гына ярар иде дип, аңа яны белән борылып утырды. Кеше белән алай артык якынлашуны өнәми ул. Кыстамады. Җәмилә янә рәхмәтле булды.

Бераздан Хәдичәнең тавышы ишетелде.

—Менә шулай яшәп ятыш, Җәмиләкәй.

Хәл-әхвәләт,
Киндер күлмәк,
Ыштан бурлат,
Киткәннәр ур...

Хәдичә төртелеп калды. Ишекне киереп ачып, бүлмәгә бөтерчектәй әйләнчек шәфкать туташы атылып керде. Җәмиләнең кулындагы китабы лып итеп идәнгә төшеп китте.

—Курыкмагыз, апа, мин сезне әлегә рентгенга гына чакырырга кердем,—дип чыркылдады кыз.—Документларыгызны үзем алып киләм, сез 18 нче бүлмәгә бара торыгыз, тизрәк, эш сәгатьләре бетә.

Суй, тек, доктор, яшәмим тәнем өчен,
Яшим синең рингит белән фәнең өчен,—

дип такмаклады Хәдичә.

Рентген дигәннәре минутлык эш, чишенүе-киенүе генә озаграк. Бөтерчек кыз ана кечкенә пыяла савытлар тоттырды, анализлар өчен, диде, иртәгәгә анализларыгыз әзер булырга тиеш, диде.

Ул әйләнеп кайтканда, Хәдичә палатада ниндидер бер карчык белән гәп корып утыра иде. Орчык кебек кенә юка гәүдәле әби. Хәдичәне яулыгыннан колагын чыгарып тыңлый. Дөбрән, күрәсең, "ә" дә "ә".

Җәмиләдән кыенсынды бугай, аны күрүгә җәт-җәт атлап чыгып та китте.

—Бу саңгыраударның бер гөнаһы да юктыр,—диде Хәдичә,—барысын да үзенчә сукалап тик утыра. Алар хакында бер шәп мәзәк тә бар. Сөйлимме?

—Сөйлә,—диде Җәмилә. Үзе эченнән генә, бу җир җимертеп йөрүче тап-таза хатын нишләп ята икән инде монда, чиртсәң каны сытылып чыгарга тора дип уйлап куйды.

—Бер гаиләдә өч кеше яшәгән ди,—дип сөйләп китте Хәдичә,—ир белән хатын да кызлары. Өчесе дә колакка каты икән.

Бервакыт бу ирне мулла күргән дә: "Ник мәчеткә йөрмисең?" дип кыздырган. Өенә кайтып ашарга утыргач, хатынына:

—Мулла миңа мәчеттән утын урлыйсың дип әйтә,—дигән. Хатыны:

—Әй, сиңа ярап булмас инде, ди. Почмак ягына чыга да кызына әйтә:

—Атаң ашың тозсыз булган дип бәйләнә,—ди.

Кызы әнисенә карап-карап торган да:

—Әй, кирәкми, сездән кем кияү сораганы бар соң әле!—дигән имеш.

Җәмиләнең хәтсездән болай рәхәтләнеп көлгәне юк иде инде. Күзләреннән яше атылып чыкты, җинеләеп китте.

Хәдичә ана каш астыннан гына көнләшеп карап торды: бар соң кайгысыз бәндәләр, дип уйлады, анализлар алдырырга кергән булса кирәк, и-и, мин үз теләгем белән анализ дип шушында кермәмме соң, больнис чирлеләрнең төрмәсе бит ул.

—Артисттыр син, Хәдичә?—диде Җәмилә көлеп туйгач.—Ничек шулай килештереп сөйли беләсең?

—Аны болай итим, көлдерим, дип уйлап тормыйм инде, үзеннән-үзе килеп чыга ул. Мин бит китапханәче, күп укыйм. Әлеге мәзәкне дә Нәкый Исәнбәт китабыннан укып оттым.

Хәдичә сәгатенә күз төшерде дә, тиз-тиз генә өстен алыштырды. Кара чалбар, ак блузка аның рәвеше бозыла башлаган гәүдәсен нәфисләндереп җибәрде. Ыспайланып, яшәреп киткәндәй булды.

—Кофта кимә инде, шушылай да бик матурсың,—дип кинәш бирде Җәмилә.

—Әбәү, чәйгә Сәхибулла төшкән, диләрме әле?—диде Хәдичә Җәмиләнен кинәшенә игътибар да итмичә.—Свиданжыга чыгуым. Минем дә чәйгә бер юньсезе төшеп маташа әле монда.

Хәдичә тигез итеп киселгән шома чәчләрен җилфердәтеп, бүлмәдән чыгып китте. Шушындый эсседә кем кофта кия инде, җә, дип гаҗәпләнде Җәмилә. Сәбәбен соңыннан гына белде.

Ул тәрәзә янына килеп басты. Көннәрнен иң озын чагы. Сон булса да тышта якты иде әле. Бөтен сырхаулар да урамда. Җылы якка китәргә әзерләнгән кошлар шикелле төркем-төркем булып оешканнар. Хәдичә дә шунда.

Күз күреме җирдә бер катлы агач йортлар тезелешеп киткән. Өстән аларның күкле-яшелле түбәләре генә күренә. Арырак Пләтән төрмәсе. Унда асфальт юл бормаланып ята. Ул бара-бара сабын заводы яныннан Тукай урамына килеп чыга. Анда инде шәһәр тормышы. Шау-шу, сөрем, ис...

Җәмилә борынын җыерып куйды. Әйтерсен лә борынына сасы ис килеп бәрелде. Анда—ис, монда—чир...

Ләкин Җәмиләнен бу күнелсез нәрсәләр турында уйлыйсы килми иде, караватына менеп ятты да кулына китап алды. Бераздан күзләре үк йомылды.

...Йокы аралаш Җәмилә кемнеңдер сулкылдап елаганын ишетте. Саташам ахры, дип уйлады башта, үзем елыйм ахры. Төшендә ул Ләйсәнне күреп алган иде, ай күрде кызын, кояш алды. И, өзгәләнде Җәмилә... Инде менә чып-чынлап яшь түгә...

Күзләре ачылды. Беренче булып тәрәзә аша кергән ай яктысына игътибар итте. Ул бүлмәнен нәкъ уртасыннан тасма булып сузылган иде. Аргы як дөм караңгы. Шул дөм караңгылыктан ишетелә икән әлеге сулкылдау.

Хәдичә ич бу! Җәмилә бүлмәдәше янына барып басканын сизми дә калды.

—Хәдичә, уян, Хәдичә...—Ул аны саташып елый дип уйлый иде. Тиз генә утны кабызды.

Хәдичә башын күтәрде. Чәче-башы тузган, йөзе чалшайган... Көндезге көләч затның шәүләсе генә.

—Хәдичә, ни булды?—диде Җәмилә эчке бер өзгәләнү белән.

—Берегезне дә күрәсем килми!—дип кычкырды Хәдичә.—Минем хәзер берәүгә дә кирәгем юк!

—Ни сөйлисең син, Хәдичә!

—Мә, күр, алайса!

Хәдичә бер селтәнүдә лифчигы белән халатын умырып ташлады. Җәмилә шул ук мизгелдә артына тайпылып, өстәл кырыена килеп бәрелде. Аның мондый иләмсез гариплеккә беренче мәртәбә тап булуы иде. Хәдичәнең күкрәге тәгәрмәчсез иске арбаны хәтерләтә иде, уң имиенең яралы урыны гына калган. Йә, алла!?

Җәмилә чытырдатып күзләрен йомды.

—Нәрсә, тутый кош, күрәсең килмимени?—дип, кибешкән ирennәрен кыйшайтты Хәдичә.—Бу сиңа анализлар алдыру гына түгел. Кулымнан килсә, мин синең шикелле иркә хатыннарны...

—Хәдичә, минекеннән дә төер таптылар бит... Ике көннән операция...

Хәдичәнең шартлап чыгардай булып киерелгән усал күзләре тоныкланып калды. Ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ләкин мондый сүзләрне шаяртып әйтмиләр... Бу чибәркәйне дә аның язмышы көтә икән ич! Ул кабалана-кабалана халатын киеп куйды. Ләкин ертылган халат күкрәген капларга җитмәде. Карана торгач, алдына кофтасын алып япты.

Җәмилә аның янына килеп утырды. Алар төнне елашып-сөйләшеп уздырдылар.

Ә иртән иртүк Җәмилә профессор кабинеты каршысына килеп баскан иде инде. Аны озак көтәргә туры килде, нииндидер семинарда, диделәр. Ул арада кичәге бөтерчектәй шәфкать туташы әрләп китте. Нигә лабораториягә анализларыгызны илтмәдегез, дип пыр туздыра, хәзер үк кан бирергә барыгыз, ди. Сезнең өчен эшемнән куыласым килми, ди.

Җәмиләдә анализлар кайгысымы соң? Аңа профессор кирәк, йөрәген телгәләгән сорауларына җавап алырга кирәк. Төнге хәл аны чыгырыннан чыгарган иде.

Ниһаять, коридорның аргы очында Кәримов пәйдә булды. Коридорны иңләп килә. Янында дежур табиб. Бер алдына, бер артына төшеп, нидер аңлата. Аклана булыр. Болар озакка инде, дип борчылды Җәмилә. Аннан соң, ул профессорның үзе белән генә, күзгә-күз калып кына сөйләшергә тели. Аның уйларын укыгандай дежур борылып китеп барды.

—Мин сезнең янга килгән идем, Сабир Хөҗҗәтович...

—Күреп торам, чибәркәй, әйдә, узыгыз.

Профессор бер күз сирпеп алуда авыру хатынның кичерешләрен төшенеп алды. Көн саен очраша ул мондый бәхетсезләр белән. Нишлисең, вазифасы шундый. Һәрберсе ярдәм өмет итә, могҗиза көтә. Ә медицинада могҗиза булмый.

—Җә, тыңлыйм...Ы-ы...

Кәримов пациентының исем-фамилиясен хәтереннән чыгарган иде.

—Әмиржанова...

—Әйе-әйе, Әмиржанова... соң...

Җәмилә сүзен башлаганчы тирән итеп көрсенеп куйды.

—Миңа Шарон Моисеевич та, башкалар да операциянең бик җиңел булачак, дип өметләндереп килделәр. Мин үзем дә шулай уйлый идем. Чөнки ул төер мине борчымый, бер җирем дә авыртмый минем...

—Бу бик яхшы, чибәркәй. Димәк...

—Нәрсә, "димәк", Сабир Хөҗҗәтович?

Кәримов капчык шикелле бүселгән іяген баш бармакларына терәп, бермәл сүзсез утырды.

—“Димәк” дигәнем, бик вакытлы дигән сүз, ышаныч зур дигән сүз, Әмиржанова. Ә төер? Төер ул тамырлы. Хикмәт тә шунда. Безгә әнә шул тамырлардан арынырга кирәк.

—Хәдичәнеке кебекме?—Җәмиләнең тавышы өзелеп китте.—Юк, Сабир Хөжжәтович,—диде ул аз-маз тынычланып, үзен кулга алгач, —мин андый операцияне ясатмыйм. Баш тартам!

Кәримов яшьләрчә жинеллек белән урыныннан купты, бүлмә буйлап йөрештереп алды, янә дә килеп йомшак кәнәфиенә сенде һәм:

—Сезнең балагыз бармы? — дип сорады.

—Бар... Кызым.. Ләйсән...

—Сез аны үзегез тәрбияләп үстерергә тиеш, Җәмилә ханым (Кәримов, ниһаять, өстәлдәге кәгазь өеменнән анын шәхеснамәсен эзләп тапкан иде), аңлыйсыздыр, шәт. Аннан сон, шуны да киртләгез, эстетикага караганда яшәү мөһимрәк.

Профессорнын логикасы гадилеге белән үтемле иде. Логика анын гипнозы иде.

Җәмилә дә ана буйсынды, үзенең дорфалыгы өчен хәтта үкенеп тә куйды. Ләкин авыру психологиясе дигән нәрсә дә бар бит әле. Авыру үзенең чире турында, барысын да белергә тырыша. Җәмилә дә әңгәмәне шундый шөбһәле нокта куеп төгәлләргә ният итте. Профессордан туптуры:

—Миндә ракмы?—дип сорады.

Әлеге сорау Җәмиләнең күнелендә күптәннән утыра. Ул аны куарга тырыша, онытырга тели. Ләкин тутык белән бер бу каһәрле сорау һаман череген чыгарып тора иде.

Кәримов бу сорауны көткән иде, аны бар сырхаулар да бирә.

—Сезнең өчен бу сүз юк, Әмиржанова! Аңлыйсызмы, юк!

Профессор бәйдәге эттән дә битәр итеп күзләренең агуы белән карады. Җәмилә утырган урынына сенеп бетә язды.

—Тагын бер сүзем бар,—диде профессор йомшара төшеп,—сезгә Казанда яки якын-тирә районда яшәү мәслихәт булыр иде. Мөмкинлегегез булса, әлбәттә. Без үз пациентларыбызны даими күзәтеп торабыз. Файдасы зур.

Җәмилә операциягә ризалашты.

* * *

Җәмилә тәне корышудан уянып китте. Эче кайнар, тышы кайнар. Гүя учактагы кисәү. Гәүдәсенә орынсаң, күмергә әйләнер кебек. Үзе ниндидер упкында... Ничек чыгарга соң? Их, йөзәсе иде Сөн суларында колач җәеп...

Ул талпынгандай итте. Шунда колагына кайдандыр, бик еракта кеше тавышлары ишетелгәндәй булды.

—Уяна, уяна...

—Ой, нинди молодец...

Мине упкыннан тартып алыгыз, дип әйтәсе килде Җәмиләнең. Ләкин теле корышып каткан, селкетә дә алмый иде.

—Күзләренне ач, Ямилә, күзләренне ач...

Җәмиләнең бу ягымлы сәер тавышны кайчандыр ишеткәне бар иде инде. Тик кайчан? Кем бу?

—Ямилә, молодец, Ямилә...

Караңгылык аксыл томан белән алышынды. Юк, томан түгел, утлы төтен! Элеккечә үк эссе, тәне яна.

—Җәмилә, жанаш, бу мин, Мансур, котлыйм...

Бу тавышны шундук таныды Җәмилә. Мансур ич. Мансур! Ул

азаплана-азаплана күзләрен ачарга тырышып карады. Әмма күз кабаклары кургаш тагып куйгандай бик авыр, бик авыр селкенәләр. Шулай да тырыша торгач, күз алдында нindидер ачыклык пәйдә булды. Аннан соң кеше йөзе. Ул ачылганнан-ачыла төште. Күзләре, иреннәре, чәчләре шәйләнде. Чем кара чәч, калын кара каш. Монголларга тартым кыяфәт. Иягендә, бит очларында мәхәббәт уемы. Искиткеч сөйкемле йөз...

—Лилия, рәхмәт,—диде Җәмилә хәлсез тавыш белән. Ул инде үзенең кайдалыгын да, ни өчен монда ятуын да төшенеп алган иде.

—Котлыйм, операция унышлы үтте,—диде Лилия,—бу хакта әле сөйләшербез.

Мансур хатынының кулларыннан сыйпады, маңгаеннан үбеп алды.

—Су,—дип пышылдады Җәмилә.

—Бераз түзәргә туры килер, җанаш, хәзергә шушылай гына,—дип Мансур марляга уралган бал кашыгын стакандагы суга манчып, хатынының иреннәренә тигезде...

* * *

Җәмилә биш көннән соң аягына басты. Аңа кадәр шактый сызланды. Бигрәк тә төннәрне үткәрү авыр иде. Җәрәхәт урынының тиресе шигрин күн шикелле әле тартыла, әле җыерыла, әле кечерәя. Хәтта шыгыр-шыгыр иткән тавышы да ишетелгән сыман тоела иде. Бер тире төшми, ярага ит үсми дигәннәредер инде, күрәсең.

Ләкин җан авыруы тән авыруына караганда да хәтәррәк икән. Утыз яшь тә тулмас борын гарип-горәбә булып кал инде. Гарип кешеким бит инде ул. Элекке бәхетле тормыш бервакытта да кире кайтмаячак. Янасы, хәвефлесе башланды. Ул яңа тормыш ничек булыр, алда аны тагын нәрсәләр көтә?

Уйлап кына очына чыга торган уйлар түгел болар. Мондый чакларда Җәмилә үз-үзенә бикләнә. Тора-бара җаны да каядыр китеп җуела, калебе боз булып ката. Аны бу томан эченнән ярасының чәнчеп алуы алып чыга. Ул даими рәвештә кабатланып тора, эченә сәгать механизмына көйләнгән пычак тегеп куйганнар диярсең.

Тәпи баскан көнне дә ул авыртыныбрак уянган иде. Тик бераздан нindидер җиңеллек сизде. Бу җиңеллекнең нидән гыйбарәт икәнен башта аңышмыйчарак торды. Баксаң, җәрәхәте тартышудан туктаган икән ләбаса! Куллары үзеннән-үзе шунда үрелде. Тик шундук салынып та төште. Күз алдына Хәдичәнең таланган күкрәге килеп баскан иде.

—Җанаш, нәрсә, башың әйләнеп киттеме әллә?—дип сорады Мансур. Ул хатынының һәр хәрәкәтен, халәтен, күңел кузгалышларын бәгыре аша үткәрә. Шуңа күрә аның авыртуын да үзе кичерә кебек иде.

—Юк, болай гына,—диде Җәмилә. Процедурныйда ул һушыннан язды. Җәмиләнең элек тә каннан коты кача иде. Куркакның күзе күрәш, ди, бинтларын алыштырганда үз канын абайлап алмасынмы.

—Аһ...

Ул шушы сүзне генә әйтеп өлгерде. Күз аллары караңгыланып китте дә, нindидер тирән упкынга очты...

—Врач чакыртыгыз!—дип кычкырды Мансур,—үлә бит...

—Шулай булмаенча,—диде шәфкать туташы тыныч кына,—гадәти ис китү. Мондый хәлләр безнең бүлмәдә еш була. Кем энәдән шүрли, кем каннан. Борчылмагыз бер дә, хәзер уятабыз без аны.

Ул Җәмиләгә нашатыр спирты иснәтте. Тегесе борынын җыерып-җыерып торды да, төчкереп җибәрде. Тагын, тагын, тагын... Аннан соң күзләре ачылды.

—Менә шулай, бик әйбәт, ярагызның җәрәхәте инде бөтәшеп килә, —дип, юмалый-юмалый, шәфкать туташы Җәмиләнең ярасын яңа марля белән каплады, тирә-ягына кләйле тасма беркетте.—Болай булса, киләсе

атнада протезга да заказ бирергә булырдыр, мөгаен. Ә хәзер киенегез... минә шулай... Әлеге хәлгә бөртек тә борчылмагыз, нервыдан гына ул. Тынычрак булырга тырышыгыз. Сезгә хәзер ин кирәге, тынычлык! Онытылырга тырышыгыз.

Онытылырга тырышыгыз, имеш. Һәммәсе дә шуны тукый, Кәримов та, Лилия дә, Мансур да. Акыл өйрәтергә ансат ул. Ә ничек итеп онытылырга? Әллә ул ана каршымы?.. Әллә анын борчылусыз-нисез тыныч кына яшисе килмиме? Килә. Бик килә!

Шулай шул, бал дип әйтеп кенә авыз балланмый. Барысына да вакыт дәва. Ә дәванын вакыты килеп житмәгән иде әле. Хәлбуки, Җәмилә соңгы ике-өч көндә шактый җайланып китте. Ярасы да ябылды.

Кәримов аннан канәгать иде. Кергән саен: "Организмыгыз таза, мин сезнен өчен шатмын",—дип күнелен күтәреп тора. Мансур профессорга бүләк итеп өч кило бал, бер каклаган каз бирде. Каршы килмәде, ул мондый биремнәргә күнеккән иде булса кирәк.

Операциядән сон Җәмиләне бер кешелек палатага күчергәннәр иде. Хәдичә ана карап читләшмәде, гел кергәләп-чыккалап йөрде. Мансурнын киткәнен генә сагалап тора да, ишек шакый. Авызы һаман ерык. Кайчак ялыктыра да үзе. Ләкин анын янында онытылып китәсен. Бүген ни сәбәпледер ир-ат, яратышу турында гәп корды Хәдичә. Дөресрәге, ул сөйләде, Җәмилә тынлап утырды.

—Син мыеклы ир-атларны ошатасынмы?—дип сорады ул Җәмиләдән. Җәмилә башын чайкады.—Минем дә мыеклы адәмнәрне женем сөйми, чөнки үзем мыеклы. Әмериканын Журик дигән каласында мыеклы егетләргә хатын-кызны үбәргә ярамый икән. Дөрес тә закон чыгарганнар, чукынмышлар, әйеме?

Җәмилә ир-ат хакындагы гыйлемен шактый тулыландырды. Әйтик, ирләрнен каны хатын-кызларныкына караганда кызылрак икән. Алар иртәрәк картаялар икән, ләкин жыерчыклары соңрак чыга ди. Егетләр чибәрләрдән битәр мөлаем кызларга сүз кушалар икән. Ир-егетләрне үзенә каратыйм дисән, биек үкчәле туфли ки икән. Чалбарын ботларынны кысып торырлык булсын ди. Чәчләреңне дә жилкәнә таратып сал икән. Ә иреннәр? Алар инде фонарь сыман янып торырга тиешләр. Ир-ат ерактан ук абайлап алсын.

—Әзер лекция ич бу,—дип көлде Җәмилә. "Белем" җәмгыятенә керергә кирәк сина.

—"Белем" җәмгыяте качмас, Җәмиләкәй. Минә син әйт әле, бу сөйләгәннәрдән нинди нәтиҗә чыгарырга мөмкин?

—Минем башым житми мона, Хәдичә... Чынлап...

Хәдичә кулларын бөеренә таянып, Җәмиләгә карап алды да, әйтте: "Ир-ат—бала ул",—дигән Коко Шанель атлы бер мәхәббәт белгече. Шушыннан нәтижәсе дә килеп чыга инде анын, Җәмиләкәй. Бала уенчык ярата. Шуна күрә ир-ат ялтыравыкка мөкиббән. Димәк, безгә ялтырап торырга кирәк.

Хәдичә такылдады-такылдады да Җәмиләгә тыныч йокы теләде.

—Бу лекциядән сон йокларсын монда...

—Авыруым-авыруым, авызым тулы даруым. Дару эчәсе дә бар бит әле, киттем...

Монысы—кичтән. Ә иртән? Иртән хирургия бүлеге Везувий вулканын хәтерләтә иде. Гөж. Хәдичәне бер ир белән тотканнар, имеш. Сәламәтләнеп килүче бер яшь ир. Өлкән шәфкать туташынын бүлмәсенә ачкыч яратып кергәннәр ди. Дежур табиб эләктергән ди.

Җәмилә бу хәбәрне ишеткәч өнсез калды, ни уйларга белмәде. Мөмкин хәл түгел ич бу! Сырхауханәдә. Операциядән сон. Монын өчен азгыннын азгыны булырга кирәк ләбаса! Хәдичә шаян, шук хатын. Анысы хак. Тик... мәртәбәле ир хатыны.. ана... югары мәгълүматлы белгеч...

Бу дәлилләрнен берсе дә әлеге гамәлгә киртә була алмый, билгеле. Моны Җәмилә үзе дә яхшы белә. Барыбер ышанасы килмәде. Алай

дисән, кичтән һаман шул хакта сайрады бит. Бәлкем, ниятен Җәмиләгә читләтеп кенә житкерүе булгандыр?

Икесен дә сырхауханәдән куалар. Боерык инде эленеп тора. Укол кадатырга барганда Җәмилә үз күзләре белән күрде. Әхлакый тотнаксызлыгы өчен, дип язганнар. Димәк, барысы да дөрес.

Кычынган Әстерханга барган ди, и, исәр баш, исәр баш, шулай сантый булырга ярыймы соң инде? Юк, барыберниндидер яшерен япмасы бар бу вакыйганың. Бар! Күңеле сизә. Хәдичә әле китәргә өлгермәгәндер, ничек тә күрешеп, сөйләшергә кирәк.

Җәмилә кыенсынып кына 7 нче палатаның ишеген ачты. Хәдичә жыенып ята иде. Үзе генә. Тыныч күренә, йөзендә үкенү-кайгыру галәмәте сизелми.

—Әйдә, уз,—диде Хәдичә. Шөгыленнән туктамыйча гына комплимент та әйтеп алды:—Бик матур күренәсең, күз тимәсен.

—Рәхмәт...

Җәмилә тик басып тора. Нидер әйтергә кирәк, ә теле кузгалмый, гүя аңкавына ябышып каткан. Хәдичә үзе ярдәмгә килде.

—Җәмиләкәй, бу дөньяда сүз дүрт төрле: бер төрле сүз бар—бел дә сөйләмә; икенче төрлесе—белмә дә, сөйләмә дә; өченчесе—бел дә сөйлә; дүртенче төрлесе—сөйләрсең дә белмәссең. Син шуларның кайсысын сөйләргә дип кердең инде?

Аның түгәрәк күзләре тегәрҗеп шикелле генә калды. Йөзе кырысланды, иреннәре кысылды. Ул җавап көтә иде.

—Үзең шикелле мин дә мәкальдән башлыйм әле. Әңгәмә белән шик бетәр ди...

—Ә синең шиген бармыни?—дип бүлде аны Хәдичә дорфа гына.

—Сөйлиләр бит...

—Дөрес сөйлиләр. Барысы да булды. Үкенмим дә. Йөрәгең басылдымы? Бик хуш. Инде миңа хәерле юл гына телисең калды. Үзем дә саубуллашып чыгармын дип тора идем. Рәхмәт керүеңә.

—Хәдичә, юк, туктале, аңлашыйк әле,—дип, Җәмилә аның беләгенә ябышты.—Без бит бер иш. Минем беләсем килә, Хәдичә...

—Әллә кайчан шулай диләр аны...

Хәдичә учы белән яшьләрен сыпырып алды.

—Минем дә беләсем килде шул, Җәмиләкәй. Ярый ла синең Мансурың бар. Мин бит аерылган хатын. Әйтмәдем генә. Ирем ялтыравык тәтәйләрне хуп күрде. Ике балам бар. Алар әнием җилкәсендә...

—Ничек соң, Хәдичә?..

—Өлгерә алмадык, врач килеп керде. Теге ачык авыз кабалануыннан ишекне бикләргә оныткан.

* * *

Тагын ун көннән Җәмилә үзе дә сырхауханә белән хушлашты. Рәшидәләр эштә иде. Мансур табын әзерләде. Кара-каршы утырып чәй эчтеләр. Җәмилә дә, Мансур да операция турында ләм-мим. Әйтерсең лә моңа кадәрге борчылулар, күз яшьләре күңелсез бер төш кенә булган. Чөнки Лилия аерым-аерым икесен дә боргычлаган иде, бу хакта онытыгыз, чир сөйләп дошманнарыгызны шатландырмагыз, дип кисәткән иде. Профессор Кәримов та шуны куәтләде. "Хатыныгызның хастасы бик житди, әмма ул үзенең чын йөзен өч-дүрт елдан соң гына күрсәтә. Ә хәзергә тормышыгызның кадерен белеп кенә яшәгез",—диде. —"Өч-дүрт ел шактый вакыт, медицина фәне дә бер урында гына тормый. Өметне өзмик".

Мансур каш астыннан гына Җәмиләгә күз төшергәләп ала. Зур үзгәреш сизелми кебек. Шундый ук чибәр, зифа, күкрәк алмалары да бүртеп тора...

Элек алар өч-дүрт көн аерылышып торсалар, сагынышып бетәләр иде. Шушындый гүзәл хатынынны кочмый, назламый ничек түзәсен ди? Тик бүген хәл бөтенләй башка. Гомумән, бу хакта уйларга бик иртә әле. Тән сихәтеннән битәр, психологик яраклашу да зарур ич. Әлеге тетрәнүләрдән соң нинди якынлашу ди ул?

Җәмиләнең дә башында шул уйлар бөтерелә иде. Юк, теләктән түгел. Теләк дигәне жиде кат жир астында. Әлеге дә баягы, психология. Җаны сыкрый. Хатын-кыз хиссияте элекке халәтендә калды микән? Үзгәреш юк микән?

Җәмиләнең әлеге сорауларга шушы минутта ук төгәл җавабын да аласы килә. Хәдичә әйтмешли, Мансуры кул астында гына, әллә кем белән чит булмәгә кереп бикләнәсе түгел. Менә ул хатын-кызларга гына хас нәзакәтлек белән иренең изүен ачты, күкрәк йоннарын сыйпаштырып алды.

Озак та үтми, киемнәр бер-бер артлы идәнгә оча башлады. Мансур барысын да онытты. Ярсулык белән үзе дә сизмәстән Җәмиләнең күкрәк япмасын да йолкып ташлады. Япма белән бергә нindidер йон бүксә диван арасына кереп кысылды. Мансур аның ясалма ими икәнен шунда гына анлады. Үкенде дә соң. Җә, алла!

Җәмиләнең күкрәге үтмәс балта белән юнылган түмәргә ошап калган ләбаса! Сул ягын култык астына кадәр сөяге чыкканчы кырганнар. И, жанаш, ничекләр түздең икән? Пар күгәрченнәр кебек иде бит күкрәк алмаларын. Мансур хатынының тәненң тоюга, нарасый бала шикелле әлеге сихри йомгакларга үрелә иде. Йомры, йомшак, кайнар, исле... тынычланасын, ләззәтләнәсең, исерәсен... Барысына да оеткы шунда салына. Күкрәкләр анын таянычы, терәге, горурлыгы иде. Хәзер, әнә, сынары гына... Анысы да тире бияләйдәй салынып төшкән...

Мансурның тәне сүрелде, каны янә кузәнәкләренә сенде.

—Җәмилә, туктәле, жанаш...,—диде ул ни әйтергә белмичә,—соң әле...

—Ә-ә, шулаймы, ошамыйммы?

Җәмилә Мансурны бар көченә читкә этәрде дә, торып утырды. Бик килбәтсез иде ул бу хәлендә. Хатын-кызның тышкы күрке аяк, бил, түш инде анын. Ә Мансур өчен түш һәрвакыт беренче урында иде.

Мансур бөтен ихтыярын жыеп, хатынын үзенә таба тартты, иреннәрен элпә астында кызыл итләре чатнап торган җәрәхәткә тигезде.

—Кит, мин синең кызгануына калмаган!—дип Җәмилә мендәргә капланды.

* * *

Хаста өлкәннәр өчен дә зур хафа. Ә яшь кешенең авыруы әйтеп бетергесез фажига. Яшь кеше сырхавын санламаска тырыша, күнегелгәнчә яшәргә омтыла. Шуна күрә теләк белән мөмкинлекнең тәнгәл килмәве зиһенен томалый. Анын көтәсе килми, ана бүген үк кирәк!

Җәмилә дә операциядән соң барысы да элекке эзенә төшәр, дип уйлаган иде. Чөнки Бөгелмә табибы Шарон Моисеевичтан башлап, барысы да шуна ышандырып килде. Ләкин чынбарлык белән беренче бәрелешү үк бу ышанычны какшатты. Мансур аны гарипкә чыгарды, аннан йөз чөерде. Бу инде операциядән дә хәтәррәк иде. Җәмиләгә менә шулай рәнжү килде. Башта эченнән генә сызды, соңыннан рәнҗү бөтен барлыгын биләп алды. Һәм мона кадәр булган бар яхшылыкны сызып ташлады, ике арага кара шәүлә ятты. Бу шәүләнең күләгәсе башкаларга да кагылмыйча калмады, билгеле. Хәтта Лилия булып Лилиягә дә шаукымы төште. Тик Лилия ана карап суынмады, һаман ярдәменнән ташламады: дарулар табышты, консультацияләргә йөртте. Шул арада Мансурны юатырга да житешә, әллә ниләр уйлама, депрессия бу, ди, операциядән

соң була торган хәл, ди, Ләйсән янына кайткач, барысы да жайланыр, ди.

Тик Җәмилә Кормашка кайткач та үзгәрмәде. Алай гынамы, беркөнне гомер булмаганча җәнҗал куптарды. Кибеттән кайтып керде дә, сумкасы ние белән алган әйберләрен идәнгә бәрде. Сөт-катык шешәләре челпәрәмә килеп ватылды.

Бу тавышка бүлмәдән Мансур атылып чыкты. "Ни булды, хәлең киттеме әллә?"—дип, Җәмиләнең беленнән тотып алды, булыша, янәсе. Шул арада Җәмилә аның яңагына чалт итеп сугып та җибәрде.

—Бар, элдерт, урамда мәткәң көтеп тора,—дип кычкырды. Мансур исе-акылы китеп стенага килеп сыланды.

—Бал түтән,—дип ярсыды Җәмилә,—сагалап йөри, үлгәнемне көтәсез булыр, козгыннар! Өметләнмәгез, мин сезнең үзегезне кара гүргә кертәм әле...

Җәмилә Мансурның өстенә лаканлап шакшы су орды-орды да залга кереп китте.

Гайшә энеләренә килгән, күрәсең. Балын күтәрешеп кайтуның шушылай өч-дүрт елдан соң да калкып чыгуын белсә, ни әйтер иде икән? Гөнаһсызга гөнаһлы, ә? Тилебәрән орлыгы ашагандан котырына, әй. Әле ярый Ләйсән ишетми.

Мансур бу минутта шыксыз көзге басуда ялгызы утырып калган кура хәлендә иде. Уннан да, сулдан да, арттан да, алдан да әче жил талкый. Бернинди сыенып урын юк. Тирә-якта акылдан яздырырдай котсыз бушлык...

Ул юыну бүлмәсенә керде дә, суны шаулатып ачып, гарьләнүеннән туйганчы елады. Шунда тагын бер ачы хакыйкать бәрде башына: Җәмилә хак ләбаса! Хак! Аның яратуы, чыннан да, кызгануга әверелеп бара түгелме соң?

Алар икесе дә максималист иде, таякның уртасыннан сындырырга күнеккәннәр. Икесе дә үзара мөнәсәбәтләрнең нигезендә мәхәббәт кенә ята дип ялгышалар иде. Гаилә мәшәкатьләренең, тормыш-көнкүреш четреклекләренең бу эгоистик хисне таптап юкка чыгаруын белмиләр иде шул әле. Мөнәсәбәтләрне цементлаштыручы хис мәхәббәттән битәр —ихтирам. Ихтирам хисе бетсә, мәхәббәт чаткылары сүнмәгән очракта да, гаилә черек өй шикелле жимерелеп таркала.

Мансур салкын диванда гаилә тормышының шушы яклары хакында бик озак уйланып ятты. Шөкер, фикерләре чын ирләрнекечә иде, шайтан котыртуына бирелмәде. Әлеге чатаклыклар вакытлы гына, Җәмилә тернәкләнеп бетүгә, алар үзләреннән-үзләре юкка чыгачак. Мәхәббәт тә кайтачак! Һичшиксез! Түзгән тимерне өзгән, ди, түземлектән генә аермасын Ходай. Ул Әмиржановлар дигән кечкенә дәүләтнең башлыгы, һәммәсе өчен дә җаваплы. Ә хәзер аның алдында торган иң зур бурыч—яңа эшкә урнашу, күчену. Дөрес, әле мәктәп белән исәп-хисапны өзмәделәр. Ихтимал, директор аларның фикерләре үзгәрүгә дә өмет тотадыр. Операция уен эш түгел. Әмма Кормаш инде үтелгән этап. Ә монда төпләнеп калсалар, аларны да күпләп мал-туар асраучы укытучылар язмышы көтә.

—Чаллыга барып кайтырга кирәк бит инде, Җәмилә,—диде Мансур,—икенче көнне—берочтан Түбән Камага сугылып чыгарбыз.

Җәмилә дәшмәде. Ишетмәде ахры бу, дип Мансур янә тәкъдимен кабатлады.

—Әлегә саңгырауланмадым, кат-кат әйтмәсәң дә була,—диде Җәмилә төксе генә.

—Гафу, алайса иртәгәгә килештек, мин шалтыратып куям. Ләйсәнне юл уңаеннан сеңелләргә кертеп чыгарбыз. Бәлкем, үзебез дә бер-икене кунарбыз. Бераз җилләнеп алу зыян итмәс.

Җәмиләнең борын тишекләре чабыштан килгән атныкы шикелле киерелде. Ләкин начар сүз әйтүдән үзен тыеп кала алды. Алай да ысләды:

—Минем бик кунакларга йөрисем килеп тормый әле монда.

—Нинди кунак ди ул, эш турында сүз бара, эш! Инде бер ел шул хакта хыялланабыз ләбаса!

—Алай бик күченәсен килсә, үзен барып белеш.

—Аңламыйм, нигә кирегә сукалый торгансындыр...

—Әйттем бит инде, үзең барып белеш дип, тагын ни кирәк?

Шулай итеп, Мансур Чаллыга үзе генә чыгып китте. Машина йөртү, руль артында утыру аңа һәрвакыт унай тәэсир итә. Кәефе күтәрелә, күңеленә моң, җыр килә.

Бөгелмә—Чаллы юлы үзе мавыктыргыч сәяхәт ул. Шул ике йөз чакырымлы арада гуя бөтен бер географик кинлекне колачлыйсың.

Кормаштан башлап юлаучыны таулар теземе озата. Бер җепкә тезелешсәләр дә, алар ничектер оеш-оеш укмашып утыралар. Кайберләре күп манаралы мәчеткә охшап тора, бәгъзеләре әкияти корылмаларны хәтерләтә. Урыны-урыны белән бөркет ояларлык кыялар зәңгәр күккә тоташа. Таш араларыннан чишмәләр тибә. Ә тау итәкләрендә ямь-яшел болынлыклар, көтүлекләр... Искиткеч матур манзара! Гасырлар буе кайнар куеннарында нефть дигән хәзинәне саклаган мәгърур таулар. Шагыйрь бик дөрес әйткән, тау кебек тау гына гүзәл була ала.

Һәр төбәктә тауларның үз исеме, үз риваяте. Корбаштагы иярле Каран тавын, мәсәлән, Алып батыр чабаталарын каккан урында калкып чыккан, диләр. Чишмә тавының тарихы мәхәббәт белән бәйле. Имештер, зур дәрәҗәле бер Тайсуган морзасы кызын карт кешегә ярәшкән. Чибәр кыз тау башына менеп, егетен сагынып елый икән. Яшьләре таш-кыяга сеңеп барган, ди. Шуңардан чишмә саркыган.

Әлмәт янындагы Урсал тауның да риваяте тоташ могҗиза. Җирле халык аларны үз тарихына яраклаштырган. Чынында алар барысы да Урал дигән мәшһүр чал тауның тармакланган тамырлары гына.

Зәйгә җитәрәк тау теземе офык эченә кереп югала. Тик бу югалуны сизмисең, чөнки игътибарны ясалма дингез җәлеп итә. Көмеш сулы дәрья! Монда зур электр станциясе төзелде.

Ә алда—Чулман! Купшы келәмдәге чуалган тасма шикелле бормаланып ята. Ләкин ул Чаллыга яшеллек түгел, ком ташый. Шәһәрнең бердәнбер яшел урыны татар зираты. Монда яшеллек мәңгелек йортка күчкән җаннарның тынычлыгын саклый.

Чаллы Гоголь әсәрләрендә сурәтләнгән провинция шәһәрчегенә ошаган. Замана, ихтимал, урам исемнәрендә генә чагыладыр. Гадәттәгечә, бу калада да иң зур урам Ленин исемен йөртә икән. Хөкүмәт учреждениеләре дә шунда урнашкан. Ләкин урам пычрак, шыксыз. Юл читендәге сазда чучка балалары ауный, шунда гына кош-корт чүпләнә. Һәр узгынчыны этләр өреп озата. Йортларның да хәтсезе сәүдәгәрләрдән калган, аскы өлеше таштан корылган, өсте — агач. Шәһәр халык мәгариф бүлеге дә шундый йортларның берсендә урнашкан иде. Сайгаклары шыгыр-шыгыр килә. Фанер белән бүленгән вак кына бүлмәләр. Мөдирнекен генә кабинет дип әйтерлек.

—Ай-һай, малай, көттереп кенә йөрисен, ә?—дип каршы алды аны Харисов.—Әллә кире уйладымы икән дип, шикләнеп тора идем инде.

—Булды инде хәлләр, Азат—диде Мансур.—Казанга барып хатынга операция ясатып кайттык бит әле...

—Шулай укмыни? Бик җитдиме?

Азатның сипкелле йөзе монсуланып калды, чын кайгыру белән Мансурга карап торды.

—Алай бик зурдан кубып борчылыр нәрсә юк,—дип киеренкелекне йомшартырга тырышты Мансур.

—Алайса ярый. Хатын чирләү бик хәтәр ул.

Мөдирнең йөзе дә гадәти кыяфәтенә кайтты.

—Инде төп мәсьәләгә күчик,—диде ул сәгатенә күз төшереп,—сәгать икегә горком бюросына чакыралар. Аңа кадәр мәктәпне карап кайтыйк.

Ун-унбиш көннән кабул да итеп алырсың, ныклап ремонтка тотынырга кирәк. Ишеткәнсеңдер, бездә зур автомобиль заводы корылырга тиеш. Союз күләмендәге удар төзелеш булачак. Үзәк Комитетның карары бар диләр.

Мәктәп зур иде. Укытучылары гына йөзгә якын. Мансур бераз шөлләп тә куйды. Хурга калмасмы, булдыра алырмы? Хәер, бүредән курыксаң, урманга барма, ди. Әнә, завод-фабрикалар, төзелешләр, районнар, шәһәрләр, дәүләт учреждениеләре белән идарә итәләр. Шундый ук ике куллы, ике аяклы кешеләр. Тырышырга, өйрәнергә туры киләчәк, билгеле. Иң мөһиме, үз команданны туплау, коллективта иҗади атмосфера тудыру һәм дә тәвәккәллек! Курыкмыйча-шикләнмичә төрле экспериментлар үткәрү. Мәктәпне республика, ил масштабына чыгару. Моның өчен тормыштан бер-ике генә адым булса да алдан бару зарур.

Мансур, Харисов белән саубуллашып, юлга чыкты. Куллары рульдә, аяклары үзеннән-үзләре әле тормоз, әле газ педаленә баса. Ә башында мең төрле уй. Мең төрле булса да, аларның барысы да яна вазифасы белән бәйле. Ул, әлбәттә, диссертациясенә өр-яңадан тотыначак. Мондый зур, мондый абруйлы мәктәпнең директоры галим-практик булырга тиеш. Сухомлинский кебек. Ул Украинаның Кировоград өлкәсендәге гади бер авыл мәктәбен җитәкли. Үзе Педагогия Фәннәре академиясенең әгъза-корреспонденты. Ихтимал, тәҗрибә өйрәнү өчен анда барып кайтырга да туры килмәгәе әле.

Кормашка Мансур төнлә генә кайтып житте. Өйдәгеләр инде жиденче төшләрен күрәдер. Шуңа күрә ашыкмады. Анын уй-хыялларына бирелеп, ялгызы гына хозурланасы килә. Гаражда башланган яртысы бар иде. Тәмен белеп кенә ярты стакан хәмер эчте. Хыяллары күктәге каурый болытлар шикелле тагын да кабарыбрак китте. Әйе, зур өметләр баглыйлар аңа. Хәзер барысы да үзеннән тора. Бик җайлап, ат белән чыпчык кумыйча гына эшне көйләп җибәрергә кирәк булачак. Фатирына кадәр әзер бит, ә? Мәктәпнең ишек алдында гына. Клуб чаклы зур агач йорт. Мондагы шикелле таш капчык түгел инде. Җылысы, газы, суы – барысы да кергән. Җәмиләгә авырга туры килмәячәк. Ләйсән бакчага йөрер. Тәрбиянең системалы, бөтен булуы кулай.

Матбугатка язышуның да файдасы тиде, әй. Азат та: "Публикацияләреннең файдасы зур булды",–диде. Идеология секретаре, үзе дә педагог кеше, укып-танышып бара икән. Ул "Социалистик Татарстан" газетасында тәрбия темасына "Жиде кат үлчә..." дигән махсус рубрика алып бара. Ошаталар. Китап нәшрияты шул язмаларны җыеп, китап итеп чыгарырга тәкъдим итә. Озакка сузмый гына төгәллисе бар. Эш кешене кеше итәр, ди. Аллага шөкер, эшкә кулы ята анын.

Аның уйларын бүлеп, ишек алдында ике нур көлтәсе сузылды. Ул коймаларны, стеналарны капшап узды да, гараж ягына авышты. Бу Мансурның күршесе. Төнге сменадан кайтышы, күрәсең. Эшкә үз машинасында йөри. Сүз боткасы. Мансурның исә тел чарлыйсы килеп тормый. Шуңа күрә, күреп алганчы дип, өйгә сызу ягын карады.

Мәче шикелле сак кына атлап, икенче катка күтәрелде, шундый ук саклык белән ачкычын йозак оясына кертте. Келт иткән тавыш та чыгармый ишекне ачты. Тик бу саклануларның кирәге булмаган икән. Ишек катында хәрбиләрчә үрә басып, аны Җәмилә каршы алды. Мансурның йөрәге сызылып китте, тагын тавыш чыгара икән инде, дип сыкранды. Әмма бу уе шундук бетте. Чөнки шатлыгы күпкә өстен иде.

–Котлый аласыз, Җәмилә Нурулловна, каршыгызда Чаллыдагы Вахитов исемендәге урта мәктәпнең гыйззәтле вә мөхтәрәм директоры Мансур әфәнде Әмиржанов басып тора,–дип май кояшыдай балкыды. –Нәчәльник хатыны буларак, сезнең дәресләрегез расписаниенең ин очында булыр.

–Очып китмәсләрме соң, алай бик оста булгач?

–Тышаулап куярбыз без аларны, җанаш, очмаслар.

Җәмиләнең инде хәтсездән "жанаш" дигән сүзне ишеткәне юк иде, йөрәге талпынып алды. Шулай да Мансурның кочагына керергә ашыкмады.

Киңгә—киң дөнья, тарга—тар дөнья. Мансурның күнеле бөтен дөньяны кочагына сыйдырырлык иде. Көлде, шаярды. Җәмилә аны ишек янагына сөялгән хәлдә читтән генә күзәтеп торды.

—Чаллы каласында бәхетебез озын гомерле булсын, жанаш, әйдә, шул хөрмәткә шушы шәрабны аз гына тотып куейык әле,—дип Мансур хатынына касә сузды.

—Рәхмәт, мин эчмәмдер, мөгаен,—диде Җәмилә сүрән генә.

—"Дер"не салам белән кыйнаганнар анда,—дип, Мансур аңа көчләп диярдәй касәне тоттырды.

—Кәҗәләнә торган көн түгел бит инде, жанаш...

—Юк, ник кәҗәләнім ди? Мин синең шикелле абруйлы, игътибарлы ирем булганга бик шат. Бүген аеруча шат. Шуның өчен тын белән суырып алырдай булып сине көтеп тордым. Казан өчен дисәң, мәслән, тостына ике куллап кушылыр идем...

Казан! Казанның авызы тар шул аның. Казан мәктәпләренә борын тыкмалымыни? Бөтен шәһәренә ике-өч татар мәктәбе калды. Хәтта сулар кирегә агып, нииндидер могҗиза белән урнашкан очракта да укытучыга фатир алу көфер затның оҗмахка керүе белән бер. Җәмиләгә боларның барысы да билгеле ләбаса! Казан күктәге торна. Чаллы, әнә, бәхет кошы сыман үзе куенга очып керергә тора.

Кәефе китте Мансурның, күнеле сынды.

—Мин телемне салындырып эш артыннан йөрим, шунда да тәгәрмәчкә таяк тыкмыйча булдыра алмадың,—диде үпкәләп.

—Башта менә бу хатны укып чык әле, Мансур,—дип, Җәмилә аңа ачык конверт тоттырды.

"Социалистик Татарстан" газетасының фирма мөһере сугылган конверт иде бу.

Хатны Мансур ике-өч тапкыр укып чыкты. Аны редакциянең югары уку йортлары һәм мәктәпләр бүлеге мөдире Хәмзә Зариф язган.

*"Мансур!*

*Мине Мәскәүгә югары партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Урыным бушый. Әлбәттә, дәгъвачылар күп. Әмма ләкин эш мәнфәгатьләреннән чыгып караганда, синнән дә кулайрак кандидатура күрмим. Фикеремне хуҗага да җиткердем. Ул ачык кына бернәрсә дә әйтмәде. Үзең килеп сөйләшеп кара. Бу форсатны кулдан ычкындырмыйсы иде.*

*Тәкъдимемне кабул итсәң, ашык!*

*Сәлам белән Хәмзә. 1/VII-1970 ел".*

Мансур касәгә шәраб агызды да, аны капылт эчеп җибәрде.

—Сиңа иртәгә Казанга чыгып китәргә кирәк,—диде Җәмилә.

Мансур озак кына дәшмичә утырды. Аннан соң, сүзләрен теш арасыннан гына сыгып әйтте: "Мин укытучы, Җәмилә, үз белгечлегем буенча эшләргә телим. Бу—бер. Икенчедән, соң инде, мин сүз биреп кайттым. Сүзең үлгәнче үзең үл, ди, мин инде башкача булдыра алмыйм".

—Ихтыярың,—диде Җәмилә,—ләкин шуны бел, мин Чаллыга бармыйм. Ләйсән белән без Казанга күченәбез. Башка эш таба алмасам, урам себерермен. Мин алай синең кебек морзалар нәселеннән түгел. Нәселебездә кулаклар да, муллалар да юк. Карьераңны минем сәламәтлегемнән өстенрәк күрәсең икән, анысы инде синең эш.

Бу ультиматум инде. Суксаң авырттыр, әйтсәң ишеттер, диләр. Гадәттә, ир-хатын арасындагы "җә-җә"ләр аерылышу белән тәмамлана.

Аерылышу! Нинди мәгънәсез сүз. Аерылу канатың каерылу дигән сүз ич. Мансур үзен Ләйсәнсез, Җәмиләсез күз алдына китереп карады. Юк, бу мөмкин түгел! Ләкин ул хатын кубызына биеп кенә дә яши алмый. Аның үз план-ниятләре, хыяллары бар. Менә кадәр Җәмилә

аларны тулысынча хуплый иде. Хәзер, әнә, ультиматум куя. Күр инде, ә? Тәки Ләйсәнне алып Казанга китәр иде микән? Ул аны белеп бетермәгән икән әле. Юк, белеп бетермәгән. Хәер, хатын кеше мич башыннан тәгәрәп төшкәнче дә житмеш төрле уй уйлый ди бит ул.

Мансур гаражга чыгып китте. Машина аның юанычы да, куанычы да. Аз гына буш вакыты чыктымы, шуның янында кайнаша. Машинаны икенче хатын дип бик дөрес әйткәннәр. Борчуларың онытыла, тынычланып китәсең. Ул үзе дә корыч аргамагын бик кадерли. Сөяркә кебек тота. Эче чиста, тышы чиста, тузан да кундырмый. Мансур, гомумән, ыспайлыкны ярата. Чүп түгәргә чыкканда да галстуктан булыр.

—Чалбар-пинжәкләрне үтүкләп кенә туздырасың,—дип үрти аны Жәмилә.

Чалбар-пинжәк кенәме, гаилә тузарга тора әле монда.

Мансур радиоалгычны кабызды да, машина кәнәфиенә янтаебрак ятты...

Уянып киткәндә Казан сөйли иде инде. Нindidер таныш тавыш. Колаклары шәмдәй торды. Сафа ич бу! Әйе, ул! Кара, кем булган? Институтта укыганда кәтәнә генә бер күчән баш иде. Өченче каттан бау төшереп, бүлмәсенә егетләр үрмәләткән өчен институттан куылып торган бер юмарт Уфа кызына ияреп киткән иде. Кызның әти-әнисе алышбиреш белән шөгыльләнә икән. Егетне дә укыганда ук баштанаяк киендерделәр. Сафаны "байлыкка сатылдың", дип күзен дә ачырмыйлар иде. Түрә, имеш. Казанга күченгәннәр, күрәсең.

"Мин сезне, хөрмәтле башкорт дуслар, борынгы татар жиренә, мәшһүр Казан каласына аяк басуыгыз белән тәбриклим",—дип бик зурдан кубып сөйләшә.

Мансур тәмам уянды, күзләрен уа-уа торып ук утырды. Кара инде, шул кәтәнә дә Казан исеменнән сөйләп маташа бит, әй. Башка бер дә адәм рәтле кеше калмады микәнни соң инде бу башкалада? Хәер, кем әле ул башкаларны шулай кимсетергә? Бака лайлы жир карый, ялкау жайлы жир карый, юньле жайсыз жирне үзенә жайлый, ди. Сафа жайлаган. "Бишле" аңа. Ә ул вак-төяккә чумып, авызына кергәнен дә йота алмады...

Шыгырдап гараж ишеге ачылды. Жәмилә икән. Ни гажәп, йөзе ачык. Мансур ни уйларга да белмәде. Ялыккан иде инде ул хатынынын каш жыерып йөрүләреннән.

—Теремок, теремок, мине куна керт әле,—диде Жәмилә уенчак тавыш белән. Мансурның бит жепселләре тартышып куйды. Һаман хатынына ышанып бетми иде, бер-бер хикмәте бардыр бу үзгәрешнен, төнлә белән генә ультиматум теле белән сөйләшкән иде бит, дип икеләнде. Алай да машинаның ишеген ачты.

Жәмилә Мансурны кочаклап алды да колагына: "Гафу ит, жанаш, мин сине бик яратам",—диде.

Мансур мондый борылышны көтмәгән иде.

—Чынлапмы?

—Чынлап.

Куллар шушы сүзләрне генә көткәндәй киемнәрне сыпырып төшерде. Иреннәр ачылды, телләр телгә беректе. Уртак шатлык—икеләтә шатлык, дөньялары онытылды.

—Эһ.. эһ...

Машина ишегенең тимер тоткалары тәннәрен сытып керде, аралыкка башлары салынып төште. Өстәвенә, аяк сузарга кысан иде. Әмма ут телләре ялмап алса да, сизәр хәлдә түгел иде алар. Бу аларның ожмахы иде.

Ярсулы яратышуның беренче дулкыныннан соң, шактый вакыт сүзсез генә яттылар.

Бермәл Жәмилә тиктомалдан көләргә тотынды. Көлә дә көлә, көлә дә көлә. Ә Мансурга шатлык. Чөнки куанычтан көлә Жәмилә. Күптәннән мондый бәхетле авазны ишеткәне юк иде аның.

Бу көлү жил кебек Җәмиләнең бөтен шик-шөбһәләрен очыртып алып китте. "Барысы да элеккечә, элеккечә",—дип куанып типте йөрәге. Күп тә үтми, көлү капыл гына елауга әйләнде. Көлү жылауның кардәше инде ул, нишлисең, шатлык жырлата да, елата да.

—Синең хатының жүләр, пәп итәргә кирәк үзен, — диде Җәмилә назланып.

—Иренә чыбыркы житми...

Җәмилә Мансурның авызына капланып, сүзләрен йотты..

Машина янә дер селкенде. Гүя зөфаф киче, яратышып туя алмадылар. Ак жәймәле көннәре! Гаилә корабын тәки давыллы диңгездән исән-имин алып чыктылар бит. Ачуланышулары да тирәнгә киткән иде шул. Гади ачуланышу су өстен жыерчыклап үткән шаян жил кебек кенә ул. Үтә дә китә. Рәнжеш—башка. Рәнжеш төптән чыга, болганып чыга. Ялгыш адымнар да шуның шаукымында ясала.

—Чаллы турында сораштырыр идең,—диде Мансур.

—Чаллы кайгысымы соң әле...

—Ә Казан? Әллә тәвәккәллибезме?

—Миңа син генә кирәк, Мансур!

Җәмилә жил жилфердәткән ефәк шәл шикелле янә иренә уралды.

* * *

И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан! Казан милләтнең асыл затларын, зыялыларын һәрвакыт үзенә тартып торган. Казан — татарның Мәккәсе. Тукайча әйтсәк:

"Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур..."

Әмма шуның белән бергә, Казан кырыс, тәкәббер һәм шәфкатьсез кала. Мәскәү шикелле үк ул да күз яшьләренә ышанмый. Иң элек син үзеңнең аңа лаеклы кеше икәнлегеңне дәлилләргә тиешсең. Шуңа кадәр ул сине мәрхәмәтсез рәвештә сыный: утка да сала, суга да агыза, упкыннарга ташлый, давылларга чөя... Әкияттәге сыман. Шул киртәләрне исән-имин үткән очракта гына ул сине кабул итәчәк.

Казанда тупланган барлык авыл кешеләренең дә башыннан үткән хәлләр бу. Авыл баласы тырыш, максатчан бит ул. Шуңа күрәдер, мөгаен, галимнәр, язучылар, мәдәният әһелләре, артистлар арасында авылда туып үскән кешеләр күпчелекне тәшкил итә. Иң кара эштә дә авыл балалары...

Баш мөхәррир Мансурны көттереп кенә кабул итте. Кабинеты зур, якты. Иң түрдә фил бастырып куйсаң да сыгылмаслык бинаһая олы өстәл. Шул өстәл артында патша мөнбәрендәге кебек киң жилкәле, эре гәүдәле, шома йөзенә беленер-беленмәс кенә ясмык шадралар сибелгән мәһабәт кеше утыра.

Ишек катыннан стенага кадәр затлы келәм сузылган. Мансур бераз шушы араны ничек үтәргә белмичә аптырабрак торды. Ахыры келәмне читләтеп, секретарь ханым күрсәткән урындыкка чүмәште.

—Шушы инде ул Мансур дигән авторыбыз, Шаһбаз Хәйруллович, бик актив эшли, каләме бар,—дип тәкъдим итте аны кемдер. Тавыш ишетелгәч кенә абайлады, зур өстәлгә шундый ук нык, әмма күләме ягыннан күпкә калыш тагын бер өстәл терәтеп куелган икән. Як-якта ике кеше утыра. Бу сүзләрне шуларның берсе—жаваплы сәркәтип әйткән икән. Ул аның белән очрашкан иде инде. Бик игътибарлы кеше. "Артык сүз сөйләмә, бәхәскә кермә, ни әйтсә, шуңа риза бул,—дип кисәткән иде ул аны. Эшли башлагач, барысы да үз урынына утырыр".

—Мәктәптән кыякларга ниятләгәнсең икән, энем, редакцияне дезертирлар жыеп ята торган урын дип белдеңме әллә?—диде Харрасов жаваплы сәркәтипнең сүзләрен игътибарга да алмыйча.

Мансур борчак кузагы шикелле бөрешеп төште. Бу минутта ул күзгә кергән чүп халәтендә иде. Дөресен сөйләсәң дә, Харрасов аны барыбер аңламаячак, тел әрәм итүнең фәтвасы юктыр, мөгаен...

—Нигә дәшмисең, энем, туры сүз күңеленә тидемени?—дип иренен кыйшайтты мөхәррир.—Без барыбыз да качаклар. Шул исәптән мин үзем дә. Синең кебек укытучы идем. Шәйгәрдәнов колхоз рәисе иде. Ташлап качты. Тимербаев обкомнан урап кайтты. Качаклар без, качаклар.

—Мансурның шәхеснамәсе, Шаһбаз Хәйруллович, күз йөртеп чыга аласыз,—диде Шәйгәрдәнов. Ул һаман үзенекен сөрә. Әйтерсең лә, мөхәррирнең сүзләре аңа кагылмый.

—Нәрсәгә миңа аның кәгазьләре? Кәгазь сезнең эше бюрократларга кирәк ул...

—Татарча яхшы беләсеңме?—дип сорасы итте нигәдер Тимербаев. Бу мөхәррирне "чын юлга" тартып кертүнең бер ысулы иде булса кирәк.

Ә Харрасов чыгымчы алашадай барыбер үз ягын каера.

—Энем, кайда яшәячәксең, пропискага ничек керергә уйлыйсың?

—Ул бу мәсьәләләрне хәл иткәндер инде, Шаһбаз Хәйруллович,—дип Мансур өчен Шәйгәрдәнов җавап бирде.

—Беләм мин аларның ничек хәл иткәнен. Эшкә генә кабул ит, фатир сорап бугазыңнан алачак. Гарык инде мин андыйлардан, хәерче кебек һаман мин генә соранып йөримен.

Шәйгәрданов та, Тимербаев та мөхәрриргә теләктәшлек белдереп, башларын кагып куйдылар. Әмма аларның икесе дә Мансур тегерменәнә су коя иде.

—Егет үзебезнеке, үзебез үстердек, әллә тәвәккәллибезме, Шаһбаз Хәйруллович?—дип үз тәкъдимен кертте Тимербаев.

—Фатир дәгъва итмим дип гарантия хаты язсын әле иң әүвәле, аннан карарбыз,—дип Харрасов телефонга үрелде. Бу сүзнең тәмамлануын аңлата иде.

Казан менә шулай тоташ билгесезлек белән каршы алды Мансурларны. Бернәрсә дә тәгаен гына ачык түгел, эш тә, яшәү урыны да, башкасы да. Элекке җепләр инде өзелгән, яңалары әле үрелмәгән. Харрасовның ярым-йорты сүзләренә ышанырга мөмкинме-юкмы? Шайтан белсен. Җәмилә әйтмешли, урам себерергә калмагае әле. Бик авырга туры килсә, машинаны да сатып җибәрергә туры килер, бәлки?

Җан биргәнгә юнь бирә, ди. Йөри торгач, Борисково бистәсендә үз йортларында яшәүче авылдашлары ике-өч айга сыендырырга ризалашты. Иң зур шатлыклары менә шушы иде.

Хуҗаларның бакчасы зур. Алма, чия, кура җиләге, виктория күп. Яшелчә мулдан. Җәмилә шуларны җыеша. Мансур машинасы белән хуҗа хатынны базарга илтә, кичен алып кайта. Бик тату яшиләр. Кичен һәр көнне өстәлдә—коньяк.

"Бу коньякның әҗерен ничек кайтарып бетерербез икән",—дип борчыла башлады Җәмилә.

—Дефицит шәраб бит әле,—диде Мансур,—ничек юнәлтәләрдер?

Озакламый "дефицит"ның сере ачылды. Баксаң, заводы сарайларында икән. Шикәр комыннан бал коялар да, көмешкә кудыралар. Аннан соң "первач"ны әллә нинди үләннәр, эссенцияләр, соклар кушып, "коньяк" хәленә житкерәләр. Тәме дә, куәте дә шул затлы эчемлекне хәтерләтә. Итәк астыннан гына саткалыйлар да, ахры.

Эшсез, йорт-жирсез калган алдынгы педагог әнә шулай сыйланып кына ятты. Маршруты көйләнгән: Борисково—колхоз базары—редакция. Редакция—колхоз базары—Борисково.

Харрасовны башта чит илдә, диделәр. Инде кайткан. Журналистлар союзы пленумында сөйләү өчен доклад яза, имеш. Беркем белән аралашмый, беркемне кабул итми. Тимербаев та, Шәйгәрданов та җилкәләрен генә җыералар. Без әйтәсен әйттек, калганын мөхәррир хәл кыла, диделәр. Әйе, аның язмышы хәзер Харрасов кулында.

Пленумга керү ирекле иде. Мансур да катнашты. Казаннықылардан тыш, район газеталарының редакторлары да чакырылган. Харрасов оста оратор икән. Доклады да эчтәлекле булды.

Тәнәфес вакытында Мансур ничектер адашып йөрде. Ялгышып түрәләр катына да кереп киткән икән. Шунда Харрасов белән чак-чак чәкешмәделәр.

—Гафу итегез,—дип Мансур артына чигенде.

—Туктале, тукта, энем, син Әмиржанов түгелме соң?

—Әйе, мин бу, Шаһбаз Хәйруллович! Пленумга килгән идем, ишекләрне бутаганмын ахырысы...

Харрасов каш астыннан гына ана текәлеп карап алды.

—Доклад ошадымы соң? Читтән, свежий күз белән караганда ничек кабул ителә? Укытучы кеше үзе дә докладларны күп сөйли бит ул.

—Сезнен колач бөтенләй башка, Шаһбаз Хәйруллович. Докладыгыз шәхсән минем өчен бик файдалы булды. Кызыксынып тыңладым, аеруча ошаган фикерләрегезне куен дәфтәренә дә теркәп куйдым.

—Шулай дисең инде, энем, ә? Рәхмәт яхшы сүзенә...

Харрасов гади генә, беренче карашка вак-төяк кенә булып күренгән нәрсәләрдән дә зур сәясәт ясый белә иде.

Редакциягә яна кеше кабул итү аның өчен зур бәйрәм. Чын тамашага әйләндерә ул аны. Анда редакциянең бөтен халкы җыела. Иң элек җаваплы сәркәтип озаклап, тәфсилләп шәхеснамәне укып чыга. Аннан соң тәкъдим ителүче кандидат биографиясен сөйли, сорауларга җавап бирә.

Харрасов бу этапта бернәрсәгә дә кысылмый, тыңлап кына утыра. Аның вазифасы—нәтиҗә ясау. Менә шунда ишетәсең инде ишетмәгәненне.

—Менә тагын бер хыянәтче безгә эшкә керергә өметләнеп йөри,—дип башлады ул сүзен Мансурның кандидатурасын тикшергәндә,—дәүләтебез күпме акча түккән аны кеше итү өчен? Авылда болай да укытучы кадрлар җитешми, ә ул күзен ертып, Казанда урнашмакчы. Ялкаулар, булдыксызлар башкалада синнән башка да буа буарлык, энем. Бар кайт, төп эшең белән шөгыльлән. Без газетаны синнән башка да чыгарырга тырышырбыз...

Мансур мондый мөгаләмәгә күнекмәгән. Шуна күрә бу нотыкны да чынга алды. Тәҗрибәле психолог буларак, Харрасов исә аның халәтен шундук тоеп алды.

—Эчеңдә ни кайнаганын белеп торам, энем, бу сина мактап түгел. Журналист партизан кебек ул, бар нәрсәгә дә түзәргә тиеш. Бездә эшләсән, горурлыгыңны, мин-минлегенне онытырга туры килер. Сине җиде сандалга салып, җиде чүкеч белән чүкиечәкбез әле. Соңыннан үзең үк рәхмәт әйтерсен. Менә монда әллә кем булып кукраеп утыручы абзаларыбның һәммәсе дә шушы юлны үтте, энем.

Мансур "сират күпер"ен исән-сау үтеп, ниһаять, 1970 елның 1 сентябрендә эшкә чыкты. Кояшлы көн иде. Җылы. Ханым вә туташлар тез башында гына эленеп торучы кыска итәктән. Шәһәрнекеләр шулай бит ул, тән күрсәтү өчен җай гына эзлиләр.

Алтынсу төскә кергән паркларда көтү-көтү кала каргалары каркылдаша. Һава саф, чиста. Күк йөзе, әйтерсең, юып чыгарылган өй, ничектер зураеп, киңәеп киткән сыман.

Матур, хозур көн. Шулай да Беренче сентябрьнең асыл бизәге—ак алъяпкычлы, ак якалы балалар. Урамнар, диварлар мәктәпкә ашыгучы кызлар һәм малайларның шат авазы белән гөр килеп тора. Аларны күргәч, Мансурның йөрәге кысылып куйды. Бу укытучылар өчен дә көтеп алынган бәйрәм ич. Эшеннән ничек кенә зарланмасын, уку елы башлануны укытучы туен житкерә алмаган кәләш кебек олы бер ашкыну белән көтеп ала.

Кормаш мәктәбендә дә "Беренче кыңгырау" бәйрәме бик күңелле уза иде. Бөтен вакълыкларына кадәр уйлап, җиренә җиткереп үткәрәләр иде. Кунаклар, ата-аналар күп килә иде. Хәзер болар барысы да төштә

күргән кебек кенә. Ихтимал, бу инде аның мәктәп белән гомерлеккә хушлашуыдыр. Тормыш сукмагы көтмәгәндә бөтенләй яна юнәлештән китеп барды бит. Теге дин әһеле әйтмешли, күрәчәккә чара юк икән шул. Бәндәнең тәдбире алланың тәкъдиреннән узмый.

Көн азагында аны Харрасов чакыртып алды. Бүгенге образы бөтенләй башка иде. Йомшак, итагатьле.

—Сиңа, Әмиржанов, бер саллы язма белән үзеңне танытырга кирәк, —диде улының язмышын кайгыртучы ата кешедәй.—"Социалистик Татарстан"га талантлы, туры сүзле, оста каләм иясе килгәнен белсеннәр. Газета кадрларны үзе үстерә. Кичә генә штаттан тыш хәбәрче идең, бүген инде профессиональ журналист! Яңгырый бит, ә?

—Рәхмәт, Шаһбаз Хәйруллович,—диде Мансур,—ниятләрем зурдан, бу турыда Кыям Тимербаевич белән дә киңәшләштек.

Харрасов йөзен чытты.

—Формалистлар алар синең Тимербаевларың. Беркемгә кирәкмәгән баш мәкаләләр язып каешланып беткәннәр. Укучы җанлы, эчкерсез сүзгә сусаган. Син әле ул дежур баш мәкаләләр, гонорарлар белән бозылмаган. Тормышны да яхшы беләсең. Газетага свежий темалар алып керерсең, дигән өметем зур. Әлегә бер тәкъдим...

Харрасов, менә мин сине ничек югары бәялим дигәндәй, аңа карап алды да, дәвам итте:

—"Совет мәктәбе" журналына безнең газетада инде күптәннән күзәтү чыкканы юк. Ә партия газетасы башка басмаларны контрольдә тотарга тиеш. Син хәзер менә шуңа алын. Әлегә моны икебез генә белик. Югыйсә, чукып бетерерләр.

Мансур эшкә тотынды. Журналның соңгы бер елда дөнья күргән нөсхәләрен бик җентекләп өйрәнде, тематикаларын ачыклады, системага салды. Журнални ул элек тә укып бара иде, үзе дә бик теләп языша иде. Шуңа күрә хәзерлек өлешен ун көндә ерып чыкты. Харрасов сагыз урынына ябышты мәгәр. Туалетка йөргәндә дә аның янына сугылмый калмый. Сораша, төпченә, түземсезләнә. Әйтерсең лә, артында кемдер мылтык төбәп тора. Мансур үзе дә борчыла. Журнал абруйлы, дәрәҗәле. Укытучылар, галимнәр, министрлык, җәмәгатьчелек ул биргән бәя белән килешерләрме? Гаделсезлектә, дилетантлыкта гаепләмәсләрме? Мәкалә әзер булгач та өстәмә арты өстәмә кертте. Кырыкмаса кырык тапкыр укып чыкты. Шуннан соң гына Харрасовның өстәленә салды.

—Бар, энем, буфетка төшеп берәр стакан чәй эчеп ал, тынычлан, укып бетергәч үзем чакыртырмын,—диде аңа мөхәррир.

Мансур графиндагы су белән генә канәгатьләнде. Атна буе тынчып беткән җылы суны голт-голт эчте дә бетерде.

Харрасов озак көттермәде. Мансур бүлмәгә кергәндә лимонлы чәй эчеп утыра иде.

—Котлыйм, энем, синнән рәт чыгарга ошабрак тора әле,—диде уены-чыны белән бергә.—Ләкин партиянең җитәкчелек ролен тагын да кабарынкырак ассызыкларга кирәк булыр. Бу бик мөһим мәсьәлә. Башка замечанием юк.

Мәкаләне чираттагы санга планлаштырдылар. "Өтерләрен дә үзгәртмисез",—дип кисәтте Харрасов.

Казанга күченеп килгәннән соң Мансур беренче мәртәбә үзенең кирәклеген тойды. Шул күтәренке уйларга бирелеп кайтып барганда кемдер аның каршысына чыгып басты. Йөзе кипкән балыкка ошаган озын гына буйлы бер кеше. Энәдән-җептән киенгән. Кулында фасонлы күн дипломат.

—Исәнмесез, Мансур, тәбриклим, газетада эшли башлагансыз дип ишеттем,—диде ул нәзек кысалы күзлеген рәтләгәндәй итеп.—Дөрес эшләгәнсез, мәктәп мәктәп инде ул, ә бу бөтенләй башка дәрәҗә. Обком органы!

—Рәхмәт,—диде Мансур. Ә башында: "Кем соң әле бу?"—дигән уй

бөтерелә. Милли мәктәпләр институтында мондый галим күренми иде шикелле, министрлыктан микән әллә?

—Мин Колбарисов булам. "Совет мәктәбе" журналының баш мөхәррире,—дип үзе ярдәмгә килде күзлек иясе,—хәтерлисезме, Әлмәттә фәнни-практик конференциядә очрашкан идек.

—Гафу итегез, Хәй Котдусович, танымадым, башның чуалган чагы...

Мансур Колбарисов белән бер генә мәртәбә күреште, белми дә диярлек. Мәкаләләренә карата редакция хезмәткәрләре баш мөхәррирнең: "Колбарисов хуплады", "Колбарисов ошатты", дигән сүзләрен генә житкерәләр иде. Инде менә үзе килеп сүз куша.

—Әйдәгез, берәр тустаган сыра эчеп чыгыйк,—диде Хәй нәфис бармаклары белән күзлек кысасына орынгалап.—Эштән соң ярый ул, көне буе энә өстендә утыргандай утырасың бит...

—Рәхмәт, Хәй Котдусович, бик рәхәтләнеп тәкъдимегезне кабул иткән булыр идем дә, итәк кыска. Рульдә мин.

Ул дөрестән дә ашыга иде. Базарда аны хужа хатын көтеп тора.

—Бер генә минутка, Мансур, әйтегез әле, пажалсты, безнең журналга нинди үчегез бар сезнең? Мәкаләләрегезне һәрвакыт бастырып килдек, берсен дә кире бормадык. Диссертациясен якласын, ярдәм итик, дидек. Шуларга жавап итеп, инде безне тар-мар иткәнсез...

Менә нәрсәдә икән хикмәт? Кай арада белеп өлгергән соң әле ул моны? Харрасов читкә чыгарасы булмагыз, дип тәкрек чәчкән иде ич. Димәк, редакциядә дә такылдык саесканнар житәрлек.

—Минем шәхсән "Совет мәктәбе"нә рәхмәттән башка бер дәгъвам дә юк, Хәй Котдусович,—диде Мансур,—әмма заман халык мәгарифенә яңа таләпләр дә куя. Журналның шул югарылыкка ирешүенә булышлык итәргә тырышуымны мин һич тә гаеп гамәл дип санамыйм.

Колбарисов барыбер тынычланмады. Икенче көнне дә ул аның каршысына чыгып басты.

—Мансур, әйтегез әле зинһар,—диде ул мескенләнеп,—ул күзәтүне сез кем кушуы буенча яздыгыз?

—Хәй Котдусович, мин редакциянең эчке серләрен ача алмыйм. Аннан ары моның нинди әһәмияте бар соң хәзер?

—Ничек кенә әле,—дип пышылдады Колбарисов,—Харрасовның гына этлеге булса, бер хәл. Әгәр өстән, обкомнан килсә?!

Мансур ашыгуын белдереп, сәгатенә күз төшерде. Әмма Колбарисов аңа сукыр черки кебек бәйләнде.

—Мансур үтенеп сорыйм, күзәтүне обком кушуы буенча яздыгызмы, Харрасов кушуы буенчамы?

—Бу минем үз инициативам,—дип әлеге әзәрлекләүгә чик куймакчы булды Мансур,—калганын мәкалә басылып чыккач аңлашырбыз.

Мансур, ниһаять, Харрасовның "чукып бетерәчәкләр" дигән кисәтүенең асылына төшенде.

Харрасовның өмете акланды булса кирәк. Мәкалә басылып чыккач, "летучка" дип йөртелә торган иртәнге мәжлестә: "Обкомда күкрәк киереп йөрдем",—диде. Редакциядә обкомның газета чыгышын хуплавы иң зур дәрәҗә санала.

Мәкалә Мәгариф министрлыгы коллегиясендә дә тикшерелде. Мансурны да чакырдылар. Утырыш алдыннан Мостафин белән гәпләшеп алдылар. Министр ничектер олыгаебрак киткән сыман тоелды. Маңгаендагы бураэналары тирәнәя төшкән, кара чәчләре арасында аксыл кылганнар да күренгәли.

—Чәчләрегезгә акыллылык каурыйлары куна башлаган, Мирзанур Искәндәрович,—диде Мансур.—Сезгә бирешергә ярамый.

—Бирешмичә. Әмиржанов кебек талантлы укытучылар мәктәптән качсын әле. Кем белән тәрбияләргә соң ул коммунистик жәмгыять төзүчеләрне?

—Минем хәлне беләсез инде, Мирзанур Исмагилович,—сәбәбе бик

житди. Мин яна урында да халык мәгарифенә файда кертермен, дип уйлыйм.

—Күренеп тора инде,—диде министр төрттеребрәк,—бер ай эчендә әнә нинди шау-шу куптардыгыз. Әлбәттә, министрлыкта да гаеп бар. Кулыбыз житми редакциягә. Ә Колбарисов күбрәк тышкы яктан ялтырарга ярата, мәсьәләнең төбенә төшәргә ашыкмый.

Гадәттәгечә, гарасатлы болытның янгырына караганда тузаны мулрак була. Мәкалә уңаеннан туган әлеге шау-шу да тиздән басылды. Шелтәләре дә онытылды, күрәсең, Колбарисов хәзер алтын кысалы күзлегенең өстеннән генә карап уза.

* * *

Редакциянең үзенә генә хас һавасы, үзенә генә хас сулышы, башка бер учреждение белән дә бутап булмый торган үзара мөнәсәбәтләр кануны, эш ритмы бар. Монда Харрасовка гына атасының исемен кушып мөрәҗәгать итәләр. Мәктәптә җыештыручыга да "Фәлән Фәләновна", дип дәшергә күнеккән Мансур шактый вакыт бу демократик "йөгәнсезлек"не кабул итә алмый йөрде. Кайберәүләрнең эш сәгатендә дә тамак чылатуы һич тә гөнаһ саналмый. Харрасов булып Харрасов та бу хәлләрне күрмәмешкә салына. Ә үзенең кырыс, таләпчән дигән даны чыккан.

Иртә белән редакция коридорында иң беренче булып секретариат ханымнарының биек үкчәләре тыпырдый башлый. Тыз да быз киләләр. Утырышка кадәр барысын да ачыкларга кирәк. Хуҗа төгәллекне ярата.

Күп тә үтми, ишек уемында җаваплы сәркәтип Кәбиров пәйда була. Һәр ишекне ачып, кем килгән, кем килмәгән—барысын да тикшереп чыга.

Ул арада як-ягына янтаеп, Тимербаев килеп керә. Шул ук мизгелдә редакцияне аның карлыккан тавышы йота. Килә-килешкә бурычлар куя, кемнедер сүгеп ташлый, шунда ук шаркылдап көлеп җибәрә.

Сәгать нәкъ тугызда бәкегә су эчәргә төшүче көтү кебек журналистлар мөхәррир бүлмәсенә юнәләләр.

Бүген боларның берсе дә юк. Чөнки шимбә көн. Дежур төркем генә эшли. Редакция ташландык йортсыман ямансулап калган.

Мансур корректураны белешим әле дип, урыныннан кузгалган гына иде, телефон шалтырады. Галим икән.

—Татарның бөек журналистына сәлам!—дип колак элпәләрен дерелдәтте аның тавышы.—Күренмисез-нитмисез, ял көннәрендә ни-нәрсә майтарып ятасыз соң сез ул Борисковода?

—Сезгә генә ул ял. Җәмилә бакчадан чыкмый, үзең беләсең, помидор сезонының кызгаң чагы. Мин базарга ташыйм. Хуҗабикә сата. Шулай үтә көннәребез.

—Минем шикелле эксплуатациягә эләккәнсез икән алайса. Әйдә, иртәгә баш күтәрәбез, чукынсын помидорлары. Бәйрәм ясыйк.

—Син ул бәйрәмне ничек күз алдына китерәсең соң?

—Мари урманында гөмбә мыж ди. Сызыйк шул якларга.

—Мин гөмбәне танымыйм да, җыя да белмим...

—Исең китмәсен иске чикмәнгә, шуңа да ярамагач, ул хатыннарни хәжәтемә, чуртым-матыр. Без мөселман ирләре түгелме-юкмы? Үзебезне күрсәтергә вакыт!

—Канишне, мөселман ирләре. Килештек алайса. Көтегез!

Ул көнне телефон арты телефон шалтырады. Әмма иң куанычлысы соңгысы булды.

—Миңа иптәш Әмирҗанов кирәк иде,—диде бер ир-ат,—чакыра алмассызмы икән?

—Мин сезне тынлыйм... Тик кем дип әйтергә генә белмим...

—Әйе, әлегә без таныш түгел. Шулай да тиздән якынлашырбыз дип уйлыйм. Мин педагогия училищесы директоры Сафин булам. Сафин Мөгамбәр Мусинович. Шалтыратуымның сәбәбе шунда, безнең бер математика укытучысы декрет ялына китә. Хатыныгыз аның урынына эшләп тормасмы, дип борчуым.

Министр эшне бик тиз тоткан, молодец, дип сөенде Мансур. Ул аңа Җәмиләгә эш турында әйтеп куйган иде.

Эшләмичә соң? Бик рәхәтләнеп. Югыйсә, кимсенеп йөри иде. Теле белән әйтмәсә дә, кайтып керүгә, берәр яхшы хәбәр алып кайтмадымы икән дип, өметләнеп карый. И, сөенер инде, җанашым. Әле кайда диген? Педучилищега!

Кичен Мансур өстәлгә чын коньяк куйды. Гәпләшеп, җырлашып утырдылар. Сәгать унны суккач, хуҗабикә ярма ташыдай кин арт санын урындыктан аерды.

—Җә, бүгенгә җитеп торыр,—диде ул,—иртәгә бәйрәм түгел. Мансур сиңа иртәрәк кузгалырга туры килер, Бишбалта базарында помидор кыйммәт йөри ди. Мине шунда илтерсең. Җәмилә минем иске урында сатып торыр. Өйрәнсен, әйдә.

Кызмача кешенең уендагы авызында бит аның. Мансур да ярып салды:

—Рәйсә апа, иртәгә ул базар богауын өзәргә дип торабыз бит әле. Дуслар белән Мари урманына гөмбә җыярга барырга сөйләштек.

Рәйсәнең йөзе кара коелып төште. Күзләренең агы белән ире Заһирга акайды да: "Өстәлне җыештыр",—дип кыска юан аякларын алпан-тилпән басып, бүлмәсенә кереп китте. Ниләрдер шатырдады, ниләрдер коелды...

Рәйсә Казан кызы. Вак кәсепчеләр нәселеннән. Армиядән кайтып кая барып бәрелергә белми аптырап йөргән шинельле авыл егетен эләктереп алган да, йортка керткән. Инде ике уллары бар. Җитеп киләләр. Өйдә хатын сүзе сүз. Заһиры да шуңа күнгән.

Әле дә ике бармагын иреннәренә терәде, янәсе, шып булыгыз, хатын йокларга ятты. Тузынамы соң Мансур?.. Киресенчә, Рәйсә апаны рәнҗеттем ахыры, дип пошаманга төште. Ул аларга бик рәхмәтле. Шундый авыр, чарасыз вакытта сыендырдылар ич. Ихтимал, шушында кышларлар да әле. Рәйсәнең тел төбе шулайрак. Ә мондый җинелчә үпкә-сүткәләр туганнар арасында да була. Кем белсең, бәлки, коньяк шаукымыдыр?

Алар йокыдан торганда Рәйсә базарына элдерткән иде инде. Үзләре дә озак юанмадылар.

Мансурның да, Галимнең дә бу якларга беренче чыгуы. Шуңа күрә олы юлдан кайсы якка борын төртергә белми аптырап йөрделәр. Ахыры, үзебез кебек берәр гөмбәче машинасының койрыгына тагылырга кирәк, дигән фикергә киленде. Ләкин сайлаган машина һич тә читкә кагылырга уйламый, туп-турыга сыздыра.

—Бу абзый безне Мәскәүгә ияртеп алып бара бит, җәмәгать, исәпләүләренә караганда, тиздән Кремль йолдызы күренергә тиеш,—диде Галим, шукланып.

—Бигрәк тә әйбәт,—диде Лилия,—Ямилә белән без кибетләрдә йөрербез...

—Акчабыз да бер букча,—дип хуплады аны Җәмилә.

Галимгә форсат кына чыксын, мәзәге дә, такмагы да әзер.

Әй, зимагур, әйттер, бетер
Сыер саткан акчаңны;
Сыер саткан акчаң беткәч,
Сат бәрәңге бакчаңны.

—Зимагурның сатар нәрсәсе булган, без ни сатарбыз соң,—диде Лилия.

—Ә гөмбә? Гөмбә дә тауар ич!

—Эрләмәгән, сукмаган, кияү сиңа ыштанлык,—дип көлде Җәмилә.

—Бака туе ясамагыз әле, әнә алда милиционер басып тора,—диде Мансур,—исерекләр дип бәйләнмәсен.

Милиционер үзе дә юлаучы икән. Тик аңа башка якка. Алай да юлны өйрәтте.

—Бераз баргач, унга борылыгыз, юл күрсәткечкә "Суслонгер" дип язылган булыр,—диде.

Суслонгер! Бу сүзне ишетүгә Мансур әллә нишләп китте. Ул аны ни сәбәпледер мәрхәмәтсез Котып таулары арасында, дип уйлый иде. Балачактан күнеленә шулай сеңеп калган. Җәфа, ачлык, чир иле. Сугышка алынган ач-ялангач кешеләр Суслонгерда хәрби өйрәнү узган. Мансурның әтисе дә шунда эләккән.

Һәм менә Мансур Суслонгерга гөмбә җыярга бара. Аңламассың бу дөньяны. Ничекләр генә тузгытмый ул адәм баласын?!

Ә Галим һаман җорлана.

—Урман ягына бор руленне, Мансур, бүгенгә Суслонгер банкын басмый торыйк, акчалары җыела торсын.

Мансур уйларыннан арынды. Ә бераздан машинасын урман авызына китереп терәде.

—Мин каравылда калам, сез коелыгыз,—диде Мансур.

—Әтием, минем дә каравылда каласым килә,—дип Ләйсән дә Мансурга кушылды. Югыйсә, үзе бик күп гөмбә җыям, дип юл буе такылдап килгән иде.

—Штат буенча каравылчыга берничә урынбасар тиеш,—диде Галим борынын чөеп,—Айрат белән мине дә исемлеккә теркә.

—Ә нигә миңа ул кадәр урынбасар?

—Каравылчы йокы бүскәндә объектны кемдер сакларга тиештер ләбаса!

—Ай-һай, телең. Бел, чалгы пәке белән кыскартам әле мин аны.

Ирләрнең сүз көрәштерүен Лилия бүлде.

—Ямилә, без урынбасарларнын урынбасарлары булабызмыни енде?

Җәмилә кәрҗиненә ябышты.

— Мин гөмбәче. Кемнәр минем ярдәмчеләрем булырга тели, ун ягыма басыгыз!

Иң беренче булып әнисе янына Ләйсән килеп басты.

—Мин, әнием, мин!

—Әй, Ләйсән, песи, песи, пескәем, хыянәтче икәнсен...

Ахыры машина янында Мансур белән Ләйсән торып калды, башкалар көлешә-көлешә урман эченә кереп киттеләр.

Урман өлеш-өлеш кисәкләрдән сырган корама юрганга ошап калган. Нинди генә төсләр юк?! Усак яфраклары ал төстә, каеннар жете сары. Ваграк куакларга әле көз жиле тимәгән. Яшел киемнәрен салырга уйламыйлар да. Ә менә, без кем дип, киерелеп утырган имәннәр бөтенләй карачкыга әверелгән. Берән-сәрән ботак очларында гына эленеп калган соңгы яфраклары да өзелеп төшәргә тора.

Бу манзараны, мөгаен, әткәй дә күзәткәндер, урман әле бүген дә аның күз явын ядкәр итеп саклыйдыр, дип уйлады Мансур. Ул инде ничә еллар аның каберен эзли. Табылмады. Билгесез, диделәр. Чебен урынына кырганнар аларны Мәскәү янында, гәүдәләрен җир белән укмаштырып изгәннәр. Ә ана, юк кеберне эзләп изаланганчы, менә шунда киләсе, әтисе йөргән җирләрдә йөрисе, әтисе сулаган һаваны сулыйсы калган...

—Әтием, син елыйсың, әйеме?

Ләйсән аңа томырылып карап тора. Ә ул яшьләрен тыя алмый.

—Юк, кызым, болай гына, күземә чүп керде. Әйдә, хәзер яфрак җыябыз. Матурларын, нәфисләрен. Әниенә бүләк итәрсең,—диде Мансур.

—Ә Лилия апага?

—Лилия апаңа да инде, кызым.

Ләйсән әтисенең "күзенә чүп кергәнгә" ышанды ахры, ул хакта башка сүз кузгатмады. Әмма авызы йомылып та тормады.

—Әтием, нигә без Казан авылына күченеп килдек соң, ә?

—Казан бик зур шәһәр ул, кызым, авыл түгел.

—Булыр шәһәр, шәһәрдә туалет фатирда була. Корбаштагы сыман. Мин фатирыбызны сагынам, әтием. Анда пианино бар иде. Ләйлә бар иде, Гүзәл... Кайтып китик без, әтием...

—Син әниеңне яратасың бит, кызым, әйеме?

—Бик-бик яратам, әнием минем әйбәт, матур. Сине дә яратам, әтием. Бик-бик. Син дә матур...

—Мин дә әниеңне бик яратам. Икебез дә яратабыз. Шулай булгач, әниеңне ныклап терелтергә кирәк безгә. Аннан соң карарбыз.

—Әнием дә шулай әйтә, син дә шулай әйтәсең, хәзер мин дә шулай әйтәм. Ә Рәйсә апа усал. Печтәннәп йөрмә әле монда бакчаны таптап, ди. Чиләкне дә чүмәкәй итеп тотыра. Мин күтәрә алмыйм. Әнием булыша аннары.

—Кызым, сиңа да, әниеңә дә авыр күтәрергә ярамый. Мин Рәйсә апаңны моның өчен почмакка бастырырмын әле, җәме?

Ләйсән кәефе килеп рәхәтләнеп көлде.

Тиздән гөмбәчеләр дә урманнан чыкты. Күңелләре күтәренке. Әйтерсең лә, хәзинәгә тап булганнар. Аучылар шикелле берсен-берсе уздырып мактанышалар.

—Киләсе атнага йөк машинасы яллап киләм, Казан базарын гөмбә белән күмәм,—дип шапырынды Галим.—Әфтәмәбиль алам, яшь хатын ярәшәм, сарай салам... их... типтерәм... биеп кенә яшим...

Борисковога да шаулап-гөрләп кайтып кердpoints.

— Кабул итеп ал, хуҗа, ел әйләнәсенә житәрлек гөмбә! — дип кул болгады Мансур күтәрмә башында басып торган Заһирга. Ләкин тегесенең мыек очы да селкенмәде. Ачы торма капкандай йөзе чытык иде.

—Рәйсәнең теше сызлый, алапа корман,—дип ул битараф булырга тырышып. Ә үзенең күзләре гөмбәдә иде. Сорашасы, белешәсе килә. "Әллә без гөмбә күрмәгәнме?"—дип мыгырдана-мыгырдана өйгә кереп тә китте.

—Бик усал черки тешләгән боларны,—диде Мансур,—авыртуы басылмаган.

—Эчеңнән тын,—диде Җәмилә,—үтәр әле. Мин Ләйсәнгә урын җаям, син күтәреп кертеп яткырырсың, уянмасын инде, бик тәмләп йоклый.

Җәмилә шундук урап чыкты.

—Мансур, кер әле монда, — диде ул шөбһәле тавыш белән.

—Нәрсә бар?

—Кер әле, кер...

Мансур верандага узды. Ә анда аларның урын-җирләре, кием-салымнары, кирәк-яраклары аунап ята иде. Бүлмәдән шушында чыгарып өйгәннәр.

Күзгә-күз карашып, телсез калдылар. Бу сүзсез дә аңлашыла иде инде. Димәк, куалар. Алдан кисәтеп куярга кирәк иде инде. Кешечә булмый иде инде болай. Песи балалары түгел лә инде алар.

—Базарга чыкмаган өчен,—дип пышылдады Җәмилә.

—Без аларның колымы әллә?

Мансур җан ачуы белән өй ишеген киереп ачты. Ә анда карачкы шәүләседәй Заһир басып тора иде. Әзерләнеп көткән, күрәсең, Мансурга авызын ачарга да ирек бирмәде, бозык патефон шикелле баягы сүзләрен кабатлады: "Рәйсәнең теше сызлый, алапа корман... теше сызлый... теше сызлый..."

—Мансур, кирәкми, тавыш куптара күрмә, Мансур,—дип Җәмилә аны ишекнең бу ягына өстерәп чыгарды.

—Җәмилә, ничек була инде бу, Җәмилә...

—Алар хужа, аларның сүзе сүз, Мансур. Вакланмыйк, горурлыгыбызны югалтмыйк.

Горурлык, дип әйтүе генә ансат. Торыр урынын, таяныр җирен юк икән, горурлык та онытыла шул. Зур шәһәрдә син беркемгә дә кирәкмисен. Синең хәлең бераүне дә кызыксындырмый. Бердәнбер ышаныч — үзең! Ниндидер җай чыга икән, монысы инде бәхет эше.

Адашкан эт кебек арлы-бирле сугылган шушы авыр көннәрдә аңа тагын бер очраклы нәни генә бәхет уты йөзен ачты. Әлегә анын Казан каласындагы тормышы әнә шундый вак-вак очраклы кыйпылчыклардан тора. Кемнәр өчендер болар кисеп ташлаган тырнакка да тормыйдыр. Мансур исә аларны бәхеткә саный. Ник дисән, очраклыкларның да үз закончалыгы бар. Әйтик, Чаллыга китәсе урынга Казанга күченеп килүләре дә, укытучы кешенең редакциягә эшкә урнашуы да, котмәгәндә Заһирларнын үзләренә сыендыруы да—барысы да очраклы. Әмма барысы да бер җепкә тезелгән зарурилык. Шундый ук зарурилык тагын бер кирәкле кеше белән очраштырды.

Мансур газетада яшь татар галимнәре турында язмалар бирә башлады. Анын бу башлангычын редакциядә хупладылар. Шул ният белән ул Фәннәр академиясенең физика институтына килде. Монда аңа бер яшь галим кандидатурасын тәкъдим иттеләр. Талантлы, өметле, диделәр, фән-техника прогрессынын бик актуаль проблемасы белән шөгыльләнә, диделәр. Проблема дигәне тышча икән. Башта Мансурга бу бик гади, примитив булып тоелды. Болар мине төп башына утыртмакчы ахры, дип уйлады. Ярар соң, күрик, танышыйк, ошамаса, аны көчләп тотучы юк ла.

Илһам Мансуров белән алар лабораториядә очраштылар. Лаборатория бик кечкенә тынчу бүлмәдә урнашкан иде. Шулай да аңа ике өстәл, өч урын сыйдырганнар. Ул урындыкларның да берсе ватык. Нигә аны чыгарып ташламыйлардыр, Мансур тәки аңлый алмады. Югыйсә, арт борырлык та урын юк. Хәер, бу, мөгаен, дәүләт милкенә сак караунын уңай үрнәгедер.

Өстәл өстендә ниндидер приборлар гөжелди. Мансурнын урыны электр плитәсе янына туры килде. Бераздан: “Бу плитә дә фәнни тикшеренүләр өчен кабызылганмы?”—дип сорасы итте.

Илһам кемнедер эзләгәндәй ян-ягына каранып алды. Ләкин бүлмәдә алар икәү генә.

—Үзең чыкканда плитәне сүндереп чык дип, ул лаборант кызнын колагына тукрандай тукып торам, артына да элми,—диде, гафу үтенгәндәй. Ул аны үзе дә сүндерә алыр иде, югыйсә, үзенең дә кулы җитми, күрәсең.

Илһамнын саф татарча сөйләшүен Мансур гаҗәпләнеебрәк тыңлады. Чөнки аны башкорт дигәннәр иде. Бер дә башкорт чалымнары юк. Татарлар белән дә уртаклыгы тоелмый. Йөзе озынча, чәчләре аксыл. Балтыйк буе кешеләренә тартым.

Мансур сүзне шуларны ачыклаудан башлады.

—Мин Башкортостаннан, гаиләдә унынчы бала,—диде Илһам,—авылда туып үстем. Бабаларым Казан ягыннан. Иван Грозный чорында чукындырудан качып Урал ышыгына килеп төпләнгәннәр.

—Сезне башкорт дигәннәр иде...

—Ә-ә,—дип көлемсерәде Илһам,—монысы инде сәяси мәсьәлә. Башкорт милләтен ишәйтәләр, имеш. Рөхсәт тә сорап тормыйлар, таныклыкка да, паспортка да башкорт дип теркиләр дә куялар.

—Ничек инде, сорамыйча да...

—Менә шулай...

—Туган ягыгыз белән элемтәләрегез бармы соң?

—Уфага бик кодалыйлар. Дүрт бүлмәле фатир бирәбез диләр, кафедра, машина...

—Ә Сез?

Илһам сәбәбе гади генә инде анын дигәндәй, җилкәләрен сикертеп куйды.

—Минем галим буласым килә.

Мансур: "Уфада галим булып булмыймыни?"—дип сорамакчы иде дә, тыелып калды, соңрак ачыклармын дигән фикергә килде. Шулай да фатир мәсьәләсеннән жинел генә узып китә алмады. Чөнки ул үзенең дә бугазына сөяк булып кадалган мәсьәлә.

—Хәер, фатир сезнең өчен монда да проблема түгелдер инде,—диде Мансур ниндидер бер жинеллек белән, янәсе, фатир аның өчен дә күптән хәл ителгән мәсьәлә.

Илһам вак тешләрен күрсәтеп көлеп жибәрде. Мансур ул көлә дип көлде. Рәхәтләнеп көлештеләр. Баксаң, икесенең дә хәле бер чама икән. Әлегә Илһам хатыны, кызы белән өйдәш булып, өч метрлы бүлмәдә яшәп яталар икән. Күптән түгел хатынының әтисенә ике бүлмәле фатир биргәннәр. Шунда чыкмакчылар. Мансур да яңа танышына үз хәлләрен сөйләп бирде. Шул ук көнне Илһам аны фатир хужасы белән таныштырды. Әйбәт кенә бер әби икән. Ризалашты. Мансур ул көнне атлап түгел, очып йөрде.

Тик мәкалә генә көтелмәгәндә зур каршылыкка очрады. Югыйсә, барасы да уңай килеп торган кебек иде. Мансур Илһамның гыйльми житәкчесе профессор Мөштәри белән очрашып сөйләште. Тышча теориясенең атасы шушы икән инде. СССРда да, чит илләрдә дә Казан мәктәбен яхшы беләләр икән. "Тышча" дигән термин бу теория белән хәбәрдар булмаган кешеләргә генә гади сыман тоела икән. Ракеталар, самолетлар, кораблар — барысы да шушы теориягә нигезләнеп төзелә икән.

Мөштәри янында Мансур оятка калды. Чөнки ул аның белән, югары даирәләрдә кабул ителгәнчә, рус телендә сөйләшә башлады.

—Нәрсә, инде татар милли матбугаты вәкиле дә ана телен белмимени хәзер,—диде ул усал бер елмаю белән.—Татар зыялысы үз татарлыгыннан үзе оялгач, башкаларга ни сан?

Мөштәри шәкертенә зур бәя бирде, ул минем алмашым, диде. Мәкалә шул рухта язылган да иде. Аны чираттагы санга кертеп куйдылар. Мансур мәкаләне кичтән укып, хаталарын төзәтеп, имзасын төшереп кайтып киткән иде. Ә иртәгәсен киоскыдан берьюлы биш-алты газета алды. Илһамга да, үзенә дә. Илһам Башкортостанга, туган-тумачаларга жибәрәм дигән иде. Ул үтә бер дулкынлану белән газетаны ачты. Сәхифәләрне берничә кат күздән кичерде. Ләкин никадәр генә эзләсә дә, газетада үзенең мәкаләсен таба алмады.

Мансур редакция бусагасыннан курка-курка атлап керде. Кешеләрнең күзләренә карарга кыймыйча гына бүлмәсенә кереп утырды. Бүлмәдәше командировкада. Шуңа бик шатланды. Аның берәүне дә күрәсе килми иде.

Ни булды икән, нинди сәбәп аркасында мәкаләсен алып ташладылар икән? Бу бит гадәттән тыш хәл! Димәк, зур мәгънәви хата тапканнар. Шелтә бирәчәкләр дә бирәчәкләр инде. Ярый ла, алай гына котыла алсаң. Эштән кусалар нишләрсең? Илһамга ни әйтер?..

Кемдер ауга чыккан мәче кебек тавышсыз-тынсыз гына ишекне ачты.

Харрасов!

Мансурның башына кан бәрде. Торып басарга теләде, ләкин урындыктан куба алмады.

—Кайгыңны уртаклашырга кердем,—дип көлемсерәде Харрасов.—Кичә полосада мәкаләң бар иде, бүген карыйбыз—югалган! Эзли-эзли гарык булып беттек. Әллә үзең чәлдереп киткәнсең инде...

Мансур шаяртуны аңлар хәлдә түгел иде. Шуны сизепме, Харрасов аны юатырга кереште.

—Борчылма, энем, син әле яшь журналист, бу эшнең үзенчәлекләрен белеп бетермисең. Бездә обллит дигән шымчы бар. Анда һәр язма иләк аша үткәрелә. Синең мәкаләңне обкомга житкергәннәр. Чөнки галимнәр

белән бәйле. Хәзер шунда кит, анда сиңа эшнең нәрсәдә икәнлеген төшендерерләр. Ишек төбендә машина көтеп тора.

Мансур Харрасовтан мондый миһербанлыкны көтмәгән иде. Эштән кумасалар ярар иде, дип көзге яфрактай дер калтыранып утырган бер чакта, менә сиңа мә, ишек төбендә машина көтеп тора!

Әйе, Мансур ул вакытта Харрасов шәхесенең табышмакларын белеп бетерми иде әле. Харрасов табигате белән—түрә. Шуннан тәм табып, рухи канәгатьлек алып яши. Иң мөһиме, түрә була белә. Тик акыллы түрә иде Харрасов. Ул кешене пычак йөзлегендә тота ала, шул ук вакытта аңа кайчан ярдәм кулы сузарга икәнен дә белә.

Обкомда Мансур фән бүлеге мөдире урынбасары янына керергә тиеш иде. Нәрсә әйтерләр икән дип, бик борчылып барды. Шулай булмыйча, бу бит партиянең штабы. Иң мөһим карарлар шушы йортта ярала. Анда эшләүчеләр дә җәмгыятьнең каймагыдыр, әлбәттә.

Мансур кабул итү бүлмәсендә тукталып тормады, килә-килешкә кертеп тә җибәрделәр. Кабинет ишеген ачкач кына, өнемме-төшемме дигәндәй, аптырап калды. Чөнки зур имән өстәл артындагы биек аркалы кәнәфидә Сафа утыра иде. Урынына бөтен сыны белән чумган, пеләш төшкән башы гына ялтырап күренеп тора.

—Сафа, бу синме? Сәлам, дустым, сәлам,—дип Мансур кулларын сузды.

Сафаның юеш учы елан тәне кебек салкын иде. Ул Мансурның кулын кысмады, тотып кына карады.

—Утырыгыз.

Сафа уңган бала чүпрәгедәй төссез керфекләрен җилпештереп, Мансурга текәлде.

—Сафа, әллә син мине танымыйсыңмы?—дип аптырады Мансур.

—Ник танымыйм ди, таныйм.

—Соң...

Сафа юк бүксәсен киеребрәк куйды, мәһабәтлерәк булып күренергә тырышуы иде булса кирәк.

—Мансур иптәш,—дип сүзләрен сузып китте,—без агай-энеләр белән ресторанда утырмыйбыз. Бу—обком! Монда фәкать эш турында гына сөйләшәләр. Сез дә эш буенча чакырулы.

Мансур гомергә булмаганны аты-юлы белән сүгенмәкче иде дә, юк белән юк булганчы дип, әлеге ниятенә кулын селтәде. Ул Сафа катнашында радиодан репортаж тыңлавын, аның ниләр сөйләгәнен яттан отып калуын, һәм иң мөһиме—Казанга радиодан аның чыгышын тыңлаганнан соң тәвәккәлләвен бәйнә-бәйнә сөйләргә, рәхмәт әйтергә җыенганын җиткермәкче булган иде.

Әллә кемгә әйләнгән ич бу, бюрократ дисәң, бюрократ түгел, ниндидер гибрид. Тыштан кавын, эчтән кабак. Менә сиңа каймак? Әтәчләнеп утыруын күр, әйтерсең лә, монда аннан да гыйлем кеше юк.

—Мөштәри, Камай ише милләтчеләргә без партия матбугатында урын бирә алмыйбыз,—дип катгый хөкемен дә чыгарып куйды Сафа.

Мансур Кормаш мәктәбе директоры Зыятдиновның кисәтүен исенә төшерде. Дөрес әйткән, партия өчен милләтпәрвар кешеләрдән дә куркынычрак дошман юк икән.

—Моннан соң,—дип дәвам итте ул сүзен,—фән бүлеге белән килештермичә галимнәр турында язмыйсыз?

—Ә бу мәкаләне нишләтәсез?

—Мин аны төзәттем инде, басарга мөмкин!

—Рәхмәт, Сафа,—диде аңа Мансур чыгып киткәндә,—Мөштәри өчен түгел, ул фәндә үз урынын тапкан инде, аны син генә какшата алмассың. Башкасы өчен рәхмәт. Анысын, үзең әйтмешли, туры килсә ресторанда, агай-эне арасында әйтермен әле бер.

Мәкалә, ниһаять, дөнья күрде. Әмма анда профессор Мөштәринең исеме телгә алынмый иде инде.

Атна-ун көннән Илһам гаиләсе белән бабасының цивилизацияле фатирына урнашты. Мансурлар алар жылыткан урынга кереп ояладылар.

Борисководан күченеп киткәндә Рәйсә белән Заһир елашып, кул болгап озатып калдылар. Элемтә соңыннан да дәвам итте.

* * *

Жәмилә әчке бер тоемлау белән кемнендер үзенә текәлеп карап торуын сизде, ул кешеләрне ера-ера алгарак үтте. Тик әлеге караш аңа тигәнәк кебек береккән иде, барыбер котыла алмады. Бу, әлбәттә, ир-егет. Ул аны хатын-кыз буларак кызыксындыра. Монысын да тәгаенлады Жәмилә. Инде хәзер үзенен дә аны күрәсе килә башлады: нииндирәк кеше икән? Борылып карар иде, шикләнә, бу үзенне фаш итү булыр иде. Әллә нәрсә уйлавы бар, ныклап бәйләнүе ихтимал. Хәер, шунын да әмәлен тапмаган хатын-кыз хатын-кыз була димени? Хатын-кызның хәйләкәрлеге шайтанны да тез чүктергән ди бит.

Ләкин Жәмиләгә бу юлы хәйләкәрлеге түгел, физика законы ярдәмгә килде. Трамвай күләгәдә калган арада каршы як тәрәзә көзгегә әверелә. Менә шунда күреп алды ул аны. Озын буйлы, киң күкрәкле кеше. Яшь әле. Күр, нинди егетләрнен күзе төшә әле аңа. Ул әле һаман каш өстендә икән, батмастан күбеккә тотынырга иртә икән әле.

Егетнен сүз кушачагы көн кебек ачык иде. Ләкин аны ничек тә алдарга кирәк. Монысы инде хәйлә, тапкырлык таләп итә.

Менә трамвай ул төшәсе тукталышка килеп житте. Бер-бер артлы кешеләр коелды. Жәмилә читтәрәк басып тора. Егет тә тынычланды. Димәк, әле бергә барасы.

Шунда Жәмилә жил житезлеге белән урыныннан купмасынмы.

—Гафу итгез, мина төшәргәе, зинһар,—диде ул трамвай йөртүчегә.

Егетне шулай аймыл итте. Әмма ул шат иде.

Казанга күченгәннән бирле Жәмилә эчтән сызып йөрде. Чөнки инде көйләнгән гаиләнен тормыш арбасы аның аркасында кискен борылыш ясады ич. Мансурның планнары челпәрәмә килде, профессиясен үзгәртергә мәжбүр булды. Өстәвенә, кеше өстендә яшиләр. Фатир турындагы хыял хәтта хыял канатларына да сыймый. Үзе күпме вакыт эшсез утырды. Мансурга рәхмәт. Тагын бер атнадан дәресләр бирә башлаячак. Үзе укыган педучилищега педагог булып кайта! Бу аның өчен искиткеч зур дәрәжә.

—Барысы да үзегездән тора,—диде директор беренче очрашуда ук, —үзегезне күрсәтә алсагыз, даими сәгатьләр дә бирербез.

Шулай, хәзергә нәрсәгә барып төртелсән дә—проблема. Әмма төп проблема—сәламәтлек! Бу корбаннар аның сәламәтлеге хакына бирелде.

Аның әле дә сырхауханәдән кайтып килеше. Канатны аңа шунда куеп жибәрделәр. Гашыйк егет исә ул шатлыкка жан өрде. Башка вакыт булса ул аны абайламас та иде.

—Каныгыз әйбәт, хафаланыр нәрсә юк, рәхәтләнеп яшәгез,—диде аңа профессор,—гадәттәгечә, күренгәләп торыгыз, онытып бетермәгез.

Бу сүзләрне Лилия дә гел әйтә килде. Тик аларны кат-кат үзе операция ясаган табиб авызыннан ишетү икеләтә-өчләтә шатлык иде.

Шушы бер жөмлә Жәмиләне күкләргә чөйде. Жиһанның гүя чаршавын күтәреп куйганнар. Урамнар кинәйгән, чибәрләнгән. Очраган бер кеше белән кул биреп күрешәсе, матур-матур сүзләр әйтәсе килә. Һәм шунда әлеге егет...

Якшәмбе көнне Муса килеп китте. Казанга килгәч бик нык үзгәрде ул. Сөнге иякле как сөяк үсмер түгел инде хәзер. Үзен студентларча иркен тота, оялмыйча күзгә туры карап сөйләшә.

—Апа, үпкәләмәгез инде, бу арада килеп булмады, яшелчә базасында эшләттеләр,—дип, ул Жәмиләгә өч бөртек канәфер чәчәге сузды.

—Рәхмәт, Муса, күңелне күтәрергә әле дә син бар.

—Ә мине кая куясың?—диде Мансур.

—Һи, сиңа тагын...

—Тукта-тукта, Җәмилә ханым, хәтерегез куян койрыгы чаклы гына икән. Чаңгы юлларыгызга чәчәк сипкән чибәр егетне оныттыгызмыни инде...

Уйнаган җиреннән әңгәмәгә Ләйсән килеп кушылды. Аның үз сүзе.

—Без зоопаркка маймыл ашатырга барабыз, әйе бит, Муса?

—Ничә мәртәбә кабатларга була инде,—диде Җәмилә, кызын шелтәләп.—Беренчедән, Муса түгел, ә Муса абый. Икенчедән, зурлар сүзен бүлдермиләр. Бар, Айсылуыңны кара, Ләйсән апам минем үземне генә калдырып китте дип, елап ята инде әнә.

—Беренчедән, апа түгел, әни. Икенчедән...

—Телеңә салынма, әйткәнне эшлә.

Ләйсән турсаеп уенчыклары янына барып утырды.

—Укуларың ничек бара?—дип кызыксынды Җәмилә шәкертеннән.

Мусаның йөзе чытылды.

—Марксизм-ленинизм белән теңкәгә тияләр, апа,—диде ул канәгатьсезлеген яшермичә,—атна саен семинар, реферат. Без бит беренче чиратта яхшы инженер, яхшы конструктор булырга тиеш.

—Син бу сүзләрне башка кешеләргә әйтә күрмә,—дип кисәтте Җәмилә,—соңыннан җыеп бетерә алмассың.

—И, апа, аны бездә яшереп тормыйлар. Кайберләрне инде комсомол комитетына да чакырганнар. Мин үзем дә аның кирәген тапмыйм.

—Кирәген Мансур абыең аңлатыр.

—Аны аңлатып та торасы юк,—диде Мансур,—менә, әйтик, һавасыз яшәп буламы? Булмый. Коммунистик җәмгыять төзүчеләр өчен марксизм-ленинизм тәгълиматы да һава кебек үк ул.

—Баш бар үзеңдә Әмирҗанов, марксизмны Луначарскийдан ким якламыйсың,—дип көлде Җәмилә.

—Безнең әле Муса белән марксизмнан да мөһимрәк шөгыльләребез бар,—дип Мансур бәхәскә нокта куйды.—Син ашарга хәстәрләгән арада без бераз майга буялып керик әле.

—Әтием, минем дә майга буяласым килә,—дип, Ләйсән дә урыныннан купты.

—Әйдә, киен, майның чүлмәгенә үк чумдырырбыз.

—Әнием, мине май чүлмәгенә чумдыралар, ура!

Бер тәгәрмәченең подшипнигы кырылган иде, гәпләшә-гәпләшә шуны алыштырдылар. Муса, әлбәттә, марксизм-ленинизмны сүгәргә дип тә, подшипник алыштырырга дип тә килмәгән иде. Алары сүз уңаеннан гына. Ә сәбәбе бик җитди. Һәм ул Мансур белән икесе арасындагы сер иде.

—Әтидән хат килде,—диде ул,—сәлам әйткәннәр.

—Рәхмәт. Теге мәсьәлә ни хәлдәрәк икән?

—Симерде дигән, хәбәр килү белән җибәрербез дигән.

—Берүк кешегә чыгара күрмәсеннәр инде.

—Безнекеләрнең авызыннан сүзне кләшчә белән суырып алсаң гына...

—Кләшчә белән дә була микән әле. Син теге вакытта үзеңә кемнәр пычак күтәргәнен тәки чишмәдең бит.

—Әллә кайчангыларны искә төшермик әле, абый...

—Менә-менә, әйтәм ич.

Ләйсән ни өчен ишек алдына чыкканын исенә төшерде булса кирәк: "Әтием, май чүлмәге кая",—дип килеп житте.

—Муса абыең алып килмәгән бит, онытып калдырган, башка вакытта инде, кызым,—диде Мансур.

Ләйсәннең кашлары җимерелде.

—Муса алдакчы, зоопаркка маймыллар ашатырга барабыз дигән иде, анда да алып бармады.

—Өйгә кергәч колагын борырбыз әле без анын, җәме?

—Нигә хәзер үк бормыйбыз?

—Әниен күрми кала бит.

—Ура, Мусанын колагын борабыз.

Сергә килгәндә, анысы түбәндәгедән гыйбарәт иде. Җәмилә кемнәндер бурсык ите канны чистарта, безләрне куа икән дип ишеткән. Аның киңәшчеләре, консультатлары бихисап. Кайсысы белән сырхауханәдә танышканнар, кайсысы үзе шул авыруны кичергән, кайсысы им-том итә. Берсеннән дә йөз чөерми Җәмилә. Үзе эзләп бара, таба. Урта Азиядән граммын илле тәңкәгә төшереп тау сагызы кайтартты. Аны спиртка салып, төнәтмә ясады. Иртә-кич шуны эчә. Бала сидегеннән файда күрүчеләр дә бар икән, ди. Хәзер менә бурсык ите.

Мансур үзе дә колагын торгызып кына йөри. Кешедән ишеткән бер сүз хәтта Җәмиләнең ниятенә дә үзгәреш кертте.

Редакциядә машинисткалар шундый оста ки, бер үк вакытта һәм басалар, һәм гәпләшәләр. Әлеге сүзне дә Мансур шулардан ишетте.

—Олы апанын канын эт ите белән генә рәтләдек, — диде берсе чәт-чәт килгән машина тавышы аша.—Ал төс кунды апабызга.

—Күрәләтә эт итен ничек ашамак кирәк,—дип йөзен сытты икенчесе.

—Без аны куй ите дип ашаттык ла.

Менә шулай менюда бурсык ите урынына эт ите пәйда булды.

* * *

Фатир хуҗасы Мөхсинә әби Ләйсәнне вакытлыча гына карап торырга ризалашты. Кичекмәстән кызны бакчага урнаштырырга кирәк иде. Аны Җәмилә үз өстенә алды. Чөнки педучилищеда мәктәпкәчә яшьтәге учреждениеләр өчен белгечләр хәзерләү бүлеге дә бар. Җәмиләнең дәресләре нәкъ шул бүлектә. Ә бүлек ясләләр, балалар бакчалары белән тыгыз элемтәдә эшли. Студентлар анда практика уза. Директор урынбасары да ярдәм итәрмен дип ышандырды. Бакча мөдире янына да алар икәү бергә барды.

Мөдир көләч йөзле, бик мөлаем ханым икән. Ачык чырай белән каршы алды. Шундук чәй китерделәр. Тәрбиячеләр кирәк икән, бу мәсьәләне дә сөйләшеп, тәгаенләп куйдылар. "Була ич бу, аллага шөкер", —эченнән балкып утырды Җәмилә.

Тик бала урнаштыру хакында сүз чыккач, мөдир бөтенләй үзгәрде. Бер мизгелдә буй җитмәс тәкәббер түрәгә әверелде дә куйды. Хәтта урындыгын да читкәрәк шуыштырды.

—Без аерым исәптә, урын юк, — дип кырт кисте.

Җәмиләнең кулындагы чынаягы чайпалып китте, итәгенә чәй түгелде.

Шуның белән сүз дә өзелде.

— Кәефегезне бозмагыз, шәһәрдә бакчалар бетмәгән, — дип юатты аны урынбасар.

—Монысы безнең өчен бик унайлы иде шул.

Урынбасар ана сынабрак карап торды да, вак тешләре арасыннан сүзләрен сөзде.

—Сез бит, Җәмилә Нурулловна, ишетүемчә педучилищега да министр аша урнаштыгыз бугай. Монда да аның бер сүзе җитә. Мөдир ханым югарыдан килгән әмерләрне җиренә җиткереп үти торган зат.

Җәмилә кыенсынуыннан бүртенеп чыкты. Мона каләр анын бер генә гамәлен дә таныш-белеш, кода-колагыйлар ярдәме белән башкарганы булмады. Үз көче белән педучилищега керде, югары белем алды. Спорт белән шөгыльләнде. Эшкә дә сатулашмыйча-сайланмыйча, кайда

билгеләсәләр, шунда китте. Менә шулай үз хәләл көчен белән яшәргә мөмкин дип, шуңа чын күңеленнән ышанып йөри иде. Чынбарлык исә бөтенләй башка икән.

Казанга күченү аның элекке карашларын төбе-тамыры белән кубарып ташлады. Сүз бер—гамәл башка. Ике яклы мораль. Шуның өчен семинарларда, лекцияләрдә буржуаз җәмгыятькә күпме эләгә иде?! Муса бу ялганның асылына инде төшенеп тә алган. Ә аңа моны аңлау өчен бик күп сынаулар аша узарга туры килде. Тик бу хәлгә ярашуы да җиңел түгел икән. Әнә урынбасарның сүзләре йөрәгенә ук сыман кадалды ләбаса! Шуңа күрә ни дип җавап бирергә дә белмәде.

Ә Ләйсәнне урнаштырырга кирәк. Шунсыз эше эш булмаячак. Үзе болай әйбәт кенә кереп китте. Беркөн дәресенә завуч кергән иде. Ошатты. Киңәшләрен дә бирде. "Талантың бар, тик мәктәп укытучысы икәнлегең әлегә шактый сизелә,—диде,—барысын да чәйнәп каптырырга тырышасың. Мәктәп өчен, ихтимал, отышлыдыр да бу. Чөнки анда укучыларның хәзерлеге бик чуар. Безнең контингент бөтенләй үзгә. Алар зур конкурстан узып, иләктә иләнгәннәр. Үз теләкләре белән белгечлек алу өчен укыйлар. Башларын эшләтсеннәр. Кыенсынып торма, күбрәк мөстәкыйльлек бир".

Мөхсинә әби инде сукрана башлады, кызыгызга урын табыгыз, карый алмыйм, картайдым, дип чыгымчылый. Җәмилә үзе дә кызының надан карчык кулында калуын теләми, йөрәге әрни. Аның хәзер шәхес буларак формалашкан чагы. Сигез яшьтә инде бала акыл үсешенең туксан процентына ирешә. Таланты бар икән, ул ун яшькә чаклы ачылырга тиеш. Бу үсешне фәкать бакча гына тәэмин итә ала.

Ләйсәнне урнаштыру барыбер Мансур җилкәсенә төште. Янә бәхет кыйпылчыгы ярдәм итте.

Шулай беркөнне редакциядә азау теше чыгарган хезмәттәшләре Мансурның кулына "Теләнче журналист" кагыйдәләре җыелмасын тоттырдылар. Ул үз эченә түбәндәге киңәшләрне ала.

"Йомышың төшкән кешегә рәсми рәвештә шалтыратып, миңа сезнең турыда мәкалә язарга куштылар, дип әйт. Ул, әлбәттә: "Кем кушты?"—дип сораячак. "Өстән!"—диген, артык сүз әйтмә. Түрә ризалыгын бирә, сез очрашасыз. Ләкин шәхси гозерең турында ләм-мим. "Мәкаләне үземә укытырсыз ич?"—дип үтенәчәк ул. "Партия газетасында андый гадәт юк шул",—дип бераз сатулаш. Аннан соң: "Сезнең өчен генә ташлама ясарга булырдыр, мөгаен",—диген. Шунда героеңны мактап ал, сезне монда озак тотмаслар, югарырак урынга күтәрерләр, дип салпы ягына салам кыстыр. Тик горур бул, үзеңне эре тот.

Мәкалә язылып беткәч, машина җибәрегез, дип шалтырат. Язма, һичшиксез, аңа ошаячак. Чөнки син аны мактап язасың.

Түрә коньяк тәкъдим итәчәк. Үзең генә эчмә. Бергәләп, чәкештереп эчегез. Бераздан ул: "Мин сезгә берәр нинди ярдәм күрсәтә алмыйммы?"—дип сорар. Рәхмәт әйт, ризалашма. Тагын бер чәркә төшереп алгач, кайтырга җыен. Һәм ишек тоткасына тотынгач кына, сүз аралаш кына, теләгеңне белдер.

Түрә шатланып телефон трубкасына үреләчәк".

Кодекс, сүз дә юк, шаяру гына. Ләкин шушы шаяру кармагына эләгүчеләр дә табыла икән әле. Әнә, шәһәр халык мәгарифе бүлеге мөдире эләкте бит.

Ләйсән бакчага йөри башлады.

Шул көннәрдә Кормаш күчтәнәче дә килеп иреште. Карап торуга сарык итеннән бер аермасы да юк кебек. Төсе генә тоныграк, болганчык суга тыгып алган кебегрәк.

Җәмилә бик шатланды. Әйтерсең лә, гает корбаны чалганнар да, шул малкай аны сират күпере аша очыртып кына алып чыгачак.

—Кечке ашны аерым ашарга туры килердер, мөгаен,—диде Җәмилә.—Һәр фирка үзенә-үзе әзерли.

—Ләйсән дә үзенә бер фиркамы?—дип сорады Мансур.

—Юк, сез икегез бер фирка.

—Күрәселәре бар икән башкаемның,—дип, Мансур юри хафаланган булды.—Ләйсәнгә рәхәт, ул бакчада ук кичке ашны ашап кайта.

—Ярар инде, миннән булсын яхшылык,—диде Җәмилә,—бу тәртипне иртәгәдән кертербез, бүген күчтәнәчтән сезгә дә өлеш чыгарырга туры килер.

Җәмилә зәңгәрсу төстәге озын халатының җиңнәрен сызганып куйды да, гәүдәсенә чит-читләре кызыл тасма белән каймалган алъяпкычын япты. Аннан соң ишеккә беркетелгән кечкенә түгәрәк көзгегә карый-карый чәчләрен яулыгына төрде. Коеп куйган хуҗабикә! Мансур хатынының артыннан килеп кочаклады.

—Мин сине яратам,—дип пышылдады ул аның колагына.

—Белмим, белмим... Элекке яратышулар бетте инде хәзер. Абый белән сенел кебек яшибез.

—Җәмилә, үзең беләсең...

—Беләм. Ләкин мәхәббәт авырлыкка, җинеллеккә карамый. Ул җә бар, җә юк. Үзең дә элек шулай әйтә идең ич, оныттыңмыни?

—Бу нинди төртмәле сүзләр инде, Җәмилә, ә?

—Дөресе шулай, Мансуркаем. Хатын-кыз күңеле лазер-барометрларыннан да сизгеррәк ул, барысын да тоеп тора. Әллә син миңа игътибар итмиләр дисеңме? Ничек кенә әле! Бик беләсең килсә, трамвайларда тынгы бирмиләр.

Татар ире мондый сүзләрне күтәрә аламы соң? Ничек инде? Сүз кушарлар ул, чибәр хатыннар янында селәгәйләрен агызып йөрүчеләр бихисап. Ә нигә дип аларны тыңларга?

—Әле син шулай трамвайларда кете-мете килеп йөрисеңмени?—дип усал эттәй ырылдады Мансур.

—Ә-ә, үтең сытылдымы?—дип ирештерде Җәмилә.—Үзең ничек, без дә шулай...

—Җәмилә, шаяртма әле, алай булмый ич инде...

Бу Җәмиләнең ирен сынап каравы иде. Чөнки ул әле һаман кимсенеп яши. Чит кешеләр аның тышкы матурлыгына, килеш-килбәтенә карап хөкем йөртә, физик кимчелеген күрмиләр. Ә Мансур барысын да белә. Ул аны астыртын гына төрлечә сынап карый. Бу юлы көнләштерергә уйлаган иде. Нәкъ төймәсенә баскан икән. Көнчелек хисләрне ныгыта, дигән бит бер француз язучысы да. Көнчелек корты ир кешенең күңелен һәрвакыт кимереп торырга тиеш, имеш. Французларга ышанырга мөмкин. Бу өлкәдә аларны уздыручы юк.

—Хатын-кыз ир-атка караганда, гөнаһлырак. Әмма әйбәтрәк. Һәм әйбәтрәк, һәм гөнаһлырак,—дип, Җәмилә кайсыдыр аксакалның сүзләрен кабатлады.

—Күрәм, син инде теориясен дә хәстәрләп куйгансың...

Җәмилә максатына иреште. Тик бәхәсне болай икеле-микеле төгәлләргә ярамый, каш ясыйм дип күз чыгаруың да бик мөмкин.

Хатын-кыз гөнаһлырак кына түгел, иң хәйләкәр пәри заты да бит әле ул. Кирәк чакта мәхәббәт угын очыртып, сихерләп тә куя. Җәмилә дә иркә мәче баласыдай мыраулап, Мансурның куенына керде, тәнен өттереп алды. Ә үзе: "Сабыр ит, җанаш, бар Ләйсәнне алып кайт, котәдер",—дип читкә тайпылды.

Җәмилә ире белән кызын күчтәнәч итеннән аш пешереп, табын хәзерләп каршы алды. Өстәл затлы ресторан табынын хәтерләтә иде. Сөттәй ак ашъяулык. Савыт-сабаның барысы да бер иш, кашык-аяклар ялтырап тора. Уртада ваза. Ваза эчендә өч бөртек канәфер чәчәге. Һәр прибор алдына ашъяулык кебек үк чиста-пакь кулсөрткеч. Бернинди артык әйбер юк. Гади дә, зәвыклы да. Җәмилә матурлыкны ярата да, аны тудыра да белә.

Ләкин Мансур табын янына теләр-теләмәс кенә утырды. Күңеленнән әллә нинди сәбәпләр, әллә нинди хәйләләр эзләп карады. Таба гына

алмады. Шунда ук эченнән генә үзен эгоист дип сүгеп тә ташлады. Җәмиләгә ярый, ә аңа—юк. Каян килгән хан-патша? Тик, ничек кенә тырышмасын, җирәнү хисеннән арына алмады. Үзенә ошаган ризыктан да әллә ниләр эзләп казынып утыра ул. Ә монда эт ите! Белә торып аны ничек ашамак кирәк, ди? Җәмиләгә дару ул. Сәламәт кешегә даруның хаҗәте юк.

—Ашың суына, житеш,—дип кыстады Җәмилә.—Ите дә бик тәмле. Әнә, кызың да ошатты.

—Тәмле, бакчада гел кәтлит тә кәтлит, ит бирмиләр,—дип куәтләде Ләйсән әнисенең сүзен.

—Салаттан арынып булмый әле монда,—дигән булды Мансур. Башкача сузып булмый иде инде, ашка тотынырга вакыт житте. Ул күзләрен чытырдатып йомды да, тәмен тоймаска тырышыбрак кына шулпаны тамагына агызды. Шул рәвешчә өч-дүрт йотымда тәлинкәсенең төбенә дә төште. Ит калҗаларын чәйнәмичә генә шудырды. Шунда ук урыныннан да торып басты.

—Нигә кузгаласың, чәй әзерлим,—диде Җәмилә.

—Мин машинаны гына карап керәм, ишекләрен бикләмәгән идем...

Мансур ишек алдына атлап түгел, очып чыкты. Чыгуга бөгелеп тә төште. Эчәгеләре авызына килгәнче косты да косты...

Сер дигәннән, Мансурның тагын бер сере бар. Анысы җиде йозак белән бикләнгән тимер сандык эчендә. Ул аны фәкать үзе генә белә.

Беркөнне аны профессор Кәримов чакыртып алды.

—Җәмилә ханым пенсиядән баш тарта,—диде ул үпкәләгәндәй,—башкалар арттан йөриләр, таныш-белешләр аша басым ясыйлар, ә ул якын да килми... Мин сезне шул хакта сөйләшергә чакырдым, атакай.

—Гафу итегез, нинди пенсия?—диде Мансур.—Сез башка кеше белән бутыйсыз булыр. Аңа әле утыз да тулмаган.

Профессор үзенә бер сәер житезлек белән терсәкләрен өстәлгә кадады да, баш бармакларының очларын иягенә тигезде. Хәрәкәтләре искиткеч матур, нәфис иде. Каршында, әйтерсең лә, тулы гәүдәле, гөбедәй юан куллы кеше түгел, ниндидер гимнаст утыра иде. Бу, күрәсең, аның профессиональ күнекмәләреннән килә иде. Хирургның хәрәкәтләре гимнастларныкына караганда да төгәлрәк булырга тиеш иң.

—Инвалидлык пенсиясе, атакай, инвалидлык пенсиясе...

Мансурның утырган урындыгы гына шыгырдап куйды, сүзе чыкмады.

—Инвалидлык пенсиясе, атакай,—дип кабатлады профессор.

—Нинди пенсия, сез соң үзегез хәле яхшы, борчылмагыз,—дип каткат тәкърарлап торасыз...

—Әйе, атакай, хәзер дә әйтәм: Җәмилә ханымның организмы искиткеч нык, күз генә тимәсен. Өмет зур. Ләкин ул шулай ук бик житди операция дә кичерде. Бер әгъзасы алынды. Аяксыз-кулсыз авырулар кебек үк без аны пенсиягә тәкъдим итәргә тиеш. Законы шундый.

Җәмилә бервакытта да пенсия артыннан йөрмәячәк. Бу аның өчен үлем белән бер булыр иде. Шуңа күрә әлеге сүзне Мансурга житкерүне дә кирәк санамаган.

—Җәмилә ханымның сырхавы икенче группага тарта. Әмма бу группа эшкә киртә куя. Әйдәгез, атакай, өченчегә килешик. Үзенә әйтеп тә тормабыз.

—Хәзергә мин берни дә әйтә алмыйм,—диде Мансур.

—Башка юл юк, атакай. Аңа бик кыйммәтле дарулар кирәк булачак. Акчасын шуңа тотарсыз. Хәзергә хушыгыз. Мин сезне көтәм.

Мансурның башын бу уй да бораулап тора.

* * *

Әле болытлар арасыннан кояшның укалы күлмәге күренгәләп китә, әле жиргә сибелгән яфракларны күккә чөеп, жил котырынып ала. Карыйсың, тирә-як ак томанга чума. Бу, әлбәттә, күз галәмәте. Күзгә күннен күлүе, күлүе дә елавы. Шушыдыр инде ул, мөгаен.

Әмма соңгы елларда табигать эзеннән чыкты, саташтыра башлады. Әлеге мәкаль инде күздән битәр, кышка туры килә. Һәрхәлдә, 1971 елның кышы нәкъ назлы кияү акылы шикелле кирәле дә чыгалы иде. Кырлач уртасында тотты да яңгыр яуды. Ә көннәрдән-бер көнне шәһәр халкын йокысыннан күк күкрәве уятты. Ул көнне халык гел шул хакта гына сөйләште. Галимның да телефоннан әйткән беренче сүзе күк күкрәү турында иде.

—Син күк күкрәвен кайсы колагың белән ишеттең?—дип сорады.

—Юк белән башымны әйләндермә әле, зинһар, ни йомыш, тизрәк сөйлә, вакытым тар,—диде Мансур түземсезләнеп.

—Харрасов булсам, синең кебек надан журналистның артына тибеп чыгарыр идем. Бәхетең, мин Харрасов түгел.

—Жорланма, әйтсәң әйт, хәзер трубканы куям.

—Алай кырт кисмә, дустым, бу бик мөһим.

—Нәрсә мөһим?

—Нәрсә-нәрсә, күк күке кычкырганчы күкрәде, димәк ки, жәйгә өмет бар. Төшенденме, шалкан баш? Монысы—беренчедән. Икенчедән —мин күк күкрәвен уң колагым белән ишеттем. Бел, абзаңның быел эше гөрләячәк.

—Кыш уртасында нинди күке кычкырсын ди, ахмак.

—Инде хәбәрнең иң кәттәсе. Урындыгына ныклабрак утыр, жә, егылып төшеп бәлә булырсың.

—Сузма инде, алла колы, кыл да сыймастай вакытта...

—Шимбә көнне Лилия мәжлес жыя. Сара Садыйкова да чакырулы. Бармакларыңны шомартып, тамагыңны майлабрак кил. Инде төшендеңме, бүген ни өчен күк күкрәде?

—Оста барда телеңне тый диләрме әле?

—Ә син үзеңнең чебен танавын чарларлык егет икәнлегеңне дәлилләү.

* * *

Сара ханым иртәнге күкрәү булып инде мәжлескә. Бусагадан атлап керүгә, ниндидер сихри тынлыкка талган мәртәбәле фатир күңелле шау-шу белән тулды. Автобуста кемдер аягына баскан икән, башта шул "аю табанны" тетте Сара ханым. Галимгә дә эләкте. Пальтосын жайсызрак салдырды, күрәсең.

—Хатын-кыз лалә чәчәге кебек бик нәзберек зат, — дип аң-белем өйрәтте йорт хужасына,—аңа бик саклык белән генә, иркәләп кенә кагылырга кирәк. Ә син мужик кулларың белән жилкәмне авырттырдың. Их, минем Айдарский шикелле джентельменнар юк инде ул хәзер, көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың.

Мансур аның радиодан жырлаганын күп тапкырлар ишеткәне бар. Чишмә челтерәвенә охшаш нәфис тавыш. Йомшак, моңлы. Ә ишек катында яңгыраган тавыш бөтенләй башка. Үсмер малайларныкына тартым калай тавыш. Ләкин ул кайсыдыр ягы белән үзенә тартып тора иде. Аның сәбәбенә Мансур соңрак төшенде. Лилиянеке шикелле шәһәр сөйләме иде артисткада. Авыл кешеләре сүзләрне сандалга жәеп салып, авызына дыңгычлап тутырып сөйләшә. Каланыкылар сүзне ирен очыннан гына очыра, аңа рус теле аһәңе дә кушыла. Кылтыграк сөйләм. Сара ханым да үзенә генә хас кылану белән сөйләшә иде. Ике сүзнең берсендә ире Айдарскийны үрнәк итеп куя. Башка ир-атларның гамәлен Айдарский

образы аша үткәреп бәяли. Табынга утыруга хатын-кызларны да җилтерәтеп алды.

—Ирләрегезнең кадерен белмисез, шуңа күрә һәмергә табыналар, азып-тузып йөриләр. Менә мин Айдарскийны бик хөрмәт итә идем, тәмледән-тәмле ризыклар гына пешерә идем, йокларга ятканда аякларын җылы су белән юа идем...

Мансур Җәмиләгә кагылып куйды, белденме, янәсе, ничек була икән яхшы хатыннар.

—Юри генә ирештерә булыр, юдырырсың артисткадан аяк.

Кашык-чәнечкеләрне уйната башлаганчы, Лилия кунаклар белән таныштырып алды. Асылда бу аларны Сара ханымга тәкъдим итү иде. Сара ханым һәр кешене күз унынннан үткәреп, үз фикерләрен әйтә барды. Җәмиләне Елена Быстрицкаяга ошатты, сезгә киноартистка булырга иде, диде. Мансур исә коеп куйган Айдарский икән...

Ниһаять, мәҗлес үз киртәсенә керде. Шәраб кунакларны батырайтып, канатландырып җибәрде. Кемдер җыр турында сүз кузгатты. Бу, әлбәттә, Сара ханымның кылын тартып карау иде. Танылган җырчы, популяр композитор һөнәрен күрсәтми калмас бит инде.

—И, дусларым, өтек койрыклы кош шул инде мин хәзер, күзгә сандугач. Түрәләр композиторлык эшемне дә хупламыйлар, син консерватория бетермәгән, чуалып йөрмә, диләр. Ә күңел "ярамыйны" кабул итми, җырларым ургылып чыга.

—Салих Сәйдәшевны эзәрлекләгәннәр иде, инде чират сезгә җиттемени?—диде Лилиянең дус табибәсе.—Ни җитми соң ул Нәҗип Җиһановка? Алмаган исеме калмады бит инде. Сәйдәшевка берсе дә тәтемәде. Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен матәме вакытында бик дөрес әйтте, Салих Сәйдәшев—халык лауреаты.

—Матурым, сүзләрең алтын. Тик монда Нәҗипнең гаебе юктыр дип уйлыйм. Алай белер—белмәс кешегә пычырак атарга ярамый. Нәҗип зур композитор. Опера язу һәр композиторның да кулыннан килми. Опера җыр сәнгатенең таҗы. Мин үзем дә опера җырчысы идем. Беләм. Җиһанов—үз урынында, Сәйдәшев—үз урынында. Икесенә дә мәйдан җитәрлек.

Мансур бәхәскә кермәде. Чөнки Галим инде хәтсездән аңа мәгънәле итеп карап-карап ала, бу аның баянынны тарт дигән сүзе иде. Нишлисең, тынламыйча булмый. Сара Садыйкованың җырларын да караштырып-барлаштырып килгән иде. Хәзер, әнә, "Казан кичләре"н яратып җырлыйлар.

Беренче аккордыннан соң ук мәҗлес тынып калды. Бүлмәгә җыр таралды.

> Кил әле, Иделнең җиләс җиле,
> Юлларга чәчәкләр сип әле,
> Ак булып, саф булып истә калсын
> Казанның кадерле кичләре.

Сара ханым җитдиләнде, буяулы нәзек кашлары ак маңгаенда сикергәләшеп алды. Муенын аз гына алга сузган хәлдә тынып, сагаеп калды.

Мансур астыртын гына аны күзәтә. Композитор, әлбәттә, үз җырларын профессиональ артистлар башкаруында тыңларга күнеккәндер. Алар үзешчәннәрне бик санга сукмый бит. Күр, ничек үзгәрде, йөзенә карасу төште. Ошатмый. Мансурның да тиз генә бирешергә исәбе юк, сыналгач сыналырга инде.

Җыр агымында ул түбәнрәк тонга күчте. Тонны үзгәртү катлаулы алымнардан санала. Әнә, композитор апабыз да күз очлары белән генә елмайгандай итте.

—Мин сезне үземнең хорыма солист итеп алыр идем,—диде Сара ханым җыр тәгәлләнгәч.—Ә баянынны алай каты басып уйнама. Моңны

чибәркәен Җәмиләгә караганда да артыграк назла. Айдарский шулай итә иде.

Шуннан соң җәт-җәт басып пианино янына барып утырды. Берара башын артка чөеп, уйланып торды. Аннан соң ун бармагы берьюлы клавишларга ятты.

Моң!

Аһәнле вә садә татар моңы! Ул әле сандугач булып сайрый, әле таш-тау арасыннан саркып чыккан иркә чишмәдәй челтер-челтер килә, әле саз кылы кебек сызлана... Анда шатлык та, юксыну да, сагыш та, бәхет тә—барысы да бар. Күңел балавыздай эри, йомшара, пакьләнә, сафлана.

Ә бармаклары? Өрфия жилдәй тибрәләләр.

Уен тәмам. Әмма бүлмәнең һавасына кадәр сарылган моң тыңлаучыларны әле һаман үз кочагында тота. Тып-тын. Берәү дә бу моңлы тынлыкны бозарга батырчылык итми.

—Мансур әфәнде, бию көйләрен сез уйнагыз, алары миннән булмый, буыннарым сызлый,—дип Сара ханым үзе кешеләрне моң әсирлегеннән чыгарды.

Мансур пианинода да шактый йөгерек уйный. Шуңа күрә бу юлы пианинога утырды. Мактанасы да килеп китте, билгеле. Гадәттә, ул башлап Җәмилә өчен уйный. Хәзер дә әлеге традицияне бозмады. Монысы да аның мактанычы. Чөнки Җәмилә бик матур бии. Ә иң яратканы башкорт биюе.

Үз көе яңгырауга Җәмилә су өстендәге аккош шикелле йөзеп тә китте. Куллары гүя камыр, әллә нинди рәвешләргә кереп бетә. Бер арада кош канатларыдай җилпенеп ала, шунда ук җәядән ычкынган ук шикелле югарыга омтыла. Икенче мизгелдә самими бер нәзакәтлек белән гәүдәсенә сылана... Ә гәүдә төп-төз. Вакыт-вакыт үкчәләре генә тыпырдап куя.

Сара Садыйкова белән очрашуга Мансур зур өметләр белән килде. Аның берничә җыры бар. Шуларга карата күптәннән берәр профессиональ композиторның фикерен беләсе килеп йөри иде. Шушы форсаттан файдаланып калу иде исәбе. Җае да туры килде. Биюләр тәгәлләнеп, янә бер тәгамлап алгач, Сара ханым үзе аның җырлавын үтенде. Һәм Мансур үзенең җырын тәкъдим итте.

Кил, Җәмиләм, минем, кил син миңа,
Таң кошыдай күңел кагынсын,
Алсу таңнар янсын безнең өчен,
Керфегеңдә йолдыз кабынсын.

Мансур башта каушабрак калды. Ләкин тора-бара җыр аны үз дөньясына тартып кертте. Җәмилә белән очрашуы, гашыйк булуы, сөйгәне турында хыялланып үткәргән төннәре, пароходта беренче тапкыр иреннәренең кавышуы—һәммәсе күз алдыннан үтте. Хисләр элекке кебек үк, сүнмәгән, сүрелмәгән. Җәмилә аның бердәнбере!

—Браво, браво, афәрин!

Җырның азагын Сара ханым аягүрә басып тыңлады. Башкалар да күтәрелде. Дәррәү килеп кул чаптылар.

—Мансур әфәнде, бу сезнең үз җырыгыз, шулай бит, әйеме?—диде Сара ханым үзенә хас балаларча шатлану белән.—Искиткеч лирик җыр! Сүзләре нәкъ Такташча: "Нигә, нигә синең шаян күзләр, күзләремә болай багалар..." Мәхәббәт җыры.

—Әйе, Сара апа...

—Дусларым,—диде Сара ханым мәҗлескә мөрәҗәгать итеп,—монда иң бәхетле зат—Җәмилә ханым. Мин дә сөйдем, мин дә яраттым. Үлепләр яраттым. Ләкин миңа атап берәү дә җыр язмады, хәтта Айдарский да. Мин шушы олы мәхәббәт өчен тост тәкъдим итәм.

Җәмилә бу минутта ак томанлы җәйге таңнарда иде. "Мин нинди

бәхетле, минем Мансурым бар". Шушы сүзләрне бөтен җиһанга ишеттерерлек итеп кычкырасы килде. Тик аны хисләр ташкыны шулай китереп кыскан иде ки, хәтта рәхмәт тә әйтә алмады.

Сара Садыйкова белән алар бер машинада кайттылар. Таксины Мансур чакыртты. Зур түрәләр өчен махсус телефон номеры бар икән. Шундук җавап бирәләр, шундук машинасын да җибәрәләр. Харрасов бер кәефе килгән чакта ул номерны Мансурга да биргән иде. Ләкин кисәтте, башта уйлан, диде, минем исемгә тап төшермәслек булсаң гына файдалан, диде. Менә кирәге чыкты бит. Ун минут эчендә такси ишек төбенә килеп туктаган иде инде. Бу да Мансурның абруен күтәреп җибәрде.

Мансур Сара Садыйкованы йортына кертеп калдырды. Ул аны бик зур, бик зиннәтле фатирда яши дип уйлаган иде. Баксаң, бер бүлмәле генә икән.

—Мансур әфәнде, җырларыгызны радиога тәкъдим итегез,—диде ул саубуллашканда,—талантыгызга йозак элмәгез!

Мәшһүр артистканың бу сүзләре Мансурны очындырып җибәрде. Аның үзенә карата "сәләтле укытучы", "сәләтле журналист" дигән сүзләрне ишеткәне бар иде инде. Әмма әле берәүнең дә "талант" дигәне юк иде. Әйе, ул үзен-үзе белә-белгәннән бирле җыр-моң яратты. Авылда аны узган гармунчы юк иде. Ходай тавыш та биргән. Җыр аны сәхнәгә күтәрде. Илһамы килеп, үзе дә берничә җыр язды. Көтмәгәндә Сара Садыйкова аның бу иҗатына олы бәя бирде. Шуңа күрә ул җырларын икенче көнне үк радиога илтеп тапшырды.

Әлеге очрашудан соң Мансур тынычлыгын югалтты. Җиде төн урталарында уянып китә дә, әллә нинди хыялларга бирелә. Их, атка атланасы иде дә, үсмер чактагы сыман Сөн буе сукмакларын иңләп-буйлап җилдәй очасы иде. Нинди рәхәт була иде: колак очларында җил сызгыра, йөзгә салкын һава бәрә. Ә күңел? Күңел ашкына, елгыр елкыдан да алдарак элдертә...

Кеше кайда гына төпләнмәсен, нинди генә югарылыкларга ирешмәсен, туган туфрактан, туган җиреннән олы була алмый. Кечкенәме-зурмы, баймы-ярлымы, кендек каны тамган җир—бердәнбер изге җир. Ә иҗатчы өчен туган җир уннарча, йөзләрчә мәртәбә газизрәк. Чөнки иҗатның чишмә башы—туган җир.

Мансур журналистикага тиз кереп китте. Инде публицистиканың иң дәрәҗәле саналган очерк жанрында уңышлы гына эшли башлады. Бу өлкәдә аның үз сукмагы. Язмасын ул ерып чыга алмастай саннар белән тыгызлап тутырмый, фикеренең хаклыгын югары даирә җитәкчеләрнең докладларыннан алынган цитатлар белән дә дәлилләми. Шуның өчен аны еш кына тәнкыйтьлиләр дә. Мансурны исә кешенең табигате, эчке халәте, гамәлләренең психологик һәм логик акланышы кызыксындыра.

Ләкин чын-чынлап әдәби иҗатка керешергә базмый, чабуыннан нәрсәдер тота, җәелеп китәргә ирек бирми. Сәбәбе нидә моның—ул аны тәгаен гына әйтә дә алмый. Югыйсә, күңеленең тирән төпкелләрендә көмәндәге яралгыдай нидер бөреләнгәнен сизеп-тоеп тора.

Мансур үзенең бу халәтен хәтта Җәмиләгә дә сиздермәскә тырыша. Чөнки ул аны ымсыну дип кенә саный. Уалып китмәсен, ватылып челпәрәмә килмәсен, дип хыялларына үзе дә кагылырга курка. Тик әлеге газаплары аңа барыбер рәхәтлек алып килә. Моны кеше белән бүлешеп тә, уртаклашып та булмый. Хыял күңеленә кереп ояладымы, шәһәр шау-шуы да, кешеләр дә, мәшәкатьләр дә каядыр китеп югала. Уйларың белән япа-ялгыз каласың. Ә уйларның аты йөгерек, минут эчендә Каф тау артларына барып кайта.

Бүген дә шундый күтәренке халәттә иде. Төш вакытында Җәмилә: "Җиңгәм авырып тора икән, Ләйсән белән хәлен белеп кайтыйк әле",—дип җыена башлады.

Мансур аларны озатып куйды да, Ленин бакчасына керде.

Табигатьнең йөзе ачык иде. Тыныч, матур көн. Бакча тулы балачага. Әти-әниләренең, әби-бабаларының сүзләренә колак та салмыйлар, ирекә чыккан кәҗә бәтиләре кебек сикерешәләр, йөгерешәләр, аунашалар. Ун канаттагы эскәмияләрне шахматчылар яулап алган. Ачык авызлар да хәтсез. Мансурга боларның берсе дә кирәкми. Аның уенда бөтенләй башка манзаралар...

—Исәнмесез, Мансур Әмирҗанович?

Мыегы керпе энәләредәй тырпайган бу кеше Мансурга таныш, әлбәттә. Тик кайда күрде соң әле ул аны? Һич хәтеренә төшерә алмый.

—Танымыйсыздыр шул,—диде Керпе мыек,—кайгы кешене үзгәртә икән...

—Нинди кайгы?—дип сорыйсы итте Мансур. Ләкин ул аны һаман танымый иде әле.

—Кифая апанны машина таптады бит. Сезне бик үз итә иде...

—Габбас абый, сезмени бу?

—Мин, Мансур дус, мин...

Теге вакытта Галим белән кызган баштан өйләренә шалтыратканнан соң белешкәне юк иде әле. Хәер, аралашуның хаҗәте дә калмады ич, диссертация барыбер янган иде ич инде. Ике-өч ел гомерен "урлаган" шушы кеше, доцент Ярмиев инде каршысында басып тора. Ничек исәнләшергә йөрәге житкән? Ихтимал, соңарып булса да намусы кузгалгандыр. Үзе әйтмешли, кайгы кешене үзгәртә бит ул. Картайган, бөкереләре чыккан. Мескен бер адәм. Киеменең дә рәте-чираты юк. Ул инде үч алырлык кеше түгел, аны фәкать жәлләргә генә мөмкин.

—Кайгыгызны уртаклашам,—диде Мансур.—Кирәгем чыкса, шалтыратыгыз, менә телефон номерым...

—Мин беләм,—диде Ярмиев,—язмаларыгызны укып барам. Кыю язасыз. Сез инде мине...

—Кирәкми, зинһар, кирәкми,—дип бүлдерде аны Мансур,—үткәнбеткән. Хушыгыз!

Мансур ашыга-ашыга китеп барды. Озак та үтми бажасының ишеген какты.

—О-о, жизнәкәй, әйдә, уз, нинди жилләр ташлады?—дип, Рәшидә аны көтеп алынган кунак кебек каршы алды.

—Китапханәгә килгән идем, берочтан хәлегезне белеп чыгыйм дидем... Айдар кая соң? Илсур ташбаш та күренми...

—Айдар командировкада. Илсур кунакта. Аулагөй, жизнәкәй. Хәзер табын хәзерлим. Сагынып сөйләрлек йтеп утырыйк әле бер.

—Килешер микән соң?

—Килештерсәң килешә ул, жизнәкәй...

Рәшидә торып кына килә иде булса кирәк. Борынга ятак исе, тән исе бәреп керде. Рәшидәнең язгы бөре шикелле кабарынкы йөзе, жилкәсенә таралып төшкән куе чәчләре табигый самимилек белән үзенә тартып тора.

Хатын Мансурның бу игътибарлы карашын үзенчә гөманлады, ахры. Җәт-җәт басып өстәл хәзерләгәндә бер генә мизгелгә озын атлас халатының итәкләре жилләнеп куя, шәрә балтырлары күренеп-күренеп ала, изүе ачылып киткәли...

Хатын-кыз ир-егетләрне юлдан яздыру өчен яратылган зат. Беренче гөнаһны да хатын-кыз кылган. Аңа кадәр гомумән гөнаһ дигән төшенчә дә булмаган ич.

Хатын-кызның килеш-килбәте, бөтен гамәле: кием дә, сөйләме дә, үз-үзен тотышы да ир-егетләрне яулап алу, кулда тоту максатына юнәлдерелгән. Аның күңелендә һәрвакыт шайтан ята. Уңайлы вакыт життеме, хәзер башын калкыта. Ә ир-ат тиз ышанучан беркатлы мәхлук, аны ияләштерү хатын-кызга берни тормый, чытлыкланып күз ату да житә. Үзен бик акыллыга санаса да, ир-ат чибәркәйләрнең җәтмәсенә төшкәнен сизми дә кала.

Ә Мансур җәтмәдә инде. Ә менә гүзәл зат бу уенны уен өчен генә уйныймы, чын-чынлапмы, анысын ул фәкать үзе генә белә.

Мансур исә Рәшидәне реаль хатын-кыздан бигрәк, хыялы тудырган илаһи мөслимә образы сыйфатында кабул итә иде. Шуңа күрә балдызын һич кыенсынмыйча, эчке бер соклану белән күзәтте. Бу аның театры иде.

—Табын әзер, җизнәкәй,—дип Рәшидә Мансурны сәхнәдән жиргә төшерде,—чәркәләргә шампан агызасы гына калды, анысы инде егетләр вазифасы.

Мансур бу ышанычны яртылаш кына аклады. Чөнки шәрабның яртысы газы-ние белән түшәмгә чәчрәде.

—Борчылма, шампанның бөтен кызыгы шушы аның,—дип юатты Рәшидә.—Инде тост әйт, җизнәкәй, жыр белән, миңа атап...

Теләкләре тәңгәл килде. Мансур инде күнеленнән жырны сайлап та куйган иде. Бокалын кулына алды да, кешегә чыгармаслык серләре бардай Рәшидә үзе генә ишетерлек итеп, жыр башлады.

Син кайда иден
Кайларда йөрден,
Ничек мин сине
Күрмәдем икән?
Син торган йортны,
Синең урамны
Ничек кенә мин
Белмәдем икән.

Рәшидә аны, чыннан да, үзенә атап чыгарылган жыр кебек кабул итте. Керфекләре дымланды, ирен кырыйлары мелт-мелт килеп алды. Ә күзләре—Мансурда.

—Нинди бәхетле минем апам,—диде Рәшидә жыр төгәлләнгәч,—кадерен белә микән ул бу бәхетнең?

—Синең Айдарың да булдыклы егет ич, Рәшидә, бар кешегә дә жырларга димәгән.

Хатын әче нәрсә капкандай йөзен чытты. Мансур аларның этлемәчеле яшәүләрен белә иде, әлбәттә, ләкин Рәшидәнең ирен бу дәрәҗәдә үк күрә алмавын күз алдына да китерми иде.

—Җизнәкәй, әйдә, чит кешеләрне онытып торыйк әле,—диде Рәшидә.—Без икәү генә, җәме!

Ул Мансурны тагын-тагын жырлатты. Шактый гына кыздылар да. Китапханә дә онытылды.

—Телевизорны кабызыйммы?—дип сорады Рәшидә бераздан.

—Миңа барыбер...

Рәшидә, әллә ялгыш басты, торам гына дигәндә авышып китте дә, Мансурның алдына ауды.

—Җизнәкәй, башым әйләнә, жизнәкәй...

Җә, алла! Нинди хозурлык! Хозурлыккынамы? Җәннәт! Инде күптәннән мондый ләззәтле хисне кичергәне юк иде Мансурның.

Ир кеше өчен сәламәт хатыннан да зуррак хәзинә бармыни ул?

...Мансур өйгә кайтканда Ләйсән йоклаган иде инде. Исерек иренә Җәмилә дә бәйләнеп тормады, урын җәйде дә яткырды. Җингәләреннән болай да кәефе кырылып кайткан иде. Элек нинди күңелле яшиләр иде. Кичләрен өстәл тутырып утырырлар иде. Уен, көлке. Җингәсе аңа карата кырыс булды. Әмма бервакытта да гаделсезлек эшләмәде. Җәмилә үзе дә аны "апа" дип кенә йөртә иде. Бу заманда кыз баланы исән-имин саклау, абруен тоту жинелләрдән түгел. Кызның исеме кыл өстендә, кыл өстеннән төшсә, ил өстендә, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Үзе Ләйсән өчен хәзер үк борчыла башлады инде.

Абыйсы үлгәч, ул дөньяның асты өскә килде. Маржа килен тәмам

үз тәртибен урнаштырып бетергән. Ишек катындагы коридорны бүлеп, бер кечкенә бүлмә әтмәләгәннәр дә, әниләрен шунда чыгарганнар. Аерым ашыйлар. Хәлен дә белмиләр икән.

Җәмилә аш-су әзерләп, җингәсенен керләрен юып кайтты, сырхауханәгә алып барырга сөйләште.

* * *

Мансур йокысыннан гадәттәгедән сонрак уянды. Җәмилә китәргә җыена иде инде. Ул иртәрәк йөри, юлы да ерак, ярты шәһәрне үтәсе.

—Башны калкытып булмыймы әллә?—диде Җәмилә бәйләнмичә генә,—кичә йөгең нык кыйшайган иде. Мондый хәленне беренче тапкыр күрүем. Нык сыйлангансыз.

—Эчелгән шул,—диде Мансур. Әйтерсен лә, хәмерне авызына егып салганнар иде.

— Ләйсәнне дә уятырга вакыт, сонга калмагыз, — дип кисәтте Җәмилә.

Хатыны чыгып киткәч, Мансур җыелмаган урын-җир өстенә утырып уйга батты. Рәшидәләргә ничек барып эләкте сон әле ул? Иблис дигәннәре әллә дөрестән дә бар инде? Кешене гөнаһлы сукмакка шул өрәк кертә ди бит. Туктале, нәрсәләр булды сон әле анда? Рәшидә табын әзерләде. Ул тост әйтте, җырлады. Эчемлекләре дә затлы иде. Башта шампан, аннан коньяк... И һәм шул! Артыграк киткән, каһәр, алай ук ярамас иде. Ә нинди ләззәтле төш керде бүген ана, ә? Шунын шаукымыдыр инде. Татлы төш. Җәмиләнен элекке чагы. Ул күкрәкләр... шалкандай ак тән... Яшь боланныкы шикелле озын нәфис аяклары гәүдәне уратып ала. Җанга ләззәт инә...

Әлбәттә, төш! Ләкин Җәмилә идеме сон ул илаһи зат?..

Уйлары бүленде. Чөнки “Әтием, мине ник уятмыйсын?”—дип Ләйсән аваз салды. Күрәсен, Мансурны хәтсездән күзәтеп яткан.

—Уянгансың ич инде, кызым, уянган кешене тагын ничек уятасың?

—Кил, өйрәтәм,—диде Ләйсән,—инде мина иел.—Кызы аны муенынннан кысып, бит очларыннан, маңгаеннан үбеп алды.—Менә шулай уяталар тәти кызларны, әтием.

Мансур кызын күтәреп алып күкрәгенә кысты. Кичәге хәлләрне оныттырса, Ләйсән генә оныттыра алачак.

—Кызым, чәй эчәсенме?—дип сорады аннан Мансур.

Ләйсән башын чайкап ана карап торды да:

—Әтием, син әллә бүген айдан төштенме?—диде.—Беләсен ич инде иртәнге ашны мин бакчада ашыйм. Өйдә дә, бакчада да ашасам, Винни Пух кебек булам ич. Әллә шуны телисенме?

— Теленә салынма, саескан, әйдә, киенәбез.

Редакциядә Мансурны яналык көтеп тора иде. Татарстанга Италиядән ике журналист килә икән, ул шуларны озатып йөрергә тиеш, имеш. Мона бик сөенде Мансур. Чөнки бер-ике генә көнгә булса да Казаннан китеп торачак. Бераз гына онытылып торыр, шәт.

Харрасов һәр эшне җиренә житкереп, бөтен шартларын да китереп куша белә иде.

—Партия өлкә комитеты, журналистлар союзы сина зур ышаныч баглыйлар,—дип белдерде ул доклад сөйләгәндәге кебек югары пафос белән,—бик җаваплы бурыч, әйтер идем, сәяси бурыч. Уяулык, тагын бер тапкыр уяулык сорала синнән. Үзең беләсең, алар капиталистик ил вәкилләре. Аларны барыннан да элек безнен тормышыбызның тискәре яклары кызыксындыра. Шуңа күрә маршрутны төгәл сакларга кирәк, аннан миллиметр да тайпылырга ярамый.

Шушы ук сүзләрне өлкә комитетында да кабатладылар. Черек күл

әһелләренең генә биремнәре үзгәрәк иде: нәрсә хакында сөйләшәләр–барысын да теркәп барырга!

Мансур "кунаклар"ны аэропортта каршы алды. Джузеппе дигәне озын гәүдәле иде. Ябык. Битендә бөркет томшыгы шикелле зур борыны гына тырпаеп тора.

–О-о, коллега,–дип авызындагы барлык тешләрен дә күрсәтеп елмайды ул.

Икенчесе Бенитто исемле. Анысы, киресенчә, юантык. Буе да чамалы. Сүзгә бик маһир түгел ахры, тешен кысып кына исәнләште. Тылмачлары хатын-кыз иде. Кыска итәкле бер чикерткә. Үзен кунаклардан да эрерәк тота. Әмма теле телгә йокмый, бик оста тәрҗемәче.

Кунакханәдә Мансур Черек күл егетләре белән күзгә-күз бәрелеште. Регистратурада хезмәт күрсәтәләр иде. Кунакларның паспортлары да беренче алар кулына керде. Дилбегәне кулдан ычкындырмыйлар, жир тишегеннән дә эзләп табачаклар болар, дип уйлады Мансур. Аларның эш алымы азмы-күпме таныш иде инде аңа. Армиядә хезмәт иткәндә еш кына бер майор чакырып ала иде. Авызында һаман бер сүз: "Сез югары белемле кеше, аңлы кеше. Батальонда безнең стройга кагылышлы негатив характердагы сүз була-нитә калса, миңа хәбәр итегез". "Карагыз аны, бу дәүләт сере, үзегез генә белегез",–дип тә кисәтә иде.

Соңыннан беленде, барлык солдатларга да шул ук биремне биргән икән майор. Һәркем күзәтү астында торган.

Италианнарны беренче чиратта КамАЗ кызыксындыра икән. Икенче көнне Чаллыга юл тоттылар. Көндезге уникегә партком секретаре Рощин белән очрашу билгеләнгән.

КамАЗ дирекциясе ГЭС Бистәсендәге биш катлы кирпеч йортта урнашкан иде. Иңкү урында төзелгәнгәме, бина жиргә сеңеп беткән сыман күренә. Ә эче киң. Коридорда кеше күп. Барысы да озын кунычлы итектән. Дөп-дөп басып йөриләр, кычкырып-кычкырып сөйләшәләр. Төзелеш кешеләре булса кирәк. Завод эш барышында гына проектлана бит, хәл итәсе мәсьәләләр бихисап, ди. Партком секретаре да шуннан зарланып торды. Тешләк дигән Бенитто аны шундук чагып та алды.

–Үзегез СССРда планлы хуҗалык дип мактанасыз, ә гигант заводны генераль плансыз төзисез, моны ничек аңларга соң?

Рощинның шома йөзенә күләгә ятты. Бермәл ни әйтергә белми аптырап та торды. Ә алдында диктофон. Ул аны челпәрәмә китереп ватып ташлар хәлгә житте.

Совет журналистларының эш коралы блокнот белән каләм. Шуңа күрә журналист язганнар белән теләсә-кем, мин болай әйтмәдем, дип бәхәскә керә, сүзләреннән баш тарта ала. Диктофон исә бөтенләй башка. Текст өстендә эшләү өчен дә уңайлы. Редакциядә дә бер диктофон бар. Түгәрәк өстәл янында сөйләшү вакытларында гына файдаланалар. Хәер, аны күтәреп йөрерлек тә түгел, үзе зур, үзе килбәтсез. Боларныкы шырпы кабы зурлыгында гына. Түш кесәсендә дә йөртергә була.

Рощин, ниһаять, үз рәвешенә кайтты. Балта сораганда чөшле тоттыргандай төзүчеләрнең фидакарь эше хакында сөйли башлады.

Бенитто елмаюын басар өчен учы белән авызын сыпырды. Ул канәгать иде. Шулай булмыйча, КамАЗның иң зур партия боссын кәкре каенга сөяде ич.

Ничек тә бу киеренкелекне басарга иде. Тылмач хатын да Мансурга карап-карап ала, үзенчә кисәтү ясый. Ул Рощинның әле күптән түгел генә Мәскәүдә диссертация яклавын, бик абруйлы житәкче булуын сөйләп китте. Ләкин ике арадагы боз барыбер эремәде. Аңа Джузеппе да үз өлешен кертте.

–Автомобиль төзелеше өлкәсендә,–диде ул елмаеп кына,–СССР белән Италия арасындагы хезмәттәшлек күптәннән килә. Мәсәлән, ВАЗ ФИАТ ярдәмендә төзелде. Ләкин ВАЗ машиналары кичәге көн машиналары. Көнбатышта аларга ихтыяж юк. КамАЗ белән дә шул хәл

кабатланмасмы, конвейерга кергәнче үк искермәсме?

Рощин бу өлкәдә белгеч түгел. Җавабы да идеологлар җавабы иде. Шуңа күрә әңгәмә мәгънәсезгә озакка сузылды, авыр тәэсир калдырды. Кин, йомшак кәнәфидә ата күркә шикелле кабарынып утырса да, чит ил журналистлары алдында хурга калды партком хуҗасы. Мин-минлеге, алай да, хәттин ашкан икән. Обкомга әләкләгән. Күп тә үтмәде, Мансурны шәһәр комитетына чакыртып алдылар.

—Сез анда нәрсә, партком секретарена имтихан оештырасыз,—дип акырды телефоннан обком түрәсе.—Үз кешеләреңне тота белергә кирәк. Шунын өчен җибәрелгән син анда.

—Алар минем кешеләрем түгел, Италия журналистлары...

—Сафсата сатма,—дип бүлдерде аны түрә,—безгә барысы да билгеле. Һәм без моны болай гына калдырмаячакбыз!

—Миңа нишләргә соң, кайтып китәргәме?

Мансур әлеге соравына җавап ала алмады, теге телефон трубкасын куйды.

Хәзер ин дөресе, Харрасов белән киңәшү, дигән фикергә килде. Бу эшне аңа ул кушты, бу авыр хәлдән чыгарга да булышмый калмас, тәҗрибәле бүре.

Бәхетенә, Харрасов урынында иде. Ул аңа барысын да бәйнә-бәйнә сөйләде.

—Борчылма, Әмирҗанов, кайткач әйбәтләп аңлашырбыз,—диде ул әлләни исе китмичә генә,—журналистлар шулай инде алар, төпченергә яраталар, формалистларга бу ошамый. Алай да күз-колак бул, бик узындырырга тырышма.

Мансурнын иңнәреннән гүя мең еллык йөкне алып ташладылар, җиңеләеп китте. Италиялылар да тынычланды кебек. Төзүчеләр янында үзләрен бик дустанә тоттылар. Рәсәйнең гомерлек проблемасы, юлсызлык кына үзәкләренә үтте булса кирәк. Бенитто чын-чынлап: "Шушындый зур эшкә тотынгансыз, башта бу объектларга юл үткәрергә кирәк иде ләбаса",—дип гаҗәпләнде.

Төзүче агайлар мыек астыннан гына елмаеп куйдылар.

Тик Мансур иртәрәк тынычланган, алда тагын да мавыктыргычрак маҗаралар көтеп торган икән.

Кичен журналистлар союзының шәһәр бүлеге аш мәҗлесе үткәрде. Табын мулдан иде. Капиталистлар алдында сынатырга ярыймы соң? Мансурнын, чит ил кешеләре бер рюмка хәмер белән бөтен кичне уздыра, дигән гыйбарәне ишеткәне бар иде. Ләкин Джузеппе белән Бенитто моның киресен исбатладылар. Тәгам ягыннан, мөгаен, тылмачбикә рекорд куйгандыр. Биле өзелергә генә тора үзенең. Кич буе берөзлексез ашады да ашады. Кай җиренә бара? Бераздан мәҗлесне оештыручыга сарыла башлады бу. Монысы да тамак хакына булган икән. Балык бик ошады, күчтәнәчкә берәр кило рәтләп булмасмы, дип сорый икән.

Хуҗалар акрынлап таралышты. Ә кунакларнын кузгалырга исәпләре юк. Кычкырышып-кычкырышып ни турындадыр гәпләшәләр.

Сәгать уникене сугуга тылмач урыныннан кузгалды. "Минем эш сәгате бетте",—дип терт-терт басып чыгып та китте.

Мансур бер ярдәмчесез калды. Төне буе бу ерык авызларны каравыллап утырып булмый бит инде. Болай да күпме нервысы ашалды.

Кунакханә администраторы кереп сәгатенә төртеп күрсәткәч кенә кузгалды италиялылар. Мансур җиңел сулап куйды. Бу минутта аның бер генә теләге бар иде, тизрәк бүлмәгә кереп япа-ялгыз калу. Ә тегеләрнең арты кызган, йоклау турында уйлау да юк. Мансурны да ике яктан култыклап алып, ай-ваена карамыйча, урамга алып чыктылар.

Төн шикәр кебек ак иде. Салкынча. Әмма тирә-як инде яз исе белән тулган. Ул кытыклый, назлый, җилкендерә, өнди. Кетер-кетер итеп аяк астында шыгырдаган ярмалы кар да, агач ботакларына сыланган сыкы да гүя язбикәнең сәламен җиткерәләр.

Ай әллә баткан, әллә чыгып өлгермәгән—күренми. Шуна күрә күккә йолдызлар хуҗа. Берсеннән-берсе уздырырга тырышып җемелдәшәләр.

Чаллы—хезмәт кешеләре каласы. Иртүк торып эшкә китәләр, җеп өзәрлек хәлләре калмыйча арып-талып кайталар да ятакка авалар. Көннәр, атналар, айлар буе шулай. Совет кешеләре өчен хезмәттән дә өстен бернәрсә дә юк. Кая карама, хезмәт турында өндәмәләргә тап буласың. Бөтен ил бишьеллыктан бишьеллыкка яши. Ә идеология шул бишьеллыкларны вакытыннан алда үтәп чыгуга юнәлдерелгән. КамАЗны да биш ел урынына өч ел ярымда сафка бирү өчен ярыш башланган. Кешенең шәхси тормышын җыелышлар, утырышлар, киңәшмәләр, конференцияләр, слетлар алыштыра. Эш-эш-эш! Кеше туганнан алып үлгәнчегә кадәр шушы тәгәрмәчтә бөтерелә. Ул мәхәббәтен дә, бәхетен дә, гаиләсен дә хезмәттә табарга тиеш. СССР әлеге җәһәттән бердән-бер кабатланмас ил.

Италианнар моны аңламый. Чөнки тормыш рәвешләре башка. Аларга күңел ачарга булсын.

Джузеппега гыйсьян каны тынгы бирми, күрәсең. Үз-үзенә урын таба алмый. Ниһаять, аның бу халәте җыр булып бәреп чыкты. Аякларын аерып басты да, сәхнәдәге артист шикелле кулларын җәеп җырлап җибәрде.

—Санта Лучия...

И могжиза! Урамның аргы башында Джузеппега бер хатын-кыз тавышы кушылды. Джузеппе шашынып нидер кычкырды. Тавыш аңа җавап кайтарды. Джузеппе ябудан чыгарылган тай кебек салулый-салулый шул якка элдертте.

Мансур аның артыннан йөгермәкче иде дә, Бенитто жиненнән тартып туктатты.

Очраштылар ахры, тавыш тынды. Менә сиңа йокы каласы?! Эзләп китәргәме инде ул башсызны, көтеп торыргамы? Нинди җүләрлек, ә? Җитди кешеләр ләбаса, халыкара темага язучы танылган сәяси журналистлар! Бөртек тә акыллары юк икән. Инде Бениттосы бер-бер нәрсә майтарып ташламасын. Аннан эшләр бөтенләй ханәгә әйләнер.

—Джузеппе кая китте?—дип сорады ул Бениттодан. Аннан гына башына бәрде, каян белсен ди инде бу кара италиан татар телен? Ләкин Бенитто Мансурның ни турында сорашканын аның борчулы йөзеннән үк аңлап алган иде.

—Джузеппе, Джузеппе...

Бенитто бармаклары белән секс рәвешен күрсәтеп, Мансурның кабыргасына төртеп алды. Әмма шаярыр чакмыни? Мансур италианны бүлмәсенә озатып куйды да, тылмач хатынны эзләп китте. Нидер эшләргә, нинди чарасын күрергә кирәктер ич инде. Әллә ни булыр?

—Лиза, ач әле, бу мин, Мансур,—дип берничә тапкыр ишеккә бәргәләде. Ләкин тавыш-тын ишетелмәде. Тагын шакыды, тагын...

—Лиза, Лиза, ач әле, ач! Джузеппе... югалды.

Ниһаять, эчке якта идән сайгаклары шыгырдап куйды.

—Нәрсә, сүзгә килештегезме әллә?—дип сорады Лиза йокыдан соңгы карлыкканрак тавыш белән.

—Бер кыз артыннан китте, ниндидер Санта Лучия...

—Сез мине шуның өчен борчыдыгызмыни? Китсә соң? Провинциальлегегезне болай ук күрсәтмәсәгез дә була иде. Ни дип саклыйсыз сез аларны. Бәби түгел ич алар, үзләре өчен үзләре җавап бирә.

—Бүрәнә аша бүре кума әле,—диде Мансур,—уен эш түгел, киңәшләшик.

Лиза яртылаш ишекне ачты.

—Сез әле һаман Гоголь чорында яшисез икән...

Мансур өннән калды. Аның каршында су сөлеге кебек нәфис гәүдәле чибәр хатын басып тора иде. Ул бөтенләй көндезге тәкәббер, кыланчык тылмачка ошамаган. Искиткеч мөлаем. Мансурны аның тәлгәш-

тәлгәш булып түгәрәк җилкәсенә салынып төшкән калын чәчләре, озын ак муены, кош балалары шикелле әчке күлмәк ерымыннан башларын калкыткан тыгыз имиләре әсир итте. Шушы бер мизгел барысын да челпәрәмә китереп ташлады. Джузеппе дә, Харрасов та, обком да, партком да онытылды. Ул ниндидер йөгәнсез тупаслык белән ишекне тибеп ачты да, Лизаны кочагына кысты.

—Нишләвегез бу, җибәрегез,—дип бәргәләнде тегесе.

—Син фәрештә...

—Мин кычкырам...

Ләкин Лизаның тавышы шундук өзелде, Мансур аның өстенә ауды...

—Теге азгын тай кайтты,—дип каршы алды аны иртә белән дежур. Мансур башын кагып, ирен очлары белән генә елмайгандай итте. Мин үзем дә Джузеппе сынары инде, дип уйлады. Тик таякның авыр башы италиан дуска түгел, аңа төшәчәк. Ярый ла, исән-сау котыла алса?

Курыккан эш хәерле була ди. Чаллыдагы хәлләр турында бер кеше дә сүз кузгатмады.

Черек күл кешеләре дә, партия әһелләре дә, Харрасов та. Италиannар киткәч, барысы да онытылды. Димәк, советка каршы бернинди дә хилаф гамәл кылмаганнар. Тик каян килеп эләккән иде ул италиан телендә "Санта Лучия"не җырлаучы кыз Чаллыга? Ничек нәкъ шул вакытта урамда йөргән? Мансур боларны белмәде. Ә Лиза белән ул соңыннан да Мәскәүдә берничә тапкыр очрашты...

Казанга кайтуына редакциядә аңа шатлыклы хәбәр җиткерделәр. Редакциягә фатир биргәннәр икән. Бушаганын Мансурга тәгаенләгәннәр, имеш.

Волков урамындагы ике катлы агач йорт иде ул. Аскы катын тулысы белән ниндидер галим били, ди. Өстә—дүрт гаилә, уртак кухня. Утын якмалы. Гаражы бар, базы. Зур бакча. Анысына әлеге күрше хуҗа.

—Ул безнең кәрван-сарай,—диде Харрасов,—анда бөтен редакция кешеләре торып чыкты инде. Син дә соңгысы булмассың, дип уйлыйм.

Харрасов Мансурның күз алдында фатир дәгъва итмим дигән гаризасын ертып чүп савытына ыргытты.

Шулай итеп, Мансурлар чын Казан кешесенә әверелделәр. Прописка артыннан йөрүләргә дә чик куелды. Иң авыры инде артта. Тәвәккәл таш яра, таяк баш яра ди, тәки ерып чыктылар бит.

* * *

Редакциягә Җәмиләнең әтисеннән хат килеп төште. Аны хатлар бүлегендә ачканнар. Көлә-көлә укыганнар, күрәсең, кызларның иреннәре мелт-мелт килә иде, пырхылдап кына җибәрмиләр.

Нурулла карт үзен хәйләкәргә чутлый, һәр гамәленә ниндидер мәгънә салырга тырыша. Ләкин аның хәйләкәрлеге су өстендәге йомычка шикелле иң өстә генә чайкала. Әлеге хатын да шундый "яшерен" мәгънә белән язган.

"Бер ифрат та файдалы эш майтарып ташладым бит әле, канәт. Самар ягында каз шәп уңа. Нәселле казлар. Йоннары муеннан. Халык шыны кая тапшырырга белми маятна килә. Башка сукты бит бу минем. Рас кына ике бәрән сарыкны суеп саттым да, шыл акчага зрә дә сыйфатлы каз йоны юнәттем. Ястык-юрганга бәһасез нәрсә, канәт. Казанда каз йоны үтми микән, шыны белеш әле, кияү, син зур кеше бит хәзер"...

Мансур мондый отышлы алыш-бирешләр турында күп ишетте инде. Хатның соңгы абзацын укыгач, сиземләүләренең барысы да дөрескә килде. Бабакайның кесәсе такрайган икән ич! Акчаны ул беркайчан да турыдан-туры сорамый. Ике-өч ел мунча сылтавы белән каерды. Аптырагач, Мансур түбәлек шиферны үзе кайтарды. Бу юлы мунча телгә алынмый.

Димәк, каз йоны белән янган карт. Сәүдәгәрлеген әйтер иде. Көтәргә алып бурычка сатып йөри шунда. Нишлисең, бабай үзебезнеке, бурычны түтәү үзе бурыч ди, булышмый да ярамый. Җәмилә генә сизмәсен. Ул әтисенең соранганын өнәми. Чөнки ярдәм акчасы гаиләгә кайтмый, сәүдә юлында тузып бетә.

Радиога барышлый юл уңаенда почтага сугылып, Мансур бабасына акча салды. Әйдә, сөенсен, башка таяныр кешесе юк бит. Үзе дә инде, коры куык, бер малай да булдыра алмаган. Өч баласы да кыз затыннан.

Радиода Мансур чит кеше түгел. Еш кына аның очеркларын эфирда яңгыраталар. Әмма музыка редакциясе башлыгы Әнвәр белән якыннан таныш түгел иде. Берничә тапкыр телефоннан сөйләшкәннәре бар. Бүген, әнә, үзе шалтыратты, сугылып чык әле, диде.

Ул Мансурны көлеп-елмаеп каршы алды.

—И, малай, сине дә күрер көннәр бар икән. Әйберләреңне укып барам. Каләмең оригинал. Берәүгә дә иярмичә үзенчә язасың. Ветеринария институтыннан әзерләгән репортажың гомумән дә мировой!—Әнвәр башын артка чөеп, кеткелдәп көлеп алды.—Үгезнең мәние шар сыман иდәнгә тәгәри... ха-ха-ха. Шәп деталь! Туңдыргач мәни ун ел буена саклана, ә? Үгез үзе инде юк, ә нәселе дәвам итә. Болайга китсә, тиздән кешеләр дә шушы ысул белән үрчиячәк бит инде, ә?

Мансурның әлеге репортажын летучкада да мактаганнар иде. Рәхмәт, Әнвәр дә укыган икән. Тик аны хәзер башка мәсьәлә кызыксындыра, шуңа күрә әңгәмәне үз ягына борып җибәрде.

Әнвәр авызына йөзек яшергәндәй тынып калды. Җитдилек килешми икән, ияге, ирennәре асылынып төште.

—"Кил, Җәмиләм" дигән җырың миңа ошаган иде,—диде, үзенең сүзләреннән үзе авырсынгандай,—худсовет үткәрмәде, Җәүдәт Фәйзинең Такташ сүзләренә иҗат ителгән "Урман кызы"н хәтерләтә, плагиат диделәр...

Әнвәрнең ярым кысык ирennәре арасыннан тагын ниндидер сүзләр коелды. Ләкин Мансур аларны ишетмәде, тиз-тиз генә саубуллашты да чыгып та китте.

Ахмак, тинтәк, җүләр, дип юл буе үзен-үзе тиргәп кайтты. Сара апа соң, күңеле булсын, дип кенә әйткән ич теге олы сүзләрне. Мәҗлес шаукымы, хәмер җинеллеге белән. Ә ул чынга алды. Композитор булу өчен җыр җырлау, музыка коралларында уйнау гына аз ул. Иң беренче сәләт зарур, аннан профессиональ белем. Анарда беренчесе дә, икенчесе дә юк. Әнә бит, Сара Садыйкова булып Сара Садыйкованы әле һаман үзешчәннәр калыбында тоталар. Аңа шул туң мәни хакында гына язарга.

Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас. Фән өлкәсенә сыймады, мәгарифне ташлап китәргә мәҗбүр булды. Журналистикасы да, ихтимал, вакытлыгынадыр? Иҗат кешесе, имеш. Дилетант! Булдыксыз!

* * *

Кырык төшнең берсе—пәйгамбәр төше ди. Элегрәк тә Мансурга матур-матур төшләр керә иде. Күзләре ачылып киткәч, их, нигә уяндым соң, дип үкенеп ятар иде. Хәер, моны чын мәгънәсендә төшләнү дип тә әйтеп булмыйдыр әле. Мәгълүм шигырьдәге кебектер бәлки?

Яхшы шундый бер көн бар,
Ярты айга биргесез,
Йөнә шундый бер төн бар,
Ятып йокы килгесез.

Шулай да барысы да төштән башланды. Әйе, әйе, төштән. Ул моңарчы төшнең могҗизалы тылсым икәнен белми, дөресрәге, бу хакта

ныклап уйлап караганы юк иде. Ньютон җисемнәрнең үзара тартышуы турындагы законны алмагачы төбендә йоклап ятканда башына алма өзелеп төшкәч ачкан, имеш. Мансур моны да хыялый затларга карата чыгарылган уйдырма мәзәк итеп кенә саный иде. Бүген исә: "Әлеге тәгъбиргә ышанасыңмы?"–дип сорасалар, һич икеләнүсез: "Ышанам",–дип җавап бирер иде.

Төшендә иң элек Нигъмәтулла бабасы белән очрашты. Ул аны әбисе сөйләве буенча гына белә иде. Ә монда үзе! Сакал-мыеклы бик күркәм зат. Әнә, атын туктатты да, тегермәнгә кереп китте. Ул арада күктән төшкәндәй берничә җайдак пәйда булды. Берсе Горилла маймылына охшаган. Юан, бөкрерәк гәүдәле. Куллары тезенә җиткән. Килә-килешкә тегермән эченә ыргылды бу һәм күп тә үтми, Нигъмәтулланы өстерәп алып чыкты.

–Сволочь, нигә кешеләрне колхозга каршы котыртасың?–дип наган түтәсе белән тегенең каш арасына төндырды.

–Юк, Газзалый хәзрәт, нахак, нахак...

–Мин сиңа хәзрәт түгел, кызыл комиссар!–дип акырды Горилла. –Ал кирәгеңне, контр!

Көчле шартлау яңгырады. Нигъмәтулла йөзе белән туң җиргә капланып төште. Ак тула оеклары ал канга манчылды...

Газзалый муллалыгын ташлаган, совет власте өчен җан атып йөри. Революционер! Мондый тәвәккәллеккә бару өчен бик көчле шәхес булу зарур. Менә дигән унай образ! Тик нигәдер күңел кабул итеп бетерми әлеге "геройлык"ны. Иманга хыянәт итү ич бу! Иманына хыянәт иткән адәмгә югары хакимият мөнбәренә үрләү өчен шартлар тудырган, көпә-көндез бандитларча кеше үтерүне хуплаган җәмгыять үзе дә гадел микән әле?

Мансур әлеге уйларыннан куркып китә. Бу уйлары белән ул үзе дә иманына хыянәт итмиме соң? Ул корбаннар социалистик җәмгыять төзү хакына бирелгән ләбаса. Революция корбансыз булмый. Марксизм-ленинизм шулай өйрәтә. Хәер, төш кенә ич бу. "Юк, син моны гади төш дип кенә кабул итмә, бу сиңа бирелгән илаһи форсат,–дип тәкрарлый аңа нииндидер югары көч.–Бу илһам. Ул башка килмәячәк, файдаланып кал".

Мансурның йөрәгендә ут кабынды. Бу ут җә хәзер балкып кабыначак, җә йөрәген көлгә әйләндереп сүнәчәк. Икенең берсе...

Мансур урыныннан сикереп торды да, кәгазь-каләм алып, кухняга чыгып китте. Уй-фикерләре ярларына сыймый, ургыла-ургыла ак кәгазьгә ята. Кем белсен, аларның кайчан да булса, башка кешеләр өчен дә хаҗәте килеп, кувшин эчендәге җен кебек дөньяга чыгуы бар.

Мансур иртәнгә кадәр баш күтәрми язды да язды. Икенче көнне дә, өченчесендә дә, ун көннән соң да. Язу аның рухи ихтыяҗына әверелде.

Төш теләк буенча керми. Бу көннәрдә Рәшидә белән төшләнә башлады. Дөрес, безнең арада бернәрсә дә булмады, дип ул үзен-үзе ышандырырга тырыша. Шуңа күрә Җәмилә алдында да зур кыенсыну кичерми. Тик хәтерне алдап буламыни? Теге вакыттагы очрашу күңелен барыбер ымсындырып тора.

Мансур мона кадәр дә чит түтәйләр белән булгалады. Әмма Җәмиләне бердәнбер мәхәббәте дип саный иде ул. Башка кыз-кыркынга да нигездә хатынының өстенлегенә тагын бер кат ышану өчен игътибар итә иде. Шуңа күрә бер хатын-кыз белән дә башын югалтып мавыкмады, аерылышуга күңеленнән сызып ташлый иде.

Ә йөрештерүгә килгәндә, ир кешенең уҗымга чыгыштыруы гаиләне ныгыта гына. Бу инде исбатланган, дип саный иде ул..

Һәм менә сиңа мә! Рәшидә бөтерде дә алды. Үзе дә сизми калды. Ничек исән-имин чыгар ул бу капкыннан? Әгәр Җәмилә аларның Рәшидә белән ике арада булып алган якынлыкны белеп алса, гафу итмәячәк. Горурлыгы моны күтәрә алмаячак. Шуңа күрә ничек тә йомып калырга

кирәк бу мәгънәсез тайпылышны. Татлы ялганга караганда ачы хакыйкать мең өлеш артык дисәләр дә гаилә, иминлек хакына дөреслеккә дә хилафлык кыласың икән ул.

Рәшидә җилбәзәгрәк хатын. Бәлкем, башын юри җүләргә саладыр? Яратмаган ир белән яшәү бүре өнендә яшәү белән бер ич инде. Гел ырылдашып яшисең... Ашаган кызның башын Нурулла үзи. Җитмәсә, мактанып йөри бит әле, төпчегемне бик яхшы урнаштырдым, ди.

Аларга тиз арада очрашып сөйләшергә, аңлашырга, икеле-микеле хәлгә нокта куярга кирәк. Мансур шул максат белән Рәшидәне очрашуга чакырды. Очрашу урынын Рәшидә билгеләде. Килештеләр. Ул аны берара үзенә күренми генә читтән күзәтеп торды. Киенгән-ясанган, матур, җыйнак. Үткән-сүткән ир-ат борылып-борылып карый, тәвәккәлрәкләре сүз дә кушкалый. Көнләшүдән Мансурның җен ачулары чыкты. Ничек инде күрмәгән-белмәгән хатын-кызга сүз кушасың ди?

Рәшидә Мансурның алдан корган уй-ниятләрен бер кагылуда чуалтып ташлады. Каршысына йөгерә-йөгерә килде дә, бит очыннан үбеп, култыклап ук алды.

—Рәхмәт, җизнәкәй, бу минем үз гомеремдә көтеп алган беренче свиданием. Йөрәгем парә-парә килә, ышанмасаң, менә тотып кара.—Ул Мансурның кулын күкрәгенә терәде.

—Рәшидә, туктале, безгә аңлашырга кирәк бит, Рәшидә...

—Аңлашыйк соң, әллә мин каршымы? Берәр ресторанга керик тә, шунда иркенләп аңлашырбыз.

—Ресторан? Озакка китәр ул алай...

—Егет кеше бит син, җизнәкәй, маркыңны төшермә!

Кабан күленә сыенып кына салынган бер аулак ресторан бар икән. Шунда керделәр. Рәшидә очрашу урынын билгеләгәндә үк әлеге ресторанны күз уңында тоткан иде, ахры. Барысы да уйланылган, барысы да бизмәнгә салынган. Һәр хатын-кызда Мисыр патшабикәсе мәшһүр Клеопотраның ярсулы каны ага, диләр. Хактыр бу, мөгаен. Хатын-кызда ярату да, хәйләкәрлек тә, үчлек тә бергә буталган.

Рәшидә ресторанда да Мансурны йөгәненнән ычкындырмады. Тегесе сүз башлауга, җә тост тәкъдим итә, җә биергә чакыра. Тәки йомшартты. Бераздан инде Мансурның башына бөтенләй үзгә фәлсәфә керде. Балдыз сөю татарда гаеп саналмый ләбаса! Халык иҗатына гына күз сал. Никадәр мәкаль, ни кадәр җыр, такмак!? "Балдыз—алтынга манылган көмеш", "Балдыз булыр балдай", "Балдызым, калдырмам ялгызын", "Җитмәснең инен тотканчы, җизнәң җинен тотсаңчы", "Җизни, синнән күңелем бизми", "Агач башы казыктыр, балдыз сөю языктыр; язык казык башында, йөрсә минем каршымда"...

Ничәмә-ничә гасыр имтиханын тоткан җәүһәрләр ич инде болар. Гореф-гадәткә әверелгән гамәлләр... Димәк... Мансурның тышаулары тәмам чишелде. Биегәндә инде бербөтен булып бер-берсенә сыланып беттеләр.

Арып-алҗып өстәл янына утыруга Мансур чәркәләргә шәраб агызды.

—Бу минем иң бәхетле, иң көенечле көнем,—диде Рәшидә.—Әйдә, шуның өчен төбенә чаклы эчеп бетерик әле.

—Юк, мин риза түгел. Ничек инде көенечле?

—Соңыннан әйтермен, ә хәзер карышма, җәме?

Рәшидә урындыгын читкәрәк шудырып, иркенләбрәк утырды. Әле генә үзен-үзе белешмичә биегән, уйнаган-шаярган көләч йөзле Рәшидә түгел иде инде ул. Мансур бераз сәерсенеп торды, аннан үбәргә үрелде. Рәшидә аны кул ишарәсе белән туктатты.

—Мансур,—диде ул тамагына тыгылган төер аша, — әгәр апам сырхау булмаса, мин бернәрсәгә карамыйча, дөньяның асты өскә килсә дә, сине үземнеке итәр идем. Мин сине чын ярату белән яратам. Беләм, син дә яратасың. Ләкин ратуыңнан куркасың. Ир-ат куркак инде ул, нишлисең? Әлеге очрашуга да шул куркаклыгың китерде бит сине, абруең өчен

курыктын. Хафаланма, синең белән булган ике бәхетле көн минем үз йөрәгемдә генә сакланыр, кешегә чыкмас.

—Рәшидә, туктале, Рәшидә...

—Бүлдермә мине, Мансур. Ишетәсенме, мин сиңа беренче тапкыр исемең белән дәшәм.

Рәшидә алдындагы рюмкасына үрелде. Ул рюмканы башкалар сыман аягыннан тотмый, ике бармагы арасына кертеп, төбен учына утырта. Бу аңа бик килешә. Шушы кечкенә генә бер үзгәлектә аның кылтыклыгы да, самимилеге дә, купшылыгы да ялтырап кабынып ала.

Мансурның аны яратасы, колагына сөю сүзләре әйтәсе килде. Әмма кыймады. Чөнки ике арага ниндидер читләшү пәрдәсе төшкән иде инде.

Рәшидә сүзен дәвам итте:

—Аңлашыйк, аңлашыйк, дип бик үҗәтләнгән идең, менә аңлаштык та. Синең сүзләреңнең кирәге дә чыкмады, әйеме, Мансур? Мансур! Нинди матур исем! Син үзең дә бик әйбәт. Синең кебекләр сирәк хәзер.

Рәшидә күзләрен мөлдерәтеп бер карап алды да сүзләренә соңгы мөһерен сукты.

—Менә шулай, жизнәкәй, мин сиңа хәзер бары бәхетсез балдыз гына... Хуш... Бар, инде апа янына кайт. Мин калам әле. Бар, бар, борчылма, минем үземне рәнжеттерә торганнардан түгел икәнне беләсең бит. Бер генә үтенеч, зинһар, артыңа борылып карама, җәме?

Мансур кыйнаган эт кебек өстерәлеп чыгу ягына юнәлде. Ләкин сүзендә генә тора алмады, ялт итеп артына борылып карады.

Күзләре очрашты. Рәшидә дә аңа томырылып карап тора иде. Мансур йөгереп килеп, башын аның алдына салды.

—Тынычлан, бәгърем,—дип пышылдады Рәшидә.—Барысы да без дигәнчә булыр.

—Сихерләдең син мине, Рәшидә, белмим, нишләп бетәрбез без?

—Менә анысын бергәләп уйлашырга кирәк инде, Мансур.

—Ә син үзең безнең мөнәсәбәтнең киләчәген ничек күз алдына китерәсең соң?

Рәшидә фикерен җиткергәнче кечкенә түгәрәк көзгесенә карап, йөзен, чәчләрен рәтләде. Шуннан соң гына:

—Безгә никах укытырга кирәк, Мансур!—Ходай каршында ир белән хатын булыйк,—диде.

Мансур Рәшидәне читкә этәреп җибәрде. Бәбәкләре киерелгән, ирен кырыйлары мелт-мелт килә, әйтерсең лә, кемдер җеп белән тарткалап тора.

—Син, нәрсә, Рәшидә?

—Ярар, әйттем исә кайттым,—диде Рәшидә,—Яратасыңмы икән дип сынап карау өчен генә әйткән идем...

—Никахлар укытып йөрергә журналист ич мин, югары белемле кеше...

Рәшидә алдындагы чәен йотып куйды да, ияген учларына терәп тынып калды. Мансурның аны мондый моңсу кыяфәттә күргәне юк иде. Куллары үзеннән-үзе аңа тартылды. Рәшидә бу яратуны кабул итмәде. Әле аның әйтелгәннәрдән дә мөһимрәк сүзләре бар иде.

—Син белемле кеше, Мансур,—диде,—мин моны бик яхшы беләм. Әгәр шулай икән, үзеңнең хәленә дә объектив бәя бирергә тиеш ич инде син. Күңеленә авыр алма, апаның гомере санаулы гына. Рактан терелгән кеше юк әле бу дөньяда. Никах безнең икебез өчен дә бик кирәк. Әле син миңа рәхмәт әйтәчәксең. Ләйсәнгә дә миннән дә яхшырак әни таба алмаячаксың.

Рәшидә Мансурның кабынып китүен көткән иде. Ә ул, киресенчә, мәлҗерәп төште. Чөнки аның үз хәле турында болай тирәннән уйлап караганы юк иде. Барысы да үтте дип йөри иде. Чөнки Җәмиләнең

сәламәтлегенә зарланганы юк. Шул ук вакытта Рәшидә дә хаклы. Ләкин исән хатын өстеннән никах укыту–монысы инде бер калыпка да сыя торган нәрсә түгел. Намуссызлыкның соңгы чиге.

–Апа белән син дә никахлы түгел, минем дә андый йөгем юк. Безгә юл ачык,–дип Рәшидә һөҗүмен дәвам итте. Ул үзенең җинеп чыгуына шикләнми иде. Әнә, Мансурның икеләнүе инде йөзенә үк бәреп чыкты. Учакка аз гына коры кура өстәсе.

–Беләсең килсә, икешәр-өчәр никахлы кешеләр күп хәзер. Вакыты җиткәнче бу хакта икебез генә белербез, миңа ышана аласың.

–Мин мәчетләргә барып йөри алмыйм,–диде Мансур.

Бу инде аның бирелүе иде.

Рәшидә мыраулап Мансурның куенына елышты.

–И, җүләрем минем, аның өчен мәчеткә барырга кирәкми. Мин сөйләшеп куйдым инде. Мулла бабакай безне көтеп тора. Моннан ерак түгел. Йорты Кабан күле буенда гына.

–Без соң, Рәшидә...

–Борчылма, бабакай үзебезнеке.

Шулай итеп, Мансурның аңлашуы никах белән төгәлләнде.

* * *

**1970** ел пропаганда һәм идеологиянең шау-шулы чоры булды. Илебез Коммунистлар партиясен оештыручы, Совет властена нигез салучы, большевиклар пәйгамбәре Владимир Ульянов-Ленинның тууына 100 ел тулды. СССР Ленин портреты, Ленин сыны, Ленин һәйкәле, Ленин китаплары белән тулды.

Еллар үтәр, атом бомбаларын, ракеталарны юкка чыгару, әлеге таш сыннарны чүплеккә ату өчен акча сорап, Русия чит мәмләкәтләргә мөрәҗәгать итәр.

1971 ел әлеге сәяси күтәренкелек учагына тагын да көчлерәк ялкын өстәде. Бу икенче Ильич чорының җиденче елы иде. Ильич II нең сәяси олимпның иң югары кыясына менгән вакыты. "Хрущев язы" инде үткән, Сталин культы урынына Брежнев культы урнашкан. Орден-медальләр кою буенча да рекордлы нәтиҗәләргә ирешелгән.

Менә шушы купшы күтәренкелек шартларында КПСС үзенең чираттагы XXIV съездына чаң какты.

Мансурның мондый мәхшәрне күргәне юк иде әле. Бу көннәрдә редакция сугыш вакытындагы хәрби штабны хәтерләтә иде. Республиканың иң тәҗрибәле тәрҗемәчеләреннән махсус команда оештырылды, аларга ярдәмчеләр беркетелде. Ә телетайп тегермәнен тарта да тарта, төзәтмә арты–төзәтмә, өлгер генә. Харрасов эшнең барышы турында өлкә комитетына сәгать саен мәгълүмат бирә, очып кына үзе дә барып кайта. Мондый шау-шулы кампанияләрне ярата иде ул. Курчак йөртүче шикелле нәкъ вакытында кирәкле җепне тарта, шунда ук тиешле әгъза хәрәкәткә килә. Бу инде житәкчелек таланты.

Мансур бу ыгы-зыгыны читтән генә күзәтә. Чөнки мондый эшләрдә беренче катнашуы. Шуңа күрә ышаныч та юк дәрәҗәсендә. Вазифасы да ташка үлчим. Үзе кебек бер өйрәнчек белән сәхифәдәге текстны оригиналдан чагыштырып баралар. Хәлбуки, инде барысы да кырык иләктән узган, корректорлар укыган, дежур укыган... Көне буе утырып ник бер ялгышка юлыксыннар. Харрасов хата таптыра, игътибарсыз укыйсыз, дип бәйләнә. Бик тырыша торгач, бер өтернең койрыгыннан каптырдылар шулай да. Мансур зур җәен эләктергән балыкчыдай шатланып комиссия бүлмәсенә йөгерде. Күрегез, алар да юкка гына ыштан төбен ышкып утырмыйлар!

Комиссия рәисе, ветеран-журналист, иске бияләй кебек бөгәрләнгән иреннәрен җәелдереп текстны өч-дүрт мәртәбә җентекләп укып чыкты.

Мансур жаны-тәне белән үз сүзенең дөресқә чыгуын тели иде. Менә рәис башын күтәрде.

—Син, чибәр егет, ничә класс бетердең соң?—дип керфексез күзләре белән ана текәлде.

—Мин югары белемле укытучы...

—Ә нигә, хәзер пединститутта грамматикага сан юкмыни? Өтер ул, чибәр егет, син уйлаганча, тыныш билгесе генә түгел. Өтер ул—сәясәт! Партия документларында хата җибәрү, монысы инде, җинаять! Син безне үзеннең грамотсызлыгың белән шуна этәрәсең.

Рәис Мансурны хур итеп чыгарды. Әле ярый үзе генә иде, югыйсә, даны бөтен редакциягә тарала иде. Монда һәр сүзенне эләктереп алырга гына торалар, "Өтер Мансур" дигән кушамат тагып куярга да күп сорамаслар. Андыйга бик маһир журналист халкы.

Бераздан бүлмәгә тыны-көнә бетеп дигәндәй бүгенге санны алып баручы җаваплы секретарь ярдәмчесе Мәликә Нәҗмиева килеп керде. Бик житез, бик тәвәккәл хатын. Табан астыннан ут чәчә. Фигаро шикелле, әле анда, әле монда. Бу вазифада шулай булырга да кирәк, җебеп торсаң, эшкә бервакытта да нокта куелмаячак. Газета исә нинди генә ыгы-зыгыга да карамастан, иртән укучыга барып ирешергә тиеш.

Мәликәнең әле дә шул мәнфәгатьтә йөрүе.

—Егетләр,—диде ул ишектән башы күренүгә,—Брежневнын койрыгы кала, чагыштырганда искә алыгыз әле, ярыймыгыз!

"Койрык кисү" гәҗит жаргонында текстны кыскарту дигәнне аңлата. Әмма әлеге очракта бу мөмкин булмаган хәл. КПСС ҮК Генеральный секретаренын съездда сөйләгән докладын "кисәргә" кем генә җөрьәт итсен икән? Әле, әнә, өтер өчен нинди сүзләр ишетте.

—Сез безне җинаятькә этәрәсез түгелме, Мәликә ханым?—дип Мансур рәиснең сүзләрен кабатлады.

—И, егетләр, корый бит җилекләр, ул су буе докладларны кем укый дип беләсез соң сез? Кызыксынган кеше анын оригиналы белән таныша,—дип мыскыл итте Мәликә. Аннан соң аягөстен генә Брежнев бабайны сөннәткә утыртты.

Мансур Мәликәнең бу гамәлен шаярту, малайсыту дип кенә кабул иткән иде. Тик иртәгәсен газетаны кулына алгач, күзләре шакайды. Димәк, сизмәгәннәр дә. Теге ветеран белсә, ни эшләр иде икән? Мөгаен, йөрәге ярылып үләр иде.

Әмма, барысы да алай шома гына узмый шул. Күрәчәгең булса, пима кигәндә дә аягың сынар, ди. Гәҗит эшендә нindiдер бер бәддогалы канун бар: машинкада киткән хата җырлап-биеп сәхифәгә дә килеп керә. Гадәттә, ул тавыш-гаугалы хата була. Иң гаҗәбе шул, әлеге хата котылгысыз рәвештә кабатланып тора. Мәсәлән, өлкә комитеты секретаре Михаил Троицкий журналистлар өчен чын мәгънәсендә Иблискә әйләнде. Бу фамилия күпләргә җәза алып килде. Мансур да коры калмады.

—Троицкий зур кинәшмәдә катнашкан, информациясен ныклы контрольдә тот,—дип кисәтте аны мөхәррир урынбасары Тимербаев.

Тәкъдир димә инде, оригиналда ук Троицкий Троцкий булып киткән иде. Ул сәхифә саен шулай буталып йөрде. Югыйсә, корректорларны кат-кат кисәтте Мансур, колакларына киртләмәде генә. "Борчылма, авыз пешкән иде ул абзый белән",—дип тынычландырды аны кызлар. Чагыштырырга килгән соңгы сәхифә чыннан да инде хатасыз иде. Мансур имзасын сырлап, тыныч күнел белән өенә кайтып китте.

Ә газетада Михаил Трофимович янә дә оппортунист Троцкий иде. Бу юлы цехтагыларны да пәри бутаган, төзәтелмәгән вариантны тиражга җибәргәннәр.

Шулай да редакцияне талкыдылар. Харрасовка да бик нык эләккән икән. Үз чиратында ул Мансурга, корректорларга шелтә чәпәде.

Шушы хәлләр аркасында секретарь фамилиясен алыштырырга йөри икән дип тә сөйләделәр! Дөрес идеме бу, юкмы—анысы билгесез. Әмма

Мансур аның журналистларны күрәалмавын үз җилкәсендә тойды.

Партия съездыннан соң социалистик ярыш үрмәкүч пәрәвезедәй бөтен илне чорнап алды. Хәтта балалар бакчалары да үзара көч сынаша башлады. Татарстан Куйбышев өлкәсе белән килешү төзеде. Кул кую Куйбышев шәһәрендә булды. Делегация җитәкчесе итеп Троицкий билгеләнгән иде. Әлеге мөһим вакыйганы яктыртырга журналистлар да җибәрелде. Мансур шулар арасында иде. Кул кысышу, кочаклашу, тәмле сүзләрдән соң машиналар урман эчендәге мәртәбәле кешеләрне генә урнаштыра торган Кунак йорты бусагасына килеп туктады. Ылыс исе, сагыз исе. Чыршылары төз, кары ап-ак. Хуҗалар игътибарлы. Күңелле, каһәр. Үзеңне морза кебек хис итәсең.

Троицкий болай уйламый иде, күрәсең. Шунда ук кемнең кем икәнлегенә ачыклык кертте.

—Журналистларны башка җиргә урнаштырыгыз,—диде ул алар ягына ым кагып,—әллә нәрсәләреңне чокып чыгарырлар, болай да гарык.

—Делегация әгъзаларының барысын да шушында билгеләгән идек,—диде хуҗаларның берсе кыенсынып кына,—башка урын турында уйлашмадык...

—Борчылмагыз, журналистлар үҗәт халык, урамда кунмаслар.

Бу сүзләре белән түрә юлдашларын чит кешеләр алдында тизәкка батырып, изеп ташлады. Мансур үзеннән битәр аның өчен хурланды. Ул соң партия лидеры ләбаса! Ә телендә базар жаргоны. Ничек тоталар икән аны партия эшендә? Бюрократ ич ул, чиновник!

* * *

Җәмилә кием-салымга талымчан, тәкәллеф хатын. Аңа яравы авыр. Кибеттән алган киемен ике-өч тапкыр алыштырмый һич тынычланмас. Әле аннан соң да төзәтмәләр кертә-кертә арып бетә. Биленне биш җирдән бәйләп йөрер идең, дип көлә аннан Мансур. Аның урынына, көенә китергәч, киеме эчке халәте белән тоташа. Кием белән кием иясе бербөтенгә әйләнә. Французлар, мөгаен, кеше киемгә, кием кешегә тәэсир итә, дип шуңа әйтәләрдер.

Халыкта, хатын-кыз ир-ат өчен киенә, дигән тәгъбир йөри. Бу дөрес түгел. Барыннан да элек, хатын-кыз үз ишләрен көнләштерү өчен киенә. Аның күлмәге матуррак, затлырак кына түгел, бердәнбер дә булырга тиеш. Аһ итсеннәр тирә-юньдәге ханым вә туташлар, көнләшсеннәр!

Тик кием яңарту хатын-кыз хыялының яртысы гына әле ул. Иң мөһиме, аны игътибар үзәгендә булырлык итеп тәкъдир итү. Эш урынында бер-бер кичә, мәсәлән, зур мәҗлес. Ә театр бу җәһәттән беренче урында. Театр—ул модалар күргәзмәсе. Җәмилә дә яңа теккән күлмәген театрда күрсәтергә ниятләде.

Беренче карашка, гап-гади күлмәк. Бер сәдәфе юк, туп-туры үзе. Изүе белән җиң очлары гына ак челтәр белән каймалган. Куе зәңгәр төскә ак төс килешә бит ул.

Сер менә шушы гадилектә. Чөнки гадилек хатын-кызның үзен балкыта. Әлбәттә, моның өчен килеш-килбәтеңнең, буй-сыныңның камил булуы зарур.

Җәмиләнең тырышулары бушка китмәде, театрга килгән хатын-кызларның да, ир-атның да күзе анда булды.

Ләкин спектакль аңа ошамады. Кәрим Тинчуринның "Зәңгәр шәл"ен элек тә берничә тапкыр караганы бар иде. Ярата ул аны. Шуңа күрә Мансурның: "Иске нәрсә ич ул",—дип борын җыеруына да карамастан, үзенекен итте. Ул табигыйлыкны, һәр нәрсәнең башлангыч, пакь халәтен өстен күрә. Урманга барсаң, кеше аягы басмаган ешкынлык тап син аңа, болында берәүнең дә күзенә чалынмаган чәчәк өз. "Зәңгәр шәл"не дә ул миллилекнең чишмә башы, гореф-гадәтләребезнең эталоны кебек

кабул итә иде. Жыр-бию да, кием-салым да, геройларның үз-үзләрен тотышы да... Бөтен нәрсә буталып беткән, рус традицияләре генә өстенлек иткән, хәтта татарның комганына да милләтчелек тамгасы тагылган бу чорда гореф-гадәтләрне бозылмаган килеш фәкать "Зәңгәр шәл"дә генә күрергә мөмкин иде. Инде менә аның да тамырына балта чапканнар, кәмиткә әвereлдергәннәр. Режиссер моны тамашачыга яңалык, кыюлык дип тәкъдим итәдер инде, мөгаен. Мәчет катында хәмер чөмергән исерек муллаларның шау-гөр килеп йөрүе акылга сыймый ләбаса!

Лилиягә дә, Галимгә дә спектакль ошады. Шырык-шырык көлеп утырдылар. Мансур да алардан калышмады кебек. Җәмилә тешләрен кысып утырды. Кием "күргәзмәсендә" җинеп чыгуы да онытылды. Мишәр каны үзен бик нык сиздерә иде.

Галим юлда да дин әһелләрен мыскыллап, көлеп кайтты.

Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма чорналган;
Кибән чалма кибәк башта: ишан булган, имеш, хайван!

Җәмиләнең бозылышырга теләге юк иде. Шулай да Галимне җавапсыз калдырмады, Тукайның икенче бер шигырен яттан сөйләде:

Кирәк булса, әйтеп бирим: ул шәп хәзрәт,
Тулган ай күк балкып чыккан Шиһап хәзрәт.
Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа житмәс кыйбат хәзрәт...

—Татарның данын менә шундый хәзрәтләр күтәргән, Галим әфәнде, белегез!

—Әфәнде, әфәнде, әллә мин сина байгурамы?

Галим бер дә юкка чын-чынлап үпкәләде.

—Бәби,—дип көлде Лилия,—менә шулай үпкәчел егет енде ул минем Галимем, сез әле аны белеп кенә бетермисез. Дингә килгәндә, мина поп ни, мулла ни. Ямилә нигә яклыйдыр. Аларнын урыны әллә кайчан тарих чүплегендә ич енде. Пьесанын юнәлешен үзгәртеп бик дөрес эшләгәннәр. Мин хуплыйм. Атом, космос чорында яшибез ич.

Әле ярый трамвай тукталышына килеп життеләр, югыйсә, ачуланышып аерылышалар иде.

Эш пьесаның яңа режиссурасында гына түгел иде, билгеле. Җәмилә дә күрәләтә дини хорафатларга бирелеп, искелеккә ябышып ята торган кеше түгел. Югары белемле укытучы, математик. Космосны да, атом, электроникасын да Лилиягә караганда, ихтимал, тирәнрәк тә аңлыйдыр әле. Сәбәп башкада. Бу арада нигәдер эче поша. Күңеле хәвефле. Яңа күлмәк тектерү мәшәкатьләре белән бераз онытылып та йөргән иде. Ләкин бүген театрда янә шул халәте кайтты. Ул үзе аның башлануыы әүвәлгечә бер аңлашылмаучылыкка гына сылтый килде.

Хәл болай булды. Педучилищеда Кифая Мәннәнова дигән бер педагог бар. Тәҗрибәле, белемле. Шуңа күрәме, үзен бик зурга куеп сөйләшә. Аннан да өстен кеше юк. Директордан кала берәүне дә санга сукмый. Кыяфәте, килеш-килбәте, тавышы да үз образына туры килә. Островскийның Кабанихасы кебек.

Менә шул педагог курсындагы ике укучы, Әмиржанова сыйныфына күчерегез дип, директорга гариза биргән. Кифая Мәннәновна авырганда Җәмилә вакытлыча аларда дәрес биргән иде. Күрәсең, ошатып калганнар. Авыл кызлары йомшак, сак мөгамәләгә күнеккән бит ул.

Директор кабинетына чакырганда боларны белми иде әле Җәмилә. Кифая ханым анда иде инде. Бүселеп чыккан юан кулларын бөеренә таянып, бүлмәне тутырып тора. Йөзе чөгендер шикелле.

—Килүегезгә кайчан, инде коллективны бутый да башладыгыз,—дип ул директордан алда сүзгә керде.—Безнең коллективның бик матур традициясе бар, ул сезнең эше чүп үләннәрен йолкып кына ташлый. Төшендегезме?

Җәмилә мондый сөйләшүне көтмәгән иде, шаккатты. Ни өчен Кифая Мәннәновна аны шундый килешсез рәвештә мәсхәрәли соң әле? Аның нинди гаебе бар? Ни өчен директор бу дорфалыкка юл куя?

—Мөгамбәр Мусинович, аңлатыгыз әле, нинди инквизация бу?—дип, Җәмилә директорга текәлде.

—Нәрсә, сезнең итәк астыннан йөрткән мәкерле эшегезгә күз йомарлар дип уйлаган идегезме әллә? Абруй кирәк булган берәүгә, ә? Ике җебегән авыл кызын үз ягыңа аударып кына яуланмый ул абруй. Минем кебек утны-суны кичәргә кирәк аның өчен. Төшендегезме?

Кифая Мәннәновна һаман үзенекен тукый, директорга сүз кыстырырга да ирек бирми. Ахыры тегесе Җәмиләгә ниндидер кәгазьләр тоттырды. Гаризалар иде. Укыгач, тынычланып китте Җәмилә. Менә нәрсәдә икән хикмәт? Бу соң аның файдасына ләбаса! Тутәбез әйткән абруй. Ә ул шуны югалтудан курка. Чеметеп алганда да ярый икән үзен.

—Безнең татарда, яхшы иядән мал китми, дигән мәкаль бар, Кифая Мәннәновна,—диде ул чәнечкеләрен кабартып,—монда гаеп кемдәдер бит әле?

—Мыскыл итәргә хакыгыз юк, мин, мин...

—Рус алфавитына күчергәндә "мин" соңгы хәреф ул, Кифая Мәннәновна. Мин ул кызларны үземә алырга риза. Укучының педагогны сайлау хокукы да булырга тиеш.

Җәмилә әйтәсен әйтте дә, директордан рөхсәт алып, чыгып китте. Чөнки кыңгырау шалтырады. Ә аның дәресе бар.

Алар арасында нинди сүз булгандыр, анысы мәгълүм түгел, әмма теге ике кызны, Кифая Мәннәновна курсында укучылар нормадан артык дигән сылтау белән, Җәмилә сыйныфына күчерделәр. И кызларның сөенүе! Җәмилә үзе дә алардан ким шатланмады. Бу инде училищеда педагог буларак, танылу дигән сүз иде.

Ләкин тора-бара аның шатлыгы тоныкланды. Кеше исәбенә килгән шатлык озын гомерле була алмый. Кифая Мәннәновнаның таш сыман каткан йөзен күрү аның өчен мең газап хәзер.

Борчыла ул бу хәлгә. Тик шомлануның сәбәбе бу гына түгелдер, мөгаен. Борчылу белән шомлану икесе ике нәрсә. Әллә күз тигезделәр инде? Галим белән дә юкка чәкәләште, ахры. Мансурга бу ошамады, үзенне тупас тоттың ди, фикереңне кешегә көчләп тагарга ярамый, ди. Ихтимал, шулайдыр да. Ләкин болар барысы да аның ихтыярыннан тыш, үзеннән-үзе килеп чыга. Чирме бу, сырхаумы, рухи бушлыкмы?

Алар театрдан кайтканда күрше апа Ләйсәнне яткырган иде инде, ут та алып тормадылар. Мансур аяк очларына гына басып кухняга чыгып китте. Ул инде канатлы Пегасны иярләп алган иде. Папкасы да калынайганнан калыная бара. Тик бүген нигәдер бахбай чыгымчылады. Ә аны тарткалаудан файда юк. Шуңа күрә озак та тормый бүлмәгә әйләнеп керде.

Җәмилә ятагына бөгәрләнеп төшкән дә, очкылык тоткандай үксеп-үксеп елый иде. Яңа күлмәге идәндә аунап ята.

* * *

Дөньяның камиллеген, төзеклеген, зарурияттын чагыштырырдай сүз тезмәсе юк. Була да алмый. Чөнки анда барысы да мыскалына кадәр төгәл тәртипкә салынган. "Әгәр дә бер кеше табигатьдә низамсызлык вә нинди дә булса бер халал (кимчелек) тапса,—диелә пәйгамбәребезнең бер хәдисендә,—бу нәрсә аның фикере дөрес эшли алмаудан, гакылы сәламәт хезмәт итә белмәүдән булыр. Юкса табигатьдә кимчелек, житешсезлек булу сүрәт тотмас".

Әйе, дөнья төзек. Көн артыннан төн килә, кыш көзне алыштыра.

Мәхәббәт, гаилә, балалар... Һәммәсе сәйлән кебек тезелешеп бара. Тик нигә соң ул төзек дөньяга кайгы-хәсрәтләр, бәла-казалар килеп керә икән? Коръән-Кәримдә турыдан-туры: "Дөнья кәдүрәт (кайгылы) йорт булып, бер сәгать шатлыгы булса, аңа мокабил (каршы) йөз сәгать хәсрәте буладыр", диелә. Шунда ук: "Кеше бәхет өчен туа",—дигән тәгъбир дә бар. Кайсысына ышанырга боларның?

Кайгы-хәсрәт кешедән ризалык сорап килми. Әнә, һич көтмәгәндә нинди зур операция кичерде ич Җәмилә. Табиблар барысы да әйбәт, дип юатсалар да, әле аның ахыры ничек бетүен берәү дә әйтә алмый.

Әлегә кадәр бу уйлар башына керeп бимазаламады. Чөнки, чыннан да, ул үзен яхшы хис итә иде. Соңгы вакытта гына бер сәбәпсез тынычсызлана башлады. Тән авыртуыннан түгел, җаны сызлый.

Хәдичәдән килеп төшкән хат исә аның эчендә баш калкытырга сәбәп кенә көтеп яткан башка шөбһәләрен дә уятты.

Хәдичә Алабугада яши. Казанның 5 нче сырхауханәсендә аңа да шундый ук операция ясадылар. Уртак кайгы аларны бик нык якынлаштырган иде. Хәзер дә хәбәрләшеп торалар. Хәлем яхшы, дип яза иде. Әмма дустының әлеге хаты чарасызлык, апатия белән тулы иде.

"Мин бервакытта да үлем турында уйламадым, пычак астына кергәнче дә, аннан соң да. Ә хәзер бу уй минем каныма сеңде. Беләсең килсә, ул минем табигый халәтем. Бәлки элек тә шулай булгандыр, мин аны басып кына торганмындыр? Һич уйламаганда бүген иртән тәрәзәдән кергән яктылык, кояш нурлары үлем турындагы уйларымны ни сәбәпледер йөгәннән ычкындырды. Югыйсә, киресенчә булырга тиеш иде кебек. Баксаң, мин инде күптәннән яшәү өчен генә, көн үтсенгә генә яшим икән ич. Минем киләчәгем өзелгән. Шуны аңладым, иртәгә күрә алырмынмы бу кояш чыгуларын, дип өзгәләнә икән ич күңелем.

Таза кешеләр бу "юк-бар"га игътибар да итмиләр. Күптәнме әле, үзем дә шулай идем. Күңелдә гел тормыш мәшәкатьләре, берсеннән-берсе яктырак хыяллар. Джон Апдайк дигән америкалы язучы үзенең көндәлегендә болай дип язып куйган: "Мин хәзер тормышымның чигеn тоям, үлемнең шакшы сулышын тоям".

Мин дә шулай, Җәмиләкәй. Аның исе, чыннан да, бар икән, шакшы ис икән ул. Икенче яктан караганда, мин фани дөнья вәсвәсәләреннән тулысынча азат. Минем киләчәгем юк. Бу бик күп нәрсәне җиңеләйтә.

Балачакта минем гел алга гына барасым килә иде, артка борылып та карамый идем. Инде миңа теләсәң дә кирегә борылып булмый..."

Җәмилә хатны елый-елый укыды. Озын-озакка сузмыйча җавап язарга ниятләгән иде дә, бу фикереннән кире кайтты. Аның үзенә Хәдичә янына барып кайтырга кирәк! Тиз, бик тиз!

Бүген болай да кәефсез иде Җәмилә. Чүп өстенә чүмәлә—Рәшидә иреннән аерылып йөри. Себер якларына чыгып китмәкче. Һаман үз дигәнен итә, киребеткән кызый. "Яратмыйм, шуңа аерылышам",—ди. Улын ятим итүдән дә курыкмый. "Бәлкем, берәр кешең бардыр?",—дип белеште Җәмилә. "Бар апам, бар,—дип сыгылып төште Рәшидә.—Шуңа күрә Казанны ташлап китәм. Чөнки безнең бергә булуыбыз иң якын кешеләремә кайгы китерер иде". "Кем соң ул?",—дип төпченде Җәмилә.— "Мин дә якын кешең ич!" "Сорама, апа, барыбер әйтмим".

Сары түшле шук песнәк кебек тиктормас вә уенчак Рәшидә басынкыланып киткән. Үзе моңсу, сүзләре моңсу. Күзгә дә туры карый алмый, карашлары очрашуга башын читкә бора. Барыбер аңлаша алмадылар.

Рәшидә артыннан ишек ябылуга, телефон шалтырады. Ләйсәннең тәрбиячесе икән.

—Бүген мине күрерсез әле,—диде ул,—кинәшләшәсе бар иде.

—Ул-бу юктыр бит, Әминә Моратовна?

—Күрешкәч аңлашырбыз, хәзергә хушыгыз, мине балалар көтә.

Башка вакытта Әминә иркенләп сөйләшә иде, Ләйсәнне макта туя алмый иде. Бу мактаулардан Җәмилә эреп китә иде. Ни булган ан бүген? Сөйләшәсең килмәгәч, кешене шөбһәләндереп шалтыратмаска гын ич. Ул барыбер кич Ләйсәнне алырга бара, шунда күрешерләр иде. болай йөрәккә ут кына салды. Әллә нинди тынгысыз, чарасыз көн булд бу. Борчу арты борчу. Көнен-сәгатен билгеләп, чиратка салып куйганна диярсең. Хәерлегә генә булсын.

Тик Җәмиләнең бу теләге сонарган иде инде. Әминә житкерга хәбәр моннан алдагы борчуларны берьюлы юып ташлады. Менә ни өче үзенә-үзе урын таба алмаган икән? Менә ни өчен шомланган икән күнеле

—Табиблар Ләйсәннең үпкәсендә чир таптылар,—диде Әминә яшь күзләрен Җәмиләгә күрсәтмәскә тырышып.

—Ни сөйлисез сез, Әминә, нинди чир?

—Сезгә иртәгә үк Ләйсәнне балалар клиникасына алып барырга кирәк.

Җәмиләнең башы әйләнеп китте, идән белән түшәм тоташып, кү алдында әллә нинди яшелле-зәңгәрле шәүләләр бөтерелергә тотынды...

Әминә аңа егылырга ирек куймады, биленнән тотып диванга утыртты су эчерде.

—Алай бик борчылмагыз әле, Җәмилә Нурулловна,—дип юатты ан Әминә,—сүз дәвалану турында гына бара ич. Берүк яшьләрегезне Ләйсәнг күрсәтә күрмәгез инде.

Бала ана өчен иң газиз җан. Ана гөл булса, бала—Лалә чәчәге. Ала бербөтен. Баланың бармагы пешәр, ананың йөрәге шешәр, ди.

Бераз тынычланугa, Җәмилә тиз-тиз генә үзен тәртипкә китерде Чыннан да, ана кызы алдында җебеп төшәргә ярамый. Сырхау була торган хәл. Бәлкем, ул кадәр өзгәләнергә сәбәп тә юктыр әле. Карасыннар тикшерсеннәр. Балада әллә нинди куркыныч чирләр булмас.

Ләйсән әнисенең хәлен бер карауда сизеп алды.

—Әнием, әллә теге усал апа тагын ачуландымы?—дип сорады кызгану тавыш белән.

—Нинди усал апа, кызым?

—Теге соң, училищеда бар ич инде... К... Ки...

—Кифая Мәннәновнамы? Ә син аны каян беләсең?

—Әтиемә үзең сөйләдең ич, усал дидең, елатты дидең.

—Кара, нинди астыртын кыз икәнсең син? Зурларның сүзен тынла торырга ярамый. Яра-мый!

—Әнием, мин бит үзем түгел, колакларым. Мин курчаклы уйныйм, алар тыңлый.

—Шуннан?

—Шул чактагы шикелле битеңдә яшь эзләре калган.

—Монысы да колаклармы?

—Юк, әнием, монысы күзләр.

Ләйсән чирлегә ошамаган. Үзен тотышы да элеккечә. Шаяра, көлә Авызы да ябылып тормый. Тик баскычтан икенче катка күтәрелгәндә сулышы катып, тукталып калды. Ял итмичә күтәрелә алмады.

Мансур кайткан иде инде. Тиз генә Лилиягә шалтыратты. Җәмилә аны капка төбенә чыгып каршы алды.

—Лилия, Ләйсән авырый бит, нишлим?

—Йә, Ямилә, син нәрсә, бала төчкергән саен кара кайгыга төшәрг ярамый ич енде. Минем үземнеке дә еш авырый, үзен беләсен.

—Куркам мин, Лилия, бердәнберем бит...

Лилия һәрвакыт үзен акыл кысасында тота белә. Килеш-килбәте дә характеры да шул образга туры килеп тора. Кара калын кашлары нәкъ кү өстендә. Бу аны бераз олыгсыта. Җитди, сүзен уйламыйча әйтмәс. Шун күрә кайберәүләр аны тәкәббер, эре диләр. Әмма Лилия искиткеч кешелекле гадел, ярдәмчел хатын. Дуслыкның кадерен белә торган, аны саклый белә торган зат. Ул табигате белән табиб. Кешеләрне тынычландыру өчен бер

күз сирпеп каравы да житә. Аңа ышанасын, йөрәгеңне ачасың. Әле дә: "Сара апа ижат йортыннан кайткан, киләсе атнада жыелышып утырыйк әле, ул сезне бик ошаткан",—дип, сүзне икенчегә борды.

Лилия Ләйсәнне жентекләп тикшерде, күкрәген, сулыш юлларын тыңлады. Анализларны, күкрәк сурәтен алганнан соң янә дә кинәшләшергә хәл иттеләр. Лилия бер жаен табып, Мансурны бик нык кисәтте. "Анализларга үзең йөре, табибка икәү барырбыз. Ямиләне бу шөгыльгә катнаштырырга ярамый",—диде.

—Хәл шулай бик житди мени?

—Моны анализлар күрсәтер. Шуны гына әйтә алам, сулышы бик киеренке. Үпкәсендә нидер бар. Пневмониягә дә охшаган.

—Пневмонияне дәвалыйлар ич инде аны.

—Әлбәттә!

* * *

Пневмония вакытында тән температурасы югары була. Ә Ләйсәннеке гадәти. Үзе шушы берничә көн эчендә күзгә күренеп боекты. Ятып торуны гына карый. Бытбылдык урынына бытылдый торган кыз сөйләшмәс булды. Көйсезләнә. Кайвакыт, мине бакчага илтегез, дип өзми дә, куймый да. Анализлар да озаккарак сузылды. Кат-кат тикшерделәр. Төгәл генә диагноз куючы да юк. Табиблар үзләре дә каушап калдылар кебек. Әллә белеп житкермиләр, әллә дөресен әйтергә кыймыйлар. Мансурның исә кызын тизрәк сырхауханәгә саласы килә. Ачуланышып та беттеләр. Ачуланышырлык та бит, поликлиникада анализлар үткәрмичә торып, сырхауханәгә юллама бирмиләр. Ул анализларны дәвалаучы табиб үткәрсә, мең өлеш файдалырак булыр иде ләбаса! Юк, янәсе, балалар медицинасының үз үзенчәлекләре бар. Нинди үзенчәлектер инде ул, Мансур төбенә төшә алмады.

Ниһаять, барысы да рәтләнде шикелле. Ләкин Лилия хастаханәгә яткырыр алдыннан Ләйсәнне профессорга күрсәтеп алырга кирәк, дип киңәш итте. Мин сөйләшеп куйдым инде, диде. Мансур соңыннан гына белде, Сегал атлы бу профессорга ике-өч ай алдан чиратка язылып куялар икән. Тора-бара шунысы да ачыкланды, бу Бөгелмә табибы Шарон Моисеевичның туганы икән. Анысы Жәмиләне караган иде, Ләйсән монысының кулына килеп эләкте.

Шулай итеп, Ләйсән шәһәр халкы арасында төрмәдән дә хәтәррәк яманаты чыккан Кремль янындагы онкология сырхауханәсенең бусагасыннан атлап керде.

Казан ханлыгы басып алынганнан соң Кремль ныгытмаларының читендә күтәрелгән бу бинада баскакларның кара хезмәтчеләре: ат караучылар, пешекчеләр, йомышчылар яшәгән. Шунда эшләгәннәр, шунда яшәгәннәр.

Әлеге бина Кремль тавының эченә уелып кергән. Шуңа күрә күзгә бәрелеп тормый. Вак кеше үзе дә, торагы да байгураларның ак тормышын бозарга тиеш түгел, дип фараз иткәннәр, күрәсең. Ләкин бина жиренә житкереп эшләнгән. Стенасын аю да ватарлык түгел, кайбер урыннарында метрдан артып китә. Озын коридорның уң ягында бүлмәләр тезелешеп киткән, сулда—тәрәзәләр. Алары монастырь тәрәзәләре шикелле бүрек кенә сыймалы. Аның урынына, ишек уемнарына дугалы ат белән керергә була.

Ләкин заман, юклык күптәннән боларга үз мөһерен суккан инде. Элекке ныклыктан хәрәбәләр генә торып калган. Ремонт та булмаган ахырысы. Бина эче киндерә белән буып куелган иске фракка охшап калган. Үзенең караңгылыгы, шомлылыгы белән ул онкология дигән XX гасыр чумасына бик туры килә иде. Әмма монда яман шеш белән авыручылар гына ятмый. Шешнең дә төрлесе була. Ләйсән кебек консультациягә килүчеләр дә байтак. Ә ул мескенем оясыннан егылып төшкән кошчыктай дер-дер калтырана.

Мансур аны кочаклап алды.

—Әтием, өйгә кайтыйк, мин куркам,—дип пышылдады Ләйсән.

—Хәзер, кызым, профессор абый карасын инде, ярыймы?

—Ул укол кадамыймы соң?

—Юк, кызым, кадамый. Борчылма, яме?

Сегалның кабинеты иң түрдә икән. Бара-бара да ялкып бетәрлек. Ә анда Лилия көтеп тора иде инде.

—О-о, Ләйсән нинди матур күлмәк кигән,—дип елмаеп каршы алды ул аларны.

Ләйсән "күлмәк" кармагына капмады. Йөргәндә күкрәге кыса, сөйләшүе авыр иде аңа.

Бераз утырып хәл алгач, кабинетка үттеләр. Сегал такыр башлы, зур борынлы кеше икән. Сөйләшкәндә "к" авазын йөгертеп кенә уздыра. Затлы яһүд. Ул иң әүвәл анализларны күзеннән кичерде, рентген сурәтен карады. Аннан соң Ләйсәннең күкрәген тыңлады да, Лилиягә карап: "Баланың үпкәсе сары су белән тулган. Ул "Балалар үзәге"ндә шуны да суырта алмыйлар микәнни соң? Аһ, булдыксызлар, әле ничек тын ала бу бала, аңламыйм",—дип сукранды.

—Сары су мәсьәләсендә мин үзем дә шулай фаразлаган идем Абраам Моисеевич,—диде Лилия.

—Фаразларга без барыбыз да оста, җаваплылык алырга булганда гына куак артына кереп посабыз. Соң мин сезне институтта шуңа өйрәттеммени, Моратова?

—Юк инде, Абраам Моисеевич...

—Мөхәммәтҗан түгел, әйе, Абраам Моисеевич! Мин алтмыш ел инде шул атымны йөртәм. Һы. Хәзер тиз генә процедурныйга барыгыз, суны суырттырыгыз. Менә юллама, анда барысы да язылган. Ә без хөрмәтле әти кеше белән гәпләшеп алырбыз. Аһ, бу булдыксызларны, ә? Баланы интектергәннәр бит, ә?

Сүзгә керешкәнче, Сегал шар кебек кабарынкы күзләре белән Мансурга текәлеп карап торды.

—Мин сезгә, атакай, бары тик ныклык кына тели алам,—диде ул Мансурның хәленә керергә тырышып,—бик кызганыч, әлбәттә, әмма минем вазифам шундый тәкәллефсез инде, нишлисең? Безнең медицина этекитына туры килмәсә дә, турысын әйтәм, атакай. Чөнки монда вакыт бик аз калган. Кызыгызның үпкәсендә саркома. Аның нинди чир икәнен беләсездер, дип уйлыйм. Сырхауханәгә дә салмаска киңәш итәр идем. Соңгы сәгатьләрен бергә үткәрегез. Фатирыгызга килеп, атнага бер мәртәбә үпкәсен чистартырлар, әйтермен. Башка вакытта укол кадатырсыз. Анысын Моратова үз өстенә ала.

Менә шулай, атакай. Хушыгыз!

Мансур профессор кабинетыннан үз аяклары белән чыктымы, күтәреп алып чыктылармы, анысын хәтерләми. Исенә килгәндә ул туалетта иде. Ниндидер юан торбаны кочаклаган да, бөтен тавышына кычкырып елый иде. Янында кешеләр дә бар. Ачлык патшасына ошаган бер арык абзый аны юатырга чамалый.

—Энекәш, без монда барыбыз да шул чуттагы кешеләр инде, әҗәл көтеп ятучылар. Исемлегебез Газраил кулында... Кемең иде соң, әтиеңме, әниеңме дигәндәй...

Бу сүзләр Мансурны уятып җибәрде. Нинди әти ди, нинди әни? Ләйсән ич, кызы! Ул аны эзлидер, әтием кая, дип елыйдыр. Кызым, Ләйсәнем! Хәзер килеп житәм, җәме? Елама, матурым, җәме? Бәләкәчем минем... җәме...

Мансур тирә-ягындагыларны борчуга салып, туалеттан чыгып йөгерде.

—Егетнең шөрефләре бушый башлаган,—дип сөйләнде арык абзый.—Кайгы шулай ул, кайгы җаныңны суыра ул.

Мансур коридордан өермә шикелле җилләнеп узып китте. Лилия аны ябык ишек янында кая барып төртелергә белмичә суккаланганда куып

китте. Моның элекке чире кузгала күрмәсен, дип борчылып куйды ул. Бу гаиләдә хәзер иң кирәк нәрсә Мансурның саулыгы, Мансурның тотрыклыгы.

—Мансур, зинһар, Ләйсәннең кәефен җибәрә күрмә,—дип Лилия аның калтыранган кулларыннан алды. Чөнки бу минутта Мансурны упкынга тәгәрәүдән үзе упкын алдында торучы кызы Ләйсән генә коткарып кала ала иде. Лилия шуна исәп тотты да. Ялгышмады. "Ләйсән" сүзе Мансурны әти вазифаларына кайтарды.

—Ләйсән кая соң, Лилия, кызым кая?—диде Мансур ниндидер мескен басынкылык белән.

Ләйсәннең укол кадатудан коты алына иде. Ә монда иркәләнер якын кешеләре булмагангамы, бәлки җинеллек киләсен сизептер, күкрәк куышлыгына камыт энәсеннән дә юанрак энә керткәндә дә үзен тыныч тотты. Фәкать бар булган көченә Лилиянең итәген генә йомарлап кысты.

Литрга якын сыеклыкны биш-алты минутта суыртып бетерделәр. Ләйсәннең үпкәсе, сулыш юллары, йөрәге үз халәтенә кайтты. Җинеләеп китте, бит очлары алсуланды. Ләкин әле торырга рөхсәт итмәделәр, ярты сәгать ятып торырга куштылар.

—Ул әле ял итә,—диде Лилия,—үзен әйбәт хис итә.

Суга баткан кешенең саламга ябышканы шикелле Мансур Лилиянең әлеге сүзен эләктереп алды.

—Чыннан да шулаймы, Лилия, әйбәт хис итәме? Теге шар күз шимбә чыгырдан чыгара язды бит, әй. Яшь организм барысын да җинәргә тиеш ул, шулай бит, әйеме? Дөньяда могҗиза дигән тылсым да бар ич. Украинада, әнә, бер егетне үлде дип күмеп куйганнар. Йөргән кызы кайтып төшкән дә каберне казыткан. Егет уянган, мәрткә генә киткән булган икән. Менә шуннан соң ышан син табибларга?

Лилия форсаттан файдаланып калырга ашыкты.

—Могҗизалар да була, әлбәттә,—диде,—аны медицина фәне дә инкарь итми. Шулай ук табиблар да ялгышырга мөмкин. Алар да кеше. Шуна күрә мин сина әйтәм дә, Ямиләгә чын хәлне әлегә еткерми торыйк. Вакытлыча дим. Ул аны бик авыр кичерәчәк.

Мансурның янә күңеле тулып, ташып чыкты. Башын Лилиянең җилкәсенә куеп үксергә тотынды.

Лилия аны җайлап кына урындыкка утыртып, процедурныйга кереп китте. Аннан ярты стакан су алып чыкты да көчләп диярлек Мансурның авызына агызды. Мансур аның спиртлы су икәнен дә абайламады. Ә ун-унбиш минуттан хәмер үзенекен эшләде. Мансурга хәсрәте дә алай ук куркыныч булып тоелмый иде инде. Ләйсән, һичшиксез, тереләчәк. Тереләчәк! Андый гына күңелсезлекләр була инде ул. Кемнең баласы чирләми? Әнә, бакча мөдире нәрсә ди, бервакытта да тулы составта эшләгәнебез юк, ди. Надан табибларның сүзенә карасан, бер генә сау кеше дә юк хәзер. Тәмәке агулы диләр, Муса әйтмешли, үзләре рәхәтләнеп пыскыта. Хәмерен дә чөмерәләр генә. Менә шуннан соң ничек ышанасын ди аларга. Монафыйклар?! Элекке чак булса, теге Сегал дигән коры куыкны дуэльга чакырыр иде. Ул "шимбә"не әллә саклап торып, туйганчы ишәргә инде?

Мансурның йодрыклары йомарланудан аның эчендә ниләр кайнаганын сизеп тора иде Лилия. Бу халәте тиздән узачак. Ана кадәр кайбер мәсьәләләрне хәл итеп куярга кирәк. Иң мөһиме, сүзен алырга!

Тик өлгерә алмый калды. Мансур үзе һөҗүмгә күчте.

—Җәмилә Ләйсәнне бүген үк сырхауханәгә салуны таләп итәчәк. Ә син салмаска дисең. Мин ана ни дип җавап бирергә тиеш? Алдашырга, ялган сөйләргәме? Юк, мин ялганга бара алмыйм. Ул бит Ләйсәнне тудырган ана! Аңлыйсынмы? Ана! Алай булмый ул, Лилия, булмый! Син хаклы түгел.

Бу сүзләр Лилияне айнытып җибәрде. Чыннан да, нигә соң әле ул кешенең шәхси тормышына шулай тыкшынырга тиеш? Эшләсеннәр үзләренчә. Үз балалары. Әле аларның кайчан да булса, син безне ялгыш юлга этәрдең дип, дәгъва белдерүләре дә бар ич.

—Ихтыярың,—диде Лилия,—әйттем исә кайттым.—Ләйсән әзердер, бар, янына кер. Минем инде кирәгем юк, киттем.

Ләйсән урыныннан торган иде инде. Йөгереп килеп әтисен кочаклап алды.

—Әтием, мин хәзер уколдан курыкмыйм. Лилия апа әйтә, укол чирне алып китә, ди, Минем инде тыным кысылмый.

Мансурның йөрәген гуя чеметеп алдылар. Лилияне бер дә юкка рәнжетте ләбаса! Кеше ничек итеп булышырга белмичә өзгәләнеп йөри, ә бу көйсез кияү кебек тузына. Имеш, нишләргә икәнен ул үзе дә бик яхшы белә, имеш, алдашырга күнекмәгән. Рәшидә белән очрашулар... Бу алдашу түгелмени, алдашу гынамы, хыянәт!

Ул бүген үк өйләренә барып Лилиядән гафу үтенәчәк. Шулай дип күнеленә беркетеп куйды Мансур. Ләкин өйләренә барырга туры килмәде. Таш капка янында аларны Лилия үзе көтеп тора иде. Ләйсән кулларын җәеп, аңа каршы йөгерде.

* * *

Итегең тар булгач, дөньяның киңлегеннән ни файда. Тик кеше барысына да күнегә. Аның психологиясе, үз-үзен тотышы тормыш шартларына карап үзгәрә, шуңа җайлаша бара. Ул теләсә-нинди очракта да үз гамәлләрен ярлыкарлык сәбәп таба белә. Чехов кеше характерының бу үзенчәлеген бик оста тасвирлый. Аның бер герое, мәсәлән, дус-ишләрен менә болай өйрәтә. "Бармагыңа, фаразан, шырпы керде, ди. Әле ярый, күземә эләкмәде, дип моңа шатланырга гына кирәк. Әйтик, хатының хыянәт итте, ди. Янә дә шатлан. Ул бит Ватанга түгел, иренә генә хыянәт иткән".

Мансур белән Җәмилә дә инде айга якын чиратлашып Ләйсәнне карыйлар. Ике көннең берендә Лилия белән Галим килә. Сегал да сүзендә торды. Тормышлары шушы ритмга көйләнде. Әйтерсең лә, гомер буе шулай яшәгәннәр. Мансур үзен Ләйсәннең яшь организмы чирне җиңәчәк, дип юата. Шуңа үзен ышандырырга тырыша. Җәмилә чын диагнозны белми. Чөнки Лилия уколдан соң өстәлдә башка дару шешәләрен калдыра. Шуңа күрә Ләйсәннең терелүе анарда икеләнү тудырмый.

Фаҗига һич көтмәгәндә килде. Аңа Җәмилә дә, Мансур да әзер түгел иде. Хәер, кеше барысын да алдан белеп торса, җир йөзендә тотрыклы тормыш та булмас иде. Билгесезлек, өмет, хыял алдап яшәтә кешене.

Бер-ике генә көн элек Җәмиләнең сабакташ дусты Мөнирә килеп киткән иде. Аларны институтта ахирәтләр дип беләләр иде. Бу, нигездә, дөреслеккә туры да килә иде. Ләкин институттан соң аралары суынды. Җәмиләнең элек тә аңа эч серен ачканы булмады. Чөнки Мөнирә үз сүзен генә дөрескә саный торган кеше. Өйрәтергә бик һәвәс. Теләгенә ирешү өчен бернәрсәдән дә тартынмый. Шуңа күрә өнәп тә бетермиләр. Ә Җәмилә барыбер ихтирам итә. Чөнки аны Мансур белән Мөнирә таныштырды.

—Кызыңны карап торып үтерәсең икән ич син,—диде Мөнирә алдын-артын уйлап тормыйча.—Врачларга гына карап ятма. Алар бернәрсә белми. Халык медицинасы буенча дәваларга кирәк. Менә мин үзем бәвел белән генә торам. Көн саен эчәм. Иртәгәдән үк кызыңа үз бәвелен эчерә башла. Үзең дә эч! Ләкин уртасын. Аңладыңмы уртасын! Бөтен файдалы матдәләре уртасында.

Мөнирә аңа бер багучының да адресын биреп калдырды, иртәгә үк барыгыз, диде. Бик белә торган багучы, диде, кулы белән бер сыйпап алуда әнинең бөсерен алып ташлады, диде. Ышандырды. Лилиягә белгертми генә барып кайтырга булыр, дип уйлады Җәмилә. Бәлкем, дөрестән дә файдасы тияр? Лилия андый ырым-шырымнарга ышанмый.

Мөнирә усал кайнанадай әйтәсен әйтеп бетерде дә, гадәтенчә, авызындагы бар булган тешләрен күрсәтеп, тартынмыйча шаркылдап көлеп алды. Аннан соң тагын кисәтте:

—Кара аны, кызынны тизрәк аякка бастырыйм дисән, мин әйткәннәрне эшлә,—диде.—Алма пеш, авызыма төш, дип ятма. Үкенергә туры килмәсен!

Мөнирә Ләйсәнне читтән генә күзәтте, янына барып та карамады. Ерактан торып кына, әниең кебек матур икәнсен, дип елмайгандай итте. Чәйдән дә баш тартты. Чире йокмасын дип шикләнә иде, ахры. Ул аны яшереп тә тормады. Кулъяулыгы белән кулларын сөртештереп алгач кына саубуллашып китте.

—Кәкәй апа,—дип борынын жыерды Ләйсән.

Җәмилә Борисково бистәсендәге әлеге багучыга зур чиратлар аша үтеп керде. Кемнәр генә юк иде анда?! Яшьләр дә, картлар да, балалар да. Хатыннар да, кызлар да, ир-атлар да. Әйтерсен лә, бер генә исән кеше дә юк бу дөньяда. Халык тырышып-тырмашып яшәү өчен жан тырмаша.

Багучы, шома йөзле, калын гәүдәле, хатын иң элек конверт белән кызыксынды. Ул акча гына ала икән. Беренче керү—йөз сум. Ләкин түләү белән исәпләшеп торучы юк, файдасы гына тисен.

Йорт хужасы Ләйсәнне каршысына утыртып, ниндидер догалар укый-укый өшкерергә тотынды. Шул арада чире турында да сораштырып ала. Бераздан ул уфылдап, диванга барып ауды. Күзләре кызарган, куллары калтырана.

—Кешегә булышам дип, үзең аяк сузасың бугай инде,—диде ул үз-үзенә сөйләнгәндәй.

Бер өлкәнрәк яшьтәге хатын, ярдәмчесе булса кирәк, сөйләнә-сөйләнә аның мангаена юеш сөлге япты.

—Аллаһы Тәгалә сине жиргә кешеләргә ярдәм итү өчен жибәргән, абыстай, бу изгелекләрен, күрерсең, мең рәхмәт булып кайтыр, пәйгамбәр дәрәжәсендәге илаһи зат бит син.

—Моның да кадәр бозыкка күптәннән тап булганым юк иде,—дип багучы бераздан үз урынына кайтты.—Күрдегезме, мин булып мине бөтереп алды. Ай-һай. Әле ярый, Аллаһының рәхмәте белән, бозыклыгын үзем аша үткәрдем. Качты иблис. Хәзер мин сезгә ашамлыкларыгызны өшкереп бирәм, бу чибәр кыз, иншалла, бер атнадан яшь колындай чабып кына йөрер.

Җәмилә багучының аяк астына барып егылды, кулларын үпте. Аңа жире-күге белән олы шатлык килде.

* * *

Ләйсән күтәренке кәеф белән торды. Башка көннәрдә шыр тиргә батып уяна да: "Әнием, мине коч, әнием...",—дип Җәмиләгә сөлек шикелле ябыша иде.

Җәмилә кызын иркәли-сөя, чәчләреннән сыйпый, колагына татлы сүзләр пышылдый. Шулай ун-унбиш минутлап яратышып ятканнан соң гына тынычлана иде Ләйсән.

Ә бүген бөтенләй башка, ятагында көлеп-елмаеп ята. Димәк, тьфү, тьфү, күз генә тимәсен, багучының әйткәннәре дөрескә килә, димәк, Ләйсәннең бернинди сырхавы да юк. Бозыклык кына. Ә ул бозыклыкны багучы абыстай куып чыгарды инде. Мөнирәгә рәхмәт, ул килеп жилтерәтмәсә, бу турыда исләренә дә кереп чыкмый иде бит.

Җәмилә шатлыгын Мансур белән уртаклашырга ашыкты.

—Жанаш, бүген безнең хәлләр әйбәт, кризис үтте ахры. Кызың торт сорый.

—Әйттем бит, яшь организм барысын да жиңә ул дип. Тик торт белән генә булмастыр, мөгаен, шампан да кыстырырга туры килер. Минем өчен дә әп ит, ярыймы?!

—Ярар, жанаш, хәзергә хуш, көтәбез!

Ләйсән көндәгедән күбрәк ашады. Бу да Җәмиләнең ышанычын арттырды.

Чәйдән соң Ләйсән Алсу исемле яраткан курчагын сорап алды. Бик матур курчак ул, "әннә", дип тә әйтә белә, атлап та китә. Ләйсән аның күлмәген алыштырды, чәчен тарап, күбәләк бант бәйләде. Аннан каршысына бастырып, озаклап карап торды да:

—Әнием, минем дә бәбкәччәем булыр микән?—диде.

Җәмилә кер үтүкли иде, кулы кайнар үтүккә тиеп китте. Чак кычкырып җибәрмәде.

—Әнә, Алсуың бар бит инде, кызым,—дип кулын сулы савытка тыкты.

Ләйсән башын чайкады.

—Алсу курчак кына ул, әнием. Сезнең минегез бар, Ләйсәнегез. Минем дә үз бәбкәччәемне сөясем килә.

—Сөярсең, кызым, вакыты житәр, сөярсең...

—Бәби эчтә була бит, әнием, әйеме?

—Әйе...

—Мине синең эчеңә әтием кертте бит, әйеме? Мин күрдем... анда тагын бәбәй бардыр әле.

Бу юлы сулы савыт идәнгә төшеп китте...

Сырхау кызчыкның әлеге эчкерсез кызыксынуы бик олы мәгънәгә ия иде. Чынлыкта Ләйсән үз-үзе белән гәпләшә, сорауларына җавап эзли. Чөнки ниндидер илаһи көч аның табигать-ана фарыз кылган хатын-кыз хиссиятен уятып җибәргән иде.

—Үсәрсең, кызым, мәхәббәтең килер, яраткан кешең белән кавышырсыз. Кечкенәгез туар...

—Әнием, мин арыдым,—диде Ләйсән,—Алсуны да алып куй. Ул курчак кына, минем бәбкәччәем түгел.

—Ярар, кызым, ял итеп ал, җә өзлегерсең. Мин әтиең кайтуына мичкә бәлеш ясап тыгыйм. Бүген безнең бәхетле көнебез.

—Әнием, минем йокым килә...

Бу Ләйсәннең соңгы сүзләре иде. Җәмилә эшен бетереп бүлмәгә кергәндә кызының гөнаһсыз җанын фәрештәләр Аллаһы хозурына алып китеп баралар иде инде.

Күрәсең, ул үзе дә сизмичә мәңгелеккә күзләрен йомган. Иреннәрендәге елмаю әле сүнәргә дә өлгермәгән иде. Әйтерсең лә йокыга гына талган, әйтерсең лә төшендә хыялындагы бәбкәччәен сөеп, назлап, шуңа куанып елмая.

...Мансур телефон трубкасын һичнинди шикләнүсез алды. Чөнки ул әле дә Җәмиләнең иртәнге шифалы сүзләре тәэсирендә иде. Көне буе күтәренке күнел белән йөрде. Торты да, шампаны да, башка тәм-томнары да инде күптәннән хәзерләп куелган иде.

Трубкада башта сүз түгел, авыр сулыш кына ишетелде.

—Тыңлыйм,—диде Мансур түземсезләнеп.

—Мансур...

Мансур барысын да аңлады.

* * *

Җеназага килгән кешеләрне автобус илтә китте. Мансур белән Җәмилә Үзәк универмаг янында төшеп калдылар. Аларның хәтта Лилия белән Галимне дә күрәселәре килми иде. Аларны Рәшидә озата китте. Ул да бик басынкы иде, Мансурга да күтәрелеп карамады.

Урам тулы халык. Этеләләр-төртеләләр, каядыр ашыгалар. Бу ике бәхетсез затның гына ашыгыр урыны юк. Ни үле, ни тере хәлдә кай якка атларга белмичә житәкләшкән килеш басып торалар. Гәүдәләре бар, сыннары, аяк-куллары исән, күзләре күрә, жаннары гына зиратта, Ләйсән янында калды. Һай, авыр да икән йөрәк бәгъреннән яралган сабыеңны салкын каберләргә илтеп салуы. Нинди гаделсезлек?! Кеше рәнжеткәннәре юк, кеше хакына кергәннәре юк, кулларыннан килгәнчә һәркемгә ярдәм

итәргә тырышалар, урлашмыйлар, хәрәмләшмиләр... Ни өчен шушылай да зур кайгы төште соң аларның башына? Ходай булса, моңа ирек бирмәс иде. Юктыр ул, юк!

Ыгы-зыгылы бу дөньяда алар чит, ят иделәр. Бер олырак кына ханым: "Сезгә бер-бер хәл булган ахыры, ярдәм кирәкмиме?"—дип сорады.

Кем аларга ярдәм итә алсын соң? Бигрәк тә Җәмилә бетерешге. Сәхнәдәге балерина шикелле очып кына йөргән җинел сөякле хатынның атлауларына кадәр үзгәрде. Атламый, сөйрәлә. Иреннәре дә кияүгә чыкмыйча картайган әбиләрнекенә ошап калган. Бернәрсәдә, беркемдә гаме юк. Эчетышы уй. Ул фәкать уйдан гына тора. Ә уй бик хәвефле нәрсә. Ул кешене соңгы чиккә китереп җиткерә. Җәмилә дә шул хәлдә иде.

Ләйсән аның әҗәлен кабул иткән ләбаса! Әйтәләр бит, үләсе кеше үлмәсә, аның урынына башка кеше үлә, дип. Сырхау башта Җәмиләгә килде. Димәк, аның тырышып-тырмашып яшәү арбасында калуы кызының үлемен якынайткан гына. Ул үләсе урынга Ләйсән үлгән. Җә, хода! Нинди үкенеч! Ике дә уйламыйча кызы урынына үзе ләхеткә кереп яткан булыр иде. "Иде" генә шул, хәзер соң инде, бернәрсә дә кылып булмый.

Ә ничек булмасын ди? Була! Ул Ләйсәне янына ята ала ич!

—Мин Ләйсәнсез яши алмыйм,—диде Җәмилә,—минем өчен бу тормышның мәгънәсе калмады. Чөнки мин бур. Кызымның гомерен урладым. Мин аның янында булырга тиеш.

Мансур үзе дә иләс-миләс иде. Әллә аңлап, әллә төшенеп җиткермичә: "Мин синең үзеңне генә җибәрмим",—диде.

Җәмилә Мансурның кулын салкын учына алды. Ният-гамәлләренең уртаклыгы аны бик нык куандырды. Чын ир икән Мансур! Сынау сәгатендә бернинди икеләнүсез Җәмилә ягына чыкты. Синең өчен җаның бирергә дә әзер торучы якын кешең булу нинди зур бәхет!

Ләкин ул Мансурны үзе белән алмаячак. Аның әле асыл чагы. Гаилә дә кора ала. Ә Җәмилә кысыр хатын. Операция аны Аналык бәхетеннән мәхрүм итте. Ләйсән беренче һәм соңгы шатлыгы иде.

Кисәк кенә шәһәр урамнарын ак мамыкка төреп кар ява башлады. Ишә генә. Мизгел эчендә юллар, тротуарлар, трамвай-троллейбуслар, машиналар, өй түбәләре кар белән капланды. Кешеләр дә муеннарын җилкәләренә җыерып, башларын җил уңаена борып атлыйлар. Җепшек кар барыбер үз урынын таба, кашларга, керфекләргә, киемнәргә сылана. Мөгаен, бу соңгы кардыр инде. Апрель уртасы ич! Һавада яз исе. Тик ни хикмәттер, күпләр дөнья белән дә нәкъ менә шушы чорда, табигать уянган чорда хушлаша.

Алдан сөйләшеп куйгандай, Мансур белән Җәмилә житәкләшкән килеш урам чатындагы даруханәгә таба атладылар. Бер-берсенә карамыйча тын гына пыяла шкафларга куелган даруларны җентекләп күздән кичерделәр. Ләкин ул даруларның берсен дә рецептсыз бирмиләр икән. Аларны кызыксындырганнарын хәтта күргәзмәгә дә куймаганнар.

—Әйдә, кайтыйк, мин нишләргә икәнен беләм,—диде Мансур ниндидер битараф салкынлык белән.

Сөйләшмичә генә атладылар. Кайгы аларны тәмам үз кочагына алган иде инде. Күзәнәкләренә кадәр сагыш, әрнү белән тулган. Олы җанның хәсрәте дә олы. Аларга хәзер кайгы баш, зиһеннәре шул кайгы белән томаланган.

—Мин үзем барысын да рәтлим, әзерләнә тор,—дип Мансур Җәмиләне өйгә кертеп җибәрде. Ул хатынының баскычтан менеп җиткәнен көтеп торды да, гараж ягына борылды. Иң элек машинасын юды, чистартты, утыргычларын көйләде. Моторын кабызып, яхшылап җылытты —сүнмәслек булсын! Аннан соң машинаның газ чыгару торбасына шланг кигезеп, очын салон эченә беркетте.

Инде барысы да әзер. Мансурда һичнинди икеләнү тойгысы юк. Хәтта бу коточкыч гамәлнең зур фаҗига булуы хакында да, аның якыннарына, туганнарына ничек тәэсир итүе хакында да уйлап карамады. Әйтерсең лә,

каядыр баралар гына, хәзер урап кайтачаклар...

—Мансур, җанаш, миңа атап чыгарган җырыңны җырла әле,—диде Җәмилә.

"Кил, Җәмиләм" җыры популяр җырга әверелде. Халыкка ул сәхнә, эстрада аша таралды. Аны хәзер радиодан да яңгыраталар, худсовет кушмый дип тормыйлар. Җәмилә үз җыры белән бик горурлана иде.

Киенгән-ясанган, өстендә затлы кара күлмәк, башына кара төстәге челтәр япкан. Читтән караганда ул поезд астына ташланырга җыенган Анна Каренинаны хәтерләтә иде. Шундый ук нәзакәтле, шундый ук сагышлы, шундый ук тәвәккәл.

Мансурның бармаклары баян төймәсенә ятты. Беренче аккордны алды, тик дәвам гына итә алмады, башы баян өстенә салынып төште.

Җәмилә аның муеныннан кочаклап алды.

—Син елый аласың әле, җанаш, ә минем күзләрем кипте,—диде ул үкенечле тавыш белән. Көчем дә, хисем дә юк, коры кабыкка әйләндем. Шәүлә генә инде мин хәзер...

—Минем синең алдыңда бик зур гөнаһым бар, Җәмилә, авыр булса да әйтми булдыра алмыйм...

—Мин аны беләм, хатын-кызның йөрәге сизгер аның...

—Беләсең? Рәшидә белән булган хәлне беләсеңме?

Хатыны аңа ялынып-ялварып карады. Мансур барысын да төшенде, Җәмиләнең бу хакта сөйләшәсе дә, ишетәсе дә килми.

—Син фәрештә кебек пакъ, җанаш...

—Мине шулай күз алдыңда калдыр...

—Ничек калдыр? Ә мин?

Баянның күрүге идәнгә сузылып төште.

—Кеше дөньяга ялгызы килә, ялгызы гына китеп тә бара,—дип дәвам итте сүзен Җәмилә.—Хәдичә шикелле мин дә күңелем белән гомеремнең чиген тоям. Ләйсән өчен җәзаны мин алырга тиеш. Син дә китсәң, кем килеп хәлебезне белер, кем безгә чәчәкләр китерер? Ташландык кабер-хәтерсез кабер. Минем эзсез генә югаласым килми. Шулай килешик, җанаш, ярыймы?

Җәмилә Мансурның алдына утырды, кулы белән аның чәчләреннән, битләреннән сыйпады.

—Миннән инде башканы көтмә...

Мансур Җәмиләне иплэп кенә итәгеннән төшерде дә, тәрәзә янына килеп басты. Бу тәрәзә эчке яктан гына тәрәзә. Рамы бар, пыялалары бар. Яктысы гына юк. Чөнки тышкы яктан томаланган. Дөресрәге, янгын куркынычсызлыгы максатларында йортның күләгә ягына кирпечтән саклану стенасы өйгәннәр. Шуңа күрә бүлмәдә һәрвакыт караңгы, тәүлек буе ут яндырырга туры килә.

Безнең тормыш та нәкъ менә шушы томаланган тәрәзә кебек хәзер, дип уйлады Мансур, дөм караңгы. Бөтен нурны, яктылыкны Ләйсән үзе белән алып китте. Бу стенаны җимерүдән дә файда юк. Элегрәк җимерәсе калган. Ләйсән исән вакытта.

—Фатиханы бир,—диде Җәмилә.

—Сөйләштек ич инде, җанаш...

Мансур бер бит кәгазьгә зур хәрефләр белән: "Бәхил булыгыз, безне кызыбыз Ләйсән чакыра",—дип язды да хатынының алдына килеп тезләнде:

Кил бәгърем, якты илһам бул син,
Яз шагыйре—назлы былбылга—
Сиңа атап былбыл моңын сибәр,
Өзелеп сайрар синең алдыңда...

Көтмәгәндә ишек шакыдылар. Зур гаеп өстендә тотылгандай икесе ике якка тайпылды. Җәмилә ишек чаршавы артына кереп посты, Мансур кая барып сыенырга белмичә идән уртасында таптанып калды.

Янә шакыдылар. Мансур ишеккә келә салырга онытган икән, ишек

уемында шакучы үзе пәйдә булды.

—Галим!—дип кычкырып җибәрде Мансур.

—Мансур!

Аларга Җәмилә белән Лилия килеп сарылды. Сүзләр артык иде. Бу кичерешләрне аңлатырдай сүзләр әле уйлап табылмаган.

Галим күз кырые белән генә өстәл өстендәге язуны күреп алды. Башта аңышмый торды, ниткән "бәхил булыгыз", ди ул? Дусларының килеш-кыяфәтләрен күздән кичергәч кенә бу куркыныч язуның мәгънәсе башына бәрде. Шул ук секундта Мансурның изүеннән эләктереп алды да, уңлы-суллы чәбәкләргә керешге. Куллары талганчы чәбәкләде.

—Туксан тугызлы икәнлегегезне белә идем. Шуның өстенә сез әле мисез дә икән,—диде Галим сулышына буыла-буыла.—Үз-үзенә кул салган кешедән дә каргалган кеше юк, шуны беләсезме? Элек аңдыйларның мәетен зиратка да кертмәгәннәр. Күпме якыннарыгызны бәхетсез итә идегез бит, аңгыра башлар!

—Мин үзем генә...—дип акланды Җәмилә.

—Үзең генә, имеш, әйттең сүз. Син соң арабызда иң көчле ихтыярлы дустыбыз идең лә. Белүемчә, сине табиблар әле дә үрнәк итеп сөйлиләр. Нинди чирне кудың бит син! Ул тырышуларның нәрсәгә кирәге булды соң алайса? Ләйсән безнең өчен дә бик кадерле бала иде. Ә сез аның якты истәлегенә хыянәт итәргә җыенасыз?

Галимнең сүзләре Мансурны да, Җәмиләне дә сискәндереп җибәрде. Айнып киттеләр, зиһеннәре кайтты. Соң алар бүген генә Ләйсәнне җирләделәр ич. Әле аның өчесен, җидесен, кырыгын, елын уздырасы бар. Нинди китү ди ул? Кая? Алар булмаса, Ләйсәннең хәтерен кем саклар иде?!

—Ямилә, син еларга тырыш,—диде Лилия гадәттәгечә сабыр, йомшак тавышы белән.

—Күзләрем кипкән,—диде Җәмилә,—елый алмыйм.

—Җәле, тот әле баяныңны,—диде Галим Мансурга,—бернәрсәгә карамыйча уйна да, җырла да.

Мансур карышмады. Үзе уйный, үзе җырлый. Яшьләре чишмә булып ага. Җәмилә генә тораташ булып каткан. Каны качкан йөзендә ник бер тамыр селкенеп карасын.

...Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән.

Бу йөрәк өзгеч сүзләр дә аны эретә алмады. Җәмиләнең үз җыры да көткән нәтиҗәне бирмәде. Мансур "Җырлыйм әнием турында" дигән көйне башлады.

Кояш, кояш
Мәңге балкый,
Мәңге нур сибә;
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа.
Ә-ни-ем, сиңа,
Ә-ни-ем, сиңа...

—Житте, Мансур, йөрәгемне телгәләмә,—дип яшь аралаш өзгәләнеп кычкырды Җәмилә,—Ләйсәнемнең яраткан курчагы Алсуны бир миңа!

* * *

Җәмилә Ләйсәннең елын үткәрә алмады. Тагын алты айдан баш очындагы Тума кошның канатлары киселеп төште. Тәкъдир аны кызы хозурына иңдерде.

*

# ШИГЪРИЯТ



**Нур Әхмәдиев**

## САГЫНУДАН БҮТӘН ЗАРЫМ ЮК...

### Наркоздан соң

**Гомеремнең таңымы бу,**
**Көндезе, шәфәгыме?**
**Татлы төшләргә тиңлимен**
**Булган бар яшәвемне.**

**Әллә шаярып булса да**
**Уйнавы аҗаганның—**
**Күкләргә китеп барганда,**
**Утларда кала җаным.**

**Яшеннең бер сызылуы,**
**Ут йотып яратулар...**
**Ялгыш та әгәр онытсам,**
**Мәңгелек яра туар.**

**Илле бер еллык гомерем**
**Әкиятме, чынбарлык?**
**Хыялым, дәртем югыйсә**
**Хаҗга юлга чыгарлык.**

**Саубуллашып китеп барыш**
**Әкият илләреннән.**
**Җаным—чиста бодай гына,**
**Чүп-чары җилгәрелгән.**

**Иртәнге, төшке намазмы,**
**Ахшамымы? Йә Хода!—**
**Ярты җаным шигырь яза,**
**Ә яртысы—йокыда.**

## Еламыйм һәм көлмим

Елар өчен килмәдем мин,
Җырлар өчен килдем.
Көләр чакта еладым да
Елар чакта көлдем.

Заман хәзер нык үзгәртте,
Нишләргә дә белмим.
Нишләргә дә белмим—
Еламыйм һәм көлмим.

## Яңа Орлеанда

*Академик Әбрар Кәримуллинга*

Урамына чыктым иртә таңнан,
Саф һавасын сулыйм янәсе.
Шундый тынчу!
Әйтерсең лә монда
Тире иләү остаханәсе.

Йә булмаса ерак түгел генә
Бармы әллә үләт базлары?
Шушы исне сизми, күлләрендә
Хозурлана үрдәк, казлары.

Озак йөрим дисәң урамында,
Ки син противогаз йә битлек.
... Кесәдәге долларларны саныйм,
Керә калсаң,—ике-өч кибетлек...

Үпкәләре ничек түзә икән,
И кызгандым җирле халыкны.
Ул арада мәрхәмәтсез кояш
Башның очында ук калыкты.

Төкердем дә һотелемә кердем,
Үзләренә булсын кибете!
Иң мөһиме мин бит—Орлеанда,
Конгресста—татар егете!

Русиядә без икенче сортлы,
Конгресста япон, инглиз,
Американ—акмы, негрмы ул—
Без татарың белән тип-тигез.

«Говори на русском!»—димәделәр,
Мин татарча шигырь укыдым.
«Рояль Сонеста»ның залларында
Иркәләнеп очты шигырь, моң.

Татар моңы...
Аннан алкыш, алкыш...
Моң, сыймыйча, чыкты ишектән.

*Рояль Сонеста—кунакханә исеме.

Алтмыш илдән килгән делегатлар
Татарчаны тәү кат ишеткән.

Мондый чакта мескен булалмыйсың,
Син бөексең мондый чагында.
И илаһым, бүгенгедәй мизгел
Кайчан килер безгә тагын да?

Шушы хакта ул да уйлагандыр,
Трибунадан төшкәч карадым:
Күзләрендә яшь тамчысы иде
Күпне күргән Әбрар аганың.

## Чайнтоунда* татар турында уйлану

«Ач кытай» дип башлап кем әйткәндер,
Ач булырмы тырыш бу адәм?
Мондый сүзне башлап әйтүчеләр
Юк, белмәгән аны, белмәгән!

Нинди генә кыен шартларда да
Тапмый калмый кытай бер җаен:
Нью-Йорк, Нью Орлеанмы—
Һәммә җирдә бар чайнтоун.

Тавыш-тынсыз, бер җәнҗалсыз яши,
Характеры шуннан беленә...
Татар нигә берсен берсе ашый?—
Ике татар өчкә бүленә?!

* * *

«Биек булмаса да тауларым бар**»...
Текә булмаса да—үрләрем.
Мин тормышта һәрбер биеклеккә
Хыялларым белән үрләдем.

Карыш арты карыш җир яуладым,
Тырнак төпләремне канатып.
Кыенлыклар аша ләззәт алдым,
Уй һәм хисләремне яңартып.

Шуңа күрә артык кадерледер
Биеклекләр—үзем яулаган.
Арып-талып, тирләп-пешеп кенә
Бу тынгысыз җанга ял алам.

Соң сулышта кайтып егылырга
Туган нигез, туган авыл бар.
Биек булмаса да үрләрем бар,
Текә булмаса да тавым бар.

*Чайнтоун (инглизчә)—кытай шәһәре
**Г. Афзал шигыреннән.

## Сентябрь яңгыры

Кирәк түгел идең әле, яңгыр,
Нигә бераз сабыр итмәдең?
Җыйдыртмыйсың бер дә игенчегә
Бураларга салыр икмәген.

Көнбагышлар кояш көтеп арды,
Карабодай һаман карала.
Тоташ яңгыр ул бит игенченең
Бәгыренә килеп кадала.

Атналык эш кырда калган иде,
Ник ашыктың, нигә түзмәдең?
Башка елны юкса бу вакытта
Алтын туйда чагы көзләрнең.

Челпәрәмә килде уй-хыяллар,
Болай да бик фәкыйрь чагында
Көнбатыштан хәер сораныргга
Калыр микән инде тагын да...

Алар исә икмәк сораганга
Өстәп бирер сагыз, «Рама»сын.
Мескен булгач, алмый бер хәлең юк,
Риза булмый кая барасың.

«Сникерс», «Тампекс»лар белән
Кыш чыгуың ләкин икеле.
Тукта, яңгыр, без адәмнәр кебек,
План кумыйсыңдыр бит инде!

Эшне бетерик тә, көне-төне
Коярсың да аннан коярсың.
Бөтен халык сиңа рәхмәт әйтер,
Уҗым керфекләрен юарсың.

Кирәк икән, син туктасын диеп,
Корбан чалам менә бүген үк!
Ишетмиме, әллә аңламыймы?—
Томаланган көе бөтен күк.

Атна буе бертуктамый ява,
Беткән ахры актык түземе:
—Коткарыгыз!—диеп басуларда
Ыңгыраша бодай теземе...

## Син–минем соңгы сөюем

*Җыр*

Җилкәйләрне узар тулпарым юк,
Сагынудан бүтән зарым юк.
Йөгерепләр генә кайтыр идем,
Каршы чыгып алыр ярым юк.

**Син—минем соңгы сөюем,**
**Син—минем соңгы ярам.**
**Әрнүләрем басылмасмы—**
**Җилләргә каршы барам.**

**Сахраларда йөри, ай, кырык куй,**
**Чит кояшлар никтер җылытмый.**
**Онытырга инде күптән вакыт,**
**Тик нишлим соң, йөрәк онытмый.**

**Син—минем соңгы сөюем,**
**Мәңгелек газап кынам.**
**Исемнәрең әйтә-әйтә,**
**Таңнарда сәҗдә кылам.**

**Кояш бата җирнең ник читендә,**
**Кичләр җитсә, бигрәк читен лә.**
**Ай чыкканчы, шәмнәр элеп куям,**
**Ялгызлыктан ни хәл итим лә?**

**Син—минем соңгы сөюем,**
**Тик үзем белгән серем.**
**Тауларга менеп күрмәдем,**
**Айларга менеп күрим.**

*

## КОНКУРС!

Әдәби тәнкыйтьне җанландыру максатларында «Казан утлары» журналы редакциясе 2000 елның гыйнвар аеннан иң яхшы рецензияләргә ачык конкурс игълан итә.

Конкурска килгән рецензияләрнең соңгы 3—4 ел эчендә басылып чыккан әдәби китапка яисә әдәби әсәргә (шигырьләр яки хикәяләр бәйләмен дә кертеп) булуы шарт итеп куела. Күләме машинкада 12 биткә кадәр.

Конкурста җиңеп чыгучылар өчен түбәндәге акчалата бүләкләр билгеләнде:

**I урынга—1000 сум.**
**II урынга—750 сум.**
**III урынга—500 сум.**

Конкурска рецензияләрне хат белән җибәрергә яисә редакциянең әдәби тәнкыйть бүлегенә кертеп тапшырырга мөмкин.

Конкурста язучыларны, тәнкыйтьчеләрне һәм әдәбият сөючеләрне актив катнашырга чакырабыз.

*Редакция.*

*Нәкый Исәнбәтнең тууына 100 ел*

# МӘКАЛЬЛӘРЕБЕЗ ТУРЫНДА

## Татар халык мәкальләренең байлыгы, эчтәлеге, тематикасы һәм андагы үзенчәлекләр

Безнен мәкальләр монарчы бик аз җыелган һәм сирәк чыгарылганга күрә, аларнын саны күпмегә җитүен чамалап әйтү кыен. Инде минем тарафтан эш арасында гына җыелганнары да бу томнарга баса икән, гомер буе мәкаль җыючы һәм шуны гына өйрәнүче бер фольклорчы аларны күпме җыя алган булачак? Билгеле, берничә мәртәбәләргә артык җыячак һәм бу сан йөз меңгә барып басачак. Инде шул эш һәртөрле гыйльми җәмгыятьләр, экспедицияләр яки Фәннәр академиясе көче белән оешкан рәвештә эшләнсә, бу санны кимендә унга кабатларга кирәк булыр иде. Чөнки, халык мәкальләре табигый урманболыннарда үскән җиләк шикелле: берәүләр җыеп киткән артыннан икенчеләр тагын килсә, алар да шулай ук чиләкләрен һаман тутырып җыячаклар. Шунын шикелле, мәкальләрнен санын беркем дә белгәне юк, тик бөтен гомерен шуны җыюга гына багышлаган ялгыз кеше дә аны, һәрхәлдә, миллионнан ким тапмас иде дип уйлыйм.



*Нәкый Исәнбәт эш кабинетында. 1959 ел.*

Кулда булган материалларга караганда, татар халык мәкальләре эчтәлекләре буенча түбәндәге төп темаларга җыела: хезмәт һәм аңа мөнәсәбәт; табигать дөньясы һәм аны эшкәртү (монда урман эше, аучылык, терлекчелек, кошчылык, игенчелек кебек табигатькә турыдан-туры бәйләнешле эшләр дә керә); семья һәм өй тормышы; күрше-күлән, авыл-шәһәр тормышы; кәсеп-сәүдә, базар; дус-дошман; сыйнфый бүленеш; иҗтимагый тормыш (монда гомумән көнкүреш, ил-көн, ватан тормышы керә); кешенең физик һәм әхлакый табигате, яхшылык-яманлык сыйфатлары; кешенен тойгы һәм акыл сыйфатлары (монда аң-белем, гыйлем, иман һәм башка ышанулар, гомумән әхлакый һәм идеологик яклар керә).

Боларны күргәч, ихтимал, әйтерләр:—кайсы гына халыкны алып карама, һәркайсының да мәкальләре шул саналган темаларга җыела ала, безнең өчен монда нинди аерма яки үзенчәлек бар? Болай булгач, безнең мәкальләр темалары буенча гомуми һәм башка халыкларныкы белән уртак нәрсәләр икән, диярләр.

—Әйе, дибез,—темалар гомуми; тормыш дигән нәрсә үзе дә барлык халыклар өчен гомуми булган дәрәҗәдә, безнең мәкальләрнең дә темалары гомуми, чөнки бу темаларда саналган нәрсәләр мәкальләр эчендә генә калмыйча, бәлки алардан тыш тормышның үзендә дә ята. Эш темаларның исемендә түгел, җисемендә. Безнең өчен әһәмиятлесе шул: татар мәкальләре тормышның үзе куйган бу темаларны яктыртканда, аларга кайсы яктан килә? Бу нәрсәләр хакында халыкның

---

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы санында.

карашлары, ышанулары ничек? Безнең халык үз тәҗрибә, үз тормышыннан карап аларга нинди мәгънә, нинди бәя бирә, нинди хикмәтләр әйтә һәм бу мәгънәләрне үз теленчә нинди алымнар, нинди чаралар белән тәгъбир итә? Халык бигрәк тә нәрсәгә, кайсы якларына әһәмият бирә яки нәрсәгә бөтенләй кагылмый? Ахыр чиктә, безнең мәкальләр, халкыбызның культура һәм иҗат әсәрләре буларак, үзебез өчен генә дә әһәмиятле булып калмыйлар, аларның тагын гомуми кешелек дөньясы өчен дә әһәмияте булырга тиеш бит, ягъни, безнең мәкальләр шул темалар буенча кешелек культурасына нинди яна мәгънәләр өсти, нинди хикмәтләр алып килә, нинди өлеш кертә? Кыскасы, монда моңарчы безгә беленмәгән яки без игътибар итмәгән нәрсәләр шулхәтле күп ки, алары аерым махсус өйрәнелергә тиешле яклар. Бу кереш мәкалә, ул киң тармакларга җәелә алмый. Безгә кала мәкальләрнең тематик эчтәлекләре нидән гыйбарәт икәнен язып чыгу. Бу да әһәмиятле. Әсәр өйрәнүдә бу юл безнең әдәбиятчыларыбызның иң яраткан эше. Хәтта күп кенә әдәби әсәрләребезне яки фольклорда җыр, табышмак йә башка шуның шикелле жанрларны тикшерүебез дә аларның бөтен эчтәлеген язып чыгып, шуңа социологик бәя бирү гадәт булып киткән. Мәкальләр буенча да моны язу авыр түгел кебек. Ул шушы китап хәтле үк булмаса да, аның яртысы урынын алачак. Ләкин бу китапка җыелган мәкальләр үзләре үк тематик тәртипкә дә салып бирелгәнгә, аларны шул рәте буенча карап баручы һәркем үзе дә андый эшне эшли алачак. Шунлыктан бу бүлектә мин аларның тематик эчтәлекләре һәм үзенчәлекләренә карата бары тик искәртмә төсендә кайбер күзгә чалынган якларына гына тукталачакмын.

Башта «Хезмәт һәм аңа мөнәсәбәт» темасы, дидек. Иң элек бу мәкальләр үзләренең күләм күплеге белән игътибарны җәлеп итәләр (1450 мәкаль). Ләкин болар әле гомумән хезмәтнең һәм аңа мөнәсәбәтнең уртак якларына караган мәкальләр генә. Әмма инде башка темаларга бәйләнешле булганнары да бергә җыеп каралса, аларның сан һәм күләм ягы тагын да зур булачак.

Бу мәкальләрдә хезмәтнең михнәт дәрәҗәсендә авыр һәм каты булуы, ләкин рәхәт, шатлык яки тәмле ризык шул хезмәт авырлыгының бүләге дигән кебек әйтелгәннәре дә шактый. Болардан күрелүенчә, элекке сыйнфый җәмгыятьтә ике катлы милли изелү астында яшәгән татар хезмәт ияләренә бу авыр һәм эксплуатацияле хезмәт процессы әллә ни зур табигый шатлык һәм иҗат китермәгән булуын, күбесенчә, табыш кызыктырганын, шунлыктан хезмәткә практик исәп ягыннан бәя бирелүен дә очратып була.

Билгеле, бу мәкальләрдә югары квалификацияле белгечлек, техник-инженерлык хезмәтләре хакында сөйләнми, күбесенчә, игенчелек, вак һөнәрчелек яки башка авыр кара эшләр турында сүз бара. Аның каравы, бу мәкальләрдә хезмәтнең кайсы ягына гына кагылынмый да нинди генә тәҗрибә һәм мөһим киңәшләр тәкъдим ителми! Безнең өчен иң күңеллесе дә—татар мәкальләрендә иң нык алга сөрелгән, иң макталган нәрсә тырышлык, уңганлык, эш сөючәнлек, хезмәтнең һәр нәрсәдән алда тотылуы һәм авыр эшләргә, михнәткә түзү, принципиальлектер.

Халыкта, бигрәк тә авыл кешесендә, «тормыш» дигән сүзнең төшенчәсе эш турындагы төшенчәдән аерылмый. Тормыш итү шул ук эшләү дип карала. *Эшләгән интекмәс, эшләмәгән көн итмәс* һ. б. Кызның идеалдагы матурлыгы да аның кысыр чәчәк шикелле корыга ялтыравында түгел, эш белән балкуында:— *Бакма тешенә, бак кулындагы эшенә* һ. б.

Иренчәк һәм эшсезләрне дөнья бетереп хурлау, ялкаулык, паразитлыкка каршы аяусыз көрәш, уяулыкка, активлыкка өндәүләр татар мәкальләренең иң яраткан эше. Мондый мәкальләрнең бик күп булуы татар халкының чынлап та бик тырыш, бик тернәкчел, хезмәт сөючән булуын, эш белән куәтле булуын күрсәтә торган әһәмиятле моментлар. Хезмәт—кешенең бәясен билгеләүдә төп үлчәү. Хезмәт ул байлык чишмәсе һәм зарурият кына түгел, ул кеше тормышының төп шарты:—*Эшләгән савыккан, эшләмәгән кабыккан.*

Мәкальләрдә халык хезмәтне данлап кына калмый, тәҗрибәне беркетә, ныгыта, камилләштерергә өйрәтә. Шунлыктан алар күбесенчә кинаясез, беренчел мәгънәдә яки эндәшеп әйтелә:—*Карама яшенә, кара эшенә;—Тиз эшлә дә тиз аша;—Эшләмәгән ашамас* һ. б.

Икенче зур һәм бай тема: «Табигать дөньясы һәм аны эшкәртү»гә караган мәкальләр. (Бу китапта 5 мең мәкаль.) Әмма башка темаларда да бик күп мәкальләрнең табигатьтән берәр янәшәлек (параллель) китереп әйтүгә корылган булуын искә алсак, татар мәкальләрендә табигатькә мөнәсәбәт кызыклы, шулай ук үзенчәлекле һәм бай урын ала диярга кирәк.

Татар табигатьне ата-анасын яраткан кебек ярата, сөя. Бу нәрсә аның исламгача бик борынгы заманнарда үзен турыдан-туры табигать баласы итеп хис иткән, ана табынган чагында ук туган авыз иҗатында үзенә хас алымнарда чагылган, ул шул алымнарны җыр, мәкаль һәм башка жанрларда әлегә хәтле югалтып бетермичә саклап килә алган. Татар халкы ислам дине кабул иткәч тә үзенең ай, көн, җир, су, ут, агач һәм тимер кебекләргә табынган булуын әле дә онытмый, су аркылы чыкканда:—*Мине тотма, шуны тот,* дип, су иясенә чүпрәк сала. Утка төкертми, ана пычак тыктырмый, әмма тышта яшен бик каты яшьни башласа, ана кыскыч янсә кисәү агач кебек берәр тимер чыгарып ыргыта. Табигать безнең бабайларның Тәнресе булган. Менә ни өчен дә ул җырларда булсын, мәкальләрдә булсын, үзенең югары, хөрмәтле хисләрен, хикмәтле уйларын һаман да агач, таш, җил, су кебек нәрсәләргә бәйләп яки янәшә куеп йөртә:—*Имән агачының иелгәне—сынганы, ир егетнең оялганы—үлгәне;—Тауны-ташны җил бозар, адәм затны сүз бозар;—Ком җыелып таш булмас, кол җыены баш булмас;—Үткән гомер—искән җил;—Су әйләнеп ярыгын табар, ир әйләнеп языгын табар* һ. б.

Хайван җәнлекләргә, терлекчелеккә караган мәкальләрнең күплеге дә игътибарга лаеклы. Болар арасында, билгеле инде, беренче урынны ат тота. Татарның ат яратуы, билгеле ки, борын заманнарда аның туганнан алып үлгәнче ат өстеннән төшмәве белән, соңыннан сәфәр һәм сугыш өчен булган бу атның аның өчен эш атына, сәүдә атына әйләнүләре белән бәйләнгән. Дөрес, моның белән атка мөнәсәбәт үзгәрә барган, ыру тормышында, борынгы Идел белән Тын (Дон) елгасы далаларында болгар, кыпчак бабайларның өер-өер елкы асраулары да, кәрван һәм сугыш сәфәрләре дә күптән беткән, әмма атның эштә, юлда, сәфәрдә иргә юлдаш булып, күкрәк көче белән авыр михнәт күтәрешүе, түземлелеге аны яраттырган, үзенә якын күргән. Ат шулай безнең җыр башларыбызда, бигрәк мәкальләрдә ир сүзе белән мәгънәдәш (синоним) булып, ирлек, егетлек, һиммәт көче урынында образ-символ булып кулланыла башлаган. Шул рәвешле, ат турындагы мәкальләрнең күпчелеге туры мәгънәсендә булмыйча, мисал мәгънәсендә йөри. (Бу хакта алдарак, шигъри үзенчәлекләр бүлегендә янәшәлек хакында сөйләгән җирдә аерым сүз булачак. Шунлыктан монда артык тукталмыйм.)

Аттан кала безнең мәкальләрдә безгә файдалы сыер, сарыклар ин күп урынны алырга тиеш кебек булса да, *эт* ала. (Ярты меңгә якын мәкаль.) Ана бу хәтле киң урын бирелү бу хайванның татар тормышында үзе бик әһәмиятле саналганы өчен түгел, киресенчә, кадерсез бер түбән урын тотканы өчен. Ат нихәтле ирлек символы булса, *эт,* киресенчә, әрсезлек, битсезлек символы булып йөри. Ул тамак хакына кеше өчен өреп, кеше кулыннан өмет итеп яшәргә калган, шөкеранасыз, тискәре бер сурәтләмә итеп алына. Шулай ук *ишәк* турындагы мәкальләр дә шактый. Бу хәл татар тормышында ишәкнең нинди дә булса практик урын тотканы өчен түгел (чөнки безнең халыкта хәзер ишәк бөтенләй юк), бәлки ангыралык сурәтләмәсе буларак мисалга яравында. Шуның өчен дә *эт* һәм *ишәк* хакындагы мәкальләр барсы да диярлек туры мәгънәдә әйтелмичә, икенчел сурәтләмә мәгънәсендә йөртеләләр. Безнең бу җирдә булмаган *арслан* җәнлегенә карата мәкальләр булуы да шуның белән аңлашыла. Чөнки ул көч, власть һәм олылык образы буларак кирәк. *Аю, бүре, төлкеләр* дә, күп мәсьәләләрдә күрелгәнчә, мәкальләрдә күбесенчә тупас көч, ач күзлелек, хәйлә шикелле сурәтләмә буларак йөриләр һәм мондый алымнар башка халыклар фольклорында да булуы билгеле.

Димәк ки, мәкальләрдә хайваннарның тема буларак алынулары, аларның тормышта, хуҗалыкта тоткан әһәмиятләре өчен булудан бигрәк, мисал яки бер-бер сурәтләмә төсендә файдаланырга унайлыклары алдарак тотылган өчен. Шуның аркасында, табигать дөньясы турында әйтелгән мәкальләрнең күпчелеген кеше турында дип аңлап булган кебек, кеше турында әйтелгәннәрен дә, киресенчә, табигатькә, хайван-терлекләргә карата кулланып була:—*Атта гаеп булган кебек,*

*тәртәдә дә гаеп бар;—Эт талашыр, авызын-борынын ялашыр;—Агачына күрә алмасы;—Ит үзеннән кортлый* шикелле табигать турындагы мәкальләрне кеше турында төрле хәлләрдә кулланып булган кебек, кеше турында әйтелгән:—*Ит изгелек, көт явызлык;—Үз балаң типкәләсәң дә китмәс;—Һәркемнең баласы үзенә газиз;—Аннан качкан, моннан качкан, яманчылык белән күзен ачкан;—Усалдан усал туар* шикелле әллә нихәтле мәкальләрне терлек-туар, хайваннарга карата да кулланып була.

Безнең Болгар бабайлар борынгыдан игенче булганга, билгеле, бу хакта да мәкальләр бик күп. Бу мәкальләрдә туган җиребезнең табигате һәм аны эшкәртү, иген үстерү эшендәге тәҗрибәләрнең турыдан-туры чагылганнары күбрәк:—*Арыш чәчсәң, көлгә чәч;—Тирес чыгарган җиренә, ташып бетерә алмаган өенә* һ. б. ишеләр. Шулай ук мисал мәгънәсендә булганнары да шактый:—*Тары колактан беленер;—Ашлыкның йозагы—салам* һ. б. ишеләр. Гомумән, кошчылык, терлекчелек, игенчелеккә караган мәкальләрнең байтак кынасы тәҗрибә ягыннан бүгенге көндә дә хуҗалыкта практик әһәмияткә ия булып торалар.

Кеше турындагы мәкальләргә килгәндә, боларда кешенең җәмәгатьчелек урынын күрсәткән мәкальләрнең күп булуы уңай күренеш. Иң элек бу нәрсә анның семья, аннан күрше-күлән, дус-иш, аннары авыл-шәһәр һәм гомумән җәмәгатьчел-сыйнфый көнкүреш мөнәсәбәтләрендә чагыла.

Семья мөнәсәбәтләренә караган мәкальләрдә татарның көнкүреше, ата-ана, бала-чага, өйләнү, килен, кияү булу, кардәшлек, кода, каенана һәм башкаларның тормышта тоткан урыннары, аларга карашлары чагыла. Монда халыкның борынгыдан килгән үз патриархаль гореф-гадәтләре алга йөзеп чыга. Татар карчыгы, мәсәлән, килененә караганда кияүне якынрак күрә, яхшы сыен иң элек аңа куя:—*Көзге катык, көмеш кашык киявем белән кызыма, язгы катык, ярык кашык киленем белән улыма;—Кияүгә торса да камау, утырса да камау* һ. б. (урысларда кияүне бик үк алда тотмыйлар бугай.) Шуннан алып татар көнкүрешендәге бетмәс-төкәнмәс килен белән каенана даулары, бер-берсен кимсетүләр китә:—*Килен салмасы кыек;—Килен кеше ким кеше;—Кандалага дару юк—каенанага үлем юк;—Килен булдым, каенанага ярамадым, каенана булдым, киленгә ярамадым* һ. б. ишеләр. Киленнең уңганлыгын мактаган мәкальләр бик күренмәсә дә, ялкаулыгын хурлаганнары бик еш очрый. Мондый мәкальләрнең күпчелегеннән килен булып тормышка башлап аяк баскан элекке татар кызының авыр язмышын, гаилә бәхетсезлекләрен чамалап була.

Татар мәкальләрендә кызларның урыны кадерле тотылса да (*Кыз бала кунак кына* һ. б.), аларның мәһәргә сатып бирелүләре, бер киткәч, ата йортына киредән кучеп кайтырга тиеш түгеллекләре әйтелә:—*Кыз акчасы—тоз акчасы;—Кызга биргән күренмәс, комга сипкән беленмәс;—Киткән кыздан пумала куркыр;—Кайта чапкан яу яман, кайтып килгән кыз яман* һ. б. Шулай ук кызны кияү сайлауда бик үз ирегенә куярга ярамаулар да әйтелә:—*Кызны иркенә куйсаң, думбрачыга барыр;—Кызның күнеле кызылда* һ. б. Уйнашчы булу, зиначылык татар тормышында бик зур гаеп саналып, аларга карата кара хөкемнәр ясалып, андый кешеләр хур ителгән; кызларның пәрдәле, гыйффәтле, оялчан булулары макталган:—Пәрдәле кыз—мыскалга салмаган ефәк;—*Пәрдәсез кыз пәригә тансык;—Кызның исеме кылдан нечкә, кылдан төшсә, борының түзсен искә* һ. б.

Мәкальләр балаларны яшьтән үк эшкә бөгәргә, корырак тотарга һәм яшьли өйләндереп, яшьли кияүгә бирергә киңәш бирәләр:—*Агачны баштан бөк, баланы яшьтән бөк;—Кызын тыймаган тезен кыйнар;—Чыбык вакытта бөгеп кал;—Иртә өйләнгән—улы-кызыннан кинәнгән;—Кыз бала ирдә яхшы, ир алмаса гүрдә яхшы* һ. б.

Ата-ананың кәсеп-һөнәре, сәләтләре, әлбәттә, балаларга да мирас булып калырга тиешле санала:—*Ата күргән ук юнар, ана күргән—тун печәр;—Атасы болан атмаганның баласы колан атмас* һ. б.

Ирлек-хатынлык мөнәсәбәтләренә килгәндә, үзенең мәкальләрендә татар гадәттә хатынга тугры булучан, семьячыл булып күренә. Ул гомумән бер хатын белән тора; хатын-кыз артыннан сөйрәлергә яратмый. Хәер, баеса гына азып китүчән:—*Татар баеса хатын алыр;—Ике яхшы, бер тыныч;—Хатын-кыз артыннан йөргәнче, арслан артыннан йөре һ. б. Ул ике хатын белән торудан да бигрәк,*

*яман хатыннан курка:—Ике хатын алганның дау өендә, яман хатын алганның яу өендә;—Яман хатыннан дию пәрие качкан* һ. б. Шулай булса да, хатынның яхшы булуын татар үзеннән күрә, семьяң нык булсын дисәң, хатын-кыз сүзе белән йөрмәскә, гайрәт күрсәтеп, аны кулга алырга куша; мәкальләрендә татар үз хатынына үзе баш булып яши:—*Ир—баш, хатын—муен;—Арбаны яхшы йөрткән—дегет, хатынны яхшы йөрткән—егет;—Ир гайрәтле булса, хатын гыйбрәтле булыр;—Хатын-кыз сүзе белән йөрсәң, әҗәлең җитми үләрсең* һ. б.

Татар хатыны исә, авыр язмышына күнеп яшәргә өйрәнгән өченмедер, мәкальләрендә иренә караганда тугры, ул иренә нык бирелүчән һәм иреннән дә шуны ук таләп итүчән; аның холкында кызык кына каршылыклар бар: ул үзе күндәм булса да, шактый озын телле; сабыр булса да аны холкыннан чыгаруга илтеп җиткерергә ярамый, бер тәртәгә тибеп дулап китсә, арбаны аударып, ватып-кырып бетерергә дә кыйбат алмый. Изелгән булса да, ул иргә бик ышанып тормый, ачуга китсә, ана да шул тәнкә белән үч кайтара:—*Иргә ышанма, Иделгә таянма;—Сыер дуласа аттан яман;—Ир дуласа өй тузар, хатын дуласа авыл тузар* һ. б. Хатын-кызның шундый озын телле, кыска холыклысы татарда да байтак табылганы өченмедер, белмим, башка халыклардагы кебек бездә дә:—*Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска*, дигән мәкаль йөри. Билгеле, мондый чакларда «көч позициясеннән» торып сөйләшүләр дә була:—*Хатынның теле озын булса, иренең кулы озын* һ. б. Гомумән, шундый кашыгаяк бик шалтырап киткән чакларны алмаганда, татарның ире дә, хатыны да семьяда ул-кыз җиткереп, төче коймагын ашап дигәндәй яши бирәләр. Татар үзе гадәттә тырыш, уңган, кызу булгангамыдыр, хатыны да эшкә уңган булса, бик тиз уртак тел табышып, бик матур көн итәләр.

Билгеле, семья, өй-йорт тоту, күрше-күлән булып яшәү, көнкүреш темасы мәкальләрдә бик киң урын тота. Боларга татарның аш-су әзерләве, туйлары, кунакка йөрешүләре килеп тоташа. Бу нәрсәләрдә кинәш-үнәш яки искәртеп куюлар төсендә, төрле сәер вакчыллыкларга хәтле мәкальләрдә күренә. Ләкин моңа карап, мәкальләрнең мондый бүлекләре әһәмиятсез дип караучылар ялгышалар. Чөнки халыкның борынгыдан килгән гореф-гадәт, тормыш үзенчәлеге, аның рухи йөзе, эчке табигате нәкъ шул көндәлек мөнәсәбәтләрендә вак төгәлләмәләрдә тагын да аныклырак, төсмерлерәк чагыла, монысы бер. Икенчедән, мәкальләр конкрет бер очраклы нәрсә турында әйткәндә дә гомумән мәгънә, типик мисаллар чыгаруга, сурәтләмә бирүгә оста булалар икәнен дә онытмыйк.

Семья тормышын яратучылык үзе ил һәм халыкны яратучылык белән бәйләнештә каралырга тиеш. Чөнки семья, учак безне туган җиргә бәйли, ана мәхәббәте һәм атаның кайгыртучанлыгы безне туганлык хисенә, нәсел, кардәшлек мөнәсәбәтләренә, уртак гореф-гадәткә, көнкүрешкә һәм шулар аша уртак анабыз булган илгә, халыкка китереп бәйли. Бу газиз тойгыда ватанчылык, гражданлыкның яхшы сыйфатлары, бишектән алып зиратка хәтле бер-беренә карата уртак бурычлар һәм бер-береннe кайгыртучанлык чагыла. Шунлыктан мондый мәкальләрне көнкүрешнең вак-төягенә артык катышу, артык вакка бирелү яки бар да патриархальлек карашлары гына дип бер якка селтәргә тырышучылар бик җинелчә һәм өстән генә карауларын күрсәтәләр.

Татар йомык яшәми, ул кешегә катышучан һәм ул сәфәр, юлга чыгудан бер дә иренми. Шунлыктан татарны Рәсәйнең һәр почмагында күреп була. Кешенең җәмәгатьчел һәм катнашучан булырга тиешлеген күрсәткән мәкальләр дә моны раслый:—*Кеше булган кешенең кеше белән эше бар, кеше булмаган кешенең кеше белән ни эше бар?* һ. б. Инде юл, сәфәр турындагы бүлектән каралса, аның ярты гомере юлда, кәсептә һәртөрле кешеләргә катышуда үткәнен чамалап була.

Татар (болгар) элек-электән Идел өстендә яшәп, Азия белән Европа арасында арадашлык иткәнгә, аның кешегә катнашучанлыгы, кәсепчәнлек һәм эшчәнлеге базар һәм сәүдә мөнәсәбәтләренә караган мәкальләрендә дә киң күренә. Акча, мал табу, байлык белән торырга тырышу ирлек сыйфаты итеп карала:—*Акча акчаны таба;—Ак акча кара көн өчен;—Җан рәхәте тән белән, тән рәхәте мал белән;—Мал—бәгырь ите;—Малны тапкан баксын* һ. б. Сәүдәгәрлек итү макталган:—*Алтыга ал, бишкә сат, атың булсын сәүдәгәр;—Алу өйрәтми, сату*

*өйрәтә* һ. б. Моның ише мәкальләр күп. Ләкин малны табу бер эш, хикмәт аны тота белүдә дә икәнлеге әйтелә. Шунлыктан, гәрчә:—*Юмарт малын үзе ашар, саран малы саранның үзен ашар*, дигән кебек кайбер мәкальләрдә юмартлык макталса да, мал тота белү ягыннан саранлык та артка куелмый:—*Саран ирдә мал торыр*;—*Ашлыкның йозагы—салам, акчаның йозагы—саран* һ. б. Ләкин татарны мал өчен генә яши, акча өчен җанын сата дип әйтеп булмый. Ул байлыкның фани икәнен дә, акчага, малга комсызлык кешене күтәрмичә, киресенчә, әхлакый яктан түбәнәйтә, төшерә икәнен дә, шуңа күрә дә байлык, милекчелекнең адәм баласы өчен максат булмыйча, чара гына икәнен дә белә:—*Байлык морат түгел, фәкыйрьлек оят түгел*;—*Мал малга җиткәнче, газраил җанга житәр*;—*Байлык—бер айлык* һ. б. Монда инде без мәкальләрдә бик әһәмиятле урын тоткан сыйнфый бүленеш һәм җәмәгатьчел-экономик темага килеп тоташабыз.

Кешелек тарихы өчен бик күп уртак яклары булган бу тема да, безнең мәкальләрдә, билгеле, үзенчәлекле яктыртыла. Бу хакта башта үзенә аерым бүлек бирелгәнлектән, монда аларга яңадан кайтырга хаҗәт юк.

Инде кешенең әхлакый йөзен, рухи байлыгын күрсәткән мәкальләргә килик. Мәкальләрнең иң яраткан бер эше—кешенең җәмгыятьтәге урынын, кешенең кешегә мөнәсәбәтен билгеләү булганга, әхлак темасы аларда зур урын тотмый хәле юк. Хәтта, табигать турындагы мәкальләрдә дә (мәсәлән, ат, эт, ишәк, аю, бүре турында) күбесе кешенең рухи, әхлакый йөзенең сурәтләмәсе итеп бирелгәнен югарыда күреп үткән идек. Билгеле, бу тема һәр халыкта бар. Ләкин әхлак дигән нәрсә үзе иҗтимагый караш һәм принцип булса да, кешегә каяндыр әзер килеш салынган абсолют нәрсә түгел. Ул тарихка, тормышка, тәрбиягә бәйләнешле әйбер, шулай булгач, аның һәр халыкта үзенчәрәк булмыйча хәле юк. Татар мәкальләрендә дә холык, яхшылык-яманлык кебекләрне үзенчә аңлау, үзенчә төшенүләр булуы һәм заманга карап бу карашларның да үзгәрешләргә очравы табигый.

Татар халык мәкальләрендә иң мактаулы әхлакый сыйфатларның берсе—түземле булу, сабырлык. Ашыкмый уйлап хәрәкәт итү ни хәтле макталса, ашыгу шулхәтле гаеп ителә. Мондый сабырлыкны, ашыкмауны мактаган мәкальләрне замана темпын сизмәүчелеккә чакыру, урта гасырлар сүлпәнлеге дип аңлатучы иптәшләр аз түгел. Шулай ук сабырлык татар мәкальләрендәге элекке сыйнфый коллыкка баш салып яшәү һәм көрәштән качу күренеше дип аңлатулар да еш очрый. Ләкин мин моның белән килешмәс идем. Чөнки мәкальләр ашыкмаска дисәләр дә, эштә ялкаулыкны, өшәнлекне гаеп итәләр һәм эшне кичектерүгә, иртәгә калдыруга бик нык каршы торалар:—*Бүгенге эшеңне иртәгә калдырма*;—*Калган эшкә кар ява*;—*Иренчәк—иртәгә эшлим диер* һ. б. (Бу хакта мәкальләрнең ни дәрәҗәдә күп булуын хезмәт бүлегеннән кара.) Шулай ук сабырлык, түземлек сүзләрен христианлык лозунгасы булган смиренность сүзенең механик тәрҗемәсе итеп, золымга баш салып яшәү мәгънәсендә генә алу да, билгеле, дөрес түгел. Шулай булса да, гасырлар буе колонизация астында изелеп, төрлечә эзәрлекләнеп яшәүнең кайбер ачы нәтиҗәләре аркасындамы, белмим, татар ашыгуы белән берәр үкенечле хәлләргә дучар булганмы, ул үз мәкаль һәм җырларында бары тик шул сабырлыгы, түземлеге аркасында ахыр бер көн бар авырлыкларны җиңеп чыгып, алда якты бәхетенә, морадына ирешәчәгенә тәкъдиргә ышанган кебек (фатализм дәрәҗәсендә) ышана. Шунлыктан, сабыр, түземлек сүзләре бездә пассивлык мәгънәдә генә алынмыйча, күбрәген алдыңа алган эшеңдә ахырынача принципны, эзлекле булу, өмет өзмәү кебек актив мәгънәләрне дә үз эченә ала, шулай ук акрынлык дигәнне дә алдынны-артынны уйлап, төпле һәм эзлекле хәрәкәт итү мәгънәсендәрәк йөртә:—*Сабыр иткән, морадына җиткән*;—*Түзгән тул җыяр*;—*Ашыккан ашка пешкән*;—*Акрын баскан ат булган, ашыкмый йөргән ир булган*;—*Ашыккан кыз кияүгә барса да мантымас* һ. б. шуның ишеләр.

Шул ук сабырлык янына татарның тыйнаклыгын да кушарга кирәк. Аның мәкальләрендә мактанчыклык, тәкәбберлек бик нык гаеп ителә:—*Үзен-үзе белмәгән, борынын күккә күтәргән*;—*Юктан бар булган—тәңре белән тиң булган*;—*Үзеңне-үзең мактама, сине кеше мактасын* һ. б. Белмим, монысы да шул изелгәнлек галәмәтеме, татар тормышта да, гомумән, үзе куйган кагыйдәсенә бик туры килә, ул, әйтик, тау халыклары белән чагыштырып караганда, артык дәрәҗәдә тыйнак, хәтта үзендә бераз гына горурлык булырга тиешлекне дә оныткан шикелле

күренә. Анарда, мәсәлән, башкорттагы кебек—*Үзенде үзен мактамаһан, кеше һине кайсан мактаһын?* дигән мәкальләр бөтенләй дә юк. Киресенчә, үзенне артык кече тоту:—*Ишек төбендә урын барда түргә узма* кебек мескенлек, башка халыклар арасында бусага төбендә калу кебек түбәнсенүне яклауларга хәтле барып җителә.

Мәкальләрдә әхлакый сыйфатлардан иң зурысы булып турылык мактала. Үзенә һәм кешегә биргән сүзенне үтәү, аманәткә хыянәт итмәү канун хөкемендә. Мәкальләрдә иң элек кеше үз принцибына туры булсын дип куела һәм, бу төрлечә кабатланып, бик нык таләп ителә:—*Кешенең эше белән сүзе бер булсын;—Кешенең сүзе үлгәнче, үзе үлсен;—Турылык таш ярыр;—Әйт тә сүзенә җит, чап та өенә җит;—Егет сүзе бер булыр;—Сүз бер, Алла бер;—Әйткән сүз—каккан казык* һ. б. Болардан хәтта турылыкны татарның Алла урынында күреп табынуы, аны тормышында төп нигез итеп куюы аңлашыла. Билгеле, намуска кайтып кала торган бу күркәм холык һәм карашның урнашу тамырлары бик ерак. Кайчандыр, исламга чаклы, табигатькә табыну заманнарында, бездә сүз белән эш һәм сүз белән хокук бер-берсеннән аерып каралмаган. Ялган сөйләү, хыянәт мөмкин булмаган эш саналган; сугышларда, сәфәрләрдә ул шул турылыгы белән җиңеп чыккан. Ант итү, сүз бирү бик олы эш булып, аны бозу бөтен кешелекне бозу, хәтта алай гына да түгел, бөтен җир-күк, бөтен галәм тәртибен бозу дип каралган. Ант бозучыга, хыянәтчегә бөтен табигать дөньясы каршы күтәрелә, андый кешенең җитмеш тамыры корый, аны икмәк ора, җир йота, кояш аннан йөз чөерә дип ышанганнар. Татар ант иткәндә бүгенге көндә дә:—*Ялган әйтсәм җир йотсын, икмәк орсын, кояш йөзен күрмим,*—диюләре шуны күрсәтеп торалар. Билгеле, феодализм таркаулыгы дәверендә борынгы кабилә берлеге, һәм шунын артыннан бу эш белән сүз берлекләре какшый, капитализм җәмгыятендә вак хосусый милекчелек интереслары белән борынгы турылык йолалары нык каршылыкларга очрый. Ант какшый, вәгъдәнең «вау»лары кырыла башлый, туры сүз гаеп ителә. Билгеле, татар һаман туры булырга тырыша. Ләкин бу инде аңа шактый гына кыйбатка төшкәли, шунлыктан ул турылыктан зарар күрүләреннән зарлангалый башлый:—Турылыкның төбе корылык!—*Туры телемне тыя алмыйм, туганыма керә алмыйм;—Туры әйткән туганына ярамаган,*—ди һ. б. Боларда инде турылык мәсьәләсендә такт һәм чама белергә сак һәм исәпле булырга дигән карашлар сизелә. Бу бигрәк тә дуслык турындагы мәкальләрдә күренә. Борынгы мәгънәдә үзара дуслык, ыру-кабилә, ил-ара, ил, сәфәр дуслыгы кебек төшенчәләр бозыла, сыйнфый эксплуатация, милекчелек, һәрнәрсәдә вакчыллык, исәпчәнлек тудыруы аркасында дуслыкның да күбрәген практик якка, исәпкә корылуын китереп чыгара башлый:—*Дустыңнан аерыласың килсә, көтәргә бир;—Исәпле дус аерылмас;—Дус белән аша, эч, итмә алыш-биреш* һ. б. Хәтта дустан да сакланырга, серенне аңардан да яшерергә тиешлекләр әйтелә башлый:—*Сер дусы күп булыр, серне тоткан бер булыр;—Вафасыз дус башны ашый;—Кар башына кар җитәр;—Дус башына дус җитәр* һ. б. Билгеле, мәкальләр арасында мондыйларның да булуын дуслык кебек бөек хиснен вак буржуа һәм мещаннар арасындагыча:—*Син миңа бер яхшылык ит, минем дә сина бер яхшылыгым тияр,* дигән кебек, яхшылыкны бары акча урынында бурычка гына биреп торыла торган бер нәрсәгә, вак исәп-хисапка, тар практицизмга кайтарып калдыруны күрсәткән күнелсез карашлар җимеше булып торалар.

Ачучанлык һәм кеше гаебен тикшерүчәнлек, гайбәтчелек, доносчылык кебек тискәре холыктан тыярга тырышкан мәкальләрнең күп кенә булуы бу кимчелекләрнең татар арасында шактый урын алуын да күрсәтә булса кирәк. Татар югыйсә үзе кызса һәм принципка китсә, соң чиккә барудан да кире тормый торган кызу канлы, хәтта, кайгысын да шатлыгын да үткен кичерүчән (зәһәр) табигатьле, дуамал булганга, кызулык белән хатага төшүләрдән саклану өчен, шундый мәкальләрне профилактик чаралар йөзеннән яки «арткы акыл»га утыру төсендә кулланырга ярата да гаҗәп түгел.

Безнең мәкальләрдә усаллык мактамаган кебек, юаш-йомшак булулар да мактамый:—*Аю кашка булмас, усал яхшы булмас;—Усалның артына суык су сал;—Йомшак агачны корт басар* һ. б. Бу икенең арасында урта юл тоту татар өчен хәтта сайланган башлык, дәүләт ире булуның да идеалы булып тора:—*Усал*

*булсаң асарлар, юаш булсаң басарлар, уртача булсаң ил агасы ясарлар.* Шул ук вакыт татарның бу «уртача» дигән әхлакый сыйфатына ач күз, комсыз булмаска, канәгатьчел булырга чакырган мәкальләрне дә кушарга кирәк. Барлык шул китерелгән мисаллардан җыеп кына әйткәндә, татарның тормыштагы «уртарак» бер кешесе килеп чыга. Бу урта кул кеше, мәкальләр буенча, холык ягыннан үзенең каршылыклы яклары булуга карамастан, шактый яхшы, уңай табигатьле булып алга килеп баса: ул шактый изелгән, тыйнак, күпне күргән, йомыш-юлга күндәм, хезмәтендә ихлас күнелле, тырыш, ләкин шуның белән бергә алны-артны бик карап, сагаеп, исәп-хисапны бик дөрес йөртеп эш итүчән, шактый коры табигатьле, каты серле кеше. Теоретик булудан бигрәк, ул практик. Гәрчә саран кешегә карата ул:—*Кызганма, кызыл эт ашар,* дисә дә шул ук вакыт кешене бик кызганучан булу, юл куючанлыкны да мактамый:—*Кызгансаң, кызганычка калырсың;—Ит изгелек, көт явызлык,*—дип тә куя. Ятим-үксезләргә карата булган мәкальләрдә дә аларны асраганнан күп хәер күрмәссең дигән мәгънәдәрәк сүзләр ычкындыргалый.

Кыскасы, мәкальләр буенча тормыштагы бу урта татар кешесе бик шәфкатьле, йомшак бәгырьле кеше булып чыкмый. Бу нәрсә аның тыйнаклыгы, канәгатьчәнлеге белән һәм шулай ук лирик җырларындагы сентиментальлек нечкәлеге, моңга бирелүчәнлек сызыгы белән, ничектер, бик үк ятышып җитми шикелле. Халык күнеле шундый тирән катлаулы һәм каршылыклы, утын-суын бергә җыйган нәрсәдер, күрәсең.

Шул рәвешле без, мәкальләр буенча, татарның тормыштагы уртача кешесе ниндирәк булуын беркадәр чамалый алдык. Инде идеалдагы кешесен дә эзләп карыйк. Бу кеше аның мәкальләрендә ир яки егет дигән сүз белән әйтелә булса кирәк.

Югарыда семья турындагы мәкальләрдә без ир сүзенең хатын ире дигән бер мәгънәдә әйтелешен күргән идек. Ләкин бу сүзнең мәкальләрдә тагын да югарырак һәм безнең өчен тагын да әһәмиятлерәк булган сурәтләмә (образ) мәгънәсе бар. Бу чагында ул безгә *ирлек, егетлек сыйфатларына ия булган кеше* дигән мәгънәне үз эченә алып, шуның шәхси һәм типик төсмерләнешен тапкан сурәтләмә булып килә. Ир сүзен баш хәреф белән язып күрсәтергә мөмкин булган мондый кулланыштагы мәкальләрдә без тормыш тоткан төп татар кешесе холкы-фигыле белән ниндирәк булырга тиешлекнең идеалын шактый анык билгели алырбыз. Мәсәлән:—*Арсланның ялы, ирнең сакал-мыегы;—Акрын баскан ат булган, ашыкмый йөргән ир булган* дигәндә, *Ир*—тышкы кыяфәте белән дә мәһабәт, үзенең килеш-килбәт хәрәкәтләрендә дә чәпчеп таралып бармый, бәлки



*Рәсемдә (сулдан уңга) Х. Туфан, Г. Минский, Н. Исәнбәт, Ш. Галиев, Ә. Еники, Ә. Давыдов. 60 еллар уртасы.*

үз максатын үзе белеп хәрәкәт итүче, карарлы һәм салмак кеше:—*Ир икмәге ирекле;—Ирнен унмаганы икмәксез булыр;—Ир булган ир ашны таштан чыгарыр* дигәндә, *Ир кеше*—иң элек үзен, семьясын үз кул көче белән туйдыра алучы кеше:—*Ирмен дигән ирнең эчендә бишекле олан ятыр;—Ир йоласы өчкә чаклы;—Ир сынамак—бурыч* дигәндә, ул бик каты серле, ихтыяр иясе һәм сынаучан:—*Ат чанада беленер,* ир сәфәрдә беленер дигәндә, ул шулай ук юлда-нидә, кеше арасында сер сынатмый торган кеше:—*Ирнең сүзе үлгәнче, үзе үлсен;—Ирне намус үтерер дигәндә,* ул беткәнче вәгъдәсендә туры һәм үзенең сүзе, намусы өстендә үләргә әзер торучы:—*Ирнең малы ирдә, иреккәндә кулда* дигәндә, ул малны тота белү белән бергә, кирәк урында юмартлык күрсәтә белүче:—*Ир әүвәлендә җәфа күрми ахырында вафа тапмас;—Ир бул—җир бул* дигәндә, ул үз теләгенә ирешү өчен, озак һәм теләсә нинди авыр җәфаларга түзә белүче:—Ир үлсен дә дан калсын дигәндә, ул зур эшләргә омтылучы кеше; шулай ук:—*Ир туган җиренә, ат туйган җиренә;—Илнең эше ир муенында, ирнең эше ил муенында* дигәндә, аның ватанчылыгы, ил өчен яшәве:—*Ирләрнең һиммәте тауларны урыныннан кубарыр* дигәндә, аның иң зур сыйфаты—олы җанлы булуында икәнлекләре әйтелә. Кыскасы, мондый мәкальләрне укучы үзе китаптан тагын да күбрәк һәм әһәмиятлерәкләрен таба алачак. Мондый мәкальләрдән күренүенчә, *ИР* исемен күтәргән татар идеалда шундый олы сыйфатларны үзенә җыйган булырга тиеш. Билгеле, бу олылык сыйфатлары өстенә аның тырыш һәм батыр табигатьле булуын өстәп әйтергә кирәк. Кешенең юашлыгы, тымызыклыгы бу мәкальләрдә бер дә мактамый, бәлки ачык, туры, тәвәккәл һәм кыю булырга тиешлеге алга куела. Бездә батырлык турындагы мәкальләрнең күп булуы аны төрле яктан төсмерләргә мөмкинлек бирә:—*Батыр ярасыз булмас;—Батыр яуда беленер;—Сугыштан соң батыр күбәер;—Батырга да җан кирәк;—Юмарт дигәннәр—малдан чыгарганнар, батыр дигәннәр—җаннан чыгарганнар* һ. б. Батырлык, тәвәккәллек бик мактальп, куркаклык гаеп ителсә, сак булырга өндәгән мәкальләрнең булуына да игътибар итәргә кирәк. Борынгы татар-болгарларның барлык ир-аты гаскәри хисапланып, башларыннан канлы һәм кыю сугышларны күп кичергәнгә, батырлык турындагы мәкальләрнең күбесен борынгыдан калганнар дип уйласак, инде сак һәм посып яшәргә өндәгән мәкальләрнең дә патша хөкүмәте кулында халыкның хокуксыз һәм эзәрләнеп яшәвеннән килеп чыккандыр дип уйларга кирәк. Ләкин батырлык турындагы мәкальләрнең һаман да саклануы, аның гражданлык һәм соңгы ватан сугышларында үзен шул яктан күрсәтә алуы, татар, чынласа, бүгенге тормышында да шушы идеалдагы *ИР* гә үзенең бик туры килә ала икәнен күрсәтә.

Шул рәвешле, әгәр дә без егет, кыз яки хатыннар турындагы мәкальләрне китаптагы бүлекчәләрдән укып карасак, беренче карауда каршылыклы булып күренгән андагы сурәтләмә һәм мисаллардан аларның уртаграк бер тибы күз алдына килеп басар. Бу исә күп яклы, төрле сыйфатларга ия булган татар егете яки кызы, йә татар хатыны булып чыгар. Монда аларның кем булулары һәм тормышта тоткан урыннары төрле яктан бирелгәнгә, аларның шактый бөтенлекле реалистик сурәтләмәсе яки төсмерләре булыр. Кызыксынган иптәшләр аларын үзләре өйрәнә алырлар дип уйлыйм.

Әхлак өлкәсендә гомумиләштеребрәк тукталырга яраткан тагын бер тема—яхшылык-яманлык турындагы мәкальләрнең күп булуы. Билгеле һәр заманда да, һәр халыкта да яхшылык мактала, яманлык гаеп ителә. Әмма ләкин нәрсә соң яхшылык, нәрсә яманлык? Бу төшенчәләрдә мәңгелек һәм абсолют булмыйча, заманына, халкына карап төрлечәрәк мәгънәдә аңлашылганын әйтергә кирәк. Шунлыктан бу яктан һәммә халык бер уртак карашка җыела алмый. Бер халыкта яхшылык саналган нәрсә икенчесендә яманлык дип саналуы яки бер заманда бер халык яхшылык дип таныган нәрсә икенче заманда яманлык итеп саналу мөмкин. Хәтта бер халык өчен сый-хөрмәт яхшы сыйфат булып саналса, икенчесенә явызлык, зәхмәт булып та күренә ала. Мәсәлән, урысларда—*Злее зла честь татарска* дигән мәкаль бар. Аның килеп чыгуын Снегирев болай аңлата: элек Урдага килгән урыс князьләренә татарлар хөрмәт (честь, почесть) күрсәтү йөзеннән, аларны кымыз белән сыйлый торган булганнар. Сый-хөрмәт кабул итмәү дигән нәрсә дошманлык күрсәтү булганга, билгеле, князьләр аны эчәргә мәҗбүр

булганнар. Ләкин христианнар шәригатендә ат ите мөселманга дуңгыз ите кебек булганга, бия сөтеннән булган кымызны эчү дә борынгы фанатиклар өчен гаять куркынычлы гөнаһка төшү булып тоелган. Шунлыктан татарның аларга күрсәткән иң зур явызлыгы да кымыз эчерүләре дигән мәгънәдәге шушы мәкаль килеп чыккан була. Димәк, бер халыкча яхшылык, икенче халык күзлегеннән яманлык булып чыга. Яки тагын шундый бер мисал алыйк. 986 елда олы князь Владимир дин сайлап кабул иткәндә, безнең Болгардан да илчеләр барып аңа ислам дине тәкъдим иткәннәр. Безнекеләр аңа—ислам аракы эчүдән, дуңгыз ите ашаудан тыя дигәч, Владимир боларсыз яшәү урысларга мөмкин түгел икәне әйтеп:—*Руси есть веселье пити, не может без того быти* дигән мәкаль белән җавап биргән. Димәк, бу ике халыкның ышануынча, бер үк нәрсәләргә ике төрле мөнәсәбәт булган. Урыс мәкальләренчә дуңгыз ите ашау, аракы эчү, эчертү яхшылык, әмма ат ите ашап кымыз эчү яманлык булса, болгар-татарлары аңлавынча, кымыз эчеп, ат ите ашау яхшылык, әмма дуңгыз ите белән аракы яманлык саналган. Инде Петр I дән соң Россиягә фән-белем керә башлап, кымызның файдалы дәва икәне дә беленгәч, шул ук урыс алпавытлары башкорт арасына кымыз эчәргә килә башлыйлар. Һәм хәзер шул ук болгар-татарга килсәк, бу заманда аракының фән буенча адәмгә бик зарарлы булуы исбат ителүгә карамастан, кунагы алдына бик һәйбәтләп аракы белән дуңгыз казылыгы чыгарып куя икәнен күрәбез. Бер халыкта яхшылык дип табылган нәрсә икенчесендә яманлык дип саналганын, тора-бара бу төшенчә дә үзгәреп, хәтта бер халыкның үз эчендә дә бер заманда яманлык саналган нәрсә икенче вакытта яхшылык саналырга яки, киресенчә, элекке яхшылык соңыннан яманлык саналырга мөмкин икәне шул мисаллардан аңлашылса кирәк. Шулай ук бер үк заман эчендә дә бер сыйныфка яхшы булган нәрсә, икенчесенә начар булып тоелырга мөмкин. (Бай, ярлы турындагы мәкальләр бүлеген кара). Йә булмаса, әле шушы йөз башында гына татар хатын-кызының йөзен каплап йөрүе яхшылык дип саналып та, хәзер, киресенчә, йөзне капламау яхшылыкка саналуын алып карагыз. Шул рәвешле, яхшылык-яманлык төшенчәсенең диалектик каршылыклы, һәм әверелешле булуын мәкальләр безгә тагын да яхшырак ачып бирәләр:—*Яхшысыз яман булмас, ямансыз яхшы булмас;—Яхшыдан яман туган;—Яманга яхшы катышмый булмас* һ. б. Шул рәвешле, яхшылык белән яманлык күп вакытта бер үк мәкальдә бер-берсенә янәшә, яки капма-каршы куела:—Яхшылык күзгә күренми, яманлык күмеп куелмый;—*Яхшыга ияргән чәчкә, яманга ияргән тозакка;—Яхшыга ияргән азыкка, яманга ияргән казыкка* һ. б. Мондый мәкальләр яхшылык белән яманлыкның һәрвакыт каршылыклы яки көрәш хәлендә булуларын күрсәтәләр. Шуның белән без боларда халыкның ничек тормыш каршылыгы диалектикасын тотып ала һәм аны сәнгать чаралары белән тәгъбир итә белүләрен күрәбез.

Яхшылык һәм яманлык төшенчәсендә татар мәкальләре фәлсәфи һәм абстракт фикерләүгә, яхшылыкның түләү яки бүләк алу өчен генә эшләнмичә, яхшылык исеменә, кешелек хакына эшләнүен, ягъни аның һәртөрле эгоизмнан азат һәм югары булган идеалдагы күренешен тәгъбир итүгә ирешәләр:—*Яхшылык ит тә диңгезгә ат, балык белер, балык белмәсә халык белер;—Таш белән атканга аш белән ат;—Яхшылыкка яхшылык һәр кешенең эшедер, яманлыкка яхшылык—ир кешенең эшедер;—Яхшы кешенең яхшылыгы тияр тар җирдә, яман кешенең яманлыгы тияр һәр җирдә;—Ай уртак, көн уртак, яхшы кеше уртак* һ. б.

Татарда яхшылык яки яманлык гамәлнең сәбәпчелек кануныңа буйсынуына, аның хәерле яки яман нәтиҗәсе, әлбәттә, шуны эшләүчегә әйләнеп кайтачагына нииндидер язмыш кануны кебек итеп ышану бар. Дөньяда һәр тотылган энергия көче бервакытта да юкка чыкмаганы һәм яңадан чыганакка әйләнеп кайтканы шикелле, башкаларга карата эшләнгән яхшы-яман гамәлләр дә, борынгы бабайлар ышануынча, үзенә кайта һәм үз башына ук була:—*Яхшылык кылсаң да үзеңә, яманлык кылсаң да үзеңә;—Юкә өзсәң, каеш түләрсең;—Үрдәк бирсәң, каз алырсың;—Дошманга үлем теләгәнче, үзеңә гомер телә;—Кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең* һ. б. Яки шул төшенчәләрне бик кыска итеп, җыйнак кына ике сүз белән:—*Үзенә кайта* дип куя. Билгеле,

мәкальләрдә бу *үзенә әйләнеп кайту* сәбәп-нәтиҗә чылбырының иң кыска юл белән, хәзер яхшылык яки яманлык иттең дә, шундук нәтиҗәсен күрден төсендә уйланмый, киресенчә, яхшылыкка каршы күп вакыт яманлык белән кайтаралар икәнен, бу хакта бик белеп, урынына һәм кешесенә карап сак хәрәкәт итәргә кирәген дә белә *(Ит изгелек, көт явызлык!)*. Юк. Аның бу үзенә кайтасы яхшылык—яманлыкның югарырак һәм бервакытта да юкка чыкмый торган озын сәбәп чылбыры аша йөрүенә һәм нәтиҗәсе бик ерактан, хәтта үзе үлгәч булса да, бер әйләнеп кайтачагына ышанудыр. Белмим, әллә үзен озын-озак һәм хаксыз газаплар чиккән дип белгәнгәме, бу ышану кайчан да булса бер гаделлек-хаклыкның өскә чыгуына иманы шикелле үк, аның төп тормыш нигез кануны булып тора.

Кешенең акыл-белем сыйфатларына килгәндә, татар мәкальләре аларга да зур урын бирә. Акылның төп көче, бер билгесе, анынча, кешенең характерында, ихтыярында. Анынча бу, иң элек, ачуны йота белү, аннары үз теленә, үз эчке серенә хуҗа була белүләрдә күренә:*—Ачу йоту—тау йоту;—Акыллының теле күңелендә, юләрнең күңеле телендә;—Акыллы ирнең эчендә бишекле олан ятыр* һ. б. Шулай ук акылның эш белү, һөнәр, гыйлем өйрәнүдә тырыш булуы турында да күп әйтелә. Безнең мәкальләребездә гыйлем-мәгърифәткә чакыру, гомумән, зур урын ала. Шул ук вакыт белдек сату, кирәк-кирәкмәскә артык кызыксыну һәм һәр белгәненне сөйләү гадәтләре мактэлмый. Элек ханнар кулында һәм соңыннан патша хөкүмәте кул астында ана күпне белергә ярамаганга артыкны белгән кешеләр тиз зинданга олагып, асарга хөкем ителгәнгә, белем турында сак булырга ишарә иткән мәкальләр дә юк түгел:*—Күпне белсән, асарлар;—Белмим бер сүз, беләм ике сүз* һ. б.

Шул ук вакытта юләрлек, тилелек турында мәкальләрнең күп булучылыгы да игътибарны үзенә тарта. Беркатлы, сәер кешеләрдән, диваналардан кызык табу, гомумән, көнчыгышта таралган хәл. Мәкальләрдә юләрдән кызык табу, аның белән юану кебек хәлләр сизелә. Ул ахмакны *исәр, юләр, урта юләр, чын юләр, акылсыз, ахмак, дивана, сантый, тинтәк, тиле* дигән кебек төрле дәрәҗәләргә бүлеп йөртә:*— Үтә исәр буйга үсәр;—Чын юләр үзен мактар, урта юләр хатынын мактар;—Тинтәк типсә, тимер өзәр,—Акыллы атын мактар, ахмак хатынын мактар;—Акыллы уйлап торганчы, тинтәк эшен бетерер;—Тиле тиле дигән саен тигәнәк буе сикерә;—Юләргә көн дә бәйрәм;—Акыллы әйтер—юл куйдым, юләр әйтер—җиндем* ишеләр. Болардан күрелүенчә, татар юләрлекнең билгеләрен гамьсезлек, бәйрәм ярату, лыгырдык сату, эшне уйлап тормый эшләп ташлау, һәр сүзгә ышану, юмартлауга килү, үзен яки хатынын мактау, сүз көрәштерү, карышу, үҗәтлек кебек хәлләрдә күрә. Ахмаклыкка төшүдән саклану өчен мәкальләр эшне эшләүдән, сүзне әйтүдән элек ахырын уйларга, бер сыналган хатаны кабатламаска, каты серле, аз сүзле булырга, бигрәк тә үз ачуына үзең хуҗа булырга, кызып-чәнчеп бармаска киңәш бирәләр. Ачу йота белү акыллыкның хәтта беренче билгеләреннән санала:*—Ачу пычак, акыл сап;—Ачу алдан йөрер, акыл арттан йөрер;—Ачу дошман—акыл дус, ачуына акыл куш* һ. б.

Татар мәкальләрендә тагын да игътибарга алырлык бер як булса, ул да уку, язу, белем-гыйлем алу турыларында мәкальләрнең күп булуы. Бу нәрсәгә хәтта үткән йөздә үк кайбер урыс галимнәре дә игътибар иткәннәр (мәсәлән, Березин). Безнең халык элек-электән мәктәп-мәдрәсәләр һәм сабак абыстайлары аша башлангыч хәреф тану ягыннан Рәсәйдә алдынгы бер урынны тотып килгәнлеге үз заманында матбугатларда язылып үткән иде. Патша хөкүмәте татарга мәгърифәт керүне төрле юллар белән тыеп килгәнгә, бу мәктәпләр дә хөкүмәт челтәренә кермәгәнлектән, бу укулар, билгеле, белем бирү ягыннан бик түбән, артта һәм бәхетсез хәлдә яшәгән. Шулай булса да, татар халкы үз-үзләреннән укырга тырыш халык булганга, мәкальләре арасында аң-белем, мәктәп-мәдрәсә, уку-язуга караганнары шактый күп. Болар арасында да халыкның үз туган тел һәм әдәбиятына караганнары аеруча әһәмиятле.

Мәгълүм ки, электә безнең әдәби телебез «төрке» дип аталган. (Игътибар итегез: *төрки* түгел, *түрке*.) Мәдрәсәләрдә, сабак абыйстайларында хәреф танырга, укырга өйрәнүне «төркегә төшү», «төрке тану» дип йөрткәннәр һәм бу уку

программасы кызлар өчен Йосыф китабын көйләп укуга хәтле барып житкән. «Йосыф китабы»нын XIII йөз башында язылган булуын игътибарга алсак, бездә «төрке» дип йөртелгән әдәбият татар-монголларнын бу якларга һөжүмнәренә чаклы ук булганлыгы анлашыла, алар килгәнче *татар* сүзенен бу якта кулланылуы да мөмкин түгел. Монголлар басып алганнын сонында да бездә Болгарда гына түгел, Казан ханлыгында да һәм аннан сон Россия кул астына кергәч тә *татар* сүзе кулланылмаган, тик үткән йөз ахырларында туган яна әдәбият белән генә керә башлап, шуна хәтле килгән борынгы язма әдәбиятыбыз һаман төрке дип аталып килүендә дәвам иткән. Бу «төрке» дигән әдәбият, кайберәүләр уйлаганча, Госманлы төрек әдәбияты да, Чыгтай әдәбияты да түгел, үзебезнен шушы Идел буйларында борын-борыннан бирле яшәп килгән *болгар төркесе, Казан төркесе* булып, бу атама ана жирле тел билгесе ягыннан карап бирелгән. «Төрке» дигән әдәбият бездә мен ел буе озак һәм авыр көрәшләр аркылы яшәп килгән. Феодаллар, руханилар, соныннан патша теле итеп бары тик гарәп, фарсы телләрен генә таныганда, мәктәп-мәдрәсәләрдә әлефбидән башлап балаларны шул телләрне укырга мәжбүр иткәндә, татар халкы аларга каршы һаман үз төркесен яклап килгән. Тел-әдәбиятта гасырлар буе барган бу көрәш мәкальләрдә чагыла:*—Төрке барнын күрке бар;—Укыдым гарәп—тордым карап, укыдым фарсы—килде каршы, төркем бар да күркем бар, төртермен дә егармын* кебек мәкальләр татар халкында үз туган тел-әдәбиятына, үз милли культурасына ни дәрәжәдә мәхәббәт булуын, аны ул чагында дини һәм изге саналган гарәп-фарсы культураларыннан да югары һәм кадерлерәк күреп килүен һәм, халык буларак, яшәү мәйданында анын борынгы төрке әдәбияты да гарәп-фарсы кебек чит культураны «төртеп егарлык» корал итеп тануын күрәбез.

Һәртөрле мифләргә, дингә, Аллага ышануга турыдан-туры караган мәкальләр артык күп күренми. Бигрәк тә кыямәт, теге дөнья, ожмах-тәмугъ турындагы мәкальләр юк дәрәжәсендә аз. Мәкальләргә карасан, татар үлсә, күмеп кайталар да шунын белән эше бетә шикелле:*—Үлүенә күрә күмүе;—Гүргә кергән кире чыкмас* һ. б. Бездә муллаларнын азгынлыгыннан, суфыйларнын пүркилыгыннан көлеп, паразитлыкларын фаш итеп чыгарылган мәкальләр дә бик күп:*—Мулла үзе урлый, үзе юллый;—Суфый суган сөймәс, күрсә кабыгын да куймас;—Иртә намаз, кич намаз, каккан казыгын калмас* һ. б. Боларга карап халыкны электән Алласыз, материалист булган дип күрсәтүчеләр булды. Ләкин бу дөрес түгел. Билгеле, боларга карап кына татар халкынын электән теге дөньяга ышанмавын яки атеистлыгын китереп чыгарырга ярамый. Бу хәл мәкальләрнен, күбесенчә, тормыш һәм аннан алынган ачы тәжрибә жимешләре булып, үзе тәжрибә итмәгән теге дөнья яки ожмах-тәмугъ хәлләре турында халыкнын белем-хикмәт әйтә алмавыннан килеп чыккан. Әмма мулла яки суфыйларны исә халык тормышта үзе күреп сынап яшәгән.

Анын каруы тәкъдиргә, язмышка, бәхеткә, ризыкка ышану турындагы мәкальләр күп кенә. Һәм бу ышанулар башка темалар рәтендә дә һаман күренә, сизелә килә. Язмышка ышану ислам дине аша киләме, әллә бу анын элекке борынгы ышанулары белән бәйләнгәнме, алары үзенә бер мәсьәлә. Әмма ләкин татар ышануынча, язмыш һич кайтарылгысыз бернәрсә. Ул аны якын бер сәбәп-нәтижә яки зарурият төсендә генә алмый, бәлки үзе туганчы ук булган ерак сәбәпләр яки табигатьнен үзеннән үк килгән нәрсә шикелле итеп карый:*—Язмыштан узмыш юк;—Мангайга язганны күрми чара юк;—Күрәсен күрми, гүргә кереп булмый* һ. б. Бу ышану татарны үзенен тарихи-социаль хәленә буйсынырга, көрәштән кул селтәргә, бәндәчелеккә күнеп килергә мәжбүр иткән. Ләкин икенче яктан шул ук язмыш кешесе булу аны да үз табигате белән килешергә, тәвәккәл һәм үлемнән курыкмый торган кеше булуына да ярдәм иткән. Чөнки бит, анынча, үлем дә язмыш эше, үлемнен кайда булачагын беркем дә алдан белми, *туфрагын кайда язган булса, шунда була.* Әмма инде сина язылмаган жирдә нинди һәлакәтле эштә, нинди канлы сугыш мәйданында булсан да сина үлем булмый, дип ышанган.

Шул рәвешле мәкальләрнен гомуми эчтәлегенә ашыгыч бер күз йөгертеп үткәндә дә, андагы темалар күпчелеге башка халык мәкальләрендәге белән бер

ук булсалар да, алар безнең халык язмышын, тормышын, табигатен, рухи, әхлакый сыйфатларын һәм характерларын, тарихын шактый күп яклы, тапкыр һәм тирән чагылдыра икәнен күреп була. Мәкальләрне укып барганда, моны бөтен күләме һәм тирәнлеге белән күреп булачак. Бу хәл мәкальләрнең тематик эчтәлеге һәр халыкта үзенчәлекле булуын, аларга гомуми бер үлчәүдә генә килеп, берсендәге үзенчәлекләрне икенчесенә механик күчерергә ярамаганлыгын күрсәтә. Тема ягыннан да шулай. Берсендә берләре бар яки баерак булса, икенчесендә алары булмас яки аз әһәмият бирелгән булыр. Бу нәрсә халыкларда тормышның, зәвыкларның төрле-төрле булуына бәйләнгән. Моны безнең мәкальләрне урысныкы белән чагыштырганда бик яхшы күреп була. Аларда, мәсәлән, һәртөрле чиновниклар катлавы, суд-судья, закон йөртү, дәүләт тәртипләре турында мәкальләр бик күп. Чөнки Рәсәйдә бу эшләр 1917 елга хәтле урыслар кулында гына булган. Шунлыктан аларда мәкальләргә бары тик хокук материаллары күзлегеннән генә караучылар булган. Билгеле, андый мәкальләр Казан алынганчы бездә дә күп булгандыр, әмма хәзер безгә хәтле килгән мәкальләрдә бу темалар яктыртылмый диярлек, күп булса тылмач-фәләннәргә генә кагыла. Ни өчен? Чөнки татарлар күп йөз еллар буена дәүләт идарәсенә якын җибәрелмичә, күп булса берәр конторда тылмач-фәлән (тәрҗемәче) булып кына эшли алганнар. Алар чинсызлар. Шулай ук татар дворяннары да, күбесенчә, исемдә генә булып, христиан дине кабул итмәгәннәре җирсез, чабаталы аталганга, крәстиәннәры да урыс крепостное хәлендә беркетелүе бик сирәк ихтималда гына булганга, бездә крепостнойлык хокукына һәм мөнәсәбәтенә караган мәкальләр бөтенләй юк. Борыннан килгән кол сүзе гомумән очраса да, *холоп, смерд (Смерда взгляд хуже брани)* шикелле халыкка сыйнфый җирәнү кушаматлары да, аларга бәйләнешле мәкальләр дә бездә юк. Шулай ук бездә урыслардагы кебек чиркәү, монастырь, монах, поп турыларында мәкальләр була алмый. Аннан тагын ялкаулыкны, бәйрәмчелекне яки кабакны идеаллаштырган мәкальләр күренми диярлек. Әмма кол белән би, бай белән ярлы, ач белән тук кебекләр турында мәкальләр бездә күп кенә. Шулай ук базар, товар, акча мөнәсәбәтләре турында, юл-сәфәр йөрүләр турында мәкальләрнең күп булуы татарның сәүдә яратуы белән һәм кәсеп эзләп юлда күп йөрүләре белән бәйләнгән. Патшачылыкны мактау, ихлас мужик буйсынучанлыгын, аның юашлык һәм мескенлеген идеаллаштыру кебек мәкальләр дә бездә юк шикелле. Шулай ук урыс мәкальләрендә күрелгәнчә, төрле өлкәләрдәге кешеләрне үртәп әйтелә торган (присловие) сүз төре бездә бөтенләй булмаган кебек, башка халыкларга өстән караш яки расалык күзлегеннән югары торып әйтелгән мәкальләр дә юк. Шунысы характерлы, татар баскынчылыгы турында тарихларда сүз күп булса да, башка халыкларны басып алучылыкны яклаган мәкальләр дә бездә күренми һәм моннан йөз ел элек безнең мәкальләрне тикшергән Березин дә, башкалар да моны күрсәтә алмаганнар. Бу хәл Идел буе болгарларының үз күршеләренә карата гомумән тыныч халык булуыннан, монгол-татарлар кул астына кергәч тә аларның һөҗүмчелеген якламаган булуларыннан булса кирәк. Батырлыкны төрлечә мактаган яки:— *Тимәгәнгә тимәм, тигәнне тиген калдырмам* дигән лозунг мәкальләре булса да, болар да басып алучылык турында булмыйча, бәлки үзләрен яклау яки үз җирләрен басып алучыларга каршы ил-йорт намусын яклау йөзеннән әйтелгән булулары аңлашыла.

Шунысы да кызык хәл: бездә башка халыкларга карата аларның агрессорлыгын яки башка шундый тискәре якларын сыйфатлаган мәкальләр очраса да, алар татарның үзенә карата әйтелгән дәрәҗәдә каты түгел. Мәсәлән:— *Татар барда хәтәр бар;— Татар түрә булса, чабатасын түргә эләр;— Татар атка менсә, атасын танымас;— Татар түрә булгач, иң элек атасын үтергән* кебек үз адресына карата әйтелгән тискәре мәкальләр бездәге хәтле бер халыкта да юктыр. Бу хәл күпләрне гаҗәпләндергән һәм татарлар үзләренә үзләре бик түбән карыйлар, аларда үзләренә хөрмәт, милли горурлык дигән нәрсә бер дә юк дигән уйларга да китергән. Ләкин шул мәкальләр яхшылап каралса, алар безнең үз халкыбыз турында булмыйча, шәһре Болгарны килеп җимергән татар-монголларга карата әйтелгәнлеге мәгълүм булыр. Чөнки безнең халык

тарихта үзен татар дип атап йөрткәне дә булмаган, ул исем безгә монастырьда утыручы урыс монахлары тарафыннан бирелгән. Урыс кнәзлекләрен Чыңгыз явы басып алганнан соң, шул хакта елъязма язучы монахлар монгол белән төрки халыкларын аерып таный алмаганга, Болгар-Казан төрки халыкларын да кенәгәләренә татар дип язып, шулай теркәү рәсмиләшеп киткән. Бу хатаның безнең өчен унайсыз нәтиҗәсе шунда: татар һөҗүменә каршы ул чагында урыслар әйткән мыскыллы мәкальләр дә, шулай ук болгар-казанлыларның шул ук монгол-татарларына карата үзләре әйткән тискәре мәкальләр дә хәзер бар да безнең халык башына килеп өелгән. Бу хатаны кабинетта утыручы галимнәр, тарихчылар аерса да, урыс халкында да, безнең үз халкыбызда да шулай ук мәктәп тарих китапларында да ул тискәре мәкальләрнең кем адресына караганлыгы аерып беленмичә, шул килеш кулланыла. Һәм урыс халык иҗаты буенча шундый мәкальләр дәресләрдә мисал урынына китерелеп, аңлатмасыз укыту шикелле күңелсез хәлләр дә килеп чыга.

Ничек кенә булмасын, югарыдагы мисаллардан бернәрсәне ачык билгеләп була. Мәкальләрнең жанр буларак, башка халыклар белән уртак яклары булса да, алардагы эчтәлек һәм темаларның сайланышы һәм яктыртылышы һәр халыкта үзенчәлекле, тормышы һәм табигате буенча үзенеке. Шуның өчен дә урысларның алдынгы язучылары, шагыйрьләре һәм тәнкыйтьчеләре үз мәкальләренең урыс милли характерын, көнкүрешен һәм халык тормышын өйрәнүдәге әһәмиятен бер генә кат күрсәтеп үтмәделәр. Бу үзенчәлек урыс мәкалендә *куас*, ә татарныкында *әйрән* турында әйтелгән булуында гына түгел, бәлки аның тышкы тормыш, көнкүреш шартларыннан алып, халыкның барлык мәелләре, гадәтләре, акылы фигыле—кыскасы, бер халыкның бары тик үзендә генә табыла торган сыйфатлары, ягъни милли характерына чаклы аның мәкальләрендә үзенчәлекле чагыла. Чөнки халыкның тормышында, гореф-гадәт, йола һәм ышануларында, аның әхлагында, тәҗрибә һәм дөньяга карашларында ясалып чыккан бу үзенчәлек рухы, үз табигый мәелләре шунда туган, бар да шундагы ук үз җир-суына, климатына, метеорологиясенә, шунда хасил булган аш-суларына, хезмәт мөнәсәбәтләренә һәм халыкның шунда тарихлар буенча үзе өчен ясап чыгарган теле, тормышы һәм культура дәрәҗәсенә бәйләнгән. Әйтик, аучылык, игенчелек кебек кәсепләре бер яктан үз климат һәм метеорологик шартларына бәйле булса, икенче яктан үз тарихи, иҗтимагый хәленнән һәм культура дәрәҗәсеннән башка да була алмый. Шулай булгач, бу нәрсәләр аның мәкальләрендә дә үзенчәлекле чагылмый хәле юк.

Бу үзенчәлекләр мәкальләрнең тематик эчтәлегенә генә кайтып калмыйча, барлык яклап һәм бигрәк тә аларның тел һәм шигъри төзелешләрендә тагын да ачыграк күренәчәк. Аларына соңыннанрак тукталырга туры килер.

## Тормыш хикмәте булу ягыннан мәкальләр
## Аларның фәлсәфәсе

Без татар халык мәкальләренең эчтәлегенә, тематик байлыгына өстән генә булса да, бер кат күз йөгертеп үттек. Ләкин мәкальләрдә алынган нәрсәләргә һәм күренешләргә татарның акылы ничек һәм ни дәрәҗә тирән үтеп керә, ул ничек дөньяны таный—болары икенче эш. Чынлап та, без мәкальне халык хикмәте дип атыйбыз икән, аның тирән һәм хикмәтле булуы нәрсәдә? Моны аңлау өчен мәкальләрнең эчтәлеген барлап яки бәяләп чыгу гына житми, бәлки халыкның әйбер һәм күренешләрне ничек таный, аера белү сәләтенә дә игътибар итәргә кирәк.

Дөньяны, тормышны тану өчен, кеше әйберне бер карау белән тышыннан ук эчен белергә, шуның белән файдасын, кыйммәтен, үзенең мөнәсәбәтен билгеләргә тырыша. Дөрес, кайбер әйбердә моны белергә әллә ни зирәклек кирәкми. Эчтәлеге тышына ук чыккан була:—*Май чүлмәге тышыннан билгеле;—Бүйдакның акылы ике күз;—Баканың йөрешен күргәч, сикерүен нигә сорыйсың?* һ. б. Ләкин бу күбрәген сай һәм катлаусыз әйберләрдә яки тышы белән эче

бергә тапкыр килгән, килешкән нәрсәләрдә генә шулай. Әмма гомумән нәрсәне тану, аның төбен, затын, асылын белү иң хикмәтле һәм тирән нәрсә булып, әле дә бөтен фән-гыйлем дөньясы аның белән мәшгуль. Халык үзенең тормыш практикасында моның авыр һәм озак сынаулар таләп иткәнен бик яхшы белә:—*Кеше кешене таныганчы бер пот тоз ашый;—Нәрсәнең тышы якын, эче ерак, коймасы кала, ишегендә йозак;—Бөлә-бөлә беләсең* һ. б.

Күренеш һәм әйберләрнең, шулай ук кешеләрнең үзләре дә туып үсеп, үзгәреп торулары, яңарып-искерүләре, картаю һәм үлүләре, шул яшәү өчен көрәштә тышкы яктан гына түгел, эчке, рухи яна сыйфатларга да ирешүләре яки һәлакәткә очраулары мәкальләрдә бик нык чагыла. Мәкальләрдә бу каршылыкларның күренүләре, кайберәүләр уйлаганча, аларның композиция төзелешләрендәге янәшәлектән килеп чыккан контрастлык, антитеза йә булмаса башка шундый сәнгать чаралары өчен ягъни форма өчен генә булмыйча, бәлки тормышның һәм эчке мәгънәнең шуны кыставы, таләп итүе аркасында, зарурый рәвештә килеп чыга.

Шул рәвешле, һәрнәрсә үзенең эче-тышы белән бер бөтен булса да яки шулай булып күренә дә, асылда бу эч белән тышның күп вакытта бер-берсенә ярашмавын мәкальләр бик яхшы беләләр. Алар нәрсәнең (яки әйбернең диик) шул каршылыгын танырга, аерырга, шуның белән нәрсәләрне дөрес бәяләргә, алданмаска өйрәтәләр. Мәсәлән, әйбер тыштан бертөрле күренеп тә эчке хәле шуна яшерен рәвештә каршылыклы булуы турында:—*Алданма кызыл алмага;—Үтә кызыл тиз уна;—Юләр кызылга гашыйк;—Тыштан ал да гөл, эчендәген үзең бел;—Адәм аласы эчендә, хайван аласы тышында;—Тымызык күлдә корт уйный;—Чуртанның үзе үлсә дә теше үлмәс;—Сукыр күп күрер, аксак күп йөрер;—Суфый суган сөймәс, күрсә кабыгын да куймас;—Көндез абыем, кич җаным;—Өе биек, өйрәсе сыек;—Бай дигән даны бар, тик чыкмаган җаны бар;—Аты олы, кабыргасы коры;—Таяк ике башлы;—Этнең баласы эчендә өрә* һ. б.

Хәтта кайбер нәрсәләрнең эче-тышының бөтенләй киресе булуына мәкальләр бик нык игътибар итәләр:—*Еланның тышы йомшак, эче зәһәр;—Эче жылый, тышы көлә;—Тышы мамык, эче кабык;—Хаҗи дигәнебезнең кесәсеннән хачы (тәресе) чыкты* һ. б.

Бу эчке каршылык ничек килеп чыга? Мәкальләр өйрәтүенчә, үсү таркалу эчтән башлана һәм бу башланып китүнең мизгеле, мәле кайсы кисәктә булуы бар:—*Ит үзеннән кортлый;—Балык башыннан черер;—Олан яшьтән, тары*




*Язучыларның Г. Тукай клубында әдәби кичә бара (1975).*
*Президиумда (сулдан уңга)—Нәкый Исәнбәт, Мөхәммәт Гайнуллин, трибунада—Хәсән Туфан.*

*колактан беленер;—Туа мөгез чыкмый, тора мөгез чыга;—Бишектәге бишкә төрләнер* һ. б.

Һәртөрле тышкы сәбәпләр һәм шартларның кыставы астында, бу эчке бүленеш нинди төс алачагын һәм нинди нәтиҗәгә юнәлгәнен мәкальләр тормыш мисаллары белән алдан ук төсмерләргә өйрәтәләр:*—Китәсе кошның башы элгәре;—Башта чыккан колактан, соңыннан чыккан мөгез узар;—Җәй килеше кыштан билгеле;—Ит ашасаң тешкә кирә, ашамасаң төшкә кирә;—Юкны кирәк таптырыр;—Кирәк тирәкне ега;—Һәрбер эшкә сәгать бар, һәрнәрсәгә сәбәп бар* һ. б.

Нәрсәләрнең шулай эче-тышы күп вакыт туры килешмәсә дә, мәкальләрчә, алар һаман бөтенлеккә, тинлеккә омтылалар:*—Тин тинне тарта, аршын бүзне тарта;—Зат затына тарта;—Ике сыңар—бер пар;—Иш ише белән, дуңгыз түше белән;—Иш янына куш сыя;—Егет—егетнең көзгесе;—Кәкре белән бөкре икесе дә бер;—Бере тукмак, бере чөй, берен ал да берен төй;—Тиң тиңе белән—тизәк кабы белән.*

Ләкин һәрвакытта да мондый тигезлек, тинлек килеп чыкмый икән шул, бармаклар да тигез түгел:*—Игез бәрәннәр дә тигез булмый;—Егет егеттән ким түгел, бәхете генә тиң түгел* һ. б.

Яки мондый бөтенлек бәхете чиратлашып, алмашып килә:—Бер ел тартай симерер, бер ел бүдәнә симерер;*—Бер яшьлектә, бер картлыкта;—Иске байның бөлгәне, яңа байның көлгәне;—Берәү сыер сава, берәү мөгезен* тота һ. б.

Бу бөтенлеккә, тиңлеккә, «һәр яктан түгәрәк килү»гә, яки камиллеккә, бәхеткә ирешү хәрәкәте гел туры сызыкта гына үсеп бармый, үзендәге омтылыш көче ирешә алган дәрәҗәдә камиллеккә, сыйфатка ирешә дә аннан кире кайта башлый:*—Яшь ай кимүдән курыкмас;—Айның күрке төгәл булгач, кире кайтыр;—Ай да кайта, көн дә кайта;—һәр камалның бер зәвалы бар* һ. б. Кайчагында бу кире кайту берьюлы гына була:*— Чуан тулгач тишелер;—Уеннан уймак чыгар* һ. б.

Ләкин бу омтылышлар максатсыз булса, камиллек таба алмыйча яки бер якка да була алмыйча калган хәлләре дә күп була. Бу чагында сыйфат урынына рәтсезлек, характер урынына үҗәтлек яки хаос килеп чыга:*—Ни Аллага, ни муллага;—Ни он түгел, ни камыр түгел;—Ни думбыра белмәгән, ни сызыгыра белмәгән;—Эт баш, сыер аяк;—Син тартасың табакка, ул тагаракка;—Үзе белми, кешедән сорамый;—Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?—Ни ылтыра, ни пылтара, калган ике уртада* һ. б.

Яки бу каршылыкларның бергә җыелуы һич тә мөмкин булмый торган ике хәл килеп чыга:*—Бүре дә тук булсын, куй да бөтен булсын;—Кыз да булсын, буаз да булсын;—Ике тәкә башы бер казанга сыймый;—Ике кимәне учлаган су төбенә китәр* һ. б.

Билгеле, бу яшәү өчен көрәш, уен түгел. Мәкальләрчә, ул зур тәвәккәллек, фидакарьлекләр сорый: йә баш, йә мал:*—Йә иренчәк үләр, йә күңелчәк үләр;—Бүген дөнья, таңда ахирәт.*

Һәм бу көрәштә ике як аяусыз рәвештә бер-берсен алып ташларга, бетерергә омтыла:*—Тычканга үлем—мәчегә көлке;—Эткә эт үлеме;—Бардан юк булган, үлем белән тин булган;—Бүген бар, иртәгә юк* һ. б. Иҗтимагый-сыйнфый мәкальләрдән:*—Бай барын бирмәс, ярлы карап тормас;—Җан карендәш булса да, мал карендәш түгел;—Ярлы кеше яман чир, туры килсә канын эч (байлар әйткән);—Явын аяган яралы калыр* һ. б.

Шундый ике рәхимсез каршылык арасында кайчагында өченче бер битараф (нейтраль) торган як килеп кысылучан була. Мәкальләр аны да күрмичә үтмиләр. Бу өченче як ике каршылыкның бергә килеп бәрелешеннән йә үзенә файда итә, икесеннән дә өлеш ала, йә шунда кысылып ике йодрыкны да үзе ала:*—Ике карга сугышса, ябалакка йон була;—Сугышканга бер үлем, арачыга ике үлем;—Ат тибәр, качыр тибәр, ике арада ишәк үләр;—Кул кулга сукканда, арада чебен үләр;—Ат үлеме туй* һ.б.

Билгеле инде яшәү өчен көрәш давы коры яшәү өчен генә бармый, бәлки яңа сыйфат яулап алу бәхетенә ирешү өчен бара. Бу бәхеткә ирешү, мәкальләрчә, кат-кат һөҗүм белән каршы якны җину (фәлсәфә теле белән

әйтсәк, саннын сыйфатка әверелүе) яки җинелеп, катастрофага очрап та эчке янарыш табу төсендә килеп чыга. Мәсәлән, саннын ничек сыйфатка әверелүе турында:—*Тамчы-тамчы күл була, тиен-тиен сум була; Бер тиен бер акча, ике тиен күп акча;—Куй кузыдан үсә, сума тиеннән үсә;—Ил төкерсә күл булыр, бер төкерсә ни булыр;—Тугыз көнгә бер баш, көн дә саен бер аш;—Биш чумар, биш чумар—йөз көнгә биш йөз чумар;—Кул кулны юса, ике кул йөзне юар;—Күп баланың эчендә бер карт бала булыр, күп картның эчендә бер бала данә булыр;—Күп авыз бер булса, бер авыз юк булыр;—Чебешне көз көне санныйлар* һ. б.

Ләкин, мәкальләрчә, коры сан үзе генә кабатлануы яна сыйфат бирми:—*Бер тарыдан ботка булмый;—Ике тинтәк берексә ил булмас;—Санйм утыз, чыга тугыз;—Булыр бала ун яшендә баш булыр, булмастай бала алтмышка җитсә дә яшь булыр;—Алтмышныкы бетә, алтыныкы кала;—Белмәгән эше юк, кинәндергән төше юк;—Сүзе сүзгә охшамый, авызы сүздән бушамый;—Акча бакыр, санарга такыр* (Саны күп тә сыйфаты аз);—*Кабак олы, бәясе бер тиен* һ. б. Кыскасы, коры сан һәм күләм артыннан куу, мәкальләрчә, сыйфат бирү дигән сүз түгел. (Кәгазьдә зур цифр, зур процентлар күрсәтеп, үзенә дәрәҗә «сыйфат»ы алуга ярамаса, тормышта гамәлдә бу нәрсә үзе генә күп эшкә ярамый дигәндәй).

Мәкальләрдән күренүенчә, нәрсәләрдә бу яна сыйфат яки үзендә рухи яналыкка ирешү, күпләр уйлаганча, һәрбер очракта да унай якның тискәрене җинүе булып кына да килеп чыкмый, бәлки унайның көрәштә җинелүе, һәлакәткә очравында да килеп чыккалый. Бу вакытта аның яна сыйфаты—үзенең ник җинелүенең сәбәбенә ирешүендә, үзенең хатасын төшенүендә булып чыга. Хатанны, гаебенне төшенү исә, аны икенче мәртәбә кабатламаска арткы акыл һәм сабак була, белем һәм тәҗрибәгә ирешүгә илтә:—*Ангармаган тумгәк чана аудара;—Авыруын яшергән үләр;—Бөлә бөлә беләсен;—Эт белән кода булсан, сөяк белән туй итәрсең;—Кая егыласымны белсәм, салам җәяр идем;—Акча бетми—акыл керми;—Атын алдырган—абзарын бикләгән* һ. б. Аннары бу яна сыйфат һәрвакытта да унай як өчен генә булмыйча, кайчагында һәлакәтчә очраган тискәре як өчен дә гыйбрәтле була. Бу чагында ул үз тискәрелегенең җәзасын тату, үз гаебен тану, җинаятен икърар итү, үкенү яки тәүбә итү төсендә анын өчен эчтән янару (трагик катарсис яки арыну) булып чыга. Бу нәрсә кеше табигатенең эчке үсеше, камилләшүе, яна сыйфатка ирешүе һәм гыйбрәтле хәл булганлыктан, мәкальләрнең эчтәлегендә анын чагылуын читләтеп үтү мөмкин түгел: яхшы, яман эшләрнең нәтиҗәсе үзенә үк бер әйләнеп кайта икәнлеккә татар тәкъдиргә ышанган кебек ышана:—*Аләм каны атлатмый, үзенә кайта;—Атана ни кылсан, алдына шул килер;—Күз яше җирдә калмый;—Козгын кычкырса, үз башына булыр;—Әүвәлгенен мазасын, соңгы бирер җәзасын;—Чәчкәнне урырсын* һ. б.

Инде мәкальләр әйбернең үзендә яки алар арасындагы каршылык барышын һәм аларның кайсы унай, кайсы тискәре якка икәнен күрергә яраткач, унай якны яклаулары табигый. Ләкин бу әле мәкальләр нәрсәләргә гел унай яктан гына карыйлар, шул якны гына күрсәтәләр дигән сүз түгел.

Шул рәвешле, сыйфат мәсьәләсе унае белән, без мәкальнең тагын бер әһәмиятле алымына килеп җиттек. Ул да булса, тискәре яктан суктырып әйтү. Чыннан да, безнең мәкальләргә ныклабрак игътибар иткәндә, ин элек шундый бер хәл күренер: аларның иң зур күпчелеге кире яктан, тискәре яктан әйтүгә яки инкяр аша сурәтләүгә корылган. Мәсәлән, фигыльләрдә *булмас, алмас, бармый, кайтмый* кебек юклык фигыльләре куллану бик күп:—*Ут төтенсез булмый;—Басуда балык булмас;—Иргә ышанма, Иделгә таянма;—Колынлы биядән кое суы да артмас;—Тимер тапкан тилмермәс;—Алтын черемәс* һ. б. шуның кебекләр. *Яки юк, түгел* шикелле юклык сүзләре аша бирелү:—*Кояш та тапсыз түгел;—Кояш юк—көн юк, көн юк—терлеклек юк;—Дуңгызны кондыз итәр хәл* юк төрендәге мәкальләр. Боларда ни дә булса, кире яктан әйтелә, тискәресе бирелә, нәрсә дә булса инкяр ителә.

Ни өчен болай тискәре әйтелә соң?

Билгеле инде, болай әйтү әйбер һәм хәлләрнең үзләрен юкка чыгару,

танымау түгел. Бәлки, киресенчә, аның барлыгын тагын да ныграк беркетү, ача төшү өчен шулай.

Әйтик, *Кояш юк—көн юк, көн юк—тереклек юк* диелә икән, бу инде кояшны яки тереклекне тану, инкяр итү түгел һәм беркем дә аны алай анлатмый. Киресенчә, кояш аркасында көн һәм тереклек бар икәнен һәркем бу мәкальдән тагын да ныграк анлый. Чөнки моны әйткәндә, кеше бер үк вакытта шунын кире ягы аша уңай ягын төшенә, ягъни, кояш булмаса, көн һәм тереклекнең дә киресе—төн һәм үлем булыр иде дигәнне анлый, бу исә ана күренешне контраст һәм күләгә ягы белән (негатив ягы белән) беркетергә, аның барлык чикләре, контуры белән сурәтле итеп күз алдына китерергә ярдәм итә. Әгәр дә без шундый инкяр итү төсендә әйтелгән мәкальләрнең *юклык* фигыльләрен *барлыкка* әйләндереп әйтеп карасак, аларның шул ук вакыт уңай якны беркетү икәнлеге тагы да яхшы аңлашылыр:—*Жир чокырсыз булмас, урман киексез булмас*—дигәнне киресенә әйләндереп:—*Жир чокырлы булыр, урман киекле булыр* дип әйтсәк тә ул шул ук бер мәгънә, шул ук сүз:—*Ат тартмаса арба бармас;—Бер атка ике камыт киертмиләр дию шул ук вакыт:—Ат тартса, арба барыр. Бер атка бер камыт киертәләр* дигән сүз. Димәк, инде болай булганда да фикер бер, әмма ләкин мәгънә генә саега һәм мәкаль буларак әдәби, сәнгатьчә әсәрлеген югалта. Ни өчен? Чөнки болай гына әйткәч, аның тормыш каршылыгында әйтелүе калмый, мәкаль үзенең инкяр иткән ягын югалту белән тормышын югалта, хикмәт саега, шигъри яктан төссезләнә, ул гади абстракциягә яки риторик прозага әйләнә. Инде ни өчен юклык яки инкяр алымы белән әйткәндә шул ук мәкальләр мәгънә һәм сурәтләмә табуга ирешәләр. Чөнки алар бу очракта нәрсәне инкяр итү аша аның ук уңай ягын беркетәләр, аның күләгә һәм чикләрен күрсәтү белән аны коры, ялангач итеп алмыйча, конкрет тормышы белән алып жанландыралар, сурәтләмәгә күтәрәләр. Кайбер мәкальләрдә бер-бер сыйфат яки санның булмау ягы әйтелгәч, шунда бергә үк аның киресе булган яңа яки аерым бер сыйфаты барлыгы әйтеп беркетелә:—*Тамак түгел тамуктыр* дигәндә, башта *түгел* сүзе белән аның *тамак* булуы инкяр ителгәч, аның яңа бердәнбер сыйфаты—тамук кына бар итеп беркетелә. Комсызлык, ач күзлелек кешенең утка, бәлагә төшерә дигәне:—*Акыл яшьтә түгел, башта* дигәндә, акылның еллар санында булуы инкяр ителгәч кенә кайда булуы әйтелә:—*Кешене урын аруландырмый, кеше урынны аруландыра.* Монда *урынны* теләсәң *урын-ара* (мосафә, пространство) дип, теләсәң хезмәт урыны дип анла. Бу мәкальдә урынның кеше тарафыннан үзгәртелүе, кешенең урын колы булмыйча, үзе яңа сыйфат тудыручы булуы, актив роле ачыла. Ләкин мәкаль монда да ике хәлнең берсен инкяр итүгә корылган.

Кыскасы, безнең мәкальләрдә тискәре яктан бирелгән алым һәм сурәтләмәләрнең күп булуы тискәренең үзе безгә максат булганы өчен түгел, киресенчә, аларның кире яктан (инкяр юлы белән) әйтеп уңайлы беркетүендә. Ягъни, уңайның кире ягы да бар икәнен әйтеп, күләгә якларын чикләп, киртәләп, бөтен контурын да сызык эченә алып бирүендә. Бу нәрсә безгә уңайлы әйткәндә аның тискәресе бар икәнен дә онытмаска, безне шул тискәрелеккә каршы көрәшергә, аны инкяр итәргә, юкка чыгарырга юнәлтә[1]

Күп кенә мәкальләрнең шулай тискәре яктан суктырып әйтүгә корылуының мәгънәсе шунда. Чөнки бу алым, күрәсез, мәкальнең хикмәтен, мәгънәсен, шигърилеген тирәнәйтергә ярдәм итә.

---

[1]Бу уңай белән сәнгатьтә күп бәхәс тудырган тискәре образдан курку, абсолют уңайны тудыру бәхәсе хәтергә килә. Югыйсә, халык ижатында һәм язма әдәбиятта да тискәре аша уңайны сурәтләү шундый кин таралган алым ки, әсәр хәтта гел тискәре сурәтләмәләрдән торырга мөмкин. (Әйтик, Гоголь һәм Щедрин алымнары.) Монда мәкальләрдән алынган конкрет мисаллардан да аңлашылуынча, хикмәт тискәрене бирелүендә түгел, бәлки аның ни дәрәжәдә инкяр ителүендә һәм аның аша ни дәрәжәдә уңайның ачылуында булып чыга. *Абсолют уңай* образ дигән нәрсәләр күләгәсез, яссы итеп чәпәп ясалган әүлия «сурәт»ләре кебек, коры һәм имансыз булганга, киресенчә, мондый көч һәм динамикага ирешә алмыйча, үзен-үзе инкяр итә; ягъни, уңай дигәнебез кире тәэсир калдыруы белән, үзе сәнгатьчә *тискәрегә* әйләнә.

Мәкальләр әйбер һәм хәлләргә карап анын төп сыйфатын билгеләргә тырышалар:—*Тиле үзен мактар;—Ат яхшысы—тездән, егет яхшысы күздән билгеле* һ. б. Яки—*Ут төтенсез булмый* (ут булу өчен анын шул сыйфаты булу шарт);—*Җөйсез йомырка була, сөяксез бәрәңге була* (бер сыйфатнын бернәрсәдә юклыгы, икенчесендә дә анын юклыгын китереп чыгармый) һәм башкалар. Бер сыйфат икенчесен юкка чыгара, инкяр итә, ләкин шунысы кызык, тискәре сыйфатларнын бер-берсен инкяр итеп маташуы бер дә яналык тудырмый, бәлки үзе көлке бер тискәрелекне, комедия күренешен генә тудыра:—*Ертык тишектән көлгән;—Баткан тайганнан көлгән;—Үз күзендәге бүрәнәне күрми, кеше күзендәге чүпне күргән;—Кәҗә сарыктан итәген япмый дип көлгән;—Кәкрене бөкре күрә алмый* һ. б.—*Искесез яна булмас, ямансыз яхшы булмас* дигәндә, искенен инкяр ителүе, анын белән көрәшнен яңаны тудыруына сәбәп булуын һәм искенен дә бу тудыруга күпмедер өлеш яки мөмкинлек җирлеге бирүен күрсәтә.

Мондый мәкальләрнен тормышка тагын да тирәнрәк үтеп керә алмаганнары да—бернәрсә бара торгач бер чигеннән үтсә, үз тискәресенә әйләнеп төшүен күрсәткәннәре. Әйтик, башта син каршы якнын ниндидер бер тискәре сыйфатына һөҗүм иттен, гомеренне шуна бирден, бер заман карыйсын, шул тискәрелек белән хәзер син үзен сыйфатлангансын һәм, билгеле, хәзер шул ук һөҗүм синен үзенә үк каршы алып барыла. Мәсәлән:—*Килен булдым каенанага ярамадым, каенана булдым киленгә ярамадым.* Килен башта үзе дошман күргән каенана сыйфаты белән ахырда үзе сыйфатлана. Бу сыйфатнын анын үзенә күчүе өчен бер адәм гомере кирәк булган (шул ук нәрсәне берәр иҗтимагый формация гомеренә карата да күреп була. Мәсәлән, буржуазия башта феодализмны бәреп төшергәндә, революцион булып та, сонынннан үзенен дә шул ук дошманы фоедолизм кебек реакцион һәм ирек буучы булып калуы, инкяр иткән сыйфаты белән үзе сыйфатлануы шикелле).

Бездә барлык-юклык, яшәү-үлем шикелле нигез мәсьәләгә кагылган мәкальләр дә күп. Бер мәкальдә:—*Кин тар булмас, юк бар булмас* диелсә дә, икенчеләрендә гомумән барлык-юклык үзе дә абсолют бернәрсә итеп каралмавы, аларнын да сыйфат шикелле үк береннән-беренә күчеп торулары, яки бер-берсенә әйләнүләре, шартлы һәм мөнәсәбәтле булулары күп кенә мисалларда әйтелә:—*Синен бар булганын, минем юк булганым* дигәндә, барлык-юклыкнын бәясе сыйфат ягыннан гына карап бирелә. Үлем зарурый:—*Әҗәлгә дару юк;—Әҗәлдән акча биреп котылып булмый;—Үлем үкенечсез булмый,* ләкин анын һәлакәт һәм кайгы булуы да һәм хәтта булып-булмавы да шартлы һәм мөнәсәбәтле генә:—*Тычканга үлем, мәчегә көлке;—Былтыр үлгәнябалак быел башын күтәргән;—Бардан юк калган, юктан бар булган;—Барына шөкер, югына тәкер;—Юкка суд юк* һ. б.

Исем белән җисемнен булуы да шартлы һәм мөнәсәбәтле рәвештә генә исеме бар һәр әйбернен үзе дә булуы шарт түгел:—*Исеме бар, җисеме юк;—Аты бер булса да, заты башка;—Бай даны бар, тик чыкмаган җаны бар;—Аты олы, кабыргасы коры* һ. б. Шундый күп юллар белән мәкальләрдә нәрсәнен нәрсәлеген аеру, асылын, затын, хикмәтен белүгә ирешү килеп чыга:—*Нәрсә нәрсәгә башка;—Әйберне әйбергә катсан, заты беленер, ташны ташка чаксан, уты беленер* һ. б. Яки нәрсәләрнен сыйфатларын янәшә куеп карап, очраклы булганнары кире кагылып, гомумән әһәмиятле һәм нигез булганы гына беркетелә:—*Матурлык түйдә кирәк, мәхәббәт көн дә кирәк.* (Ягъни, чын матурлык төстә түгел, мәхәббәт—эчтәлектә.) Шулай ук яхшылык-яманлык кебек абстракт төшенчәләрне дә мәкальләр кылны кырыкка ярган кебек яралар һәм аларнын үзара да, башкалар белән дә бәйләнешле, шартлы нәрсәләр булуларын бик анык конкрет һәм кызыклы мисалларда бер-ике сүз белән ачып бирәләр:—*Кызымнын каенанасы усал, үземнен киленем усал;—Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы.* Ләкин бу әле гади яки практик яхшылык. Мона карап татар яхшылыкны гел исәп-хисап, табыш-уныш яки сәүдәгәрлек күзлегеннән генә бәяли икән дип уйларга ярамый. Юк, шул ук вакыт татар һич шартсыз һәм мәнге бетми, югалмый торган югары мәгънәдә абсолют саф изгелек бар дип тә ышана. Изгелек кешенен төп кешелеге һәм гомумән бер көч, шунын өчен дә яхшылык үз алдына да яманлыкны, әлбәттә, җинеп чыга. Шуна күрә дә чын

кеше аны бер тиенгә бер тиен өчен генә эшләми, бәлки яхшылыкның үзе өчен, аның зурлыгы һәм кешенең асыл табигате гомуми, нигезе шул булганлыгы өчен эшли:—*Яхшылык юлда калмый;—Яхшылык ит тә дингезгә ат, балык белер, балык белмәсә халык белер;—Яхшылыкка яхшылык һәр кешенең эшедер, яманлыкка яхшылык ир кешенең эшедер;—Яхшылык үлми, яманлык күмеп куелмый* һ. б.

Билгеле, монда язылганнарга карап, халык борынгыдан ук фәнни нигездә фәлсәфи яктан дөньяны тануга ирешкән, мәкальләр нәкъ шуны күрсәтә дип аңларга ярамый. Киресенчә, халык, билгеле, ул вакытларда фән һәм техника ягыннан артта булган, әллә нихәтле хорафәткә, мифләргә ышанган. Борынгы заманда кеше табигатькә кол булган һәм аннан да начаррагы—тәне, фикере белән кешегә дә кол булган, хәтта үзеннән бик күп түбән, начар, залим кеше кул астында кол булып яшәгән чаклары аз булмаган. Патриархальлек, фанатизм, фатализмнарга кереп баткан, шуннан чыга алмаган һәм шул турыдагы мәкальләр дә бездә аз түгел. Билгеле, мәкальләрнең хикмәтлеге аның бу адашу, ялгышуларында түгел. Шуларга да карамастан, татар халкы дөнья тануда тирәнгә керә һәм тормыш хикмәтен төшенә алган икән, билгеле, ул моны бернинди фән-фәлсәфә китапларыннан өйрәнмичә, бары тик үзенең тормыш тәҗрибәсеннән, ишеткән-белгәннән, нәрсәләрне таныргa өйрәнүеннән һәм шигъри төшенчәләреннән туган хикмәтләр генә. Шулай булса да, аның бу кечкенә әсәрләрендә халыкның дөньяга карашлары, аны ничек танып белүләре, алар аша ничек тормыш көен көйләп барулары бик яхшы чагыла. Аның бу тормыш танучанлыгы ни дәрәҗәдә тирән һәм үткен булса, шигъри хыялы житез булса, мәкальләрнең мәгънә һәм хикмәтлеге дә шулхәтле тирән һәм үткен була алганын күрәбез. Шул рәвешчә, мәкаль үзе дә халыкның иҗади эше, мәкальнең хикмәте дә тормыш хикмәте, фәлсәфәсе—тормыш фәлсәфәсе була. Шушы яктан караганда, Тукайның: «Халык әдип ул, шагыйрь ул, даһи ул» дигәннәре янына бер дә икеләнмичә—«хәким ул, философ ул» дип тә өстәп куярга була.

Мәкальләрнең халык хикмәте булучылыгы турында күптән әйтелеп киленсә дә, әлегә хәтле, ни өчендер, бу өлкәдә махсус язылган хезмәтләр күренми. Башка халыкларда бу бәлки бардыр? Билгеле, бу бик тирән һәм махсус өйрәнүне сорый торган мәсьәлә. Инде мин бу кереш мәкаләдә сүз уңаенда шуңа бераз кагылам икән, аны тулысынча чишәргә өстемә алуым түгел. Бу тик мәкальнең халык хикмәте дип йөртелүе юкка түгел икәнен, халык чынлап та хикмәттән буш түгел икәнен, халыкның үз иҗаты аша күрсәтергә тырышу, мәкальләрнең эчтәлеген өйрәнгәндә темаларын бәян итү белән генә чикләнмичә, эшнең бу ягы да бар икәненә бераз булса да күз салып үтү өчен генә, шулай булмаганда, мәкальгә бирелгән билгеләмәдә аның халык хикмәте дип атауның үзендә күп хикмәт юк. Аннары монда китерелгән мәкальләрнең күпләре диалектика канунчылыгы белән дә килешә торган булып чыкса, бу аларны нинди дә булса әзер схемага көчләп сыйдыру, шуңа гына кайтарып калдырырга тырышу дип аңлашылмаска тиеш. Бу әйбер мәкальләрнең үзләреннән һәм аларның ни дәрәҗәдә тормышка үтеп керә алуларыннан да килә. Күп кенә мәкальләр кире җөмлә алымнары белән төзелеп, каршылыклы бер мәгънәне җыйган бөтен фраза булганга, каршылыклар берлеге булып килеп чыкканнар. Укучы үзе андыйларны китаптан тагын да күбрәк таба алачак. Мәкальләрдә аерым фәлсәфи фикерләр күп, ләкин моңа карап, билгеле инде, аларда бөтен бер фәлсәфи караш системасын эзләп булмый. Гәрчә аерым чәчелгән мәкальләрне берәр темага җыйганда, алар, югарыда китерелгәнчә, тормышның төрле каршы якларын ачыкларга һәм халыкның тормышка карашын тулырак аңларга ярдәм итсә дә, билгеле, моңа карап, мәкальләрне бары тик диалектик материализмга әзер шәкелләмә (иллюстрация) яки ана кушымта итеп карарга ярамый. Һәм мәкальләр фәннең, фәлсәфәнең, ул ысулның положениеләре дә була алмый. Тәрбиядән килгән дини, әхлакый төшенчә һәм хөрәфәтләрдән, тормыш-көнкүрешеш тәҗрибәсеннән, гадәт-йолалардан тыш халык тормышка ниндидер фәлсәфи теория яки схемалар белән коралланып килмәгән. Мәкальләрдәге каршылыкларга килсәк, ул тормыш каршылыкларының үзендә ята. Халык үзе шул каршылыклар

эченә куелган булып, монда хикмәт анын мәкальләрендә дә шул каршылыкларның чагылу кадәрлесендә. Бу—стихияле материализм. Шунлыктан мона гажәпләнергә һич тә туры килми.

Аннары тагын мәкальләрнең хикмәтлеге эчендә, шигъри ягы тышында дип, берсен мәгънәгә, икенчесен формага гына кайтарып калдырырга ярамый. Хикмәт мәкальнең нәрсә әйтүендә генә түгел бит, ничек әйтелүендә дә! Ягъни, аның тапкыр һәм матур итеп, конкрет әйтелешендә дә.

Шулай ук мәкальләрнең хикмәтлеген аларның шигъри мисал мәгънәсеннән аерым нәрсә, абстракт рәвештә карарга ярамый. Моны шуннан да күреп була: кайбер мәкальләр бары тик мисалга яраган өчен генә гомуми мәгънәле яки хикмәтле мәкаль булып торалар. Мәсәлән:—*Кыштан соң яз булыр* дигәнне алыйк. Бу сүз михнәттән соң рәхәте булыр дигән мәгънәдә әйтелсә генә мәкаль була. Туры мәгънәсендә болай гына әйтелсә, бу бары *Сыер печән ашый* дигән кебек һәркемгә мәгълүм бер хакыйкатьне сөйләп тору гына булып, андый сүзне ел фасылларын төшенмәгән балаларга гына әйтергә мөмкин:—*Җилсез яфрак—тибрәнми;—Арканлы ат казыгына уралыр* кебек күп кенә мәкальләр үз мәгънәсендә генә әйтелсәләр, шулай ук бик гади сүзләр генә булып калырлар иде. Бу китаптан мәкальләрне шулай үзалдына бер сүз итеп кенә укучы кеше кайберләрен чыннан да бер дә хикмәтсез, буш сүзләр итеп караячак һәм ник китабына җыйган дип үпкә белдерүгә хәтле барып житәчәк. Мәсәлән:—*Тауга менәсе кыен, төшүе ансат* дигәнне шулай ук укып карыйк. Бу җөмләне чыннан да мәкаль итмичә, тауның үзенә менү-төшү турындагы бер сүз итеп кенә дә әйтеп була. Ул чагында анда хикмәт тә юк, мәгънә дә юк. Аны кем белми? Иң гади бер сүз! Әмма шуны дәрәжәгә менү һәм төшүгә карата әйтсәң, ул хикмәтле бер мисалга һәм мәкальгә әйләнә.

Кыскасы, тормыш хикмәте һәм фәлсәфәсе булу ягыннан мәкальләр күп яклы һәм үзенчәлекле. Шунлыктан бу китаптан укучы һәркем, үз аңы һәм зирәклегенә карап, үзе өчен бик мәгънәле, тирән хикмәтле һәм үз тормышында кагыйдә булырлык файдалы мәкальләрне күп табачак.

Аннары бу хакта сүз моның белән генә бетми, бәлки мәкальләрнең башка якларына бәйләнешле рәвештә, урыны чыккан саен сүзләр алда тагын күп булачак.

*Ахыры киләсе санда*

*Хәтер*

# КЕЧЕ УКМАСКА СӘЯХӘТ

## «Нинди төбәк ул бу яклар?»

Язмамны Мөхәммәт Мәһдиевнең шушы сүзләре белән башлыйм әле. Әлеге сорау аның күңеленә 1994 елда, Кече Укмаста туып, әдәбият дөньясында шактый танылу алган шагыйрь Миргазиз Укмасыйның (Зәбиров) тууына 140 ел тулган көннәрдә килгән («Казан утлары», 1994, №12). Бу төбәктән, ягъни Балык Бистәсе районыннан, гаҗәеп күп әдәбият әһелләре—күренекле шагыйрьләр, прозаиклар, драматурглар чыккан. Кайберләрен санап китик. Гасыр башындагылар һәм мәрхүмнәрдән—Мөхәммәт Гали, Миргазиз Укмасый, Сәет Шәкүров, Кадыйр Сибгатуллин; исән-сау иҗат итүче әдипләрдән Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Вакыйф Нуруллин, Әхәт Гаффар, Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет), Әхәт Сафиуллин, Рәшит Гарипов, Мансур Шиһапов, Хәлим Җәләй; яшьрәкләрдән—Мансур Шаһимәрдән, Нурулла Гариф, Фәүзия Солтан...

Мин җырларымны бик яратам, дәртен табам,
Җыр дисәләр, бар кайгымны онытып калам.
Байлыгын, акчаларын, былбылларын,
Валлаһи, кирәк түгел атын, чанаң...

- дип язган бер шигырендә М. Укмасый. Күрәсең, бу якта борынгы дәверләрдән үк рухи башлангыч матди байлыклардан күпкә өстен торадыр.

М. Мәһдиев шагыйрь Укмасый язмышы хакында уйланганда Кече Укмас халкының холкы турында кайбер нәрсәләрне теркәп калдырган. Капма-каршы фактлар алар. Беренчесе: Укмасый Сталин репрессиясенә эләгеп, кулга алынгач (ул Чистай төрмәсенә озатыла), Миргазиз аганың хатыны да авырып үлә. Ике кызы ятим кала. Ятим калган шушы ике кызны Укмас авылы җитәкчеләре урамга куып чыгаралар... Икенчесе: Укмас авылының бер миһербанлы хатыны ятимәләр—Гайшә белән Ләйләне үзенә сыендыра һәм, Миргазиз ага төрмәдән чыгып (бәхеткә каршы, ул анда бик үк озак утырмый бугай), Казанда ныклап урнашканчы, әлеге мәрхәмәтле хатын ике кызны ачтан үтерми, саклап кала...

Күренекле татар шагыйре Кадыйр Сибгатуллин туып-үскән якларны мин, әнә шулай, нәкъ М. Мәһдиев язганнардан чыгып күз алдына китердем. Бер яктан—кеше язмышына үтә битарафлык, икенчедән—рәхим-шәфкатьлек үрнәгенә ия булган кешеләр яши торган як, дип. Укмасый күп кенә шигырьләрендә, һичшиксез, үзе туып-үскән Укмас якларын, кешеләренең күңел халәтен тасвирлагандыр сыман:

Төрле якта кошлар җырлый, һава томан,
Нур тарала юаш кына, күренә урман.
Алтын тавы артыннан кояш кәлә,
Ярты карап уйный безгә, үзе поскан.

Матур, күңелләрне таңга, кояшка әйдәүче юллар бу. Иҗатчыны табигать иркәләмәсә, күңеле мөлдерәмә табигать гүзәллеге белән тулмаса, мондый юлларны язуы шикле, әлбәттә.

Безнең замандашыбыз Кадыйр Сибгатуллинның җанында туган як гүзәллеге исә илаһи хис—мәхәббәт белән бергә үрелеп, җырга әверелә:

Нурлар суга төшә сынып-сынып,
Балкып китә дулкын суларда.
Ташка бәрелеп вак тамчылар оча,
Кулын суза кызый шуларга...

Бу юллар инде К. Сибгатуллинның сиксәненче еллар башында чыккан «Авазлар» китабыннан алынды. Укмасый язган «Тан» шигыреннән соң ким дигәндә, житмеш еллар үткәч язылган. Әмма туган якка сыгыну бер, көнне һәм кешелекне уяткан тылсымлы манзара—танга табыну бер.

Күнелне әйдәкләп торучы хис—Кадыйр Сибгатуллинның туган тияге Кече Укмас якларына барып чыгарга, шагыйрь эзләреннән үтәргә адарынып яшәдем соңгы елларда. Сәбәпләрнең иң тәүгесе—аның ижатын өйрәнергә алынуым булса, әле бит тагын бер серле көч тә тарта—нинди икән ул шагыйрь туган яклар? М. Мәһдиевне уйга салган шушы хис минә да тынгылык бирми иде.

Ходайның «Амин» дигән чагына туры килгәндер теләгем, Кадыйр Сибгатуллинның вафатына биш ел тулган көннәрдә (ул 1994 елның 4 июнендә безнең арабыздан китте), шагыйрьнең соңгы еллардагы тормыш иптәше, чын мәгънәсендә ижатташ дусты, фикердәше, инде Кадыйр абый вафат булгач, аның ижади байлыгын бөртекләп туплаучы, саклаучы Фәния ханым Хамматова шылтыратып, Кече Укмас якларына жыенуларын әйтте. Бергәләп барырга килештек.

Июньнең матур иртәсендә юлга кузгалдык. Юлдашларыбызның берсе—Фәния ханымның сеңлесе, Кадыйр абыйның яраткан балдызы Нәсимә ханым, икенчесе Кадыйр абыйны шагыйрь буларак та, кеше буларак та яхшы белүче, үзе исән чакта гаилә дуслары булып яшәгән Рәйсә ханым, рульдә аның улы, студент егет Азат.

Чаллыдан чыгу белән Фәния ханым Азатка магнитофон тасмасын суза:

- Шуларны тыңлат әле, энем...

Кадыйр абыйны күмгәндә, аның кабер ташын куйганда Кече Укмас авылында тасмага яздырылган чыгышлар икән. Татарстан Язучылар берлеге житәкчелеге, район житәкчеләре, авылдашлары, Чаллыдагы каләмдәшләре сөйләгәннәрне тынлап барабыз. Һәркайсы Кадыйр Сибгатуллинның шагыйрь буларак зурлыгын, аның, һичшиксез, әдәбият тарихында урын алачагын искәртәләр, ижатын барлау, өйрәнү, халыкка житкерү мәсьәләсе һәр чыгышта телгә алына, вәгъдәләр бирелә...

Кадыйр Сибгатуллинның якташы—Яншык авылы егете, шагыйрь Мансур Шиһапов сөйли:

—Минкадыйр (тулы исеме шулай, Кадыйр Сибгатуллин—әдәби тәхәллүсе) серле кеше иде. Әле малай чактан ук мин аңа бераз сәерсенеп карый идем, аны аңларга тырыша идем. Ул башлангыч сыйныфны Кече Укмаста, жидееллык мәктәпне Яншыкта тәмамлады. Алтынчы классларда укыганда игътибар иттем—укулар тәмамлана, ул Укмаска кайтып китә, күп тә үтми—яңадан Яншык урамында күренә бу. Беркемгә бер сүз әйтми, нигә килгәнен дә белгән юк, эндәшми-тынмый йөри дә, кинәт юкка чыга. Килүендә нинидер сер бар кебек. Балык Бистәсендә, район газетасында эшләгәндә дә шушы ук хәлгә тап булдым. Мин ул чакта Татарстан Язучылар берлегендә эшли идем. Минкадыйр Казанга еш килә иде, көлемсерәп кенә исәнләшә, хәл-әхвәлләр сөйләшә, икенче карасаң—инде юкка да чыга. Нигә килгән—белми дә калам. Гел сердән генә торган кеше иде ул.

Истәлекләр агыла да агыла... Күнелдә Кадыйр Сибгатуллин шигыре янара:

Һәр тарафтан жырлар, моңнар килә,
Барысы да якын, илһамлы.
Әллә дөнья,
Әллә үзем сәер,
Аңлап бетерә алмыйм бу хәлне.

Машина Казан юлы буйлап чаба торгач, ниһаять, Балыклы Чүкәй авылы юлына борылды. Балыклы Чүкәй әлеге тарафта зур авылларның берсе. Олы юл шушы авылга кадәр генә килә.

Кадыйр Сибгатуллинның туган нигезе—Балыклы Чүкәйдә. Урта мәктәп укытучысы Илгиз Галиев бу хакта болай дип яза: «Соңгы тапкыр Б. Чүкәйдә очраштык.

—Туган йортка, Чүкәй табигатен күрергә, халык белән танышырга кайттым әле. Гажәпләнмә, мин Чүкәйдә, математика укытучысы Зәйнәп Сибгатуллина торган йортта туганмын,—диде. Минем белән саубуллашып, чишмәләрне карап кайтам дип, «Чаптырган» чишмәсенә табан китеп барды...»

«Туган жире булмаган шагыйрь буламыни? Шагыйрь булып, иң мөһим

сүзләрен туган жире турында әйтмичә, нәрсә хакында әйтсен?!»—болар инде Кадыйр Сибгатуллинның үз сүзләре.

Шагыйрьнең тормыш юлын, нәсел-нәсәбен өйрәнү шактый көч сорый кебек. Чөнки әнисе—Миңзифа апа, сөйләүләре буенча, Кече Укмаста яшьли кияүгә чыгып, бик тиз тол калган, икенче мәртәбә инде Б. Чүкәйгә, Һидиятулла исемле кешегә кияүгә чыга. Әмма озак та үтми, сугыш башлана, Һидиятулла яу кырына китеп, хәбәрсез югала. Миңзифа апа яшь сабыен—Кадыйрын кочаклап, янә Кече Укмаска, туган нигезенә кайта.

Б. Чүкәй—шактый төзек, урта мәктәпле авыл. Мәктәптә К. Сибгатуллинга багышланган почмак булдырылган, диделәр. Авылда Зәйнәп апаның (ул вафат инде) сеңлесе Хәдичә абыстай исән икән әле, аның белән бик озакка сузмыйча очрашасы иде, дигән теләк белән алга кузгалдык. Ашыгабыз шул без, ашыгабыз...

Күңелгә бик тә ошаганы—Б. Чүкәйнең зираты булды. Тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган, төзек, чиста. Яшеллеккә, чәчәкләргә төренеп утыра. Юл зират буеннан гына үтә, кошларның чыр-чуы ачык тәрәзәдән машина эченә үк керә. Үзем дә сизмәстән:

—Бу зиратта ятсаң да була...—дип куйдым.

Юл дигәннән, Балыклы Чүкәйдән Олы Укмас, Кече Укмас авылларына баручы юл каралмаган, күрсәткеч язулар юк, безнең кебек беренче мәртәбә килеп чыккан кешеләр өчен бу чын мәгънәсендә газапка әйләнә торган чакрымнар. Бигрәк тә яңгыр яуса. Безнең ашыгуыбызның бер сәбәбе дә шул иде—баш өстендә әледән-әле болытлар куера, машина тәрәзәсендә тамчылар биешеп ала. Кече Укмаска кереп тормастан, авыл башындагы зиратка юл тоттык.

... Җимерек киртәне атлап, эчкә үттек. Кадыйр Сибгатуллин каберенә куелган кызгылт таш янында гына. Соңыннан: «Кадыйр абыйның каберенә барып торабыз» дигән сүзләрне ишеткәләсәк тә, кабер тирәсенә күптәннән инде аяк басмаганнар. Шагыйрьнең баш очына утыртылган яшь нарат күтәрелеп килә. Кабер ташыннан бераз сагышлы да, көлемсерәгән сыман да кыяфәттә шагыйрьнең сурәте безгә, безнең аша әллә кайда, ерак офыкларга карап тора:

Күрми диеп кайчак уйлыйлардыр,
Кызганычка каршы, күрәм мин.
Һәрбер туган белән туа торам,
Һәрбер үлгән белән үләм мин...



*Якташ шагыйрьләр Кадыйр Сибгатуллин (уңда) һәм Әхмәт Гадел. 1977 ел.*

Каберне чистартып, Фәния ханым үзе Чаллыдан ук үстереп алып килгән чәчәкләрне утыртты.

Алга китеп булса да әйтеп узам, Кадыйр абыйның каберенә китешли тагын бер тукталдык. Бу юлы зиратка безнең белән шагыйрьнең якын туганы Гомәр абый да килде. Балык Бистәсеннән Нәсимә ханым янә дә матур гөлләр алган иде. Аны утырттык, бергәләп кабер өстен, тирәсен тәртипкә китердек.

Кече Укмас халкы фани дөнья янәшәсендә бакый дөнья да барлыгын һәрдаим тоеп, уйлап яшидер сыман. Зиратны киртәләү, коймалау мәсьәләсен озаккарак сузсалар да, фани дөньядагы туганнары ягыннан мәрхүмнәргә игътибар шактый күренә. Каберлекләр яхшылап рәшәткәләнгән, матур шатлар куелган. Кайбер тирәлекләр тимерчыбыклар белән әйләндереп алынган—боларны үз ырулары өчен алдан ук жир алып кую билгесе.

Кадыйр Сибгатуллин әнисе Миңзифа апаның аяк очында ята. Берара Гомәр абый да хискә бирелеп алды. Шагыйрьнең чистарып калган каберенә тын гына карап торганнан соң:

—Минкадыйр безнең килгәнне белеп, сөенеп ята торгандыр ул, әйеме,—диде. Куана торгандыр. Бер чакта да догадан калдырмыйбыз. Не мужет, сизмәскә. Һи, Минкадыйр бит ул!..

... Якындагы басудан арыш шавы ишетелә. Болытлар каядыр таралышып беттеләр. Зәңгәр күк. Кояш. Кошлар сайрый. Колакта Кадыйр абыйның йомшак тавышы яңгырый. Аны жилләр уйнатамы, тавыш әле якында гына ишетелә, әле ерагая. Нәкъ үзенчә, бераз ашыга төшеп, сөйләп бирергә өлгерә алмам дигән кебек, каударланып, әмма һәр сүзен ачык әйтеп шигырь укый ул:

Баш астымда яшел түшәк икән,
Юрганым да яшел икән... дим.
Кочагында ятып
Бу болынны
Төштә күреп ятам икән мин...

## «Боз белән дә кыен саубуллашу...»

Кече Укмас сиксәнләп өйдән торган авыл. Без Гомәр абый Сабиров өендә тукталдык. Әйтеп узганымча, Гомәр абый—Кадый Сибгатуллинның якын туганы. Миңзифа апа белән Гомәр абыйның әнисе бертуган.

Гомәр Сабиров төс-кыяфәткә дә, гәүдәгә дә шагыйрь туганына бик охшаган. Сөйләшүләрендәге ихласлык, дөньяның вак-төякләренә ис китмәгәнлек гел бертөсле.

—Минкадыйр миннән бер генә яшькә кече. Икебезнең дә әткәйләр сугышта ятып калдылар. Һай авыр үстек без! Бигрәк тә Минкадыйр мохтажлыкта үсте,—дип сөйли Гомәр абый.—Миңзифа апа бик тыйнак, басынкы, әрсезлек ише нәрсәне белмәде. Һидият абыйдан соң башка кияүгә дә чыкмады. Төп нигездә әби янында көн иттеләр.

Әби юмарт иде.
Ачлык елда
килеп кергәч сукыр теләнче,
елый-елый мичтән алып бирде
Соңгы алабута күмәчен.
«Бабагыз да сукыр иде,—диде,—
бу кеше дә сукыр,
жәлләдем...»

Моның өчен булачак шагыйрь әбисенә ул көнне нык үпкәләгән. Инде еллар үткәч кенә әбисенең никадәрле изге, кешелекле зат булуын төшенә, «Саклап калган әби рухыбызны, жаныбызны ялангачлыктан» дип, аңа рәхмәт әйтә.

Гомәр абый исә истәлекләрне тезә генә.

—Безне башлангыч классларда Хәят апа укытты. Исән әле, шәп укытучы иде. Минкадыйр тырыш, үжәт иде. Әйбәт укыды. Укуга хирыс булмадым, мин Хәят апаны,

Хәят апа мине интектердек шунда,—дип көлә ул.—Соңгы тапкыр 1989 елда кайтты ул. Без яңа гына шушы өйгә күченгән идек,—дип, зур, матур таш өйләренә ым кага.

Күз тимәсен, Гомәр абый, хатыны Әлфия апа белән таза, ныклы нигез корганнар. 1986 елда афәт килә—йорт җирләре нигезенә кадәр утырып яна (күршеләренә кайткан кунак малаеның казасы). Әмма җебеп, югалып калмыйлар, өр-яңадан ихата коралар. Әле һаман эшлиләр: икәүләп каршыларында гына төзелгән яңа мәчетне җыештырып, карап торалар икән.

—Хәзерге чорда авылда яшәүләре ничегрәк соң?—дип кызыксынам.—Колхоз дигәннәре кая таба бара?

—Шәп иде хәлләр,—дип, бераз уфтанып куйды Гомәр абый.—Кече Укмаста халык ипле, тырыш, эшчән. Без Яншык, Бәтке авыллары белән бер колхоз булып яшәдек. Үзгәртеп корулар башлангыч, үзбашка аерылып, күмәк хуҗалык оештырдык. Рәисебез дә үзебезнең егет, җин сызганып эшкә керешә. Авылга газ керде. Мәчет, клуб, башлангыч мәктәп тә газ белән җылытыла. Халык рәхәт яши башлаган иде. Мәчет төзедек, гомергә күперсез интегә идек. Күрәсеңме, нинди күпер салып куйдык. Акчаны да вакытында ала идек. Районга яңа житәкче килгәч, кире куштылар безне. Ну, дөрес эшләделәр инде ансы. Яншыклар, ни җирләрен сөреп бетерә алмыйлар, ни чәчеп дигәндәй. Безнекеләр ярдәмгә бардылар. Бәткене әйтәсе дә юк. Урыс бик ватылып эшләми ул, малай. Җәл, идарәне Бәткегә күчерделәр. Әйтәм бит, урыслар тәки үз сүзләрен иттеләр. Хәзер безнең егетләрсез бер эшләре дә эшләнми...—Гомәр абый янә Кадыйр абый хакында сөйли башлады.—Бездә табигать матур бит. Кара инде, ул таулар дисеңме, инеш дисеңме?! Чишмәләр шәп Кече Укмасның. Ике чишмә бар, суын эчеп туймаслык. Менә Яншыкта бер чишмә юк. Ничек яшиләр алар чишмәсез?—дип аптырый ул.—Кадыйрның шигырьләре җанга ятышлы шул. Хәер, мин аны шагыйрь итеп кенә түгел, туганым, дустым итеп сагынам. Малай чактан бергә тәгәрәшеп үстек. Соңгы кайтуында безнең өйне күреп әй шаккатты инде: «Син чын кеше бит, Гомәр,—ди.—Авылның күрке булган йорт төзеп кергәнсең. Йорт салган кеше—иң бәхетле кеше ул. Ә мин нәрсә калдырам дөньяга,—ди». Син дә эшсез тормадың Кадыйр, дип юаттым аны. Укыдың, зур шагыйрь булдың. Авылның горурлыгы бит син, дим. Шулай төн буе сөйләшеп чыктык.

Кадыйр Сибгатуллин үскән нигездә инде башка кеше йорт җиткергән. Бакчада шаулап үскән сәрби куаклары гына шагыйрьне бераз хәтерли торганнардыр. Кайчандыр Миңзифа апаларның күршесе булып яшәгән пенсионер укытучы Анна Андреевна Кутузова Кадыйр абыйның мәктәп елларын яхшы хәтерли. Сүз һаман мохтаҗлыкта, ятимлектә үткән балачак хакында.



*Кадыйр Сибгатуллинның Кече Укмас авылындагы туганнары.*
*Сулдан беренче —язма авторы Факил Сафин.*

«Еллар безнең үскәнне бик сизгер күзәтеп тордылар. Арбасына буй җитә башлагач, тормыш безне ат җигәргә өйрәтте. Ул авыр елларны ирләрчә җилкәсенә күтәргән кешеләр кемнәр булсын? Алар безнең әниләр, толлар һәм аларның балалары!» Шагыйрь балачагы турында шулай яза.

—Олы Солтан мәктәбенә җәяү йөреп укыды Минкадыйр,—дип дәвам итә Анна Андреевна.—Аркасына биштәрен аса да, егерме чакрым ераклыкка чыгып китә. Биштәрдә кечкенә икмәк була инде. Өйгә кайтса, бер минут тик тормый, киндер капчык күтәреп малларга азык юлларга чыгып китә. Безнең якта болыннар юк. Печән, салам юнәлтүе бик авыр иде.

Сүз уңаенда әйтеп китү кирәк, Олы Солтан урта мәктәбе ул чорларда районда бердәнбер татар урта мәктәп булган, дип тә ишеттем. Шуна күрәдерме, Балык Бистәсе районының татар халкына билгеле күп шәхесләре нәкъ менә Олы Солтан мәктәбен тәмамлаучылар. Анда Лаеш, Балтач, Арча районнарыннан да килеп белем алганнар. Анна Андреевнаның сүзләренә караганда Кадыйр Сибгатуллин Олы Солтанда укыганда шигырьләр яза башлаган. Шагыйрь бу хакта үзе болай яза: «Беренче шигыремне хәтерләмим. Табигый, ул беркайда да басылмагандыр. Ләкин нык ышанам, ул минем белән уйнап үскән песи баласы, урамыбыздагы каз бәбиләре, өебезнең ишек каты почмагындагы минем бишмәт итәген чәйнәп аптыраткан бозавыбыз турында булгандыр. Минем яшәвем дә, туган илем дә шуннан башланган бит.

Ә соңрак кешеләр—авылыбызның тол апалары, бик иртә ир булып житлеккән малайлары, каберләре бөтен Европа буйлап сибелгән ир-атлары турында язасы килде минем...»

Анна апага «телемне кычыттырып» торган сорауны бирәм:

—Кадыйр абыйның кечкенә чаклары турында хатирәләр сакланмаганмы күңелегездә?

—Истән чыкмый торганы берәү. Яз көне, бозлар агып беткәч, Минкадыйр иптәш малае белән инеш буена төшкән. Шул чагында алар янына авылдагы хәлле кешенең малае килеп чыккан. Кулында көлгә күмеп пешергән ике бәрәңге. Ач балаларның күзләре бәрәңгедә инде. Теге малай шарт куйган: кем инешнең теге ярына йөзеп чыга, шуңа бер бәрәңге! Башта бу эшкә иптәш малае тәвәкәлләп карый. Юк, су тәнне өтә, кире борылып чыга. Шуннан Минкадыйр тиз генә чишенеп ташлый да, язгы суга ташлана, инешне йөзеп тә чыга. Теге малай да куйган шартын төгәл үти тагын, каршы як ярга бер бәрәңге ыргыта...

Гомәр абый да, Фәния ханым да җөпләп куялар:

—Аның иң яраткан ризыгы бәрәңге иде...

Шагыйрьнең «Гамь» дигән китабында ике шигырь янәшә тора. «Бозлар» һәм «Саллар». Шул шигырьләрдәге ике строфа әлеге истәлектән соң бөтенләй янача ачылды сыман.

... Боз белән дә кыен саубуллашу,
томанланып тора күз алды.
Җанымда да, ахры, бозлар булган,
барысы да эреп кузгалды...

... Салдагылар, и-и, бәрәңге ашый—
Тозга мана-мана.
Бу җиһанның бар ләззәтен җыеп
Салмак саллар ага».

Әлеге авыр чорлар Кадыйр Сибгатуллин иҗатында аерым урын тота. Бигрәк тә «Кар шыгырдый» шигырен тетрәнеп укыйм...

Салкын өйдә ике ач бәндә без,
Икебез дә елап арыган.
Карангыда иске шәлен капшап,
Иннәренә барып сарылам...

Кече Укмас авылы китапханәчесе Кәбирә Нуриеваның да терәлеп торган күрше абыйсы—Кадыйр Сибгатуллин турында истәлекләре хәтсез. Ул бездән китаплар сорый:

—Кадыйр абыйның китапханәдә бер китабы да юк дисәң дә ярый. Чыгарыгыз китапларын, рәхәтләнеп укысын халык,—ди ул өзгәләнеп. Без инде аңа китап чыгаруның хәзерге чорда нинди эш икәнен аңлатып тормадык. Үземдә булган китапларны Кәбирә ханымга калдырып киттем.

Фәния ханымны да, юлдашларымны да борчыган мәсьәлә—ул Кече Укмаста Кадыйр Сибгатуллин музеен булдыру. Шагыйрьне җирләгәндә һәр чыгыш ясаучы шушы мәсьәләгә тукталган. Татар дөньясына ике күренекле шәхесне биргән авыл өчен бу чишә алмаслык нәрсә дә кебек түгел. Әмма халык белән сөйләшә торгач, авылны яхшылап өйрәнгәч, күңелгә: «ай-һай, монда музей ачылыр микән?»—дигән шөбһәле уйлар да килде башка. Ни өчен дигәндә, беренчедән, Кадыйр Сибгатуллинның җеназасында ук музей өчен акча кертә башлаганнар. Ул күпме суммага җыелгандыр безгә караңгы, кызганычка каршы, авыл советы рәисе белән очрашып сөйләшә алмадык, ул җирле үзидарә эшләре белән—урманга, яфрак азык хәзерләргә киткән иде. Авылдашларының әйтүләренә караганда, җыелган акча, изге эшкә—мәчет төзүгә һәм зират коймасын ныгытуга киткән икән. Мона район җитәкчеләреннән рөхсәт алынган, имеш. Әгәр дә бу чыннан да шулай булса (моңа ышанырга туры килә, чөнки шагыйрьнең вафатына 5 ел үтте инде, авылда аның истәлеген мәңгеләштерү буенча бер генә эш тә күрмәдек без). Кече Укмаста музей төзибез дип күпме акча тупласаң да, ул «ереп» бетә торачак. Авылның «тишек-тошыгы» азмыни соң? Фәния ханым авыр сулап:

—М. Укмасыйның вафатына 53 ел инде... Теләкләре булса, шул гомер эчендә әллә нәрсәләр эшләрләр иде,—дип кенә куйды.

## «Таң чишмәсе яшен коя...»

Күңелдә ике шагыйрь сөйләшүен ишетәм. М. Укмасыйның җилкенүле йөзен күз алдына китереп, шигырьләрен кабатлап, шәйләп алам:

Әй егетләр. Кочле шәүкәт—
леләр котә сезне, әнә!
Ник яшәргә, бер батыр
Йә бер даһи булмагач?!

Бу юлларны куәтләп, Кадыйр Сибгатуллинның салмак, әмма ныклы сүзләре яңгырый:

Мәнгелеккә үтеп бара торган
Кешелекнең без бер буыны.
Алып кара,
Өзеп ташлап кара
Чылбырдагы безнең урынны!

Бер авылдан ике шагыйрь, ике шәхес... Тик авылдашларыгыз сезгә карата гафләт йокысында булса кирәк. Аларның күңел күзләрен ачасы, уятасы бар әле...

... Шундый борчулы уйлар белән Балык Бистәсенә килеп кердек. Бу якларда юллар яхшы. Котлы Бөкәш ягына асфальт җәелгән. Мондый юллардан җилдерергә була, шофер егетебезнең дә йөзе ачылып китте әнә.

Балык Бистәсе борынгы заманнарда Лаеш өязенә кергән. Хәзер үзе район үзәге. Миңа ул никтер бик күркәм, иркен булып күренде. Юллар тигез, урамнар киң, кая карама—яшеллек. Йортына аз гына тузан кунса да, су алып җыештырырга тотынган, чисталык, пөхтәлек сөюче киленгә охшаган ул—урамнары киң, Чулман-суга ук сузылып төшкәннәр. Редакция дә Чулман буенда ук. Янкорма төзеп, аны шактый зур, төзек бинага әйләндергәннәр. Биек баскычлардан икенче катка күтәреләбез. Безне «Авыл офыклары» газетасы мөхәррире Вазыйх Фатыйхов каршы алды. Бүлмә тәрәзәсеннән көмештәй ялтырап, диңгездәй җәйрап Чулман күренеп тора. Вазыйхны шагыйрь буларак беләм, хөр күңелле, әйбәт хуҗа икәнлеге сизелә.

Үгезне мөгезеннән дигәндәй, Вазыйх әфәнде безне күрше бүлмәгә алып кереп китте. Кадыйр Сибгатуллин музеена нигез салынып килә икән. Шагыйрьнең шәхси документлары инде шушы бүлмәдә. Кыйммәтле экспонатлар—язучылык билеты,

паспорты, хәрби билеты, 50 яшьлегенә котлаулар...

—Кадыйр абый минем остазым иде,—дип искә ала Вазыйх.—Редакциягә килеп кергәч, ин беренче каршы алган кешем ул булды. Вафатын авыр кичердек. Әле бездә анын белән ингә-иң торып эшләгән кешеләр хезмәт итә.

Кадыйр Сибгатуллин Оргсинтез заводында электромонтер булып эшләгән жирдән, 1966 елның 8 апрелендә «Октябрь юлы» газетасына күчеп кайта. Беренче әсәрләре басылган газетага... Һәм газетада 1978 елның 20 июненә кадәр, ягъни Чаллы каласына күчеп киткәнче эшли. Газета хезмәткәрләре генә түгел, хәтта якын-тирәдә яшәүчеләр дә Кадыйр абыйны яхшы хәтерлиләр, үзе, гаиләсе, уллары хакында төпченеп сорашалар, сагынып искә алалар.

—Кадыйр Сибгатуллин исемендәге премия булдырдык,—дип сөйли Вазыйх әфәнде.—Бу премияне инде дүртенче мәртәбә тапшырдык. Иң беренче лауреат—актив хәбәрчебез М. Садыйкова булды. Икенче елны Габдрахман ага Фәйзуллинга бирдек премияне. Танылган шагыйрь Равил Фәйзуллинның әтисе ул. Дини-әхлакый тамаларга бик яхшы мәкаләләр бәйләме язды. Югары Тәгәрмәнлек авылыннан Фәнүзә Галимуллина, Балыклы Чүкәйдән Илгиз Галиев тә Кадыйр Сибгатуллин исемендәге премиянен тәүге лауреатлары.



*Кадыйр Сибгатуллинның 50 яшьлек юбилей кичәсе (1992 ел). Сулдан уңга: Тәбриз Гыймалетдинов, Илсөяр Хакова, Кадыйр Сибгатуллин, Рахмай Хисмәтуллин.*

—Премияне бөтен татар дөньясында билгеле итү буенча кайбер чаралар күреп булмыймы соң?—дип, бу хакта үз фикерләрем белән уртаклашам.

—Уйларга кирәк,—ди Вазыйх әфәнде күп сүзгә урын калдырмыйча. Гомумән, Кадыйр Сибгатуллин исемен мәнгеләштерү буенча гамәлләр кылына тора. Редакция каршысында шагыйрьнең бюстын урнаштырмакчылар икән. Сынчы Марс Ахунов эшләргә алынган.

—Район үзәгендәге яна төзелгән бер урамга Кадыйр Сибгатуллин, янә дә берсенә Миргазиз Укмасый исеме бирелде,—диде В. Фатыйхов.—Аларның эзләре сакланган жирләр бит бу...

Тагын тәрәзәгә күз төшерәм. Кояш нурларына сөенә-сөенә дулкыннар уйный. Кайчандыр Каманы Идел, Агыйдел дип тә йөрткәннәр. М. Укмасый:

Агыйделнең агым суын кичкән чакта,
Туя алмый дарьясыннан эчкән чакта,
И Ходаем, бернәрсә дә кирәк түгел,
Үз жанашым исләремә төшкән чакта,

—дип язган. Мондый шигырьләргә Галимжан Ибраһимов бик тә разый булып, «авызыннан энжеләр чәчелә»- дигән.

Хәсән Туфанны исә Кадыйр Сибгатуллинның түбәндәге юллары сокландыра:

Кама ярларыннан эзлим сине,
Дулкын өсләрендә—күләгән.
Мәхәббәтне юк диюче булса,
Андый кеше сине күрмәгән!

Шул рәвешле, ике авылдаш шагыйрьнең иҗатлары гел янәшә, бергә үрелеп барган сыман.

Әмма озаклап уйланырга форсат юк, без юл кешеләре, Вазыйх әфәнде исә эш кешесе, мөхәррирнең бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләре көтә. Безнең белән бер сәгатьләп сөйләшеп утырырга вакыт таба алуына сөенеп, рәхмәтләр әйтеп, кузгалыша башладык. Мөхәррирнең дә хатирәләрдән күңеле урыныннан купкан иде, «икенче килүегездә, һичшиксез, чәйләр эчеп, иркенләп утырырбыз»,—дип, озатып калды.

Кайтырга чыктык. Колакта Кадыйр Сибгатуллин сүзләре яңгыраган кебек: «Бүгенге чуар тормышыбызда, киләчәкнең гадел, олы җаваплы кешеләрен тәрбияләргә уйласак, шигъри сүз, моң артык микәнни? Шигырьнең дә, шагыйрьнең дә бүген бурычы бирәү генә—бөтен көчне, бөтен иҗатны кешеләрнең, бигрәк тә яшь буынның рухын тәрбияләүгә багышлау. Моннан да изге бурыч булырга мөмкин түгел».

Кече Укмаста тагын бер тукталыш ясадык. Киң күңелле Гомәр абый белән Әлфия апаларда ял итеп, сыйланып та чыктык. Урам якта капка төбендә, Гомәр абый белән сөйләшеп торабыз. Кул сузымы гына тоелган тау итәгенә сыена-сыена агып ятучы елгага күрсәтеп сорыйм:

—Гомәр абый, елгагызның исеме ничек?

Хуҗа сәерсенеп миңа төбәлде.

—Исеме юк аның... Инеш инде, инеш дибез...

—Ә чишмәләрнең исеме бармы?

—Алары да исемсез. Чишмә саен кем исем куеп йөрсен, ди?..

Тынекы гына каршы төшәм:

—Бардыр аларның исемнәре, бардыр... Миргазиз Укмасый, Кадыйр Сибгатуллин туып-үскән авылда исемсез чишмәләр була ди мени?! Хәер, бер чишмәгә Миргазиз Укмасый моннан йөз еллар элек үк, исем кушкан инде—«Таң чишмәсе» дип язган ул...

**Факил САФИН**

*

# Кадыйр Сибгатуллин

## ШАГЫЙРЬ АРХИВЫННАН

### Яши кеше

**Васыятьләрен әйтеп китәр кеше.**
**Варисына әйтер—**
**улына.**
**Бәя бирер кылган гамәленә,**
**борылып карар үткән юлына.**
**—Шөкер!—дияр,—**
**эшем төгәлләнгән—**
**ахырына кадәр башкардым;**
**ә калганын улым дәвам итәр:**

үзем исән чакта башладым.
Шулай диләр.
Шулай диелгәндер
ун ел элек,
йөз ел элек тә...
Үти алмас кеше бөтенесен
мең ел гомер белән килеп тә.
Һәрбер кеше—үзе бер дөньядыр.
Бик тирәндер кеше гаваме.
Ә шула да,
туып, яшәүнең дә,
үлемнең дә ул тик дәвамы.
Кайда башы?
Кайда ахырлары?
Гомерләргә гомер кушыла...
Шушындадыр аның көчсезлеге,
кодрәте дә аның шушында.
Дәвам гына шул без.
Дәвам булып
үтә кебек гомер әрәмгә...
Бер уйласаң,
нәрсәнеңдер бары
дәвамы бит Җир дә,
Галәм дә...
Яши кеше—
үлеменә бара,
белеп котылгысыз икәнен.
Яши кеше
йөрәгенә кысып
мәңгелекнең нәни кисәген...

## Бер уйласаң...

Тыныч булган әле табигать.
Бер кеше дә Җирдә булмаган.
Бәхетенә каршы,
ул вакытта
Җирдә әле кеше тумаган.
Кайчан туган?
Кайда туган кеше?
Бик телибез шуны белергә.
Ничә буын үзен багышлаган
шушы сергә үтеп керергә.
Ул да зарур.
Аныкларга кирәк:
кем баласы,
нинди заттан без?
Галәм биек энә,
күкләр биек,
ә үзебез кайсы каттан без?
Дөрес булмас, ләкин,
гомер итсә
бүгененә кеше уй-гамьсез.
Җир дә матур, юкса,
дөнья матур.
Әллә нәрсә генә бик ямьсез.
Без кем идек кичә?

Бүген кемнәр?
Кеше булып инде җиттекме?
Берәр ялгыш белән
әллә инде
кешедән дә узып киттекме?
Инде шактый гомер итәбез бит.
Яшәдек бит инде бу йортта.
Үлемнән дә калдык,
гомерләрне
кыл өстенә кайчак куеп та.
Тормыш!—дибез.
Карыйсың да аңа,
тирән кайгы телә бәгырьне.
Булыр кебек иде
бик тә гадел,
бик тә гүзәл,
бик тә кадерле...
Кеше!—дидек.
Бөек!—дидек аны.
Иң гүзәл зат!
Камил!
Илаһи!
Үзебезне үзебез күккә чөйдек:
Галәмнәргә киттек—
без даһи!
Шушы даһи бүген ыштан ямый.
Бөтен гаме тамак хакында.
Хәер сорап чират көтеп тора
зыялылар ишек катында.
Үзен үзе талап гомер итә
табигатьнең шушы җанвары.
Рухың тузса,
ямау салып кына
саклап булмый икән җаннарны.
Ни китерде?
Алып килде кеше?
Дөньялыктан үзе ни алды?
Кемнәр санар,
кемнәр барлар икән—
дөньялыкта безнең ни калды?
Бер сүзе юк.
Дәшми кеше бүген.
бернәрсәдә аның эше юк.
Бер уйласаң,
кеше бар да кебек...
Бер уйласаң...
һаман Кеше юк.

## Ак уйлар турында

Бик табигый булган безнең өчен:
олылар бар иде,
кечеләр...
Гел ак чәчле иде, никтер,
безгә
акыл-үгет биргән кешеләр.
Алар исән чакта

үзебезгә
узынырга ирек бирмәдек.
Ак чәчләрне акыл, зирәклеккә,
ак уй-фикерләргә тиңләдек.
Олыга да,
кечегә дә—
бердәй
иртә төшә хәзер кыраулар.
Ак чәч булып,
җавап булып чыга
җавап табалмаслык сораулар.
Безгә якын булган кануннарның
мөмкин бүген безне алдавы.
Чәчләре дә аның ап-ак булыр,
кыен булыр
үзен аңлавы.
Уйлау кирәк.
Агарсын ла чәчләр.
Яратылган башлар уйларга.
Кызганычка каршы,
чәч агара
ак уйдан да,
кара уйдан да.
Сагындыра игелекле заман:
булмас инде кире кайтулар.
Чәчтән түгел,
без танырбыз болай—
безгә таныш бит ул—
ак уйлар!

## Дога

Оныттык без сине, Хак тәгалә:
гөнаһларга батты адәмнәрең.
Ярлыкавы ансат түгелдер шул
бисмилласыз кылган гамәлләрен.

Догасыннан аерылды кеше.
Миһербанын җуйды—
савапларын...
Бәндәләргә килде авыр көннәр—
бирә инде хәзер җавапларын.

Дөнья тулды угры-карак белән.
Иялнде яман ришвәт,
фәхеш...
Адәм бүген таныр хәлдә түгел—
үзе сәрхүш,
балалары сәрхүш...

Кая баксаң—
ага кеше каны.
Кая баксаң—
тагын ятим бала.
Кешеләрең генә түгел, Хода,
халыкларың ирсез,
ятим кала.

**Кулын сала якын кардәшенә—
туган, дими,
гүя мөэмин түгел.
Имансызлар артты, шәфкатьсезләр...
Болай яшәү, Хода, мөмкин түгел.**

**Кичер безне!
Борыл безгә таба.
Туктата күр безнең вәхшилекне.
Соңгы өмет синдә.
Тик син генә
коткарырсың безне—кешелекне!**

**Кодрәтләрен ал син явызларның.
Коткара күр безне угрылардан.
Бир син безгә кабат
көч һәм куәт—
бар бит әле Җирдә тугры балаң.**

**Үзебезгә хуҗа була алмадык—
без яңадан синең колың булыйк.
Алла сүзе керсен адәмнәргә—
без яңадан синең улың булыйк.**

**Комсызларның тый син нәфесләрен,
хәрәм азык бирмә бирәннәргә.
Мәрхәмәтле бул син разыйларга—
биргәнеңә шөкер дигәннәргә.**

**Оятсызны, зинһар, узындырма.
Бирмә ирек артык әрсезләргә.
Тыйнак җаннар шактый кыйналдылар—
сихәт кирәк хәзер хәлсезләргә.**

**Гөнаһларны безнең кичерә күр.
Алдык бугай инде җәзаларын...
Син күрсәтмә инде яңаларын
без күрмәгән бәла-казаларның.**

**Шунысын да сорыйм синнән, Хода:
тигезләп үк тәмам бетермә син.
Кеше итеп үзең яраткансың—
мескен итеп аны үтермә син.**

**Дөньялыкның кырыс кануннары
канатларны безнең каермакчы.
Иң заруры—
илгә Иман кирәк!
Изге Иманыңнан аермачы.**

**Какшамасын өмет!
Кодрәт кирәк.
Вакыт җитте безгә уяныргa.
Хак тәгалә!
Коткар җаныбызны:
ярдәм ит син безгә
инаныргa!**

**Барып җитсен иде сиңа, берүк,
кабул булсын иде шушы догам.
Башларымны күккә бәрә-бәрә
сорыйм синнән,
сорыйм синнән, Ходам!**

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Кешелек җәмгыяте өчен гаять мәгънәле дата—2000 нче ел якынлашып килә. Бу дата тормышыбызның төрле тармаклары турында житди уйлануларга этәрә, үткән чорга нәтиҗәләр ясауны, киләчәк елларга күз салуны сорый.

Шул уңайдан "Казан утлары" журналы редакциясе язучыларга һәм киң катлам укучыларга, әдәбият сөючеләргә гасырыбызны йомгаклаучы туксанынчы еллар әдәбияты турында түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:

**—Соңгы ун-унбиш елда басылган кайсы әсәрләрне (проза, поэзия, драматургия, публицистика) әдәбиятыбыз казанышы дип саныйсыз? Ни өчен?**

**—Сезнеңчә, туксанынчы еллар татар әдәбиятында нинди уңай сыйфатлар бар? Ә кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырга Сез кайсы әсәрләрне алып керер идегез һәм татар әдәбиятында нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?**

**—Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда ничек итеп күз алдына китерәсез?**

### Фаяз Дунай:

Яна гасыр бусагасында торганда «Казан утлары» журналының язучыларга һәм киң катлау укучыларга житди сораулар белән мөрәҗәгать итүе, әлбәттә, бик тә табигый хәл, фарыз һәм зарур шөгыль. Сораулар исә әдәбиятыбызның туксанынчы еллардагы йомгакларына бәя биреп, аның киләчәге турында кайгырту белән сугарылган.

Шәхсән минем үземне туксанынчы елларда шатландырган, мине яңа эшләргә, иҗади уйлануларга, шактый кыю хәрәкәт-гамәлләргә рухландырган, канатландырган әдәби әсәрләр, шөкер, рус әдәбиятында да, безнең татар әдәбиятында да аз булмады. Мин дә аларны бәйнә-бәйнә санап китә алыр идем, алар хакында үз хөкемнәремне дә әйтеп уза алыр идем. Минем дә хәтеремдә, күңелемдә «Менә мондый-мондый әсәрләрне яңа гасырга да алып чыксак—һай, шәп булыр иде!»—дигән ышанычлы, якты теләкләр бар. Әмма жанымдагы бер хис—курку һәм шомлану хисе мине болай бәян итүләрдән тотып-тоткарлап калды шул, әй, җәмәгать...

Шәт, күбәүләр беләләрдер: мин гомерем буе тормыш фронтларының алгы сызыкларында яшим, халык арасында яшим, күп төрле һөнәр ияләре белән якыннан аралашып яшим. Ходай рәнҗүе төштеме, белмим, Иблис-ләгънәт биздердеме: безнең халык, безнең ул һөнәр ияләребез соңгы дистә елларда матур әдәбият әсәрләрен бик тә аз укый башлады лабаса! Табибларны, инженерларны, пешекчеләрне яки сурәт төшерүчеләрне әйтмим дә мин, хәтта әдәбият-тел укытучыларның да бик күбесе роман, поэмалар димим, ел буена берәр хикәя-парча яки шигырь, мәсәл

укып чыкмаган бит! Көл дә, ела... Уелып уйлаган кешегә сәбәпләре аңлашыла: илдә-көндә соңгы дистә еллардагы сәяси тотрыксызлык һәм бик кискен икътисади кризислар халыкның мәдәни ихтыяҗына, зыялы зиһененә китереп сукты. Ул көн итү, җан асрау михнәт-нужалары белән йөгерә башлады. Бу урында милли каһарманыбыз Мирсәет Солтангалиевнең сүзләре белән дә фикеремне ныгытыйм әле. Галимҗан Ибраһимовның «тел культураны билгели» һәм «тел—культура коралы» дигән формуласына каршы килеп, Мирсәет болай дип язган: «Я выступил с решительным возражением против этой формулы и вскрыл всю несуразность, идеалистичность и лживость этой формулы и противопоставил ей другую формулу диалектическую, а именно: «Культуру определяет экономика, а язык является лишь надстройкой экономической базы». Исходя из этого принципа я выставил положение, что «национальную культуру... можно создавать и развивать лишь на основе «национальной» экономики в широком смысле этого слова».

Зиһенле кеше аңлагандыр, шаять—халкыбызның матур әдәбияттан, калын-юка китаплардан бизүе, газит-журналларга языла алмавы, димәк, аларны укып бара алмавы, язылган басмаларның да почта ящикләребездән урлануы, язган әсәрләребезне бастырып чыгара алмый интегүләребез, болар барысы да безнең икътисади-финанс кытлыгы кичерүебез белән бик нык бәйләнгән. Көн итү ихтыяҗыбыз интеллектуаль ихтыяҗларыбызны тоткарлый хәзер безнең. Димәк, матур әдәбиятыбыз, телебез дә олы, кыю адымнар белән алга барсын дисәк, без иң әүвәл милли экономикабызны җайга салырга, аны ай саен, ел саен үстерә, баета барырга тиешбез. Бары шул шартларда гына халык безнең әсәрләрне укыр һәм сатып алыр.

Өметсез—шайтан гына, ди. Әйдәгез, яңа гасырга ышаныйк, олы, якты өметләр баглыйк аңа.

## Илһам Фәттахов:

**Казан дәүләт университеты аспиранты**

**1**. Соңгы ун-унбиш елда татар әдәбиятында сан ягыннан тыш зур сыйфат үзгәрешләре дә булды. Соцреализм методы богауларыннан тулысынча азат милли прозабызның күренекле повесть-романнарын укып заман укучысы бик сөенде.

Аерым алганда, повесть жанры житмешенче һәм сиксәненче еллардагы кебек бүген дә актив. Шулай да... Аз гына арифметика белән шөгыльләнеп алыйк. Ул елларда ел саен ун-унбиш повесть язылган. Аларны алтмыштан күбрәк әдип иҗат иткән. Бүген саннар башка: 1995 елда «Казан утлары»нда барысы сигез повесть басылган. 1996 елны өч, ә 1997 дә фәкать 2 генә. Әйе, 1996-1997 еллар—безнең прозада романнар елы булды.

Ә менә 1998 елда «Казан утлары»нда ун повесть дөнья күргән. Димәк, элекке еллар күрсәткече кире кайта.

Повестьны әдәбиятыбыз аксакаллары да, урта буын да, башлап иҗат итүчеләр дә ярата.

Соңгы 15 елда прозада иң актив иҗат итүче һәм еш басылучы язучыларның берсе мәрхүм халык язучысы М. Мәһдиев (авыр туфрагы җинел булсын) иде. Егерменче йөз татар әдәбияты тарихына Мөхәммәт Мәһдиев дигән классик әдип кереп калды. 1981 елда «Казан утлары» оештырган «Проблемаларның үзәгендә—кеше. Әдәбиятта яңалык тойгысы» исемле дискуссиядә катнашып: «Кайчан безнең китапларыбызны, Айтматов китаплары кебек, чиратка язылып укырлар икән»,—дип әйткән М. Мәһдиевнең инде бүгенге үз әсәрләрен китапханәләрдә чиратка язылып укыйлар. 1990 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган бу әдип иҗаты—әдәбиятыбызның олы казанышы.

Язучыны заман тудыра. Моны халык язучысы Аяз Гыйләҗев үз иҗаты белән тагын бер тапкыр исбатлады. А. Гыйләҗевнын илле еллык илһамлы иҗатын әгәр игътибар белән күздән кичерсәк, аның барлык әсәрләренә ике хис—мәхәббәт һәм нәфрәт хас. Игелекле кешеләргә олы мәхәббәтен яшерми, гаделсезлеккә ачы нәфрәтен белдерә әдип. Соңгы елларда иҗат иткән, авторның шәхси тормышына—төрмәдә уздырган елларга багышланган»—Йәгез, бер дога» роман-истәлеге һәм «Яра» повесте А. Гыйләҗевның иҗат кыйбласын тагын да тирәнрәк ачты.

А. Гыйләжевны язучы итеп таныткан «Өч аршын жир» повесте (1962) белән 1992 елда язылган «Яра» арасында утыз ел вакыт узган. Шул ук вакытта ике әсәрдә уртаклык күрергә дә мөмкин: автор, үз гадәтенчә, гади кешеләр язмышына игътибарлы, аларның рухи дөньясына үтеп керергә омтыла. Ләкин кабатланмый һәм «Яра»да әдип тормышны сурәтләүнең яңа үзенчәлекләрен таба. Беренчедән, бу Габдулланың үлемсезлегендә күренә. Ул ничек кенә яраланмасын, мифик герой кебек исән кала. Габдулла яшәргә тиеш, чөнки ул язучыга кирәк! Чынлыкта моңа ышануы кыен, әлбәттә. Ләкин әдәби әсәр буларак ышанабыз. Антик әдәбияттан килә торган тану-танымау мәсьәләсе килеп чыга. Яраланып кайткач аны әти-әнисе танымый, ә сөйгәне таный. Икенчедән, бу мәхәббәтнең илаһи көче дигән сүз. Мондый мәхәббәт дастаннарда, романтик әдәбиятта гына була.

А. Гыйләжев—оста психолог. «Яра» әсәрендә әти-әнисенең Габдулланы көтүе, Зәйтүнәнең сагышы, илдәге кара атмосфера, шәхес культы котырган чор тирән психологик анализ аша тасвирлана.

«Яра»—тел-стиль ягыннан да заманча әсәр. Язучы табигать сурәтен, чишмә буйларының матурлыгын илһамланып сурәтли. Кыскасы, «Яра» әсәре—соңгы еллар татар повестенең бер казанышы.

Халык язучысы Гариф Ахунов та повесть жанрында җан-фәрманга эшли. «Өйрәнүнең иге дә, чиге дә, ояты да юк»,—дигән әйтем бар. Гариф ага өчен бу сүзләр тормыш, иҗат кредосы булып тора. 1969-1987 еллардагы совет сәүдә системасын, кибетчеләр тормышын, универмаг директорларының хәйләкәр эшгамәлләрен сурәтләгән һәм бүгенге көнгә аваздаш «Акча күктән яумый», 1991-1992 елларда язган «Тимерханның яшьлеге» повестлары белән укучының күңелен яулап алган иде инде. «Казан утлары»ның 1996 елгы 6 санында «Тимерханның авыл юллары» дигән документаль повестьны укып татар укучысы тагын да куанды. «Кеше гомере нинди генә вакыйгаларны сыйдырмый!»—ди автор. Чыннан да, без Тимерхан Борһановның ятимлектә үсүен дә, авыр сугыш юлларын узуын да, житәкчелектәге һәм гаиләсендәге тормышын да әлеге ике повестьтан укып белдек. Г. Ахунов «Тимерханның атылган наркомнарны эзләве» дигән өченче повестен да укучы игътибарына тәкъдим итте. «Татар китабы» нәшрияты быел бу повестларны аерым китап итеп чыгарды.

Повесть жанрының документаль төрендә эшләргә ярата бүгенге прозаиклар. Аларда чын мәгънәсендә тормыш, чынбарлыктагы кешеләр сурәтләнә. Андый повестьлар йөгерек, мавыктыргыч тел белән язылган. Шуңа да укучы ярата. Биредә туксанынчы еллар матбугатында исеме аеруча еш күренгән язучы Радик Фәизовның «Узган гомер—янган күмер» документаль повестен атамый мөмкин түгел.

Тарихи повесть төренә мөрәҗәгать иткән язучылардан Вахит Имамов аерым урын алып тора. Сүз биредә аның «Сәет батыр»ы турында. Төп тема—татар-башкорт халыкларының азатлык көрәшен сурәтләү. Мина калса, бу әсәр хәзер, Башкортстандагы, анда яшәүче 1 млн. ярым татарның мәнфәгатьләрен санга сукмаган дәүләт телләре турында Канун кабул ителгәч тагын да актуаль яңгырый. Чөнки бүген гасырлар буена милли азатлык өчен бергә көрәшкән татар белән башкортны ясалма рәвештә аерып куйдылар.

Ринат Мөхәммәдиевнең соңгы елларда укучылар яратып кабул иткән һәм кат-кат китап булып басылган «Ак кыялар турында хыял», «Истәлек өчен—Гыйлемханга» повестьларын, «Сират күпере» романын сүз сәнгатебезнең өлгергән җимешләре дип беләбез.

Мажаралы повесть өлкәсендә ин-ин актив эшләүче—ул Нәбирә Гыйматдинова. «Алан уртасында ялгыз йорт» (1984), «Ут күбәләге» (1987), «Ханым-солтаным» (1988), «Каракош», «Сихерче» кебек повестьлары белән ук беренчелекне үз кулына алган бу язучының «Кыргый» исемле җыентыгы кулдан-кулга йөртеп укылды. «Елның популяр әсәре» сериясендә катнашып 1996 елның иң күп укылган әсәре булды.

Сатирик повестьның казанышы дип Марат Әмирханның «Дөя муены» әсәрен саныйм.

Шулай итеп, бүгенге прозада повесть жанры үз позицияләрендә нык тора, аның барлык төрләре диярлек үсештә.

Роман жанрында Айдар Хәлимнең «Татар вакыты» әсәре чын мәгънәсендә

тетрәндерде. Ул милләтебезнең чуар дөньясын аңларга, яңача фикерләргә өйрәнергә ярдәм итә.

Безнең халыкны үткәндәге хаталарны кабатламаска, сабак алырга чакыручы һәм коллык психологиясендә тәрбияләнгән татарның милли аңын үстерүче әсәрләр булуына ихластан шатланам. Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар», Батулланың «Сөембикә», Ф. Латыйфиның «Хыянәт», М. Хәбибуллинның «Иван Грозный һәм Сөембикә-ханбикә» романнары бу юнәлештә гаҗәеп файда китерделәр.

Публицистикада Фәүзия Бәйрәмова кебек укучыны тетрәндереп язучылар аз. Аның «Үтерелгән пәйгамбәр» мәкаләсен укыганда күздән яшь тама, бугазга төер утыра. Рифә Рахман язмалары да көчле тәэсир калдыра.

Драматургиядә Зөлфәт Хәкимнең «Кишер басуы», Туфан Миңнуллинның «Гөргери кияүләре», «Сөяркә» пьесалары соңгы елларның иң кызыклы ачышларыннан булды.

Шигъриятебезнең дә иң гүзәл казанышларын әйтеп үтәсем килә. Бу елларда милли шигърият күгендәге йолдызлар яктырак яна башлады, минемчә. Р. Харисның «Бүре күзе» поэмасында заман сулышын тойдым. Автор татар һәм чечен әдәбиятлары арасындагы бәйләнешләрне ныгытты. Әхмәт Рәшитнең «Сөембикә», «Колшәриф», «Мөхәммәдьяр» поэмалары тарихи фикерләве, үткәннең фаҗигасын ачу, сурәтләү чаралары ягыннан хәзерге татар поэзиясенең казанышы. Р. Фәйзуллин иҗаты үз триумфына житте. Н. Гамбәр хаклы язганча: аның соңгы елларда чыккан дүрт томлыгын 20 гасырның соңгы чирегендәге әдәбиятыбызның үзенчә бер шаһитнамәсе, әдип кузаллавындагы бер елъязмасы дип бәяләп була» *(«Мәгариф» журналы.—1999—№ 7.—23 б.)*.

Р. Гаташ—мәхәббәт җырчысы булып балкучы йолдыз. Ул татар шигъриятен яна, яхшы күпер салып көнчыгыш әдәбиятына тоташтырган шагыйрь. Илһам чыганагы аңа Шәрыктан килә.

Халык шагыйрьләре Г. Афзал Ш. Галиев, И. Юзеев шигырьләрендәге тапкырлыкка, эчке мәгънәгә, сурәтләү чараларына, сүз куәсенә, фикер тирәнлегенә сокланам. Ф. Яруллинның шигърияте («Серле дөнья», «Жан авазы», «Көзге моң» жыентыклары) укыган саен язмышы кебек тетрәндерә. Р. Миңнуллинның «Китеп барам көләч җәйдән», Зөлфәтнең «Жирнең йөрәгенә юллар якын», М. Әгъләмнең «Ярты гасыр гомер акты...», Э. Шәрифуллинаның «Толлар жаны» дигән шигырь тәлгәшләре, Ж. Дәрзаманның «Моңнар фәрештәсе» поэмасы җанга тынычлык бирми, димәк, безнең шагыйрьләр кеше күңелен тетрәтә беләләр.

**2.** Минемчә, туксанынчы еллар әдәбиятында уңай сыйфатлар түбәндәгеләр:

*а)* Гаяз Исхакый мирасын кире кайтару;

*б)* Социализмнан котылып, чын иҗат ирекгә алу—тәнкыйди реализм белән коралланган цензурасыз әдәбият барлыкка килү;

*в)* Милли патриотизм тәрбияләүче әсәрләр язылу;

*г)* Халкыбызның таркаулыгын, бердәм булмавын курыкмыйча сурәтләү.

Ошап житмәгән яклар да бар, әлбәттә. Мәсәлән:

*а)* Татарстан язучыларының иҗат йорты һаман да юк. Татар язучысы кемнән ким?! Ни өчен безнең әдипләргә уңай шартлар тудырылмый?

*б)* Башлап иҗат итүче яшьләрне матбугатта кысу сизелә: йә журналлар хикәянә урын бирмиләр, йә газитләр язмаңны бастырмый. Кәефеңне күтәрер өчен берничә юлын гына бассалар да ярый бит! Өлкән абзыйларны болай да яхшы беләбез, ә менә безне белмиләр. Яшьләргә игътибарны сүздә генә түгел, ә чынбарлыкта арттырасы иде!

*в)* «Дөнья авыр» дип зарланучыларның монологлары туйдырды. Әдипнең тормышын иҗат өчен көрәш дип аңлыйм мин. Мәсәлән, Х. Туфан, И. Салахов, М. Мәһдиев h. б.лар иҗатлары. Казаныш саналырдай әсәрләр тормыш авыр чакта, кризис чорында язылалар. Зарланучы язучыларга «Жаныңның ваклыгын сылтама заманга!» дигән шигъри юллар белән җавап бирәсе килә.

**3.** Татар әдибе егерме беренче гасырда бернинди сәяси партиягә дә кермәгән, бары тик халыкка хезмәт итүче милләт сакчысы гына булсын иде. Илдә сәяси режим алышынган очракта да (әйтик, хакимиятка коммунистлар кабат килгәндә дә) намуслы язучы намусына тугры калып, татар халкының азатлыгы, милли идея өчен көрәшергә тиеш дип саныйм. Калганын ВАКЫТ галиҗанәпләре күрсәтер.

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Вахит Юныс

## «КЫЗЫЛ КХМЕР»

*1998 елның 15 апрелендә Кампучия һәм Таиланд чигендәге джунглида, үзенең яшерен оясында Пол Пот вафат булды. Дөнья әле белмәгән-күрмәгән яңа җәмгыять кору елларында үз иленең 30 процентка якын кешесен үтергән бу юлбашчы турында дөнья матбугаты күп шаулады. Кампучия һәм башка бик күп илләр аны Халыкара трибуналда хөкем итүне таләп иттеләр. Ләкин теге дөньяда кануннар башкача, диләр...*

*Пол Потның хыялы—иң гадел, иң дөрес җәмгыять—коммунизм төзү булды. Хәзер инде нигезле йомгак ясау өчен җитәрлек тарихи материал бар. Төрле илләрдә төрле юлбашчылар, коммунизмны үзләренчә аңлап, ил җәмгыятен үзләренчә төзәргә тырыштылар: Сталин һәм Хрущев, Андропов һәм Горбачев, Мао Цзе-дун һәм Хо Ши Мин, Хонеккер һәм Тольятти, Ракоши һәм Гомулка, Чаушеску һәм Кадар, Ким Ир Сен һәм Кастро... Бер генә илгә дә алар рухи азатлык һәм муллык-байлык китерә алмадылар, ә бәхетсезлек, үлем күп булды. Кешелекне тетрәткән иң зур вәхшилекләр эшләүче Пол Пот хөкүмәте булды. Кампучияне барып күргән һәм элек тә ул турыда язган кеше буларак, минем үз фикеремне белдерәсем килә.*

### Пол Потның яшьлеге

УЛ 1925 елны Пном Пень шәһәреннән төньяктагы авылда 9 балалы Пен Салот исемле бай крестиән гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Аның чын исеме—Салот Сар, ә Пол Пот исемен ул партиядә эшли башлагач, Сталиннан үрнәк алып, үзенә тага.

Аның зур абыйсы Пном Пеньдә король сараенда клерк булып эшләгәнгә күрә, әтисе 6 яшьлек улын башкалага абыйсы янына илтеп калдыра. Пол Пот иң элек буддист монастырендә, аннан соң башлангыч мәктәптә (7 ел) укый, тик имтиханнарын бирә алмаганга, урта мәктәпкә керә алмый, агач эшкәртү мәктәбен бетерә.

1945 елда абыйсы ярдәме белән аны Франциягә, Парижга радиотехнология буенча укырга җибәрәләр. Уку һәм стипендия расходларын король хөкүмәте түли. 3 ел Парижда укыганда, ул француз коммунистлары белән якынлаша, Сон Сен, Иенг Сари һәм башкалар белән Кхмер («кызыл кхмерлар») компаниясен төзи.

Пол Пот лекцияләргә йөрми, күп вакытын партия эшенә һәм Сталин томнарын (французча) укырга сарыф итә. 1948 ел ахырында ул Кхмер король династиясен бик нык сүккән-таптаган трактатын Париж коммунистлары гәзитәсендә бастыра. Шуннан соң Нородом

Сианук хөкүмәте аңа стипендия түләүдән туктый һәм иленә кайтарта.

Пол Пот тулысынча «идән астында» революциягә хәзерлек башлый, үзеннән 1 яшькә өлкән укытучы, «кызыл кхмер» Кхиу Поннарига өйләнә.

Ә тарих үз юлын дәвам итә. 1954 елда Женева конвенциясе нигезендә Кампучия Франциядән бәйсезлек ала. Нородом Сианук үзенең корольлегеннән баш тарта, илдә беренче гомуми сайлаулар үткәреп, анда җиңеп чыга һәм дәүләт башлыгына әйләнә. Илдә амнистияләр һәм күп кенә демократик ирек игълан ителә.



*Пол Пот джунглида. 1979 ел.*

1960 елда Пном Пень тимер юл депосында кызыл кхмерлар җыелып, бөтен коммунист группаларын берләштерәләр һәм зур «Кхмер эшчеләр партиясен» төзиләр. Үзләрен Хо Ши Минның «Һиндокытай Коммунистлар партиясеннән» мөстәкыйль дип игълан итәләр. 1962 елда Пол Пот партияне үзе җитәкли башлый.

1963 елда ул Вьетнамга кача, анда Сон Сен һәм Иенг Сари белән коралллы восстаниегә хәзерлек башлый. Вьетнамнан Кытайга барып, бик җентекләп андагы «Культура революцияс»е теориясен һәм практикасын өйрәнә, Мао белән таныша һәм катгый рәвештә үз партиясен сталинизм һәм маоизм юлыннан илтергә ант итә. Кампучия джунглиларында Кытай ярдәме белән коралллы отрядлар төзи башлый. 1970 елда коралллы «кызыл кхмерлар»ның саны 3000гә җитә.

Нородом Сианукның Хо Ши Мин белән мөнәсәбәте яхшыра һәм Сианук Төньяк Вьетнамнан Көньяк Вьетнам партизаннарына коралллы Кампучия джунглилары аша ташуны күрмәмешкә салыша.

Ә Көньяк Вьетнамда гаскәр тоткан АКШка бу хәл бөтенләй ошамый. 1970 елда Сианук чит илләргә дәүләт визиты белән киткәч, АКШ яклы кхмерлар Нородом Сианукны дәүләт башлыгы урыныннан төшереп, аның урынына Сианукның премьер-министрын—АКШ яклы генерал Лон Нолны утырталар.

Моңа чиктән тыш нәфрәтләнгән Нородом Сианук «кызыл кхмерлар» белән союзга керә һәм асылда илдә гражданнар сугышы башлана. Күп провинцияләр Сианукны һәм «кызылларны» яклыйлар. Пол Потның джунгли армиясе 70 меңгә җитә һәм 1975 елның 17 апрелендә бу армия тантаналы рәвештә Пном Пеньга керә. Бу Хо Ши Мин армиясе Сайгонны алганнан соң 2 атна элек була. Пол Пот—гасыр башлыгы, сәяси юлбашчы һәм стратег, кхмер халкы герое. АКШ Вьетнамда да, Кампучияда да оттырды, җиңелде...

## «Иң гадел һәм бәхетле» җәмгыять төзү

АКШ ЯКЛЫЛАРНЫ җиңүдә ярдәм иткән өчен Нородом Сианукны башта, «титульный президент» итеп билгелиләр, ләкин асылда үз сараеның берсендә йорт сак астында тоткын итеп тоталар. Аның бер сүзе дә ишетелми. Бик күп тапкыр үтенгәннән соң, аңа Кытайга (Франциягә түгел) китәргә рөхсәт бирәләр һәм Кхиу Самфанны президент итеп утырталар.

Ләкин хәрби сәяси, партия һәм дәүләт хакимияте—Пол Пот кулында. Аның һәр авазы—закон. Һәм әле кешелек дөньясы күрмәгән яңа җәмгыять төзү башлана.

3 миллион кеше яшәгән Пном Пень шәһәре бөтенләй бушап кала. «7 миллионлы халыкның нигә 3 миллионы башкалада яшәргә тиеш?! Барысын да авылларга куарга, барысын да эшләтергә!!»—ди

Пол Пот. Бер аягы гүрдәге картлар, чирлеләр, йөкле хатыннар, гариплар, яңа туган балалар,—барысы да авылларга эшләргә озатыла. Мәктәпләр, шифаханәләр, китапханәләр ябыла. Базар-кибет, банклар, кунакханәләр, төрле дәүләт оешмалары, судлар, институтлар, фәнни үзәкләр барысы да юк ителә. Сәүдә итү тыела. Барысы да—авылга, җирдә эшләргә! Болай да аз булган завод-фабрикаларның бик азы гына исән кала. Кайберләре корал ясарга һәм төзәтергә кирәк булачак...

Акчаны «кешеләрне боза торган агу» дип игълан итәләр, аны урамнарга тау-тау өеп яндыралар. Китап өемнәре дә шулай яна. Әз калган типографияләр Мао Цзе-дунның һәм Пол Потның «иң кадерле өйрәтүләрен» басып, бөтен исән калган халыкка бушлай тараталар.

Авылга эшкә китәргә теләмәгән кхмерлар шундук атып үтерелә. Элекке буржуйлар, банкир, сәүдәгәр, Лон Нолга хезмәт иткән чиновниклар, хәрбиләр атыла. Укытучылар, табиблар, фән эшчеләре кирәк түгел, бу вазыйфаларны партия оешмалары һәм «АҢКАР» хәрби отрядлары үтәячәк.

Авылларда ир хатыннан, ата-ана баладан, туган туганнан аерылып яши, барысы да казарма кебек тулай торакларда йоклыйлар, 16 сәгать эшлиләр, барысы да бергә җыелып, коммуна ашханәсендә бераз дөге һәм яшелчә белән соя бурдасы ашыйлар. Коммуна шулай булырга тиеш! Тырышып эшләгән кеше чирләргә тиеш түгел. Дару юк, дәвалау юк. 20 меңнән артык больницаларда чирләп яткан авырулар да (хәтта инвалидлар колясkaларында) авылга эшләргә куыла. Меңләгән, йөз меңләгән кешеләр ачлыктан, чирдән, авыр эштән вафат була. Төп дин булган буддизм юк ителә. Ислам дине тоткан Чам мөслим кешеләренең күбесе атыла, юк ителә. «Чиста» Кампучиядә башка телдә сөйләшмәскә, башка гореф-гадәт тотмаска, тик «кызыл кхмерларча» гына яшәргә!!.

Кампучиянең бөтен чикләре ябыла, беркемгә дә чит илгә чыгарга һәм чит ил кешеләренә Кампучиягә керергә рөхсәт ителми. Буш Пном Пеньдә берничә «дус илнең» илчелеге генә кала, аларның дипломатлары да һәр хәрәкәтләре өчен рөхсәт алырга тиеш булалар.

Халык чын-чыннан колларга әйләнә. Ял көне, бәйрәм, мәхәббәт, туй, музыка, театр, кино, концерт һ. б. ш. кебек «кеше алдый торган» нәрсәләр юкка чыгарыла. Авылларда бөтен кеше коралланган «АҢКАР» хәрбиләре чолганышында эшкә бара, эшли, эштән кайта, коммуна казармаларына кереп йоклый. Кемгә һәм кайчан өйләнү—партия кулында. Балалар үзләренең ата-аналары (аларны күргәндә) сөйләгән сүзләрне атна саен җитәкчеләргә җиткерергә тиешләр. Каршы сүз әйткән һәм ризасызлык белдергән кешеләрне үтерәләр, яисә пуля саклау өчен тереләй күмәләр, крокодилларга ыргытып ашаталар, берничә «АҢКАР» гаепләне һавага ыргытып, башкалары күтәргән штыклар өстенә төшерәләр. Нәтиҗәдә, «кызыл кхмерлар» илдәге 7 миллион кешенең якынча 2 миллионын теге дөньяга озаталар...

Кул көче белән (механизация дигән нәрсә юк) джунглилар чистартып, дөге утыртырлык җир ясау, каналлар казу һәм җир эшкәртү елдан-ел азрак азык бирә, икътисад асылда бөтенләй җимерелә. Халыкның эчке нәфрәте үсә бара. Пол Пот моңа «халык дошманнарын» гаепли, меңләгән кешеләр (шул исәптән «кызыл кхмерларның күпләре) митинглар алдында атыла-асыла.

Матур утопия урынына илгә җәһәннәм килә...

## Пол Потны бәреп төшерү

БУЛДЫРА алган кхмерлар (хәтта «кызыллары»да) джунглидагы чикләр аша Вьетнамга кача башлыйлар. 1989 ел ахырында шундый бер төркем качкач, Пол Пот Вьетнамга гаскәр җибәрә һәм Вьетнамның

бер кисәк җирен үзенә алырга карар кыла. Моңа җавап итеп, берләшкән Вьетнам гаскәрләре 1978 елның 25 декабрендә чикне үтеп, Кампучиягә бәреп керәләр, 2 атнадан Пном Пеньны һәм илнең күп өлешен яулап алалар. Пол Потның хөкүмәтен бәреп төшерәләр һәм аның урынына Хун Сенны куялар. Хун Сен үзе дә кайчандыр «кызыл кхмер» булган, ләкин Пол Пот белән араны өзеп, Вьетнамга качкан кеше. Хәзер Хун Сен—Пол Потка һәм Кытай ысулындагы коммуналарга һәм халыкны репрессияләүгә каршы. Ул Вьетнамдагы яисә СССРдагы «дөрес һәм гадел коммунизм» төзү ягында.

Күргәнебезчә, бу регионда түгелгән каннарның төп сәбәбен 3 бөек держава сәясәтеннән эзләргә кирәк (Кытай, СССР һәм АКШ). АКШ ирекле икътисадны яклый, Кытай коммунизмның бер төрлесен, әлекке СССР—икенче төрлесен төзергә тырыша (иде). Ә мескен кечкенә милләтләр алар өчен кан коя...

## Пол Пот—партизаннар юлбашчысы

ПОЛ ПОТ 1979 елның январенда үзенең якыннары белән Таиланд чигендәге төньяк-көнбатыш джунглига качып, партизаннар сугышы игълан итә. Төп дошман—Хун Сен һәм Вьетнам. Кытай һәм Таиланд аңа корал, медикаментлар һәм бик авыр көннәрдә качу урыннары биреп ярдәм итәләр. Таиланд бит АКШның бик якын дусты, нигә ул Лон Нолны бәреп төшергән Пол Потка ярдәм итә? Бу да бөек державаларның катлаулы һәм хәйләкәр сәясәте. Вьетнам—АКШның дошманы, ә Пол Пот Вьетнамга каршы сугыша. Аңа ярдәм итәргә кирәк, тик андый палачка ачыктан-ачык ярдәм итәргә ярамый, ул «исемне» пычратачак. Шуңа күрә АКШ аңа үзе түгел, ә Таиланд аша ярдәм итә. Менә шулай...

Партизан сугышын Пол Пот 1979 елдан 1991 елга чаклы, актив кына алып бара. Тик 1991 елда Кампучиядә ирекле сайлаулар үткәрү турында протоколга Хун Сен кул куйгач, сайлаулар үткәрелеп, Нородом Сианук Пном Пеньга кайткач, принц Нородом Ринарит Хун Сен хөкүмәтендә эшли башлагач, Таиланд Пол Потка ярдәмен туктала. Яңа хөкүмәт бөтен «кызыл кхмерларга» (әгәр алар корал ташласалар) амнистия игълан итә. Бик күп партизаннар Пол Потны ташлап, өйләренә кайтып китәләр. Пол Пот аның өчен үз якыннарын гаепли. Үзенең ярдәмчесе (үзе белән Парижда укыган) Сон Сенны һәм аның бөтен туганнарын (хәтта оныкларын да) аттыра.

Партизаннар саны һаман кими, Пол Пот малярия һәм йөрәк чире белән авырый башлый, шуңа карамастан һаман да үзе тирәсендәге «хыянәтчеләрне» җәзалап үтерүен дәвам итә. Үзенә чират җитүен сизгән аның «ит кисүче» кушаматлы хәрби командиры Та Мок Пол Потны 1997 елның июлендә кулга ала, джунглида хөкем итә, тик үтерми, урман өендә саклау астында калдыра.

## Пол Потның шәхси характеры

УЛ ТАРИХТА «елмаеп үтерүче җәллад» исеме белән калыр, ахыры. Чөнки күреп сөйләшкән бөтен әңгәмәдәшләре аны «бик йомшак кына, елмаеп сөйләшүче кеше» диләр. Тавыш күтәрү, кычкыру, сүгенү, тупаслык, мыскыл итү, куркыту дигән сыйфатларның эзе дә булмаган бу җәлладта. Ул зур итәгать белән әңгәмәдәшен тыңлап, вәгъдәләр бирмәсә дә, аның күп фикерләре белән килешә торган булган. «Түземле, әдәпле, тыныч, сабыр, уйчан, тыйнак»,—дигән эпитетлар аның турында еш кабатлана.

Асылда, «шәхес культы» дигән нәрсә дә анда сизелмәгән диярлек. Ул кеше арасына чыгып йөрергә, зур нотыклар сөйләргә,

үзе турында мәкаләләр һәм китаплар чыгарырга яратмаган. Коммунизм теориясе һәм практикасы башка нәрсә, әлбәттә, ул турыда Пол Пот ярыйсы гына мирас калдырды.

Чиксез күп үтерүләрне һәм әшәкелекләрне Пол Пот үзенә бөтен җаны-тәне белән бирелгән якын ярдәмчеләренә елмаеп бер-ике сүз әйтү аша эшләде...

## «Елмаючы җәлладның» үлеме

1979 ЕЛДА хакимияттән киткәч тә, Пол Пот 19 ел эчендә бик күп мең кешеләрнең башына җитә. Аның партизаннары бик күп Хун Сен солдатларын, чиновникларын, аның яклы авыл кешеләрен төнлә һөҗүм итеп кыралар да, тагын джунглига качалар. Ләкин бу дөньяда һәр язмышның да чиге була. 1997 елда үз якыннары өй төрмәсенә утырткач, аның кәефе дә, сәламәтлеге дә начарлана. Дусларының күбесе аны ташлап китә. Гомумән, «кызыл кхмер» партизаннарының саны берничә йөз кеше генә кала.

Шуның өстенә, дөнья гәзитләре һәм Кампучия хөкүмәте Пол Потны һәм аның якыннарын Халыкара трибуналда хөкем итүне таләп итәләр, һәм бу гәзитләр аның кулына килеп тора. Ә хөкүмәт гаскәрләре якынлаша, хәтта джунглида да аңа куркынычсыз җир аз кала. «Өй төрмәсе» дә курорт түгел. Малярия һәм йөрәк чире җанны ашый...

Ярый әле, яшь хатыны Меа Сон әйбәт карый. Элекке картайган һәм чирле хатыны Кхиу Поннари нык авырып, Пекин больницасында урыныннан торалмыйча ятканда, Пол Пот үзенә хезмәт итүче (үзеннән 33 яшькә кече) Меа Сонга 1987 елда өйләнә. Карт хатыны рөхсәте белән, әлбәттә. Партия шулай куша. Поннари—партиянең ихтирамлы әгъзасы.

Үзен саклаган Нон Ну әйтүенчә, үләр алдыннан 1 көн элек Пол Пот үзенең ап-пак чал чәчләрен карага буята. «Дошманнар килсә, танымасыннар»—ди ул. 1998 елның 15 апрелендә ул хатыны белән дөгедән торган көндезге ашын ашый һәм йокларга ята. Хатыны башка җиргә китә һәм төнге унберде черкиләрдән саклар өчен челтәр алып килә. Караса, ире селкенми, үлгән...



*«Чиста Кампучия»: Пол Пот киткәч, Пном Пеньда табылган кеше сөякләре өемнәренең берсе.*

Хәбәр таралгач, Кампучия һәм Таиланд хөкүмәтләре, аның гәүдәсен үзләренә алырга, эчен ярып аутопсия ясарга тәкъдим итәләр. Ләкин «кызыллар» бу тәкъдимне катгый рәвештә кире кагалар.

Буддист руханиләрне чакырмыйча гына (Пол Пот буддизмны юк итте ләбаса), аның хатыны, 14 яшьлек кызы Сит һәм берничә якыннары аның гәүдәсен джунглида яндыралар һәм көлен хатыны белән кызына бирәләр. Дөньяны шаулаткан «кызыл кхмерның» гомере шулай тәмамлана...

Ләкин дөнья матбугатында Пол Потның үлүе турында сораулар дәвам итә. «Соңгы көннәрдә аның сәламәтлеге әйбәт булган»,— диләр.—Бәлки ул Халыкара Трибуналга эләкмәс өчен үзен-үзе агулап үтергәндер? «Башка кызыл кхмер җитәкчеләре турында да, Таиланд хәрбиләре турында да аның сөйләсе сүзләре һәм серләре ифрат күп булган бит, шуңа күрә алар агулап үтергәндер,—диләр икенчеләре.—Һәрхәлдә эчен ярып аутопсия ясарга тиешләр иде...»

## Халыкара трибунал булырмы?

МОНЫҢ ӨЧЕН тарихта җыелган материаллар да, әле исән-сау «фюрерлар» да җитәрлек.

«Кызыл кхмерларның» җинаятьләре турында бик күп томнардан торган (барысы 150000 биттән артык) материал Пном Пень хөкүмәтендә саклана.

Куллары 2 миллион кешенең канына баткан Пол Потның иң якын көрәштәшләре әле дә исән. Менә аларның исемнәре һәм фоторәсемнәре.

1986 елда көнбатыш Кампучиядә партизан лагеренда төшерелгән фото. Уң якта—Пол Пот үзе.

Сул якта—Нуон Чеа, Пол Поттан соң асылда икенче урында торган юлбашчы. Аңа бүген 71 яшь. Ул Пол Поттан да күбрәк җинаять эшләгән кеше. 1996 елның октябреннән соң алар Пол Пот белән аерылышалар, ераклашалар, аерым партизан көчләренә бүленәләр. Нуон Чеа, Кхиу Самфан һәм Та Мок белән уртак тел табып, Та Мок аша Пол Потны өй төрмәсенә утырта.

Уртадагысы—Кхиу Самфан, Пол Потның Кампучия президенты. Аңа бүген хәзер 69 яшь. Пол Потның якын көрәштәше, бик күп декретларга кул куеп, күп кешенең башына җиткән кеше. Ләкин беренче рольне уйнаганы булмады: элек Пол Потка буйсынса, 1996 елдан бирле Нуон Чеага буйсына. Менә тагын бер фото (1997 ел). Бу—бүген 68 яшьтәге Иенг Сари, «кызыл кхмерларның» иерархиясендә өченче урында булган кеше. Пол Потның баҗасы (ул Кхиу Поннариның сеңлесенә өйләнгән). Чит ил эшләре министры буларак, хәрби һәм эчке эшләргә аз катнашкан, шуңа күрә канлы җинаятьләрдә аның катнашы бик зур түгел. Пол Пот белән элемтәсен өзгәч, ул үзе белән бик күп «кызыл кхмерларны» Хун Сенга алып килеп бирә, шуңа күрә аны хөкем итмәячәкләр, дип уйлыйлар.

Заманында көнчыгыш Кампучиядәге Чам мөселманнарын кырып бетергән Кеа Мок исемле 68 яшьлек генерал хөкем җәзасына тартылырга тиеш. Соңгы айларда ул бөтен «кызыл кхмерлардан» аерылып, джунглиларда яшәсә дә, кеше үтерүдән туктамый, сугышын дәвам итә.

2 миллион кешенең башына җиткән «кызыл кхмер» юлбашчыларын Халыкара трибунал алдына куярга кирәкме? Кирәк, чөнки XXI гасырда (гомумән, киләчәктә) халыкларның мондый тирән фаҗигаләре кабатланмаска тиеш.

*Мәскәү.*

*Сәнгать*

# «ӘЙЛӘНӘ СӘХНӘ...»

Әйе, әйләнә! Мәшһүр шагыйребезнен кырыс сәхнә дөньясына багышланган мәгълүм шигырендәгечә—«сибелеп кала еллар, язмышлар, режиссерлар, геройлар» һәм бу аяусыз хәрәкәтне беркем туктаталмый. Яшәеш кануннары, чал галәм үзе дә шулай корылган... Ә бит сәхнәне «әйләндерүчеләр» алкыш һәм чәчәк арасында яши, дип әйтүчеләр бик күп. Алай ук түгел икән шул. Талчыгып, тетрәп, кимсенеп тә яшәргә туры килә бу олы сәхнәле йортта. Карт артист Фуат Халитов без—яшьләрне: «Театр әле сөяр, әле чөяр, әле килегә дә салып төяр!»—дип кисәтә иде. Чыннан да, театр дөньясында инде утыз алты ел гомер уздырдым, әнә шул әйтелгәннәр бары да күз алдымда була торды. Сәнгать корбаннар сорый, дигән гыйбарәне халык арасында көлебрәк телгә алсалар да, тормышта ул сәхнә кешесе каршына бөтен кырыслыгы белән килеп баса. Режиссер (соңрак халык депутаты булып та танылды) Дамир (Раид) Сиражиевка да сәхнә бик күп сынаулар алып килде.

Һәммә нәрсәгә күнә торган кеше булмады ул. Шунадыр, аның турында сүз чыкканда: «Фәрештә түгел!» дип әйтүләрен дә еш ишеттем. Инде соңга калып булса да: «Ә кем фәрештә соң?»—дип сорыйсы килә. Ходай тарафыннан ул кешегә житәрлек итеп бирелгән таланты Дамир җанын мизгел дә тынычлыкта калдырмый иде кебек. Сәхнә имгәтеп ташлаган җаннарын кемнәрдер шәраб белән юганда, гайбәт сатып юанганда, Дамир юанычны (аеруча иҗатының тәүге елларында) тау-тау хезмәт арасыннан эзләп таба килде.

Яшь аермабыз алты-җиде еллап булса да, сүзләребез беренче очрашуда ук килеште. Дамир Казан театр училищесында Марсель Сәлимҗанов курсын тәмамлагач, аны Камал театрында калдырмадылар, күчмәгә җибәрделәр. Әнә шунда Рәфкать Бикчәнтәев безне «Хөрмәне бушлай бирмиләр» дигән яңа куела башлаган спектакленә алды. 1974 елның март ае иде ул. Дамир бездә ярты ел гына эшләсә дә без аралашырга өлгердек. Соңрак бу хакта сүз чыгып, ничек алай ансат якынаеп киттек икән дигәч, (чөнки театр һәм тормыш килесе мине шактый төеп, һәркемгә дә шикләнеп карарга өйрәткән иде), Дамир: «Син квартирыңнан куылган... театр җыештыручылары чиләк, чүпрәк, себерке куя торган салкын почмакта яшисең, шулай да горур кыланасың, бер машина китабың бар, менә чын кеше шулай булырга тиеш! дип уйладым да, үз күреп сөйләшә башладым»—диде. Шул елның сентябрь аенда Дамир Г. Камал театрына яктыртучы-электрик сыйфатында барып керде. Артистлар хәтерлиләрдер, Дамир бельэтаждагы ложаларга урнашкан прожектор утларын сәхнәгә турылап утырды. Һәм әйтергә кирәк, ул бу эшне иң зур осталар кебек башкара иде. Минем өчен бу ике факт тирән мәгънәгә ия. Бары романтик рухлы, театрга җаны-тәне белән гашыйк кеше генә артист булып укып чыкса да, яраткан театрында калу өчен таныш булмаган электрик эшен эшләргә дә ризалаша. Миндәй бомж хәлендә йөрүче белән дә бары Дамир гына дуслаша алды. Кин күңелле икәне, йөрәген һәркемгә төбенәчә каерып ача алуы да соңыннан күп тапкырлар расланды.

1975 ел икебезне дә Мәскәүгә—ГИТИСка китерде. Менә бу урында, дөреслек тулы булсын өчен, шуны өстәп куям. Дамирны Камал театрына артист итеп алмаган Марсель Сәлимҗанов Дамирга үз көчен режиссура өлкәсендә сынап карарга киңәш иткән һәм Мәскәүгә барып, ГИТИСның җитәкчеләре белән дә сөйләшеп кайткан икән. Юкса, тубәтәйле һәм рухы белән дә татар булган егеткә ничек кенә талантлы булса да,

анда алынулары икеле иде. Шулай итеп, аны режиссерлар әзерли торган факультетка, ә мине Югары режиссерлар курсына алдылар. Дамир укуын миннән атна-ун көнгә алдарак башлаган иде. Әмма аны бөтен Трифоновка (без яшәгән студентлар тулай торагы) белә иде инде. Төнге өчтә (ул гомергә шулай булып калды) минем ишекне шакып ачтырды да тулай торакнын бишенче катындагы бер бүлмәгә алып менде. Бүлмә тулы кеше иде: азиялылар, африкалылар, көнбатыш илләрдән килгән студентлар... Сүз, бәхәс... Дамир дөньянын шул төрле кыйтгаларыннан жыелган яшьләр арасында да үз кешегә әверелергә өлгергән иде. Уку чоры безнен икебез өчен дә бик кадерле истәлекләр калдырды. Дөрес, мин Мәскәүдә бер генә ел укып, калган өлешен Ленинградның Товстоногов театрында тәмамласам да, без әле Дамир белән вакыт булган саен Мәскәүнен дөньякүләм танылган режиссерлары Эфрос, Любимов, Захаров репетицияләрен һәм аларнын атаклы спектакльләрен карарга өлгердек. Балтик буеннан килгән «Ванемуйне» театрынын төрле жанрдагы эшләре дә, Шота Руставели театрында Роберт Стуруа куйган «Кваркварэ» һәм «Кавказский меловой круг»ы да безгә нык тәэсир итте. Шушыларны язганда, нишләптер хәтергә ике поляк егетенен Дамирга магнитофонны ватып биргәнсен, дип шурли-шурли бәйләнүләре дә искә килеп төште. Дамир читкә китүгә үк алар аны үзара «Чыңгыз хан» дип атадылар. Минем Марсель Сәлимжановны да шулай дигәннәрен ишеткәнем бар. Качалов театрынын элеккеге режиссеры Портнов аны Малый Бронный театрынын әдәби бүлек мөдиренә әйткән иде. Бу инде башка милләт кешеләренен татарга, анын көчле рухлы шәхесләренә бирә торган «мактау» сүзләредер, күрәсен. ГИТИСнын соңгы курсында укыганда, Дамир Казанга диплом спектакле куярга кайтып төште һәм бик күпләрнен игътибарын яулап алды. Дамирнын режиссерлыкка укып йөрүе дә, дүртенче курста укыганда ук Джагирханян кебек артистлар белән Чехов хикәяләре буенча куелган «Рассказы о любви» фильмында Татарны уйнавы да, кием-салымы һәм үзенен тышкы кыяфәтен нечкә зәвык белән төрлеләндереп торуы да, хәтта жилкә аша асып йөрткән фотокамера сумкасына хәтле һәммәсе дә анын гадәти шәхес булмавы хакында сөйли иде кебек. Ә бит чыннан да, ул инде без белгән элекке шыксыз үрдәк бәбкәсе түгел, ә чын аккош булып житкән өметле талант иде. Дамирнын дүртенче курста укыганда ук С. Цвиллинг исемендәге Чиләбе театрында өч спектакль куюын да сирәк кеше белә. В. Распутин әсәре буенча куелган беренче спектакле «Деньги для Марии»ны Дамир театрнын баш режиссеры Ю. Орлов белән бергәләп куя. Шуннан инде яшь режиссерга Арбузовнын «Жестокие игры» драмасын ышанып тапшыралар. Бу эше уныш казангач, үзенә генә икенче спектакльне дә куярга рөхсәт итәләр. Анысы Горькийнын «Последние» әсәре... Әлбәттә, әлеге спектакльләрнен афишалары ГИТИСта күренгәч, гомер булмаган бу күренештән барысы да телсез калалар. Инде кабат 1979 елнын декабренә кайтабыз... Нәкъ шул чорда театр училищесынын өченче курсы студентлары, актерлык осталыгына укытучы Празат абыйлары укыту эшеннән читләшүе сәбәпле, остазсыз калды... Дамир әлеге курснын икенче остазы Ш. Әсфәндиярова белән бергәләп, аларны укытырга алынды. Х. Төхфәтулла, Р. Хәйруллина, Ф. Ситдыйк, Р. һәм Н. Юкачевлар укыган бу талантлы курс шәкертләрен шундук үзенеке итеп танып өлгерде. Әле дә алар шул чорны, төнге дүрткә кадәр репетиция ясап, хәтта берничә ай буе шул училищенын аудиториясендә кунып йөргәннәренә чаклы сагынып искә алалар. Шул курсны тәмамлап, Камал театрына алынган М. Ибраһим, Р. Закиржанова: «Анын дәресләре шулчаклы кызыклы үтә, күнелне шулчаклы баета иде, без аларны сусап көтеп ала идек»—дип, мина шуларны тагын бер кат расладылар. Аннары: «Студентнын тук чагына караганда, ач чаклары күбрәк. Дамир Равилович шуны сизгән кебек бик еш кына үз акчасына ризык китертә торган иде. Акчасын беркайчан да жәлләмәде. Ә бит 22 кешене бер сыйларга була, ике, әмма даими рәвештә ашату өчен Дамир булу кирәк...»—дип тә куйдылар. 1980 елнын 9 декабрендә без Г. Шамуков белән шушы курснын диплом эше—Брехтнын «Добрый человек из Сычуана» спектаклен карарга киллек. Аудиториянен залы шыплап тулганга, икебезгә бирелгән бер урынны бүлешеп утырдык. Дамир әле Казанда берни эшләргә өлгермәсә дә анын шәхесе театр сөючеләр күнелендә зур кызыксыну уяткан иде инде. Хәер, эшләргә өлгермәде, дип әйтеп нык ялгыштым. Шул елнын май аенда күпне күргән Казан тамашачыларын кыргыз язучысы Мар Байжиевнын «Кияү белән кәләш»е—Дамирнын диплом яклау спектакле тан калдырды. Фуат Хәлитов шушы беренче эше белән үк аны «үз эшенен чын художнигы», дип атады. Кыю булуын, артист күнелен бик тиз яулап, дәрләтеп жибәрүен режиссер иҗаты өчен бик кирәкле, әмма күпләр яши-яши генә үзләштерә алган «производство» белән бәйле барлык жепләрне дә үз кулына туплап тота белүен дә өстәде. Һәм, әлбәттә, Дамир

спектакленен төп әһәмияте—артистлар яңа яклары белән ачылды,—диде. Шуңа охшаган сүзләрне икенче СССР халык артисты Габдулла Шамуковтан да ишеттем. «Күрденме,— диде Габдулла абый, студентларның элеге «Добрый человек из Сычуана»сын карагач,— Дамир тамашачылар белән бөтенләй башкача сөйләшә». «Әйе шул,—дидем мин, безнең тамашачы артист белән бергә уйнарга ярата, ә Дамир аларны «сәхнәгә кертми». Ана ул кирәкми дә,—диде Габдулла абый,—анласыннар һәм шул житкән... Дамир бик кызыклы режиссер булачак!» «Булачак,—дисез,—Габдулла абый, ул бит инде искиткеч режиссер»,— дим. Әмма... Габдулла абый хаклы булып чыкты.



*Бу рәсем Нәкый ага Исәнбәткә 80 яшь тулган көннәрдә алынган. Фоторәсемнең артына Нәкый ага Исәнбәт кулы белән: «Хөрмәтле Сиражиев Дамир иптәшкә юбилей истәлеге. Алда Сезгә зур иҗади уңышлар теләп Н. Исәнбәт. 24/IV. 80»—дип язып куелган.*

Дамир «Кияү белән кәләш» кебек диплом спектакленнән соң да Камалга сыймады. Бу инде аның яраткан театры тарафыннан икенче тапкыр читкә тибәрелүе иде. Бер айдан соң ул ТЮЗ театрына барып керде. Һәм бу урыс театрында нибары бер ел чамасы эшли алды. Шул кыска вакыт эчендә дә «Никто не поверит», «Мальчиш-Кибальчиш» кебек бик үзенчәлекле куелган спектакльләре белән балкып алган режиссерга ТЮЗда ары таба да эшләргә ни комачаулады соң? Җавапның бер очы балачакка тоташадыр. Раил (Дамир)ның әнисе Рәшидә апа Чиләбе кызы. Искиткеч матур тавышы аны кечкенәдән сәхнәгә күтәрә. Татар халкының иң зур артистларыннан берсе Шәүкәт Биктимер белән бер чордарак Казан театр мәктәбен дә тәмамлый. Тик ана яраткан театр дөньясында артистка булып эшләү насыйп булмый. Язмыш аны булачак ире—Казан университетында юридик факультетны тәмамлаган һәм яңа гына КГБда тикшерүче булып эшли башлаган үткен дә, чибәр дә егет Равил Сиражиев белән таныштыра. Аларны Магаданга җибәрәләр. Бу яшь гаилә күргәннәрнең барсын язсаң, мәкалә журнал куйган чикләрдән чыгачак. Шуңа да, өстән-өстән Дамирга кагылганнарын гына искә алып үтәм... Дамир Татарстанның Гөбенә елгасы буендагы Подберезье авылында 1954 елда туа. 1956 елда исә аларны Чиләбегә күчерәләр. Әтисе кебек үк, булачак режиссерның әнисе дә, кайда гына барсалар да, гел берәр җаваплы урынга билгеләнә. Чиләбедә дә ана шундый эшләрнең берсе йөкләнә. Ул облкниготоргның директор урынбасары итеп куела. Шуңа Дамир, үзен белә-белгәннән бирле, гел китаплар арасында. Кайчандыр әнисе йөрәгендә йомылып калган театрга булган мәхәббәт көтмәгәндә Дамирда бәреп чыга. Нибары өч яшьлек Дамир сайлау компаниясендә ишетеп кайткан «Я встретил девушку...» җырының көен дә, сүзләрен дә ятлап ала алган. Балалар бакчасында өйрәнгән «Карбыз» шигырен укыганда: «Житәр, тукта, авыздан сулар килә»,—диләр. Кайда да ул иң алда, сораса-сорамасалар да җырлый, бии, шигырь сөйли. Нинди ярышлар узса да, класс та, мәктәп тә Дамир аркасында гел беренче урынга чыга. Аның инде җиде яшендә үк кешеләрне үз ихтыярына буйсындыра алу сәләте сизелә.

Мәсәлән, бер сайлау вакытында бик күпләр үз эшләре белән мәшгуль булганда, ул калку урынга менеп басып, Җәлилнең «Алман илендә» дигән шигырен урысча укый. Аны тыңларга хәтта сыра чиратында торган ирләргә кадәр җыела. Зур үскәч тә анарда бу гадәт чәчрәп чыккалый. Бервакыт ресторандагы дискотека вакытында чын биючеләр катнашында конкурс уздырыла. Җиңүчегә бүләк билгеләнә. Көтмәгәндә ярышка Дамир да кушыла. Һәм жюри аның җиңүче булуын әйтеп, сез профессиональ биючеме, дигән сорауны бирә. Дамир шулай ук пианинода һәм гитарада уйный, бик шәп җырлый да. Әнә шуларга әнисе Рәшидә апаның гомергә театрга саклаган кайнар мәхәббәтен дә кушыйк. Табигый, Дамирга бер генә юл кала, ул ике уйлап тормастан Казан театр училищесына укырга керә. Аның урыс группасында укып йөрүен күргән Ш. Әсфәндиярова: сина монда йөрисе юк, алар үзләре дә күп, күч татар курсына дип, үзе, Марсель һәм Хәким Сәлимҗановлар укыткан, киләчәктә искиткеч талантлы артистлар үсеп чыгачак курска күчәргә булыша. Театр шулчаклы тылсымлы дөнья ки, сәхнә өчен яратылган кеше анарга бер аяк атладымы, ул инде мәңгегә шунда кала. Дамир мин белгән кешеләр арасында театр белән иң нык «агуланган» кеше иде. Әгәр язмыш ана берникадәр мәрхәмәтлерәк булса, сәхнә дөньясы тудырган ясалма киртәләр дә азрак булса, ул татар милләтенә дә, театр сәнгатебезгә дә бик зур җиңүләр китерә алган булыр иде. Театр аны югалтып, үзенең күген бизәп торачак бик якты йолдызыннан мәхрүм калды. Бу—күпләр фикере. Милләтебез өчен бәһаләп бетергесез гамәлләр кылган, Дамир белән бергә яңашә иҗат иткән шәхесләрнең сүзе.

Югарыда сөйләгәннәрдән күренгәнчә, Дамир җитеш, булдыклы гаилә җимеше. Тумышы белән үк узаман булырга яратылган, һәр өлкәдә һәрчак беренче булырга өйрәнгән һәм күпләребез гомер буе арына алмаган коллык психологиясеннән дә тулаем азат егерме алты яшьлек бу ир-егет, баш режиссерның театрда урнаштырган тар кысаларына үзен куып кертергә тырышуын һич кабул итә алмый. Бер Казанга ике тәкә башы сыймый дигәндәй, Станиславский белән Мейерхольд, яисә Вахтанговлар да бер үк түбә астында яши алмаганнар. Дамир да беренче адымнарыннан ук үз театры хакында хыяллана башлады. Үз театрын хәтта подвалда ачарга да риза иде. Аның Казан буйлап бик күп йорт асларын карап йөргәнен күпләр хәтерли. Әмма фәкыйрьлек аны филармониягә китерде. Филармониягә урнашканчы күп тапкырлар Камалга керергә омтылды. 1981 елда анда татар яшьләр театры кебек труппа ачылган иде. Беренче спектакльне Батуллага куйдырдылар. Мин дә анда идем. Марсель Сәлимҗанов миннән «Алмазбулат»ны яздыргач кемгә бирәбез, дип сорады. Мин: «Дамир куйса ярармы»,—дидем... Һәм Дамир беренче репетициядә үк йөрәк түребезгә кереп урнашты. Аның шаккаткыч фантазиясе артыннан кайчак артист фантазиясе өлгерә дә алмый иде. Әмма ахырда балалар да, олылар да яратып карый торган спектакль туды. Хәтта «Яшь ленинчы» газетасендә очрашулар вакытында: «Бу спектакль М. Җәлил бүләгенә лаек»,—диделәр. Үз спектаклем булганнан әйтү түгел... Рәссам Р. Газиев, композитор Ф. Әбүбәкер, режиссер Д. Сиражиев һәм талантлы артистлар тудырган, тулаем милләтебез язмышы хакында сөйли торган бу спектакль зур тәэсир көченә ия иде. Без шул 1981 елда ук Дамир «коткысына ияреп», «Туган тел»не сәхнәдән гимн итеп яңгырата алдык. Ә бу чорда әле сәхнәдән бер кыю сүз әйтелсә дә зур эш эшләндегә санала иде. Әйткәнемчә, Дамирга барыбер филармониягә урнашырга туры килде. Моңа театрда урын булмау гына түгел, артистлар да гаепле. Дамир яклауга мохтаж иде. Кайберәүләр ана ярдәм итәсе урында, Марсель абый Сәлимҗановка кереп, безнең Дамирча эшлисебез килми, дип тавыш күтәреп йөрделәр. Дамир да бер көнне, тәмам өзгәләнеп: «Болай бит эшләп булмый, бер нәрсә булды исә, ярар, Марсель Сәлимҗанов үзе килер дә үзгәртеп куяр әле, дип куркытасыз»,—дияргә мәҗбүр булды. Һәм, чыннан да, Марсель Сәлимҗанов килеп, ничек Хаҗиәхмәтов, Батулла спектакльләрен үзгәрткән булса, Дамирныкын да шулай төзәтә башлый иде. Дамир шундый чакта мина да, нигә яклямыйсың, дип ябырылганы бар. Филармониядә ул ике зур яңалык кертте. Гүзәл җырчы Римма Ибраһимова белән театрлашкан концерт куйды. Ул бүгенгесе көндә киң таралган «Фәлән артист җыр театры»ның әүвәлгесе-өлгесе булды. Икенчесе—симфоник оркестр ярдәмендә балалар өчен махсус музыкаль спектакльләр башкаруны кертүе. Ул Казан өчен дә җитди мәдәни казаныш иде. 1983 елны Р. Суфиевның «Красным по белому» фаҗигасен сәхнәләштерергә омтылды. Миннән тәрҗемә ясатты. Тик эш башланып киткәннән беренче көнендә үк төп рольләрдә уйныйсы һәм башка зур артистлар: «Әсәр совет властена каршы, чөнки райком секретаре белән председатель урак өстендә эчеп, кызлар белән буталып яталар»,—дип пьесаны алдырмадылар. Мина да 120 битлек пьесаны татарчага тәрҗемә итсәм дә акча түләмәделәр. Шул ук елны «Зифа» спектаклен дә куярга

омтылды ул. Бу юлы да «Алмазбулат» белән булганнар кабатланды, аермасы шунда—әсәрне Марсель Сәлимжанов бетерде. Шулай да ел ахырында ана И. Юзеевнын «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» комедиясен сәхнәләштерү насыйп булды. Бу спектакль дә тамашачыга ансат кына барып ирешмәде, әмма бер сәхнәгә менгәч, алдагы спектакльләре кебек үк сәхнәдә йөз мәртәбәдән дә ким уйналмады. Бер елдан сон Дамир, филармониядән китеп, Мәскәүдәге Ермолова исемендәге театрга стажировка үтәргә урнашты. 1985 елда Ермолова театрыннан Марк Захаров театрына күчеп, стажировкасын дәвам иттерде. Бу, әлбәттә, сирәк кешегә генә насыйп була торган бәхетле очрак иде. Академиядә сонгы спектаклен куйганга инде өч ел үтте дигәндә, Дамир белән безгә кабат очрашу насыйп булды. Марсель Сәлимжанов мина яна әсәр яздырган иде. Баштарак ул аны үзем куям, дип тә йөрде. Аннан сон мин ана кабат: «Дамир куймасмы икән»,—дидем. Дамир килде, әмма, башта: «Минә без дә үсеп життек»не куярга телим, бүген ул ин кирәкле әсәр»,—диде. 1986 елнын январендә сәхнәгә «Ләйсән ире Хәсән» исеме астында менгән бу спектакль, чыннан да, бернichә сезоннын хит-спектакленә әверелде. Инде Дамир да Камал театрында режиссер булып эшли башлады. Анын Башкортостанга барып М. Салыйковадан алып кайткан «Бәхетлеме син?» спектакле көтелмәгән зур уныщка ирешге. Онытылган «Артист бенефисы»нын кабат сәхнәгә әйләнеп кайтуынын сәбәпчесе дә ул—эшсез тора белми торган Дамир Сиражиев. Бенефис кичәләрен бернichә ел буе уннарча артист һәм режиссерларыбызга да эшләдек. Ул чакта бенефис уздыру канун төсен алырга өлгермәгәнгәме, безне бушка эшләттеләр. Ниһаять, унышлары ана Ч. Айтматов романына алынырга мөмкинлек бирде. Дамир инсценировканы мина эшләргә тәкъдим итте. Әмма безгә аны бергә ахырынача эшләргә туры килмәде. Ул хакта икенче вакыт сөйләнер... Тик шуны әйтми булмый, бу инсценировка коллективка укылгач, барыбызда да ризасызлык тудырды. Марсель Сәлимжанов моны сизеп, Дамирга: «Бу «Плаха» режиссернын үзенә дә плаха булмагае»,—диде. Ләкин, бәхеткә, киресенчә булды—спектакль режиссернын да, артистларнын да, театрнын да, татар театр сәнгатенен дә зур җинүенә әверелде. Һәм ул М. Җәлил премиясенә лаек булды.

Дамирнын холкына хас тагын бер якны күрсәтәсе килә. Дамир кешене ничек бар, шулай кабул итә иде. Ялган-гайбәтләрне яратмый. Аны алдап та булмый, ул иртәме-сонмы ялганнын барыбер очына чыга. Чыга алмаса, үзеннән үк килеп сорый. Әйтик, ике очракта да ул үзенә мөрәҗәгать итте. Кемдер ана, Юныс КГБ белән бәйле, сак бул, дип кисәткән. Безнен «Ләйсән ире Хәсән»не сәхнәләштереп йөргән чакларыбыз иде. Ул бер-ике тапкыр шул мәсьәләдә мина ачыктан-ачык «бәйләнде»—сизләрде... Аларына театрнын иске бинасы шаһит булса, икенче очрак инде янасына күчкәч булды. Бусы минем намус эшем, ягъни хатыным белән бәйле гайбәт иде. Намус эше, дим, чөнки хатынын хөрмәт иткән һәр татар ире дә, ана намус эше итеп карыйдыр. Әйе, ике очракта да ул бу сорауларны күземә карап әйтте һәм шунсы кызык, ангәмә барышында мин әле гаҗәпләнүдән тулы җавап биреп өлгергәнче үк, үзенен логик фикерләве аша, күнелдәген укыгандай, эшнен төбенә төшә алды. Шушылай кешене үтәли күрә алу сәләте дә ана булган хөрмәтемне отыры арттырды.

Дамир Мансур Гыйләҗевнын «Рәхәт яшибез» әсәрен куйганда, Аяз абый белән аралашып йөри башлады һәм озакламый анын «Койсезләнгән сәфәр» әсәрен дә авторга лаек дәрәҗәдә сәхнәләштерде. Камал театрына куйган тугызынчы—сонгы спектакль поляк драматургы К. Хоинскийнын «Җәһәннәм бикче» булган. Әсәр җәй аенда яна укып кайткан яшь щепкинчылар белән куелды. 1988 елнын 5 декабрен Дамир инде Тинчурин театрында баш режиссер булып каршылады. Әмма анда эшли башлаганчы Минзәлә театрында А. Галиннын «Звезды на утреннем небе» әсәрен сәхнәләштерде. Тәржемәсен без икәү эшләдек. Бу театрда инде Дамир Дударевнын «Порог» пьесасын сәхнәләштергән һәм Минзәлә театры хакында Казан театр сөючеләрен дә зурдан кубып сөйләшергә мәҗбүр иткән иде.

Тинчурин театрында да Дамир бик күп спектакльләр куйды. Камал театрында яна драматург М. Гыйләҗевны ачса, Тинчуринда Р. Вәлиевны сәхнәгә китерде. Разилнын ике әсәре дә—«И машина, машина, житте минем башыма», «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» пьесалары хит-спектакль югарылыгында янгырады. Әмма Дамирнын башлап та, ахырынача житкерә алмаган әсәрләре дә күп. Алла әйтелгәнчә, Дамир өчен гел авырлыклардан торган 1983 елда Т. Уильямснын атаклы «Трамвай «Желание»сен дә башлап карады ул. Үзе театрда эшләмәгәч, алдан килешенмәгәч—туктаттылар. Инде труппага алынып, «Плаха» белән дан да казангач, Шекспирнын «Антоний һәм Клеопатра»сын куярга сорады... Тик аны ТЮЗдан Цейтлин килеп куйды. Ләкин «европача» бу спектакль өч тапкыр да бармады. Тинчурин театрында Дамир, бер-бер артлы биш драматургка заказ биреп, «Идегәй»не

яздырды. Арадан мин эшләгән вариантны сайлап куя башлады. Бер ай эшләгәч, «Идегәй»не сонрак куябыз, хәзер нәкъ менә Исхакыйның «Зөләйха»сы кирәк дип ана күчтек. Күчтек дидем, чөнки мина моннан 75 ел элек язылган әсәрне өр-яңадан бүгенге сәхнә теле белән язып чыгарга туры килде. Дамир пьесадагы поп белән урыс кешесен Качалов театрындагы Бетев һәм Коршоктан уйнатмакчы иде. Алар ризалашмады. Шулай итеп, ике спектакль дә ярты юлда калды. Р. Вәлиевның «Мәңгелек иман» фаҗигасенен ни өчен сәхнә күрмәвен авторы үзе сонрак әйтер. 1989 елда татар халкы Боек Болгарның ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулуны бәйрәм итте. Дамир композитор М. Шәмсетдинова белән берлектә ун мен кеше шыплап тулган стадионда шушы гүзәл бәйрәмгә багышланган «Изге Болгар дастаны»н куйды. Стадионны тетрәндергән бу тамашанын кайтавазы дөньяның бик күп тарафларын кат-кат әйләнеп чыкты. Бу колач житмәслек эшне Дамирдан башка берәү дә башкарып чыга алмас иде, диючеләргә мин дә кушылам. 1990 елда исә Дамир халык депутаты булып сайланды. Анда да лидерлар арасында булды. Шул чорда ул татар милләтенә күп эшләр башкарачак «Татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү» фонды идеясе белән яна башлады. Бер яктан Милли китапханә, икенче яктан Казан университеты, ягъни Р. Вәлиев һәм М. Госмановлар ярдәме белән бу идея тормышка ашты. Фонд ярдәмендә уннарча китап дөнья күрде. 1991 елда милләтебез тормышында тарихка мәңге кереп калачак «Жыен» уздырылды. Ул миннән анын афишаларын, татарча текстларын эшләтте.Бәлкем, шунадыр да күп әйберләрне хәтерлим булса кирәк. «Жыен»нын колачы шулчаклы кин, тәэсир көче шулчаклы зур иде, анда катнашучылар, Дамир куйган «Сөембикә кыйссасы»н да, Бөек Болгарга хаж кылырга баруларны да, олы бәйрәмнен ун көнгә сузылып, ана СССРда яшәүче татарлардан тыш бик күп төрки һәм мөселман халыкларынын килүен дә бүгенгәчә сагынып сөйлиләр.

Дамир 1998 елнын декабрь аенда йөрәге ярылып якты дөньядан китеп барды (урыны жәннәттә булсын!). Шулай итеп, 44 яшьлек ир-егет, хыялы тулы эшлисе эшләре, эшкә ашмый калган кайнар планнары белән салкын гүргә инде. Бу олы үкенеч турында шагыйрь генә әйтеп бирә ала. Разил Вәлиевнен ана багышлаган шигырендә шундый юллар бар: «Кайгыларнын кара төсен күрдем, тик күрмәдем жирдә бер кадер». Шагыйрь анда тагы: «ак хыяллар булып керермен мин әнкәм төшенә»—ди. Әйе, Дамир безнен төшләребезгә дә ак хыял булып керә. Бизнеска китсә дә, академик Миркасыйм Гәбделәхәтович Госманов әйтмешли, акчага табынудан китмәде. Әлеге дә баягы, ул бизнес дөньясына үз театрымны ачарлык акча эшләп булмасмы, дигән ак хыял белән атлады. Бизнес карурманы адаштыра, төп хыялы—театрдан ераклаштыра баруын күргәч, соңгы елларда гел театрга кайту уе белән «саташып» яшәде. Монысына үзем дә шаһит. Марсель Сәлимжановтан рөхсәт алды да, минем белән бергә академия театрында куясы пьесага сюжет эзләде. Төп геройларны сайлашты. Һәм бик комачауламый гына юнәлеш бирде. Бу «Сукбай артистлар»



*Утырып уйлар уйладым... Дамир Сиражиев фикердәше, режиссер Фәрит Бикчәнтәев белән.*

музыкаль комедиясе буласы иде. «Шартым шул, бик көлкеле булырга тиеш»,—диде. Ә чак кына элегрәк ул, киресенчә, фажигале мелодрама яздырырга омтылды. Ул сюжетны мин ана Тинчурин театрында «Зөләйха» репетициясендә барлык артистлар алдында сөйләгән идем. Тора-бара үзе үк: «... мина хәзер гади, әмма бик көлкеле әйбер кирәк, чөнки театрдан озак аерылып тордым»,—дип, үзәктә Р. Шәрәфи, Р. Шамкай кебек артистлар булган «Сукбай артистлар»ны яздырды. Минем акырын язуыма эче пошып, үзе белән Ташкентка үк алып китмәкче иде. Инде финалын язып ятканда, Дамир үлгән, диделәр. «Сукбай артистлар» язылып бетте. Тик аны инде мина сәхнәдә күрү насыйп булмаячак. Чөнки

аның өчен Дамир үзе кирәк. Башкалар белән бергә хыялланган хыяллары тагы да зуррак булган икән. Кызганыч, бу җыйнак мәкаләгә аларның һәммәсен кертеп булмый. Ин әүвәл сүз артистлардан башланыр. Чөнки режиссер артисттан, артистлар режиссердан башка яши алмый. Беренче сүз—«Кияү белән кәләш» героинясы Фирдәвес Хәйруллинага. Автор аның уенын Фрунзеда күреп, бик сокланып: «Милой Фирдауси—самой лучшей невесте на сцене» дигән язма белән үз китабын бүләк иткән.

**Ф. Хәйруллина**: *«Артист һөнәре турыдан-туры кешенен эчке халәтенә, рухи тетрәнүләренә тоташа. Артистны берни эшли алмас дәрәҗәгә китереп җиткерүче дә, тамашачының алиһәсенә әйләндерүче кеше дә, бөтенләй эшсез калдыручы да ул—режиссер. Дамир мине «Кияү белән кәләш»кә алганда, мин сәхнә иҗатымда торгынлык кичерә идем. Дамир белән барысы дүрт образ тудырдым. Арада Гөлчәчәкне ин уңышлысы дип саныйм. Дамир белән образ иҗат иткәндә, мине шул шаккаттыра иде. Дамир артист алдына шундый бурыч куя, башта югалып каласын. Ул синен моңача туплаган тәҗрибәнә каршы килә. Алай булганы юк, була да алмый дисен, әмма ул сине ияртеп китә, син үзендә ышану уянганын сизәсен һәм ахырда бары шулай уйнарга кирәклегенә инанасын. Әгәр ул театрыбызда эшләмәгән булса, мин күп нәрсәдән мәхрүм калыр идем. Бәлки, актриса буларак, үз-үземне югалтыр да идем. Үзе үлгәч, телевизордан Дамир төп рольдә уйнаган «Странник Булгара» дигән фильмын күрсәттеләр. Ничаклы рухи көч аның күз карашында. Эшләгән эшләре ил онытмаслык булса да, эшлиселәре үзе белән китте...»*

Мәскәү гастрольләреннән сон «Культура» газетасендә (1989, 2 июль) Б. Поюровскийның «Актерлар йолдызлыгы» дигән мәкаләсе чыкты. Анда шундый юллар бар: «... Зарипованын театрдагы топ уңышы дип, шикләнмичә, «Ахырзаман»дагы Акбүре ролен атап була. Бу образында актриса трагедия кебек югары жанрның ин тетрәндергеч нокталарына күтәрелеп, күнелләрне асылына чаклы тетрәндерә алды...»

**З. Зарипова:** *«Дамир үзенә бик күп «кыенлыклар ашаткан» кешегә дә ачу тота белми иде. Мин аның белән күп образлар тудырырга өлгермәдем. Әмма эшләгән каләренә таянып та шуны әйтә алам, әгәр дә Дамир театрга килеп мине спектакльләренә алмаса, өлешемә шундый бәхет тимәгән булыр иде. Башта ул мина популярлык яулашты. Ягъни җырлы һәм бик көлкеле Миннурый ролен тапшырды. Икенчесе—Акбүре. Менә бусы инде җанымны да, рухымны да олы яшәү дәрте белән сугарды. Аннары, ул мина Клеопатрага хәзерлән, Антоний—Ә. Шакиров, диде. Бу эше дә театрга зур җину китерер иде кебек. Нишләптер, мин ана бик ышана идем. Кайбер нәрсәләргә уйлый-уйлый гына төшенәсен. Хәтта безнен биоэнергияләребез, фикерләвебез һәм дә кешеләргә булган карашыбызга чаклы тәнгәл килә иде. Кыскасы, Дамир бездән китте һәм аның яшьтәшләре, фикердәшләре булган урта буын эшсез калды. Әйе, без эшсезләр. Театрда артистның таянычы—режиссер. Дамир безнен ин ышанычлы арка терәгебез иде!»*

Сәхнә алиһәсенә әверелгән артисткаларга да берничә сезон рәттән рольсез тилмерергә туры килә. Дамир белән очрашканда, Н. Гәрәева нәкъ шундый билгесезлек чорына кергән иде. Һәм режиссер белән артистка арасында башланган рухи дуслык, җан туганлыгы, ярдәмләшеп яшәү икесе өчен дә шифалы, игелекле булды.

**Н. Гәрәй**: *«Син Дамир дип әйттен дә, күз алдыма аның шомырт кебек кара, искиткеч тере күзләре килеп басты. Күз карашы шулчаклы тирән иде аның, мин аларның бик горур мизгелләрен дә, ялынып-ялварып караган чакларын да, хәтәр бер ялтырау белән янган вакытларын да бүгенгедәй хәтерлим, һич оныта алмыйм. Театрга булган мәхәббәте шул тиклем көчле иде, театрның аны кабул итми гел читкә кагып торуыннан ул тәмам авырута сабышты. Минем шушыны анлавым ана җинеллек бирә иде. Элек уйнаган рольләремне яхшы хәтерләгәнгәме, артистка буларак та ул мине үзенеке итеп күрде. Арабызда дәвамлы дуслык урнаштырган тагын бер сәбәп—ялгызлык. Дамир шәхесен акыл белән генә инләп була торган түгел иде бит. Шуңа да асылда ул ялгыз булды. Мин шулай ук ялгыз, эшсез артистка. Фәритем ГИТИСта, аннан ул армиягә, аннан кабат ГИТИСка кайтты. Менә шундый чорда бер-беребезгә терәк булып башланган дуслыгыбыз озын гомерле булды. Ул мине эшсез йөртмәс өчен театрда планнан тыш эш башлады. Атаклы «Трамвай «Желание» иде ул. Мина Бланш Дюбуаны, сенлесе Стелланы Фирдәвескә, ире Ковальскийны Тажига бирде. Тик Дамир театрда эшләми дип, репетицияләрне туктаттылар. Ул һаман эшләргә талпынды. Татар театры режиссерга кытлык кичергәндә, Дамирның эш эзләп ничек обком, министрлык бусагаларын таптавын үзем генә беләм. Ул бит артист та иде. Сәхнәгә чыга алмау аның өчен ин зур җәза иде. Дамир музыканы нечкә тоя, шигъри җанлы, гитарала үзе уйнап, үзе җырлый иде. Инде тагы шунысы да бар,*

*бездә куярга рөхсәт ителгән һәр спектакльдә диярлек ул мине дә уйнатты. Брехтны бездә дә, ТЮЗда да куйдырмадылар. Ул аны училищеда гына куя алды. Һәр яналыкка каршы төшә торган чаклар иде бит. Урыс группасы белән Светловның «Двадцать лет спустя»сын, Чеховның «Дядя Ваня»сын куйды. Бөгелмә театрында Дюрренматның «Физиклар»ын сәхнәләштерде. Бу мәкаләдә аның беренчеләрдән булып Төркиягә баруы һәм Мәккәдә хаж кылуы, анда корбан чалуы да язылмаган... Урыс мәдәнияте йогынтысындарак үссә дә, аның дингә тартылуы очраклы түгел иде; әбисе Сания ярдәмендә дини тәрбия ала алган; һәр дини бәйрәмне зурлап уздырып, һәр елны корбан чалды. Искиткеч бай китапханәсе булганга, мина бик күп яна китаплар укытты. Марк Захаров, Любимов театрларында күргәннәрен гаҗәеп кызык итеп сөйли иде. Кешенен кемлеген беләсен килсә, эшенә бак, диләр. Дамирның иң нык чагылышы «Ахырзаман» спектакле булды. Бу спектакль фәлсәфи дә, лирик та, тетрәндергеч фаҗигале дә, фарс тулы көлү объекты да, яхшы күнелле дә, котычкыч кырыс та, япа-ялгыз да, кыскасы, ана бөтен дөнья сыйган. Дамир аларны артистлар аша гәүдәләндерә алды. Аның кайсы гына спектаклен алсан да, аларны башкалар эше белән бутап булмый. Гомеренен соңгы көннәренә чаклы үз театрын булдыру уеннан кайтмады. Мин ана улым өчен дә рәхмәтле. Фәритне режиссура юлыннан җибәрүче Дамир иде.*


*Фәрит безнен күз алдында үсте. Галәттә, андыйларны артык үз итүдәнме, баласытып карау да булгалый. Әмма Фәрит белән алай түгел. Ул—шәхес. Дамир белән булган мөнәсәбәтләре дә бик үзенчәлекле иде».*

**Ф. Бикчәнтәев:** *«Мин театр училищесынын беренче курсында укый идем. Имтиханга Дамир да килде. Һәм ахырда ул мине котлады. Минем артист, диде. Алмазбулатны уйнатты. Марсель Сәлимжанов икенче курстан ук безгә көчебезне режиссурада да сынап карарга тәкъдим ясады. Бәлкем кемдә дә булса шул кәсепнен чаткысы күренеп китмәсме, дигәндер. Мин имтиханга О.Генриның «Дары волхвов» хикәясен әзерләдем. Дамир бу юлы мине читкәрәк чакырып: «Мондый эшләрне без өченче курста эшлибез, ә син, әнә, икенче курста ук күрсәттен, сина режиссура юлы белән китәргә кирәк»,—дип, миндә ышаныч тудырды. Шушы юнәлештә ул алга табарак та ярдәм итте. Табигый, мин ул куйган «Добрый человек...»ка да мөкиббән идем. Брехт та, куелышы да Казан өчен зур яналык иде. Дамир мине яна дөньяга алып керде, дип тә әйтә алам. Үзара сәнгать, әдәбият, музыка турындагы даими сөйләшүләр дә мина күпне бирде. Аның югарылыгында фәлсәфи фикерләүчеләр сирәктер. Иҗади доньясы бик күпне сыйдыра иде. Шунамы, иҗаты каршылыклы да иде. Бәлкем бу аның белән эшләгән артистларның үз фикердәшләре булып җитешә алмавыннан да килгәндер. Дамирны анлап, аның кебек фикер йөртсен өчен артистларны бит әле укытып үстерергә кирәк. Үзен тәрбияләгәннәр белән генә театр кадәр театр төзеп була. Ә бит ул үзенчәлекле фикер йөрткәндә, ана ияру авыр. Ни өчен һәм каян килеп чыккан бу метафора, шуны аның югарылыгында анлап кара син! Дамир мөмкинлекләре белән шигъранә, катлаулы метафоралар театры төзеп булыр иде. Ул ашыкты да... яшәргә ашыкты. Үз рухында тәрбияләнгән, һәр омтылышын анлый торган шәкертләр дә үстерде. Әгәр алар урыс группасыннан булмый, татарныкы булса... бәлкем шул Тинчуринда баш режиссер булып эшли башлагач, ана зур тәрәккә әверелерләр иде. Тинчурин театрына кучкәч, ул анда мине дә режиссер итеп чакырды. Мин: «Барам, әмма бер шарт белән: театрыгызда бер-ике ел спектакль куймыйм, бары яшьләрне укытам»,—дидем. Әмма ул: «Театрга тамашачы кирәк, репертуар кирәк диде...»*

Режиссердан соң чират драматургкадыр. Шагыйрь, прозаик, Татарстан милли китапханәсе директоры һәм тагын меңләгән җаваплы эш белән күмелгән Разил Вәлиевне бары тик Дамир драматург итә алды.

**Р. Вәлиев:** *«Син студентлар тормышыннан пьеса яздырган иден. Баш режиссерын кире кайтарды. Һәм беркөнне мина шалтыраталар. Даһи режиссер белән таныштырабыз, диләр. Дамир икән, «Әйдә барыйк, кызлар карыйк»ны укып чыккан һәм мина бер генә сүз әйтте: «Мин моны куям»... Ул бит этеп-төртеп, аллап-йоллап йөртә торган кеше түгел иде. Шул ук көнне Луиза Батыр-Болгарины чакыртты. Менә монда 14 җыр, сина 14 көн вакыт, диде, шушы булмәгә кереп бикләнәсен, ә без сина ризык ташып торырбыз, диде. Шулай булды да... Андагы җырларны әле бүген дә бик күп җырчыларыбыз башкара. Ә бит мин ул әйберне оныткан да идем. Драматургия хакында уйларга да курка башлаган идем. Ә Дамир «җенле кеше», канатландыра белә. Беркем ышанмый торган нәрсәгә дә кешене ышандыра ала. Менә иң гади мисал. Кешенен нинидер мөһим эшне эшлисе була. Ул инде мона бер ай хәзерләнә, хатлар яздырып ала. Ә Дамир нишли...*

*Бервакыт Түбән Камада хәл итәсе зур эш бар иде. Ул шундук номер жыя, бер белмәгән бик жаваплы кеше белән ин яхшы танышыдай сөйләшә башлый, «сезне тотасы авыр, әйдәгез менә хәзер без сезгә юл чыгабыз, фәлән сәгатьтән очрашабыз»,—ди. Ярты көндә без ул эшне башкарып чыккан булабыз. 1990 елда безгә чит илдәге татар концерт группасын китертә алды. Ул чакта бу мөмкин булмаслык эш булып күренә иде. Биш ел парламентта бергә утырдык. Бөек сәясәтче димим, әмма анда да ин кирәкле сүзне ин кирәкле урында әйтеп, ин дөрес адымны ясый белә иде. Дамир, идеяләр патшасы кебек, туктаусыз ни дә булса табып торды. Әле бөтендөнья татар конгрессына кадәр үк дөньянын Рудольф Нуриев, Надир Дәүләт, Рифат Таби, Софья Гобәйдуллина һәм башка атаклы татарларын Казанга форумга чакырып, халкыбызга менә без нинди, без бер халык бит дип аваз салмакчы иде. Сәнгать аша. Петербургка килгән Рудольф Нуриевны да ин беренче булып ул барып тапты. Видеотасмага төшергән. Аны Казанга килергә дә күндергән. Анын ризалыгын алгач, югарыдагылар белән сөйләшү алып барды. Һәм Нуриев Казанга килде. Дамирнын йөз хыялы арасында да гел үзәктә торганы—үз театрын булдыру хыялы булды. Төркиягә барып кайткач, мине зур полотнолы әсәр язарга димли башлады. Ибн Фадлан белән бәйле әсәр. Мин үземне язар өчен өлгердегә санап, 24 көнгә ял алып Юрмалыга китеп бардым. «Мәнгелек иман» дигән бу фажига 20 көндә язылды. Минем тагын 4 көнем калды, мин шул вакыт эчендә «И, машина, машина, житте минем башыма» комедисен дә ижат иттем. «Дамир: «Мәнгелек иман»ны укып чыгуга, театрнын бу әйберне куярга мөмкинлеге юк, артистлар да мона әзер түгел»,—диде. «И машина, машина, житте минем башыма»ны куйды. Һәм ары таба да мина бик күп сюжетлар тәкъдим итте. Анын бизнеска китүенә дә театрнын фәкыйрьлеге сәбәпче. Үзен хыялланган әйберне яздырып, шуна акча да таба алма инде, дип зарланган чакларын хәтерлим. Үзен саклый белми иде. Купчелекнен милләткә мәхәббәте чамалы булу сәбәпле, милләтпәрвәр режиссерыбыз кадер күрмәде. Бизнеска киткәндә дә кисәттем, көч-дәртен юк-бар нәрсәләргә сарыф ителәчәк бит, дидем. Башка юл күрмим, диде...»*



*Уйлар ятты күләгәләр булып...*

Мәсгудә «Сөембикә дастаны»н башкарганда еламый түзеп булмый. Дамирнын елавын да беләм. Бу сихри композитор белән очрашу мине куркыта иде. Дамирнын халык күнелендә бөркет булып очкан мизгелләре анын белән бәйле. Дамир турында дүрт сәгать буе сөйләшеп утырдык. Мондый бәхетле очрашу еш булмый. Ул сөйләгәннәр күнелемә уелып калса да, мәкаләмә аларнын меннән бере керде.

**М. Шәмсетдинова:** *Ул бөтен яклап та максималист иде. Әгәр ул сине олы талант итеп кабул иткән икән, инде сина бернәрсәне дә гафу итми. Син суперталантлар югарылыгында гына эшләргә тиеш. Ижатымда мина фәлсәфи нигезләүләр кирәк. Ә ул логик эзлеклелекне мохтажсынмый. Дөреслеккә бару юллары күп. Һәм икебез ике юлдан барсак та, шул дөреслек каршында очрашабыз. Ин көчле ягы шунда ки, ул идеяне кабул итеп кенә калмый, шуны ин югары ноктасынача үстерә алу сәләтенә дә ия. Анардагы ижатташын анлау таланты партнерларына чиксез мөмкинлек бирә иде. Беренче мисал: суверенитет алды жилләре исә башлаган чак, борынгылыкны чагылдырган музыка эзләп Петербургтан Альберт Әсәдуллин килде... Ахырда без «Болгар дастаны»н Дамирга тынлаттык. Дамир аны бөтен тирәнлеге белән анлады һәм... стадионда куйды. 450 елга сузылган коллыктан сон беренче тапкыр ун мен кешене жыеп, катлаулы музыканы берьюлы ун мен кеше анларлык итеп, арыныйк коллыктан дигән сүзне житкердек. «Дастан»да катнашкан вертолетлар, бронетронспортерлар, меңләгән хәрбиләр барысы да Дамир ихтыярына буйсынды. Бу берәүнен дә кулыннан килә алмый торган могжиза иде. Икенче*

*мисалы—ун көн барган «Жыен»дагы «Сөембикә кыйссасы». Бусы инде 1991 елның 21 июнендә кичке 8дә Сөембикә манарасы янында башкарылды. Дамир бу юлы стадионны гына түгел, ә бөтен Кремльне, Кремль тирәләрен, Казансуның аръякларын, дамба күперен һәм дамбаның үзен дә, жыелган бик күп меннәрчә кешеләре белән бергә кулында тотты. Кремль эченә сыймаган халык, чит илләрдән килгән кунаклар таш диварларны да сырып алган иделәр. Туплар гөрселдәгәч, тәрәзә пыялалары коелып төшүен, манарага чын-чынлап ут каба башлавын исәпләмәгәндә, башка чатаклыклар сизелмәде. Әйткәнемчә, кыйссаның музыкасын тынлагач ук Дамир аның либреттосын да үземә эшләргә кушты. Эш барышында мин шуңа игътибар иттем, ул дөрестән дә чын лидер иде. Без бит кеше белән дуслаштыкмы, аны үзебезнеке генә итеп күрергә телибез. Ә монда мина аның дусларының күплеген күреп, тан калырга туры килде. Мин бу «Сөембикә кыйссасы»н И. Мәһдиев белән бергә башкара торган «Сөембикә бәете»мә нигезләдем. Ул да хәзер мәрхүм инде. Дамирның сәгатьләр буе туктамый сөйләп булырлык кызык яклары бар иде. Шушы эш барышында да ул Сөембикә үлеменен мин сөйләгән күп вариантларына игътибар итмичә, аның монастырьда ябылып, монахиня киемнәрен кигәч кенә үзенен көчле рухы ярдәмендә үз йөрәген үзе туктата алуына мөкиббән булды. Кабат-кабат шуна борылып кайтты. «Мәһди»дә 1100 еллык тарихыбыз бер сәгатькә тупланып бирелсә, «Сөембикә...» дә XX гасырдан XV гасырга кайттык. Ханбикә тере чакка. Акбүз атларга атланган кызлар манарага кагылгач, ул жанланды». Без халкыбызны коллыкка китергән вакыйгаларның шаһиты булдык. Музыкасы да шул чаклы тамашачы алдында бөтенләй башка янгыраш алды. Дамир тапкан фантастик алымнар белән ул тетрәндергеч көчкә ия булды. Бу безнен коллыктан арыну кирәклеге турында күп халык каршындагы икенче житди чыгышыбыз иде. Инде сонгысы—ак хыял булып калганы... Дамир суга тартыла, күренешләрне су белән бәйли иде. Кабан күлендә тамаша куябыз, диде. Мин Казансуны тәкъдим иттем. Ана кадәр без Болгарда булган идек. Теплоход белән Болгар урнашкан тауга якынлашканда, Иделдән торып тау өсләрен сәхнә кебек карап булачак, дип сөйләштек. Һәм мин ана милли аныбызда, халык хыялларында калган ирекле чорлар символы—чабып барган атлар табуны образын болытларда чагылдырып булмасмы, дидем. Бу образ аны бөтен барлыгы белән биләп алды. Бөек Болгарыбызны әнә хәзер туристлар каласы итү, кече хаж ясау, ниндидер фондлар нигезе иттеләр. Ә жандагы символы әлегә юк. Дамир белән ул чорда без кабат Казансуга күчтек. Казан шәһәренә нигез салынган көннәр турында сөйләргә. Бу—«Казан риваяте» дә йөз менләгән халык каршында башкарыласы иде. Нигезендә—мин Финляндиядән алып кайткан «Алтын чабак» риваяте. Сәхнә—Казансу өстендә Кремльдән Матбугат йортынача сузылган понтоннар. Ана биек итеп сетка сузыла. Кремль диварында, Матбугат йортында, дамба күпере астында, 39 квартал һәм Милли үзәктә урнаштырылган махсус прожекторлар һәм аппаратура ярдәмендә әлеге тирбәлеп торган сәхнәдә Казан ханлыгы кешеләренен (уйнаучы артистлар түгел, алар күренмәс иде) символлары һәм тавышлары. Болар Петербург һәм Мәскәүдән алып кайткан махсус жайланмалар аша бирелергә тиеш иде. «Казан риваяте», алдагы ике эшебездән аермалы буларак, тагын да югарырак максатка, сыйфатлырак, күпкырлырак, колачлырак сөйләшүгә юнәлтелгән иде. Ул галәмдә безгә үз йортыбызда яшәү һәм кабат ирекле булу шарты тудырган Ходайга бер илаһи дога да булырга тиеш иде. Без инде мона әзер дә идек. Шунда Дамир: «Мәсгудә, сина илеянне гәүдәләндерү өчен каләм белән ак кәгазь дә житә, режиссерга... акча кирәк, теләнеп йөреп хәерчегә әйләнәсен, ә «Казан риваяте»н куючының рухы горур булырга тиеш!»—диде. Һәм халыкның бөеклеген тасвирлар өчен, милләтнен рухын күтәрер өчен, Казанны яулап коллык һәйкәле төзегәннәр каршына рухи һәйкәл күтәрер өчен акча эшлим дип бизнеска китте... кайталмады...*

Ул үлгәч, ана багышланган шигырьдәгечә:

Өләшенеп бетте көз алтыны...
Жанга инде салкын декабрь.

Әйе, «кеше китә, жыры кала». Өзелмәс кыл булып жан-сурәте, кылган эш-гамәлләре кала. Дамир Сиражиев әнә шундый олуг затларның берсе иде.

**Юныс САФИУЛЛИН**

*Тарих*

# ИКЕ ЙОЛДЫЗ ЯКТЫСЫ

*Гаяз Исхакыйның "Артист Габдулла Кариев" исемле мәкаләсе Берлинда, үзе нәшер иткән "Яңа милли юл" мәҗмугасында (1936 ел, 12 сан) басыла. Бу язма театр сәнгатенә нигез салучы танылган артист һәм режиссер Габдулла Кариев тормышының кайбер якларын ачарга ярдәм итә. Сәхнә йолдызының милли мәдәниятебездәге ролен "Габдулла Тукай шигырь мәйданында уйнаганнан ким түгел",— дип бәяли татар театры өчен үзе дә күп эшләгән Г. Исхакый.*

*Гәрчә "Сәйяр" труппасы Г. Исхакый пьесаларын 1907 елда ук сәхнәдә уйный башласа да, әлеге ике шәхеснең очрашуы 1913 елның көзендә Мәкәрҗәдә, әдип сөргеннән кайткач кына була.*

*Исхакый, Габдулла Кари Мәкәрҗәдә аның хөрмәтенә "Алдым-бирдем" әсәрен сәхнәгә куя, ди. Ә шул чорда чыгып килгән "Кояш" гәзитәсенең 1913 елгы 26 август санында исә,әдип хөрмәтенә "Мөгаллим" һәм "Өч хатын берлә тормыш"ның ахыргы пәрдәсе куелуы турында әйтелә. Шул кичәдә Гаяз әфәндегә "... "Сәйяр" труппасы исеменнән һәдия уларак алтын чылбыры илә алтын сәгать" бирелә.*

*1917 елгы февраль революциясеннән соң, Г. Кариев Г. Исхакыйның күптән язылып та, цензор тарафыннан тыелган "Зөләйха" пьесасын сәхнәгә куя. Сөргеннән соң Мәскәүдә яшәргә мәҗбүр булган әдип бераздан Казанга кайта, һәм аның үз куелышында "Зөләйха" янә бер кат тамашачыга җиткерелә.*

*Г. Исхакый труппаны һәм аның җитәкчесен 1917 елның 1 маенда Мәскәүдә ачылачак I Бөтенрусия мөселман корылтае вәкилләре алдында чыгыш ясарга чакыра. Шулай итеп, "Сәйяр" Мәскәүнең "Корш" театрында, "урысның үзегендә" татар милләтенең аяныч язмышын сурәтләгән "Зөләйха" трагедиясен сәхнәгә алып чыга. Бу хәл Г.Кариевның да, ялкынлы көрәшче әдипнең дә рухын күтәрә. Тик, кызганыч ки, 1917 елның октябрь бәрелешләреннән соң Г.Исхакый ниятләгән "Сөембикә" әсәре гомумән язылмый, ә 1918 ел ахырында тәмамланган "Юлсызлар" пьесасы исә сәхнәдә уйналмый кала.*

*Революциядән соң ук кабынып киткән гражданнар сугышы вакытында Г. Кариев Уфада яшеренеп ята. Ләкин иҗади эшчәнлеген туктатмый, Г. Исхакый белән дә арасын өзми. Нәкъ менә шушы хәлләрне күздә тотып, Г. Ибраһимов аның турында "...аннан ары Исхаков, Туктаров компанияләренә эләгеп, бераз адашып, ...һәм колчакстанда ...карагруһлар эчендә газап" чикте ди ("Кызыл армия", 1920, 30 гыйнвар, 249 сан).*

*1919 елның азагында Кариев Казанга кайта һәм хәрби коллегия каршында төзелгән татар театрына "хезмәткә керә" ("Габдулла Кариев турында истәлекләр".—Казан, 1967). Ләкин монда эшләү аңа насыйп булмый, артист тиф белән авырып китә. "Сәйяр" труппасының җитәкчесе, мәшһүр артист Габдулла Кариев 1920 елның 28 гыйнварында вафат була.*

*Шулай итеп, 1905 елгы инкыйлабтан соң яңа аякка басып килгән милли әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез Г. Исхакый һәм Г. Кариев кебек көчле рухлы, сәләтле, күренекле юлбашчыларсыз, үксез кала.*

**Алсу КӘРИМОВА,**
*А. М. Горький музееның фәнни хезмәткәре,*
*КДУ аспиранты*

# АРТИСТ ГАБДУЛЛА КАРИЕВ

Милли театрымызның тууында, үсүендә мәгълүм бер юлдан баручы, театр уйнаучыларымызның житешеп, "Сәйяр" труппа булып өлгереп, сәхнәмезнең милли төстә гәүдәләнүендә Габдулла Кариевның уйнаган роле, Г Тукайның шигырь сәхәсендә уйнаганынңан ким түгелдер.

Габдулла Кари таркау театр һәвәскәрләремездән үзенең коручы, төзүче көче берлә,

үзләрендә белмәгән теләкләрен вөҗүдкә *(өскә)* чыгаручы, тормышымызга яңа милли барлык тугъдыручы кадерле милли хидмәтчеләремездер. Үлгәненә 16 ел гына үткән бу бөек артистымызның туганына гына да илле генә ел. Ул үзенең кыска тормышында безнең мәдәни үсү тарихымызда һичбер онытылмаячак эзләр калдырды. Безнең яшь театрымызның үсүен, алга китүен һич бер аерылмый торган итеп үзенең исеме берлә барлады һәм аны мәдәни тормышымызда мәңгеләштерде.

Соң Габдулла Кари кем иде? Бу зур көчне ул кайдан алды? Бу сөальләргә җавап бирү бүген минем максадым түгелдер.

Бу хакта киләчәктә мөтахассыйслар *(белгечләр)* язарлар. Мин Габдулла Кари берлә, үземнең театр китаплары язучы сыйфаты берлә багланышымны вә шул арадагы тәэсирләремне генә бераз сөйләп үтмәкче булам.

Габдулла Каринын чын исеме—Миңлебай, гаилә исеме—Хәйрулла. Атасы-анасы фәкыйрь авыл кешеләре генә булсалар да, угылларын авылның галим имамы Фасах Хажи (Фуад Туктаровның атасы) мәдрәсәсендә укытканнар. Аннан соң Җаек шәһәренә барып, анда бер мәдрәсәгә кергән вә шунда Коръән хафиз булып карый исемен алгандыр. Габдуллага үзенең исеме "Миңлебай" мәдрәсәдә үк бик ямьсез кебек сизелгәнгә, ул шуңардан качарга ижтиһад иткән. Гаилә исеме "Хәйрулла" да мужик исеме төсле күренгәнгә, ул аны да бер дә сакларга теләмәгән. Хәтта үзенә шундый тупас исемне биргән өчен авылның имамы Фасах хәзрәткә үпкәли иде. Шул үпкәсен аның углы Фуад Туктарга каршы да саклап килә иде. Артистлыкка кереп китәргә имкян булгач та, ул иң элек җаны сөймәгән исемен үзгәртеп, Габдулла Кари (Кариев) булып киткәндер.* Ул шул исемдә бөтен төрек дөньясына танылып, шул исемдә милли театрымыз берлә баглангандыр.

Мин, шәхсән, Г.Карины беренче мәртәбә сөргеннән кайткач, 1913 нче елның көзендә мәкәрҗәдә очраттым. Аның оештырган "Сәйяр" труппасы** белән дә шунда гына таныштым. 1907 елда мин Казанда кулга алынып, Архангель губернәсенә 3 елга сөргенгә күндәрелгән *(җибәрелгән)* идем. Шул сөргеннән качып кайтып, Петербургта, Истанбулда, Финляндиядә яшәсәм дә, Казанга килә алмаган идем. Г.Каринның милли театр ясаудагы уңышларын вә минем бик күп әсәрләремне куюларын, гәзитәләрдә укып, ишетеп белсәм дә, нә театрны күргән идем, нә Габдулланың үзе берлә, нә труппасы берлә танышырга форсат булган идем. Габдулла Карый булмәмә күрешергә килгәндә, оялчан гына, тәрбияле генә бер яшь егет хиссиятен калдырды. Озын сөйләшеп утыра алмадык, әллә кемдер килде. Берәр көннән соң ул үзенең труппасының икенче дәрәҗә рольләрдә булына торган артисты Вәлиулла Мортаза берлә килде, вә мине театрга чакырды. Минем хөрмәтемә дип, минем бер әсәремне дә куярга теләүләрен сөйләде. Бераздан соң минем "Алдым-бирдем"не куеп, минем хөрмәтемә бер зыяфәт *(кунак иту, сыйлау)* дә ясадылар, труппа исеменнән бүләк бирделәр. Мин беренче мәртәбә үземнең әсәремнең милли труппа тарафыннан уйналуын шунда күрдем. Бу күрешүдән соң без, киләчәктә милли репертуар ясау хакында күп сөйләштек. Мин моңарчага кадәр "Сәйяр" труппасының уйнаучыларыннан үземнең әсәрләрем өчен гонарар алмаганым кеби,*** моннан соң да алмаячагымны сөйләдем. Г.Кари минем яна әсәрләремнең басылмас борын ук үзенә бирелүен рижадә булынды *(үтенде)*. Мин дә берничә әсәремне бирдем. Үз тарафымнан мин дә "Сәйяр" труппа хөрмәтенә бер зыяфәт бирдем. Бу вакытларны "Сәйяр" труппа инде Казанда йерләшеп уйный башлаган вә сәйярлеге җәйге айларга гына калган иде. Мәкәрҗәдә "Самакат" дигән бер йердә бер иске театрны тотканнар иде.

Бер көнне әллә ниндидер эшем чыгып, Г.Карины театрда очратырмын уе берлә көндез театр бинасына киттем. Ишекне ачып эчкә керсәм, көтелмәгән бер манзара алдында калдым. "Сәйяр" труппаның зур артистларыннан Гөлсем Болгар, Мәрфуга Мортаза, Сара Байкин кулларын сызганганнар да театрның идәннәрен юалар. Кәрим Тинчурин, Вәлиулла Мортаза, тагын берничә артист чиләк-чиләк су ташыйлар. Габдулла Кари да урындыкларны күчерә. Бүген булачак театрга бинаны паклау, арулау өчен кирәк булганда кеше яллап эшләтүләргә акчалары юк күрәмсең дә, үзләре шуны эшләп яталар. Минем шундый хәлдә үзләрен очратуыма труппа әгъзалары, хосусән *(аеруча)*, хатын артистлар оялдылар. Ләкин мин үзем, аларның ничек труппа булып яши белүләренең төп мәгънәсен аңлап, боларның һичбер эштән бу "кара" дип тартынмауларын күреп, киләчәктә дә үсәчәкләренә сөендем. Вә аларның күңелләрен күтәрә торган сүзләр сөйләдем.

1915 нче елның башлары иде. Г.Каринның авырып китүе, һәм дә бугаз чахоткасы алуы хәбәре йөри иде. Габдулла берлә язышкан мәктүпләремездә, аның дәвалануына ихтыяҗ зурлыгы, Кырымга китәргә кирәк булуы, ләкин акча юклыгы тотып торуы мәгълүм булып кала иде. Мин дә Кырымга китәргә димлим, акча табуда берәр төрле ярдәм итешүнең чараларын эзләүне

беллерә идем. Көннен берендә идарәмезгә Г.Кари килеп керде, ябыккан, рухи төшенке бер хәлдә, авырлыгының начарлыгыннан зарлана: "Тузан эчендә урамнан җыйнаган егет-кызларны уйнарга үгрәтә-үгрәтә, аларга кычкыра-кычкыра менә шулай булдым, менә инде тавышым бетте, артислыгым сүнде",—кеби өметсез-өметсез сөйләнә иде. "Ил" идарәсендә әүвәл вакытта кәтәбә булып Нәҗип Гасрый эшли иде. Ул әдәбият—театрны бик сөюче, нәфәсәтне аңлаучы, Истанбул дәрелфөнүненен уку йортының әдәбият шәгъбәсен *(төркемен)* тәмам иткән бер егет иде. Габдулла Карины бик таный, анар бик зур хөрмәт итә иде. Сөйләшләремездә ул да бергә иде. Без Нәҗип берлә күзгә-күз карашып, Габдулланың рухын күтәрү кирәклеген аңладык. Нәҗип әдәбияттан тотынды. Мин шуны форсат булып, телефонга чыгып, мәрхүм Габдулла Бурнашка (*"Ил" газитәсенең нәшере*) телефон берлә Габдулланың хәлен аңлаттым вә аны бүген кичке ашка чакырырга, үзара утырышырга дәгъвәт итәргә (*чакырырга*) үтендем. Яшьләрнең шул арала бер мәҗлесләре булачак иде, Шәйхулла Алкинга телефон итеп, алардан да чакырырга вә тиз үк рәсман (*рәсми рәвештә*) килеп күрешергә әйттем. Тагын кемгәдер, театр сөйгән яшьләрдән берсенә Мәскәүнең зур театрларыннан берәрсенә билет тәкъдим итүне рижалә булындым (*үтендем*). Үзем берни булмаган кеби бүлмәмә кереп сүзгә кушылдым. Сөйләшү дәвам итеп, берничә минут вакыт кичмәде, телефон килде. Идарәдәге эшче аны минем бүлмә берлә берләштерде (телефонымыз ике япьле иде). Телефонда Габдулла әфәнде Бурнаш Г.Карины сорый иде. Электән таныш булганга, шактый озын сөйләштеләр. Хәл-әхвәл сорадлы. Кайвакыт вакыты барлыгын белеште. Аның артыннан берничә минут үтмәгән, Мөршидә ханым Бурнаш телефон итеп, Г. Кари берлә сөйләшеп, безне кичке ашка дәгъвәт итте (*кунакка чакырды*). Ул бетмәгән иде, Шәйхулла берлә бер студент килеп, Г.Карины үзләренең яшьләр мәҗлесенә чакырды. Берничә минуттан берсе килеп, Мәскәүнең "Сәнаигъ нәфисә" театрына берничә көнгә билет китерә килде. Өйлә ашына чыгамыз дип торганда гына, Гали Кормай килеп керде, безне Мәскәүнең бер ресторанына алырга килүен белдерде (Анар Нәҗип телефон итеп өлгергән икән). Чыга башлаганда инде, Габдулла бик күп үзгәргән, йөзенә көләч чыккан, күзләре нурланган иде. Ишек төбенә җиткәндә, Габдулла күзе берлә бер нәрсә эзләргә тотынды. Әллә берәр киемен-фәләнен эзлиме, дип сорадым.

—Юк, ул түгел, монда бер серле нәрсә булырга кирәк, шуны эзлим,—диде. Күзе безнең телефон чолганышына очрап:—Таптым, бүгенге бу эшләрне барсын да шул эшләде. Бик шәп нәрсә икән, савыгып кайткач, мин дә телефон куйдырам,—диде.

1917 нче ел ихтилялы (*чуалышы*) булу берлә Габдулла Кари, үзенең портфеленнән минем күптән биргән "Зөләйха"мны чыгарып, ихтилялның беренче атнасында ук цензур тарафыннан мәнигъ (*кирта*) беткәч тә, Казанда "Зөләйха"ны куйды. Мин ул вакытта Мәскәүдә җәмәгать эшләре берлә бик мәшгуль идем. Ләкин газитәләрнең язуыннан һәм дә ике атна эчендә "Зөләйха"ның тулы театрда 4 мәртәбә куелуыннан "Зөләйха"ның зур уңышын аңлап алган идем. Тизрәк Казанга барып, шуны күрәсем килә иде. Сөргеннән 13 нче елны кайтсам да, Казан губернаторы мәнигъ иткәнгә, мин монарчы рәсман Казанга керә алмый идем. Берничә мәртәбә берәр көнгә кереп үткән булсам да, болар да качу-посу төсендә генә иделәр. Тагын сөйләнәчәк сүзләр, төзеләчәк планнар да Казанда бик күп иде. Габдулла Кари да "Зөләйха"ны күрергә, вә шулай уйнарга ярау-ярамау хакында "фәтва" (*киңәш*) алырга чакыра иде. Апрель башында Мәскәүдән Казанга киттем. "Зөләйха"ның куелуы игълан ителде. Ләкин "Сәйяр" труппа бу вакытка кадәр, соңгы—фәрештәле пәрдәсен куя алмаган иде. Мин аның куелуына әсрар (*серләрен*) әйттем. "Зөләйха"ның уйналуы зур бер бәйрәм төсен алды. Галәттән тыш уңышлы чыкты. Мин "Сәйяр" труппаны Мәскәүдә беренче майда башланачак Бөтен Русия мөселманнары корылтае вакытына чакырдым. Габдулла Кари бөтен труппасы берлә бергә килеп, корылтай вакытында Мәскәүнең иң зур театры "Корш"та "Зөләйха"ны 4 мең халык алдында куйды. "Зөләйха"да уйнаучылар бик күп булганга, Габдулла корылтайга килгән вәкилләр арасыннан әллә никадәресен сәхнәгә чыгарган вә туй сәхнәсен бик матур җырчылар, биючеләр берлә баеткан иде. "Зөләйха"ның Мәскәүдәге уңышы, һәм дә Мәскәүдә урысның үзәгендә "Зөләйха"ны куя алу аның рухын бик күтәргән иде, цензурның бетерелүе анар киң имкян (*мөмкинлек*) ачкан иде. Ул "Зөләйха" берлә Кавказ, Төркестан, Кырымда турнэ ясарга хәзерләнә, вә миннән берничә әсәр таләп итә иде. "Сөембикә"не тизрәк язарга кызулый иде. Ләкин ихтилял һаман тирәнәеп китеп, җәмәгать хадимәләрен (*хезмәткәрләрен*) бинниһая күп эшләр берлә томалап килгәнгә, мин дә ул әсәрләрне яза алмадым. Юллар бозылып, дөнья большевиклашып киткәнгә, Габдулла Кари да турнесына чыга алмады. Без инде аның берлә 18 нче елның көзендә Уфала очраштык. Казанда большевиклар берлә чехлар сугышы көннәрендә Г.Кари кемнән курыкканын белмәенчә, кемнән качканын да уйламаенча вапурга утырып, Казаннан Сембергә киткән, аннан акрынлап Самара аша Уфага килеп чыккан иде. Ләкин

бөтен труппасы, ун елдан артык җыйган репертуары, "Сәйяр" труппаның баеп өлгергән, театр өчен кирәкле кием-салымы, театр әсбабы—бар да Казанда калганга, күңеле бер дә тыныч түгел иде. Һәм дә мөмкин кадәр тиз Казанга омтыла иде. Үзе табигатеннән батыр булмаганга, большевикларга кайтырга курка иде. Карарсыз көенчә, Уфада яшәп тора иде. Шул вакыттагы Уфадагы күңелләләрне (*доброволецларны*) оештырып, "Зөлайха"ны бер мәртәбә уйнады. Без, милли идарә әгъзалары, Себергә күчеп китә башлагач, Уфада калырга булды. Большевикларның керүе көне-көне берлә көтелгәнгә, беренче көннәрдә үтерелеп ташламас өчен, Г. Кари әллә нинди начар киемнәр киенеп йөрергә башлады. Урынын да шәһәрдән күчереп, Уфаның Идел буендагы, Иделдән ага торган салларны угырлый торган караклар мәхәлләсенә күчте. Агач, утын угырлап кына көнен кичерә торган, һичбер буржуй булмаган бер урыс әбисенә кечкенә бер бүлмәгә йирләште.

—Мин инде монда большевиклар кергәнне көтеп калам да, Казанга китәм,—диде. Без Себергә киттек. Кызылъярда урнашып, милли идарәне корып, "Маяк" гәзитәсен тәэсис итеп (*оештырып*), милли эшкә керештек. Көннәрнең берендә Кызылъяр (*Петропавловск*) шәһәрендә уемда утырганда, янындагы бер иптәш артисты берлә Габдулла килеп керде. Мин дә гаҗәпкә калдым. "Нишләп йөрисең, ник Казанга китмәдең?"—дидем. "Уфада адәм гакыллы кеше калмады, большевиклар шәһәрне алалар, дип көтеп тордым-тордым да, туйдым. Сал караклары берлә тору да бик шәптән түгел икән. Тагын большевиклар Чишмә (*Башкортостандагы шәһәр*) янындагы сугышта җиңелеп киттеләр. Мин фронтны ярып кайтырга курыктым. Монда килдем. Минем мондалыкны беркемгә белдермик әле",—диде. Шул арада Иркутскиның бер сәүдәгәре: "Мин китеп барам, күрешергә генә кердем",—диде. Мин дә аның артыннан Иркутскига хатлар биреп, сәламнәр әйттем: "Тагын кайчан киләсең?",—дип сорашып, аңар Иркутскидан чын чәй китерергә куштым. Габдулла безнең бу сөйләшүләрдә бер сүз дәшмәенчә, үзенең исемен дә яшереп, тик кенә торды. Теге чыгып китkәч:

—Йә, сөйлә, планың ничек?—дидем.

Габдулла:

—Мин әле синең Иркутскига чәйләр асмарлануыңнан монда андый-мондый курку юклыгын күрдем. Тынычланып киттем. Алай булса, монда әле бүген, әле иртәгә үзара сугыш булмый, дип уйлыйсыз,—диде.

Мин: "Юк, юк",—дип, килгән-килгән мондагы яшьләрне оештырып, бер труппа ясап, театрлар куярга киңәш бирдем. Үземнең яңа бер әсәр язып ятуымны аңлаттым. Икенче көнне инде Г. Кари җирле һәвәскәрләр берлә сөйләшеп, "Таһир берлә Зөһрә"нең хәзерлекләренә башлады.Аны бик зур муаффиккыять (*уңыш*) берлә үткәрде. Минем яңа язып бетергән "Юлсызлар"ымны үгрәтергә тотынды. Игълан чыгарды, билет сата башлады, театр алды. 1-2 көннән, уйналырга хәзерләнеп җиткәндә генә, театрның бинасын гаскәрләр үз кирәкләренә алдылар да, вә әллә нинди гаскәр кирәк-ярагын тутырдылар. Башка бина Кызылъярда табылмады. Габдулла Кари "Юлсызлар"ны уйный алмый калды. Мин дә үземнең соңгы әсәремне сәхнәдә күрми калдым. Ләкин вакыты, форсаты булганда уйнарга дип, "Юлсызлар"ны Г.Карида калдырдым. Үзем солых хәяты әгъзасы сыйфаты берлә, Япония аша, 19 нчы елның башларында Аурупага киттем.

Габдулла Омски, Томски, Иркутскиларда театрлар куеп йөрергә булып, Кызылъярда калды. Бу минем Г. Кари берлә соңгы вә актыккы күрешүем булды. Ул бик озак төрле җирләрдә әллә кемнән куркып, әллә кемнән качып йөргәннән, большевиклар йирләшеп беткәннән соңында Казанга кайткан. Анда тиф берлә авырган. Большевиклар аны терелер-терелмәс: "Себердә акларга уйнап йөрдең бит, монда пролетариатка уйнарга теләмисең",—дип куркытып, ачыклы-тишекле салкын театрда сәхнәгә чыгаралар. Шунда ул бик каты суык тидереп, өзлегеп китә, вә савыга алмаенча, 1920 нче елның 28 нче гыйнварында вафат итә. Минем дә аның берлә танышлыгым шунда өзелә.

**Гаяз ИСХАКЫЙ,**
*Варшау.*

ИСКӘРМӘЛӘР:

* Казанда 1926 елда "Татар театры" исеме берлә чыккан китапта, хәлфәсе Зариф мулла үз мәдрәсәсендә үк аның исемен Габдулла исеме берлә алыштыра һәм "Минлебай" дип өндәүчеләргә җавап кайтармаска кушкан, дип язылган. (*Гаяз Исхакый.*)

** Бу исем "Тәрҗеман"да Исмәгыйль бәк тарафыннан бирелгән. (*Гаяз Исхакый.*)

*** Театрларда уйналган әсәрләрнең мөхәррирләренә каләм хакы түләп килəләр. (*Гаяз Исхакый.*)

# *Шәрәф Мөдәрриснең тууына 80 ел*

*Шәрәф Мөдәррис әдәбият мәйданында эзләнүчән шагыйрьләрнең берсе иде. Шуның аркасында безнең китап киштәләрендә төрле телләрдән тәрҗемә ителгән байтак әсәрләр тупланды. Көнчыгыш шагыйрьләренең иркен сулышлы, фәлсәфи әсәрләре аның күңеленә бик якын булды. Үзе дә «Тупчы Ваһап» поэмасын, «Берлинга», «Кояш чыга» һ. б. шигырьләрен шул үрнәктә иҗат итте. Каләмдәшләрнең кайберләре моны Шәрекъ-Көнчыгышка табыну дип карады, бер җыелышта тәнкыйтьләп чыгучылар да булды.*

*Гомеренең соңгы елларында ул Көнбатыш поэзиясе белән дә мавыга башлады. Сонет, октава, оратория формаларын файдаланып иҗат итте. Пушкин сонетларын, итальян сонетларының (Петрарка, Данте) русча тәрҗемәләрен табып алды. Үзе дә, татар шигъриятендә беренче буларак, «Сонетлар бәйләме» иҗат итте. Аның бу хезмәте республика матбугатында, «Москоу Ньюс» газетендә уңай бәяләнде. Шуннан соң ул Шекспир сонетларын оригиналдан тәрҗемә итү теләге белән яши башлады. Үзлегеннән инглиз телен өйрәнеп (телләр өйрәнүгә сәләтле иде), урыс телендәге тәрҗемәләрен өйрәнеп чыкты. Татар һәм инглиз телләренең грамматикасы, фонетикасы үзара якын, тәрҗемә иткәндә русча хезмәтләрдәге кайбер төгәлсезлекләрдән котылып булыр дигән фикергә килде. Бу турыда ул Маршакка хат та язып җибәргән иде. Ләкин Мәскәүдәге зур шагыйрьнең үзенә билгесез кеше белән бәхәсләшеп, вакланып торасы килмәде, ахры, җавап булмады.*

*Шагыйрьнең яратып, бирелеп эшләгән хезмәте—Шекспир сонетларының оригиналдан тәрҗемәсе тулы көе аерым китап булып басылып чыкты. Хәзер аны кайбер китап сөючеләр кулында гына күрергә мөмкиндер.*

*Ноябрь аенда Шәрәф Мөдәрриснең тууына 80 ел тула, шул уңай белән аның иҗат хәзинәсеннән кайбер әсәрләрен искә төшереп китү артык булмастыр.*

Ләбибә ИХСАНОВА

## Шәрәф Мөдәррис

### «СОНЕТЛАР БӘЙЛӘМЕ» ЦИКЛЫННАН

* * *

**Бер гаҗәп матур кыз гомер күгемдә,**
**Кояштай нур чәчеп, яктырып тора;**
**Көн димәс, төн димәс, һаман күңелдә**
**Мәхәббәт ялкынын яндырып тора.**

**Җемелдәп нур уйный сихри күзендә,**
**Әйтәчәк сүземнән яздырып тора;**
**Сизәдер, ут күп, дип, йөрәк түремдә—**
**Сабырлык янгырын яудырып тора.**

Ул кыз гел шул яктан аерылып тора.
Мин, ярсып, хисләргә артык бирелсәм,
Ул, охшап дулкынга, чигенеп китә,
Беркадәр ял һәм тын алдырып тора.
Шул вакыт назланып, мин дә чигенсәм,
Ул тагын артымнан йөгереп җитә.

* * *

Көн матур. Безгә дип туган гел менә!
Икәүләп загстан чыгып барабыз...
Бәхетне сөйләргә җитми тел генә,
Көләбез һәм кинәт моңга талабыз.

Син—минем гомерем. Син—ул бер генә!
Без бүген семьяга нигез салабыз.
Кавышкач, тормышта, бәлки—кем белә?—
Шалтырап куйгалар савыт-сабабыз.

Сөеклем, мин сизәм, андый чакларда
Тынычлык бизмәнен тигез сакларга
Булышыр һәм кушар сабый балабыз.
Бәйләнде, чибәрем, чәчебез чәчкә,
Һәм бик үк зур түгел болай чамабыз:
Җитәргә, яшь булып, йөз дә ун яшькә!

## Язгы октавалар

Без: «Яз»,—дидек тә... Урамда—буран,
Килмәде шул юш безнең юраган.
Юктыр мондый җил—сулышны буган,
Карны бетереп, ярсып улаган!
Кайсы иблиснең базында туган
Мондый кар-буран, мондый ураган?
    Тик шунда күрәм: бәхеткә каршы,
    Төште түбәдән беренче тамчы.

Мин кырда түгел, далада түгел—
Тымат нык өйдә—әйбәт барысы!
Әмма нигәдер шомлана күңел,
Ишетелсә төнлә буран тавышы.
Җил елый, сыкрый, әйтерсең бу—гел
Яшьли тол калган әнкәм сагышы.
    Әнкәм шул вакыт сизәдер төсле
    Язгы бураннан—миндәге көчне.

Җил-буран тынып, дөньяны ачкан,
Калдырып күктә каурый болытын.
Таң атлый менә, ерактан, астан
Сузып болытка алтын кылычын.
Алсу канатлы тантана япкан
Мәһабәт, тыныч кояш чыгышын.
    Күрде кебек яз кышкы көн чиген,
    Сузып офыктан кояшның читен.

Буй-буй тоташ кар—кырлар киңлеге,
Алган тылсымлы тынычлык басып.
Төнлә гөжләгән ак кар диңгезе
Калган күк иртән шикәрдәй катып.
Шагыйрь кәгазе, рәссам киндере—
Ап-ак тыныч кыр! Рәхәт бер вакыт!
Торырмы кояш эшеннән туктап?
Эреп йомшара калкуда туфрак!

Чаба кояшның алтын фаэтоны,
Ашкына алга, биеккә—күккә.
Кардагы көчле, үткен балкуны
Күтәрә алмый, яшь тула күзгә.
Тәхете итеп алтын калкуны,
Язгы яңгыраш утырган түргә.
Кояш һәм саф җил—мәһабәт көчләр
Бәйли кырларда пыяла челтәр.

Карасам базга: аптырап калам,
Кайда бәрәңгем?—Ак җеп җәтмәсе.
Суган, кыяклап, йомшаган тәмам.
Калмаган да күк ашар нәрсәсе.
Фонарем йөртеп тагын күз салам:
Кишер, чөгендер—үргән һәммәсе.
Караңгы базда сизәләр диген
Язның сулышын, басулар җилен!

Җим салыр хәл юк, кулымны чукый,
Ышылдый, гыжылдый—яшь үрчем кыйбат!
Тышта ата каз тик берне тукый:
«Чыгып кер», имеш, «как-как» та «кыйгак!»
Чыкса ана каз, эшеннән бушап,
Һич тыңгы бирми яшь салам сыйрак:
Беренче сүзе: «Әйдә тот кыска,
Бәбкәләр тизме чыгарлар тышка?»

Мышный, көчәнә, борынын тарта,
Баткылдык ясый кешегә Рөстәм.
Бераздан шунда әйләнеп кайта,
Карасаң, Рөстәм чокырга төшкән!
«Нигә билгеләп китмәдем башта,
Саграк узмадым ник соң бу төштән?»
Җылама, Рөстәм, файдасы булмас,
Үз кулың белән казылган ул баз.

Таягын тоткан , килә урамнан,
Туктап кашларын җыерып тора.
Гөрләвек акмый, көче югалган,
Тын күлгә охшап, җыелып тора.
Бөтен дөньяда иркен юл алган
Шат яз ник монда җыелып тора?
Ергалый бабай, таягын йөртә:—
Әйдә, ак та ак! Буылма бер дә!

Оста куллысы тарта гармунын,
Тышта—җыр, көлке, шау-шу да чыр-чу.
Ныклап уйласаң ние бар моның?
Тик мин нигәдер күңелсез, моңсу.

Миңа кырык өч! Шулмы бар моңым?
Саламы шул сан күңелгә борчу?
Мәхәббәт эретә тышта яз бозын,
Бүлмәмдә—үзем, урамда—кызым.

Билдән чыланып, суга манчылып,
Малайлар керде, битләре янган.
—Апагыз кайда?..—Әмма, тартынып,
Улларым миңа сиптерә ялган.
Кызым да керә, балкый таң кебек,
Яшьлек иртәсе—беренче яздан.
Ваемсыз гына яткан да булды,
Йокы аралаш елмаеп куйды.

«Мәхәббәт,—диләр,—яшьлек эшнәсе».
Тузга язмаган бу ни сүз тагын?
Кояштай балкып кайтты энкәсе,
Хөрмәтләп карыйм ишәйгән чалын.
Һәр бөртек чалның бар күк әйтәсе
Иркәм кичергән борчулар санын.
Көмеш кылларны күбәйтеп шулай,
Балалар һәм мин ярыштык бугай.

Зәңгәр читләрен өскә күтәреп,
Ярга сыешмый бозлар тыгыла;
Өлгерми күпер барсын үткәреп,
Субайлар сыкрый, басма сыгыла.
Ярдагы халык калмый искәреп,
Бичара күпер, изелә, сытыла.
Әйтә күк ташкын: гомерең узган,
Бирмәсәң ирек—үзең кит юлдан.

Кемдер ут яккан зур боз өстенә,
Бара ул дөрләп, төтен уйнатып.
Артында кала тар бер эз генә,
Барса да күкрәп, ерып, юл ватып.
Шул боз, шул учак—сәер эш менә:
Бала чакларны китте уйлатып.
Сүнәр боздагы бәләкәй ялкын,
Шатланам ләкин: мин дә бер яндым.

Гомер таңымда дәртләнеп яндым,
Тиле яшьлекнең ләззәте белән.
Утлар аркылган елларда бардым
Илемнең ачы хәсрәте белән.
Рухым сынганда янә көч алдым
Батыр йөрәкле халкымнан гелән.
Бөтен тормышым, эшләгән эшем—
Дусларым белән җыйган җимешем.*

*1962*

---

* «Язгы октавалар» шагыйрьнең соңгы әсәре. Мин аны, Шәрәфнең вафатыннан соң, кәгазьләре арасыннан табып алдым. Әнә шулай, кешеләргә якты язны, бәхетле тыныч елларны, тату гаилә тормышын васыять итеп киткән ул бу якты дөньядан. Л.И.

*Казан шәһәренең 1000 еллыгына*

# БЕР КИТАП ЯЗМЫШЫ

«Идел» журналының 1989 елгы бишенче (ноябрь) санында «Чын тарихны азлар белә» дигән баш астында тарихчы Сәлам Алишевның журнал хезмәткәре Газинур Моратов белән әңгәмәсе урнаштырылган иде. Әңгәмә барышында Г. Моратов тарихчы галимгә бик четерекле сорау бирә: «1977 елда Казанның 800 еллык бәйрәме ни өчен үткәрелмәде?» Сәлам Алишев бу сорауга болай җаваплый: «Бу мәсьәләнең уңай хәл ителмәвенә әлеге дә баягы торгынлык гаепле булды, минемчә... Җитәкчеләр әлеге идеяне Казанда да, Мәскәүдә дә хуплап, күтәреп алмадылар».




Бу әңгәмә дөнья күргәннән соң ун ел вакыт үтеп китте. Шул аралыкта археолог һәм тарихчы галимнәребез башкалабыз Казан тарихына бәйле күп кенә яңа ачышлар ясадылар. Нәтиҗәдә Казан шәһәренең 800 еллык кына түгел, 1000 еллык тарихы барлыгы ачыкланды.

Әйе, Казаныбызга—1000 ел! Без аны зурлап бәйрәм итәргә җыенабыз.

Минем исә башкалабызның 800 еллык юбилеен үткәрергә әзерләнеп йөргән көннәргә янадан әйләнеп кайтасым килә. Чынлап та, 1977 елда Казанның 800 еллык бәйрәме ни өчен үткәрелмәде соң? Сәлам Алишевның «торгынлык гаепле булды», «җитәкчеләр Казанда да, Мәскәүдә дә хуплап, күтәреп алмадылар» дигән фикеренә бераз ачыклык кертеп, укучыларга кызыклы бер өстәмә мәгълүмат тәкъдим итмәкче булам.

Әйе, торгынлык гаепле булды. Мәскәү каршы төште. Казанның 800 еллык бәйрәме Бөек Октябрь революциясенең 60 еллык бәйрәме белән кисешә булып чыкты. Әмма бу уңайдан Казандагы җитәкчеләрне дә гаепләү нигезсезрәк булыр. Хәл-вакыйгалар алай «бер каптырмалы» гына түгел иде.

Казанның 800 еллык бәйрәмен үткәрү мәсьәләсе шактый күптән күтәрелеп, ул татар зыялылары—галим-голәмәсе, әдәбият-мәдәният әһелләре һәм, шул исәптән, совет-партия җитәкчеләре тарафыннан да билгеле бер уртак фикергә килентәннән соң гына—үзенчә бик үлчәп-исәпләп кузгатылган иде. КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карары белән бу олуг юбилейны үткәрү буенча дәрәҗәле-абруйлы оештыру комиссиясе дә төзелде. Бу урында ул комиссия составына кемнәр кертелгәнлеген санап тору кирәкмәстер, хәтерем ялгышырга мөмкин. Шуны гына әйтеп үтәм, комиссия утырышлары КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Мөҗәһит Вәлиев кабинетында үткәрелә иде. Әлеге вәкаләтле комиссия бик күп оешмаларга, учреждение-предприятиеләргә Казанның 800 еллыгын үткәрүгә кагылышлы бурычлар йөкләде.

Шундый бурычларның иң мөһимнәреннән берсе СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты белән берлектә Татарстан китап нәшриятына да йөкләтелде. Бик кыска вакыт эчендә олуг юбилей көннәренә берничә басма китап нәшер итәргә кирәк иде.

Ул вакытта әзерләнеп тә, дөнья күрә алмый калган китапларның барысына да тукталып тормастан, чыкса да, имгәтелеп басылып чыккан бер китапның тарихын сөйләп бирергә телим.

Мин ул елларда Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире булып эшли идем. Шул сәбәпле, юбилейны оештыру комиссиясенең утырышларында катнашырга туры килде.

Шулай итеп, безгә бурычлар йөкләтелде. Бик ашыгыч нәшер ителергә тиешле китапларның берсе Казан кунаклары—туристлар өчен махсус әзерләнгән юлкүрсәткеч басма иде. Ул өч телдә—рус, татар һәм инглиз телләрендә булырга тиеш иде. Шуңа күрә китапның тышлыгы да «Казань. Казан. Kazan» дип (авторлары—В. В. Кузьмин, Ю. И. Смыков, А. Х. Халиков), өч телдә эшләнде. Әмма, вакыт бик тар булу сәбәпле, татарча һәм инглизчә тәрҗемәләре өлгермәде, юлкүрсәткеч басманың бары тик рус телендәгесе дөнья күрде. Һәм, әйткәнемчә, имгәтелеп дөнья күрде.

Миндә бу китапның ике нөсхәсе бар. Бер үк китап, әмма икесе ике төрле! Мин аның берсенең форзац битенә русчалатып болай дип язып куйганмын: «Уникальный, единичный экземпляр, не дошедший до читателя... Печаталась книга к 800-летию Казани. 1977 г.» Ягъни: «Укучыга барып житмәгән, сирәк очрый торган бердәнбер нөсхә... Китап Казанның 800 еллыгына басылган иде. 1977 ел.»

Хикмәт нәрсәдә булды соң?

Йөз мең (!) тираж белән нәшер ителгән бу юлкүрсәткеч басманың бер өлеше дәрәҗәле кунакларга сувенир бүләк итеп бирер өчен тәгаенләнеп, аңа Казанның күн-галантерия товарлары житештерә торган фабрикасында бик яхшы күнгә Сөембикә манарасы рәсеме төшерелгән супертышлык та ясатылган иде. Теләгәндә, аны акча янчыгы—бумажник итеп тә файдаланырга мөмкин иде. Кызганыч, кулыма керсә дә, мин ул тышлыкны саклап кала алмадым... Аны жыеп алдылар. Китапның да йөз меңле тиражы юкка чыгарылды: туралып, макулатурага озатылды. Җилгә очкан никадәр чыгым! Җилгә очкан тарих!

Инде әлеге китапның икенчесенә күз салыйк. Монысы шулай ук йөз мең тираж белән исән-имин нәшер ителде. Юк, ул бер дә юлкүрсәткечнең төзәтелгән икенче басмасы түгел. Ул һаман да беренче! Ә тегесе, минем кулда бердәнбер нөсхәсе сакланып калганы, әйткәнемчә, юк ителде.

Ике китапны чагыштырып укып утырам.

Юк ителгән китапның Казан турында өченче битендәге «Она основана в 1177 году» («Аңа 1177 елда нигез салынган») дигән жөмләсе дөнья күреп сатуга чыгарылган нөсхәдән төшереп калдырылган. Беренче китапның 6 битендә «Казань была заложена в 1177 году булгарским царем Ибрагимом» («Казан 1177 елда болгар ханы Ибраһим тарафыннан нигезләнгән») диелсә, икенче китапта янә дә «В 1177 году» дигәне төшерелгән. Беренчесенең 15-16 битләрендәге «К своему 800-летию, исполняющемуся в 1977 году, Казань подходит с населением в I миллион человек» («Үзенең 1977 елда тулачак 800 еллыгына Казан 1 миллион кешеле халкы белән килә») дигән жөмлә дә икенче китаптан юкка чыккан. 17 биттә беренчесендә «Важнейшие даты истории Казани» дигән бүлектә «1177 г. Основание Казани» дип язылса, икенчесендә ул инде «XIIв. Основание Казани» дип үзгәртелә.


Алга таба чагыштырыйк.

33 бит. Беренчесендә: «В XII веке, точнее в 1177 году» («XII гасырда, төгәлрәге 1177 елда»). Икенчесендә: «В XII веке, в феодальное время» («XII гасырда, феодаллык чорында»).

62 бит. Беренчесендә: «14. В настоящее время здесь расположился исполнительный комитет Казанского городского Совета депутатов трудящихся—штаб по руководству огромным, сложным и многогранным хозяйством и культурой миллионного города» («14. Хәзерге вакытта биредә хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр Советы—миллионлы шәһәрнең зур, катлаулы һәм күпкырлы хужалыгы һәм мәдәнияте белән житәкчелек итү штабы урнашкан»). Икенчесендә бу жөмлә бөтенләй юк.

Бу урында тукталып янә бер ачыклык кертеп узарга кирәктер. Шул кадәр көч куеп, туристлар өчен кирәкле юлкүрсәткеч итеп әзерләнгән китапны бөтенләй юкка чыгару, аны нәшер итмәү гафу ителмәслек хата булыр иде. Шуның өчен дә,

житәкчелек белән килешенеп, аны «төзәтеп» (чынлыкта—имгәтеп!) чыгарырга карар кылынды. Инде Казанның 800 еллыгын бәйрәм итү Мәскәү тарафыннан тыелган иде. Шунлыктан бу китапның текстын (бәхеткә, аның наборы әле таратылмаган, исән иде) цензура янадан бик җентекләп карап, «чистартып» чыгарга тиеш булды. Алай гына да түгел, туристларга шәһәрдә карап йөрергә тәкъдим ителгән маршрутларның схемалары төшерелгән сызымнар Түбән Новгородка (ул вакыттагы Горький шәһәре) җибәрелде. Китапны беренче тапкыр ашык-пошык әзерләгәндә без ул хакта «онытып җибәргән» идек. Түбән Новгородта СССР Дәүләт картография идарәсенен Идел буе филиалы дигән оешмасы бар иде. Мөгаен, хәзер дә бардыр. Безгә менә шул оешма рөхсәте кирәк булды. Рөхсәтне бирүен бирделәр... Ләкин, схемалардагы маршрут саннары калдырылса да, (ә кайбер очракларда алары да алынып) аерып күрсәтелгән йортлар шәһәр кварталлары эчендә «йотылырга» тиеш булып чыкты. Мисал өчен бер схеманың ике вариантын китерәбез. Алар китапларның 56 битендә һәм китап соңында кушымта итеп тә бирелгән. (Рәсемгә карагыз.) Күрәсезме, аерма нинди? Игътибар итегез: беренче схемада «14» саны белән күрсәтелгән йорт—әлеге дә баягы Казан шәһәр Советы башкарма комитеты бинасы—икенче схемада буялган гына түгел, аның «14» саны да алып ташланган. Һәм китапта «13» санына сон ук «15» саны килә. Мондый төшерелеп калдырылган саннар байтак. Шулай итеп, беренче китапның корректурасын укыганда уяулыкларын югалткан өчен шактый кыен ашаган сизгер цензорларыбыз бу бина турындагы җөмләне сызып ташлаганнар. Юкса, бу мәгълүматның шпионнар кулына эләгүе бар бит, Аллам сакласын!




Чагыштыруыбызны дәвам итик.

64 бит. Беренче китапта: «Теперь здесь находятся некоторые учреждения исполнительного комитета Казанского городского Совета депутатов трудящихся (управление благоустройства, отдел народного образования и др.) («Хәзер бирелә хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитетының кайбер учреждениеләре (төзекләндерү идарәсе, халык мәгарифе бүлеге һ. б.»). Икенче китапта бу җөмлә юк. Нинди мөһим яшерен объектлар, диярсен! Ә бит юкса 63 биттә һәр ике китапта да шәһәр Советы бинасының рәсеме бирелә. Димәк, цензорлар тагын уяулыкларын югалтканнар! Аннары шәһәр карап йөргән туристлар ул «яшерелгән» биналарның исемнәре язылган язулы такталарны күрми узалармы?

70 бит. Беренчесендә: «... напротив—в доме № 8—размещается Главпочтамт. Здесь же—междугородный телефон, телеграф, сберегательная касса, в киоске «Союзпечать» всегда имеются свежие газеты и журналы на русском и татарском языках, а также на языках народов ряда зарубежных стран» («Каршыда—№ 8 йортта—Главпочтамт урнашкан. Шунда ук—шәһәрара телефон, телеграф, саклык кассасы, «Союзпечать» киоскысында рус һәм татар телләрендә, шулай ук кайбер чит ил халыклары телләрендә яңа газета һәм журналлар һәрвакыт булып тора». Бу җөмлә «21» саны белән бирелгән. Шуннан ике җөмлә ары «22» саны белән: «После Октябрьской революции здесь располагался Народный комиссариат юстиции ТАССР. Сейчас здесь находятся Министерство юстиции ТАССР, Верховный суд и прокуратура республики» («Октябрь революциясеннән соң биредә ТАССР Юстиция халык комиссариаты урнашкан булган. Хәзер биредә ТАССР юстиция министрлыгы, республиканың Югары суды һәм прокуратурасы урын алган»). Икенчесендә бу җөмләләр юк. «21» һәм «22» саннары да төшерелеп, «20» санынан соң «23» саны китә.

85 бит. Беренчесендә: «36» саны белән «На левой стороне улицы, в доме N 17, разместился Центральный переговорный пункт Казанской междугородной телефонный станции, где Вас могут соединить почти с 200 городами Советского Союза и практически со всеми населенными пунктами Татарской АССР. Здесь же—круглосуточная автоматическая телефонная связь со многими городами страны (в том числе с Москвой, Ульяновском, Свердловском, Уфой, Перьмю, Чебоксарами и др.» («Урамның сул ягында, № 17 йортта, Казан шәһәрара телефон станциясенең Үзәк сөйләшү пункты урнашкан, анда Сезне Советлар Союзының 200 ләп шәһәре һәм Татарстан АССРның барлык торак пунктлары белән дә тоташтыра алалар. Шунда ук—илнең күп кенә шәһәрләре (шул исәптән Мәскәү, Ульяновск, Свердловск, Уфа, Пермь, Чабаксар һ. б.) белән тәүлек буе эшли торган автоматик телефон элемтәсе»). Икенчесендә «36» саны да, бу җөмлә дә юк.

93 бит. Беренчесендә: «46» саны белән «За памятником В. И. Ленину высится красивое современное здание Татарского областного комитета КПСС (1963 г., архитектор Г. И. Солдатов). Здесь расположился центр партийного руководства всей политической, экономической, научной и культурной жизнью республики». («В. И. Ленин һәйкәле артында КПССның Татарстан өлкә комитетының заманча матур бинасы күтәрелеп тора. *(1963 ел, архитекторы Г. И. Солдатов.)* Биредә республиканың барлык сәяси, икътисади, фәнни һәм мәдәни тормышы белән җитәкчелек итүче партия җитәкчелеге үзәге урнашкан.») Икенчесендә «46» саны да, бу җөмлә дә юк. Шулай кыскарткалый торгач, «46» һәм «47» саннары белән күрсәтелгән биналар 92 биткә күчкәннәр.

96-97 битләр. Беренчесендә: «51» саны белән «В доме № 36, в трехэтажном особняке прошлого века, расположились Татарский областной и Казанский городской комитеты ВЛКСМ» («Узган гасырның өчкатлы №36 йортында ВЛКСМның Татарстан өлкә һәм Казан шәһәр комитетлары урнашкан»). Икенчесендә «51» саны да, бу җөмлә дә юк.

Күрдегезме, совет-партия җитәкчелеге үзен ят күзләрдән ничек яшереп саклый!

Беренчесендә шул ук биттә «... клуб имени Менжинского МВД Татарской АССР (дом № 26)» («... Татарстан АССР Эчке эшләр министрлыгының Менжинский исемендәге клубы») дип язылса, икенчесендә «МВД Татарской АССР» сүзләре төшерелеп калдырылган.

118 бит. Беренчесендә: «83» саны белән «Здесь расположилось первое трамвайное депо ( Биредә беренче трамвай депосы урнашкан»). Икенчесендә бу җөмлә юк.

Алга таба беренчесендә (120 бит) «На здании трамвайного депо установлена мемориальная доска» («Трамвай депосы бинасына мемориаль такта урнаштырылган») булса, икенчесендә «трамвайного депо» сүзләре төшереп калдырылган. Әмма трамвайлар тарихы, трамвайлар хәрәкәте турындагы мәгълүматлардан барыбер сүзнең ни-нәрсә турында барганлыгы томана кешегә дә аңлашыла!

122 бит. Беренчесендә: «88» саны белән «В настоящее время здесь находится

Суворовское военное училище» («Хәзерге вакытта биредә Суворов хәрби училищесы урнашкан»). Икенчесендә бу җөмлә юк. Аллам сакласын, суворовчыларны шпионнар урлап китмәгәе!

140 бит. Беренчесендә: «112» саны белән бирелгән җөмләдә Кабан күле турында сөйләнә һәм «средняя ширина 400 м, глубина—8-10 м. Самая глубокая точка (22 м) находится в так называемом «Чертовом углу» Среднего Кабана» («уртача киңлеге 400 м., тирәнлеге—8-10 м. Иң тирән урыны (22 м) Урта Кабанның «Шайтан почмагы» дип йөртелгән җирендә») диелә. Икенчесендә бу җөмлә юк. Янә, Аллам сакласын! Әнә бит Сөембикә ханбикәдән соң Кабанга батырылган алтын хәзинәләрен Бельгия байлары эзләп тапмак булып, фәлән миллиард доллар тәкъдим итәләр, имеш. Киңлеген, буен, тирәнлеген үзең үк әйтеп биргәч, аны, кем әйтмешли, Мәнди анасы да эзләп табачак бит инде! Димәк, сыздыкмы бу җөмләне? Сыздык!

157 бит. Беренчесендәге: «Улица Портовая дважды проходит под железнодорожными мостами. После первого моста справа... После второго виадука,..» («Портовая урамы ике мәртәбә тимер юл күперләре астыннан үтә. Беренче күпердән соң уңда... Икенче виадуктан соң...») дигән сүзләр икенчесеннән төшереп калдырылган. Ә юкса алга таба тимер юл хәрәкәте турында шактый тәфсилле сөйләнә. Янә дә: «Моны кем генә аңламас икән?» дип көлемсерәп куясың.

Тагын да кайбер шундый «вак-төяк төзәтүләргә» тукталып тормыйк. Болай да аңлашылды шикелле.

Әле аның белән генә бетмәде.

Маршрут схемаларына үзгәреш кертеп, аларны кварталлар гына итеп калдырып, карага буяп чыгарырга боерган Дәүләт картография идарәсенең Түбән Новгород (Горький) Идел буе филиалы күрсәтмәсе белән, беренче китапның ахырында бирелгән Казан троллейбус һәм трамвай маршрутлары схемалары икенче китаптан бөтенләй алып ташланды. Трамвай-троллейбуска кергән һәр кешегә ул схемалар чекерәеп карап тора югыйсә!

Хәтерлим, Казанның 800 еллык бәйрәмен үткәрү шаукымына бирелеп, шундый житди хаталар жибәргән ваемсызлыклары өчен кайбер цензор ханымнарга тиешле җәзаларын да алырга туры килгән иде. Баш мөхәррир буларак, миңа да эләкте... Нәрсә булсын инде? Шелтә!

Казан шәһәренең 800 еллык бәйрәме өчен Мәскәү белән ике арада барган көрәш-низагның бер кечкенә сәхифәсе әнә шундый булды.

**Марс ШАБАЕВ**



Китап күзәтү

# ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ҖЫР

Татар халкының яшәеше бик борынгы чорлардан ук җыр белән бергә үрелеп барган. Бала туып, бишектә тирбәлә башлагач та, ана әнкәсе яисә әбкәсе җыр көйләгән. Үсә төшкәч, озын кышкы кичләрдә берәр өйдә утырмага җыелып, «Йосыф-Зөләйха» китабын көйләп укыганны тыңлаганнар. Тегеяки бу хезмәт белән бәйле өмәләр дә җырсыз-уенсыз үтмәгән. Яңа тормыш корырга җыенганда да, кешe җырдан аерылмаган. Әле бүген дә, борынгыдан килгән йола буларак, туй күрке җыр белән. Инде олыгайган көннәрендә дә, үзләрен ахирәткә әзерли башлаган әби-бабаларыбыз җайлап кына үз алларына мөнәҗәт көйләп утыралар түгелме?.. Әйе, рәхәттә дә, михнәттә дә адәм баласы үзенә юлдаш итеп җырны сайлаган.

Татар халык җырларына, гомумән җырларга караган тикшеренүләр фольклористика һәм әдәбият белеме фәнендә юк түгел, бар. Әмма нинди шартлар җырны жанр итеп яшәтә соң? 1998 елда Казанда «Мәгариф» нәшриятында чыккан «Шигърият һәм җыр» дигән китабында филология фәннәре кандидаты Ким Миңнуллин нәкъ менә шушы сорауга җавап бирергә тырыша да инде.

Автор хаклы: авыр, фаҗигале язмышлы халкыбызның рухын, милли хисләрен нәкъ менә җыр яшәтте. Чукындырылганда да, бәхет эзләп ачык диңгезгә чыгып киткәндә, тирән шахталарга төшкәндә дә, сугыш кырларында да өзелгән тәсбих төймәләредәй, төрле җирләргә чәчелеп яшәргә мәҗбүр булганда да, халкыбызны, күңел яраларыннан шытып чыккан, җыр аяп калгандыр, мөгаен. Инде бүгенге көндә дә, милләт янә Янарыш кичергән бер чорда, җыр сәнгатенең кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Һәм Ким Миңнуллинның нәкъ менә шушы «житез һәм хәрәкәтчән, халык күңеленә иң якын, иң тиз үтеп керә торган жанрга» мөрәҗәгать итүе үзен аклый.

Китапның исеменнән үк күренеп тора: бу—җырны әдәби яктан өйрәнүгә багышланган хезмәт. «Татар шигъриятендә җыр жанры» дип аталган беренче бүлек җыр жанрының тууын һәм формалашуын, җырларны төркемләү принципларын, җырларны иҗат итү үзенчәлекләрен, бу жанрда сүз һәм көй мөнәсәбәтен, шигырь һәм җыр текстларын ачыклауга багышланган. Җырлардагы образлар системасы, композиция алымнары һәм стилистик фигуралар, ритмика һәм авазлар аһәңлеге дә автор тарафыннан бик ныклап өйрәнелгән. Биредә шигырь белән көйнең үзара мөнәсәбәтләре, алар төрлелегенең фольклорда башка жанрлар формалашуына да йогынты ясавы турында да сүз бара. Мәсәлән, дастан жанры речетатив белән башкарылса, бәет һәм мөнәҗәтләрдә музыка өлешенең роле дастаннардагыга караганда югарырак баскычта тора. Җырларда исә музыканың роле тагын да үсә. Фольклор әсәрләрен көйләп башкару традициясенең татар җирлегенә бик тирән үтеп керүе мәгълүм: күп мәхәббәт дастаннары, дини эчтәлекле китаплар бүгенге көнгә кадәр көй белән бергә яшәп киләләр. Ким Миңнуллинның бу уңайдан лирик әсәрләрнең еш кына «җыр» дип, ә шагыйрьләрнең үзләрен «җырчы» дип атаулары турындагы фикере дә кызыклы һәм әһәмиятле.

Мәгълүм ки, XX йөз башы татар әдәбиятында «алтын чор» булып исәпләнә. Нәкъ менә шушы тарихи дәвердә татарларның, шул исәптән күп кенә башка халыкларның, шигърияте, гомумән әдәбияты, тел, әдәбият белеме, милләтнең фикер йөртү сәләте үзенең иң югары ноктасына ирешә. Җыр һәм музыка сәнгатенең дә үзенең башлангычын нәкъ менә XX йөз башында алуы очраклы түгел. Шагыйрьләребезнең аерым әсәрләре, халык көйләре белән кушылып, җыр яратучылар репертуарында инде 1905 ел революциясе чорыннан ук актив яши башлый (Г.

Тукайның «Бәйрәм бүген», «Туган тел», С. Рәмиевнең «Сызла, күңелем», «Бетте баш, кипте яшь» әсәрләре, шәкертләр иҗаты). Бу чорда Казанда һәм татарлар яшәгән бүтән төбәкләрдә әдәби-музыкаль кичәләр оештырыла, татар телендә китап басу эше зур тизлек белән үсә. Казан, Оренбург, Уфа, Әстерхан шәһәрләрендә җыр мәҗмугалары күпләп басыла, аерым авторлар туплаган җыр китаплары дөнья күрә (1910 елда Г. Тукайның «Халык моңнары», 1912 елда Ф. Туйкинның «Җырлар әхтәрисе», 1914 елда Х. Бәдигыйның «Җырлар» җыентыклары). Болар барысы да халыкта җыр сәнгатенә, гомумән, фольклорга карата кызыксыну, мәхәббәт уятуда әһәмиятле роль уйныйлар. Нәкъ менә шул чорда җырларны туплау һәм фәнни өйрәнү эшенә дә нигез салына (Г. Рәхим, Ә. Вәлиди, М. Акчурина, Ф. Сәйфи, С. Габәши, Ф. Латыйповлар хезмәтләре). 1930 елларда татар җыр сәнгатенә М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, З. Хәбибуллин, Ж. Фәйзи, Ә. Ерикәй, Ә. Фәйзи һ. б. бик күп талантлы авторлар килә, театр кысаларында туган профессиональ җыр жанры инде мөстәкыйль рәвештә яши башлый, ягъни татар авторлары җырлары халык җырлары белән бердәй таралыш ала.

Җырларның күп кенә үзенчәлекләрен («әдәби җыр», «автор җырлары») искә алып, аларны төркемнәргә бүлүне галим бер-беренә үрелеп бара торган ике принципка нигезли: башкару шартына һәм яшәү рәвешенә. Беренче принцип буенча, К. Миңнуллин профессиональ җырларны ике төргә—концерт җырларына һәм көндәлек җырларга бүлә, һәрберсенә характеристика биреп үтә. Көндәлек җырлар төренә халыклашкан, ягъни авторы билгеле булмаган, яисә онытылган әсәрләрнең халык җырлары булып йөргән җырларны да кертеп, бу өлкәдә туктаусыз дәвам иткән сайлау процессына да китапта зур урын бирелә һәм популярлашу белән халыклашу күренешләренең бер-берсеннән нык аерылып торуына басым ясала. Бу ике күренеш шартлы рәвештә җыр язмышының төрле баскычлары, төрле этаплары итеп кузаллана.

Әмма К. Миңнуллинның тикшеренүе өстә әйтеп үткәннәр белән генә чикләнми. Шигърият һәм музыка өлкәсендәге башка жанрларга караганда, җырларның иҗат ителү, әсәр булып оешу практикасы да бик үзенчәлекле. Билгеле булганча, җыр шигърият һәм музыка кушылудан туа. Профессиональ җырларны исә, халык җырларыннан аермалы буларак, шагыйрь һәм композитор иҗат итә. Әсәрне халыкка җиткерү өчен иҗатка җырчы да кушыла. Ләкин җыр бу тәртиптә генә барамы? Юк икән шул. Чөнки кайбер җырларның сүзләрен дә, көен дә автор иҗат итү һәм үзе үк башкару очраклары бар. Европада мондый авторларны трубадурлар, менестрельләр дип, бездә һәм кайбер төрки халыкларда аларны җырау, акын, чәчән дип тә атыйлар. Әгәр дә автор бу күренешнең Европага гарәпләр тарафыннан, ягъни һаман да шул ук Көнчыгыштан керүен дә әйтеп үтсә, тикшеренү тагын да тулырак булыр иде.

К. Миңнуллин үзенең хезмәтендә җырларның сүзен дә, көен дә үзе иҗат иткән иң беренче авторлардан алып (50 нче елларда Әкрәм Даутов) бүгенге көнгә кадәр аларның җыр иҗат итүдә нинди рольләрдә катнаша алуына күзәтү ясый. Алай гына да түгел, җыр ничек туа дигән сорауга да җавап бирә. Әлбәттә, җыр иҗат итүче авторлар белән уздырылган әңгәмә материалларына һәм махсус сораулыкка алынган җавапларга таянып. Мәсәлән, җыр шигырьдән дә башлана ала, әмма шул ук вакытта, композиторлар көйнең беренче булып тууын да табигый күренеш дип саныйлар икән. Кайберәүләрдә исә аерым темага караган шигырь юлларын күздә тотып көй язу гадәте дә бар. Ләкин бу мәсьәләгә—җыр язылуга—композиторлар ирекле карасалар да, шагыйрьләрнең мөнәсәбәтләре катлаулырак. Әзер көйгә шигырь язуны аларның күбесе—мәсәлән, Н. Нәҗми—кабул итми. Кайберләре—мәсәлән, И. Юзеев,—авырлык белән булса да, башкара ала. Ә инде Г. Зәйнәшева, мәсәлән, әзер көйгә текст язуны нормаль хәл дип саный. К. Миңнуллин бу күренешнең дә тирән тамырларын барлый. Җырларның башка жанрларга кушылып дөньяга килүен һәм таралуын да (мәсәлән, театр сәнгате белән) ул игътибарга лаек күренеш дип таба һәм аны XX йөз башыннан алып бүгенге көнгә кадәр күзәтә, өйрәнә. Поэмалар нигезендә туган җырлар да (И. Юзеев поэмаларыннан «Резидәкәй», «Гашыйклар тавы» җырлары) сирәк күренеш түгел икән. Кыскасы, галим «җырлар сәхнә әсәрләре һәм башка төр жанрлар белән аралашып, яңадан-яңа бәйләнешләргә кереп яши ала», дигән нәтиҗә ясый.

«Җырларда сүз һәм көй мөнәсәбәте», «Шигырь һәм җыр тексты» дигән бүлекчәләр дә кызыклы һәм яңа мәгълүматларга ия. Ләкин аеруча игътибарга лаек дип,

мин шәхсән үзем «Җырларның сәнгатьчә эшләнеше» дигән бүлекчәне атар идем. Чөнки бу бүлекчә безгә, әдәбиятчыларга, җыр жанрына карата иң кирәк мәгълүматлар өсти, җырларга тулы поэтик анализ ясауда, аларны композицион яктан өйрәнүдә дә зур ярдәм булып тора. Татар җырларында образлар системасын башка халыклар (чуаш, мари, урыс) җырлары белән чагыштырма-типологик планда өйрәнү—хезмәтнең кыйммәтен тагын да арттыра төшә.

К. Миңнуллин дөньяны образлар аша танып белүнең тарихына киң туктала. Җырлардагы образлар системасын хаклы рәвештә анимизм (һәр нәрсәнең җаны, иясе бар дип тану), антропоморфизм (кешегә хас сыйфатларны табигатькә, кошкортларга, җәнлек-хайваннарга күчерү) һәм тотемизм (үсемлекләр, хайваннар һәм табигать күренешләренең кешеләр белән кардәшлектә булуларына ышану) этаплары белән бәйләп карый. Ул бигрәк тә сандугач (былбыл), каен, дәрья, су образларының мәгънәсен тирән ачып бирә алган. Галим халык җырларына һәм профессиональ җырларга хас образларны ачыклый, зәвыксыз җырлар артуга үзенең тискәре карашын белдерә. Җыр жанрын кызыклы гына итеп, фольклорның башка жанрлары—легенда, риваятьләр, дастаннар, мифлар, йолалар, ышанулар, мәкальәйтемнәр белән үреп, чагыштырып бара. Тарихи документлар, әдәби чыганаклар, күренекле галимнәр—тюркологлар хезмәтләре белән дә иркен эш итә.

Җырларда киң таралган сурәтләү чараларыннан кабатлауларга аерым тукталып, аларның тамырларын табышмакларда, дастаннарда барлый. Лирик эндәш һәм мөрәҗәгатьләрнең сөйләмнең аһәнен, эмоциональ яңгырашын баету, хис-тойгыларын көчәйтү, аларны тагын да нечкәрәк, җылырак итеп сурәтләү өчен кулланылуы турында сүз алып бара.

Ритмика һәм авазлар аһәнлеге өстендә үткәргән тикшеренүләр нәтиҗәсендә исә автор шагыйрьләрнең халык көенә яңгыраган әсәрләре бөтенләе белән диярлек 8—7 иҗекле үлчәмгә корылганнар дигән фикергә килә. Шунысы да кызыклы: җыр текстларының шигъри төзелеше аша аерым шагыйрьләрнең иҗат стильләрен дә билгеләү кыен түгел икән.

Китапның икенче бүлегендә («Җыр һәм тормыш») К. Миңнуллин татар җыр сәнгате дөньясына караган һәм төрле елларда язылган мәкаләләрен, һәм публицистик язмаларын туплаган. Бирегә татар җыр китаплары тарихы да яктыртыла, Идел-Урал төбәге халыкларының җыр шигъриятендә уртак символика да ачыклана, «Татар җыры-89» конкурсы турында да кайбер фикерләр әйтелә, Мостафа Ногман, Әхмәт Ерикәй кебек җырчы шагыйрьләребезнең юбилее уңаеннан язылган мәкаләләр дә урын алган.

Китапның өченче бүлеге—«Җырлар нын да үз язмышы»—К. Миңнуллинның җыр өлкәсендә актив эшләп килгән шагыйрь һәм композиторларыбыз белән бергәләп башкарган уртак иҗат җимеше. Чыннан да, әгәр дә галим җыр кебек жанрга мөрәҗәгать иткән икән, ул архив, китапханә чыганаклары белән генә эш итә алмый. Тере шагыйрьләр, композиторлар, җырчылар белән әңгәмәләр корып, фикер алышырга да мәҗбүр. Бу уңайдан галим халык шагыйрьләре И. Юзеев, Ш. Галиев, Н. Нәҗми һәм башка мәшһүр авторлар белән, атаклы композиторлар Ф. Әхмәтов, Р. Еникеев, М. Имашевлар белән җыр турында кызыклы әңгәмәләр алып барган.

Китапның тагын бер бүлеге—кушымтасы да игътибарга лаек. Бирегә беренче татар җыр китабыннан алып бүгенге көнгә кадәр нәшер ителгән 500 дән артык җыентыкның хронологик тәртиптә урнашкан исемлеге бирелгән.

Әлбәттә, хезмәттә бәхәсле моментлар да юк түгел. Мәсәлән, автор «җыр итеп язылган көйнең тексты булмаса, ул җыр буларак та, үзе генә дә яшәми»,—дип яза. (42 б.) Ләкин, Ә. Бакировның җыр формасында язылган «Сүзсез җыр»ы җыр буларак яшәмәсә дә, музыкаль әсәр буларак фортепианода бик яратып башкарыла һәм бик популяр.

Шулай да, бу хезмәт яңа теоретик мәгълүматларга, күп кенә мәшһүр талант ияләребез белән җанлы, кызыклы әңгәмәләргә ифрат та бай. Ул шигърият һәм җыр сәнгате белән кызыксынучыларга да, студентларга да тәкъдим ителә. Шуны да әйтергә кирәк, бу хезмәт—җыр шигъриятен монографик планда өйрәнү өлкәсендә тәүге тәҗрибә. Һәм ышанасы килә—соңгысы түгелдер.

**Чулпан ЗАРИПОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

*Xəter*

# ONITILMAS EŞLƏR QALDIRIP KİTTE...

ŞƏRİF XƏSƏYENOFNIŅ TUUINA 70 YIL

1955 yılnıņ kezendə şaqtıy cəfalı awır «səyəxətem»ne təmamlap yaņadan Qazanğa qaytıp təştem. Dənya əllə ni üzgərməgən də, tik keşelərne tanıp bulmıy. Kem yanına barıp, niçek süz başlarga belmiçə isəngerəp torasıņ. Tərmədən çıqqan hər can iəsenə keşelər bolay da sağayıp qarıylar, ə monda minem «qara saqalım» cirdə səyrəlgən. «Tege... ni... katorjan!» Can bəten yaqlardan cılı küz qaraşı, yağımlı süz kətə. Min tanışlarıma ozatqan songı xatlarımda, ilgə qaytasıma ışanıp «bulaçaq dramaturg» dip qul quya idem. Qapçığımda «Yalgız yortta sagış» dip isemləngən bik xətər pyesam da bar!

Yarsıp, sağınıp qaytıp kerdem Qazanğa. Berençe eşem itep teatr afişalarına yabırıldım. Hm-m, Şərif Xəsəyenof digən, «Professor kiəwe» digən... Uynauçılar arasında Wəkil Zakirof iseme də çekrəep tora. Wəkil! Dus yeget!

Wəkilne teatrdan ezləp tabu qıın bulmadı. Bez oçraştıq. Ul mine kiçke spektakl'gə «Professor kiəwe»nə çaqırdı. Şul kiçtə min ataqlı Şərif Xəsəyenof belən tanıştım. Meditsina institutı şəkerte, vraç, yegetlərçə ütə çibər. Bu yegetkə min açıqtan-açıq kenləşep qaradım. Qazannı şaulatqan, səngət səyüçelərne dulqınlandırğan, qıyu, çaya, süzdə çiçən bu yegetne min ber kürüdə oşattım. Ul üze minem qaysı sıyfatlarımnan yaqın kürgənder, belmim. Şul kiçtən başlanğan tanışlıq küp yıllar dəwamında saqlandı. Ozaqlamıy dramaturglar siksiəsendə min «Xədiçəneņ keçe ulı» isemle pyesamnı uqıdım. Buldı oşatuçılar, ləkin küpçelek mine ayamadı, tetep saldı. Ə Şərifnen çığışınnan ber fiker ğemergə istə qaldı. «Ayazda Çexof dramaturgiəseneņ tə'sir keçe bik nıq sizelə», dide ul mine çəynəkləp taşlağan qayberəülərneņ awızın yomıp. Çınnan da, Çexof pyesalarına məkibbən kitkən keşe bularaq Şərifneņ sizgerlegenə çiksez səyendem...

Təüge proza əsərləremne də qulyazmamda uqıp bardı Şərif. Şularğa nisbəttən bez dənya xəlləren, ildə bulıp torğan üzgəreşlərne üzebezçə bəyələp, açıqtan-açıq səyləşə, xaqlıq digən yuğarılıqqa menep citərgə tırışa idek. Bez tanışıp yaqınayğan yıllar eçendə Rəsəy qırıqqa tərlənde, vlast' keçlərə adəm ulların əle tege, əle bu yaqqa baş orıp yəşərgə məcbür ittelər. Qara yəzle İblislər cayın tabıp Fəreştə qiəfətenə kerdelər, qarğalar sanduğaç bulıp sayraştılar, dənya tuqtausız butaldı. Şərif Xəsəyenof isə ber çaqta da üzgərməde, vlast'qa omtılmadı, matdı qiınlıqlar tatımadı. Səygən eşe vraçlıqnı taşlamadı, waq-təyək əsərlər yazıp tatarnıņ ber qatlı eleşen anğıraytmadı. Ul başta uq saylap alğan gumanistik ideallarğa xezmət itüne esten kürde. Ul tudırğan əsərlər san yağınnan əlləni küp tügel, əmma anıņ qələmennən tamğan hər tamçı ence bərtegenə bərabər bula bardı. «Zəbəydə adəm balası», «Əni kilde» pyesaları—klassik əsərlər, cir yəzendə tatar yəşəgəndə xalıq ul pyesalarnı üze belən alıp baraçaq. Küpme akterlar anıņ əsərlərə buyınça quyılğan spektakl'lərdə uynap, üzlərenə rux azığı, küņel cimeşlərə tapsa, küpme tamaşaçılar aqnı qaradan ayıra alu məktəben üttelər. Şərif Xəsəyenof tatar tamaşaçısınıņ tərbiəçese bularaq Ğ. Kamal, M. Fəyzilər belən ber yuğarılıqta tora. Ə anıņ prozası? Yumoristik xikəyələre? Nihayət, tellərdə genə yərgən zirək parodiələre! Üzək jurnallarda kürenep kitkən replika-məqələləre! Qayberlərenen tə'sir keçennən, təple dəlillərennən qurqıp Çerek külgə yuqqa ğına çaqırmadılar iç yegetne!

Şərif bik küp yaqlardan talantlı ide. Ber zaman ul foto eşe belən mawıqtı, tiz arada bu eşneņ üzençəlekle ostası bulıp əwerelde. Kaktus üstərə başlagaç ul yıllar dəwamında kaktusçılar belən aralaştı, kataloglar təzep üz mawğuın fənni dərəcəgə kütərde. Anıņ yortın tutırıp, sixri çəçəklərə belən dənyanı bizəgən kaktus kolleksiəsen qarağan keşelər soqlanıp wə ğəcəplənep telsez qalalar ide. Əmma Şərifneņ in olı, in

məqətdəs mawıģuları bolar belən genə çiklənmədе. Tatar ədiplərе arasında opera, balet səngəten tirənten belgən, ixlas yarata alğan berdənber keşe Şərif buldı. Başta ul operalar yazılğan plastinkalar cıydı, annan kassetalarğa küçte. Çirattağı yalına çığuğa Məskəügə yünəlde. Annan küņelenə xuş kilgən operalar yazılğan kassetalar ciip qayttı. Ul baytaq operalarnıņ neçkəlegen aņlap, başqaruçılarnıņ hər ımın, hər işarə serlərеn aņlauçı NAZİK KÜŅELLE, bay şəxes ide. Soņğı yıllarda anı bəyek keşebez Rudol'f Nuriefnıņ küpqırlı icatı tulayım biləp aldı. Açıqtan açıq əytməsə də, ul qabatlanmas talant iəse xaqında əsər yazarğa da qıcrap yəri ide şikelle. Ləkin anıņ bu planı tormışqa aşmıy qaldı.

Kamal teatrı xucaları—duslar saylauda ütə nəzberek bulğan Marsel' Səlimcanof belən ixlas yərdəmçel Şamil Zinnuroviç Zakiroflar Şərifne ğəmere buyına üz ittelər. Şərifneņ əcəle yaqınayğanın belep, anıņ 70 yıllıq tantanasın noyəber azağınnan iüngə küçerdelər. Sizger vraç Şərif üzen ni kətkənen açıq aņlap, yarım kələmserəp, «Əni kilde» prem'erasınıņ alğaraq küçerelüenə işarələp:

—Min bu dənyadan alqışlar astında kitəçəkmen!—dip əytep quydı.

Spektakl'dən soņ səxnəgə üz ayağı belən mengən Şərif üz ayağı belən annan təşə almadı. İke başına da ut qabınğan şəm kebek tiz arada erep bette...

Mərxümneņ icatın barlap, tarixta berketep qaldıru bezneņ izge burıçıbız dip beləm. «Əni kilde» prem'erasına çaqırğan qəğəzdə Şərif miņa «Dustım, Ayaz!» dip endəşə. Baytaqtan mondıy olı süzne işetkən yuq ide. 70 yəştə duslar qalmıy diərlek... Şərif soņğı duslarımnıņ berse, iņ talantlısı, iņ ğədele, cirdə izge ğəməllər qaldırğan BƏYEGE ide.

**Ayaz ĞIYLƏCEF,**
*sintəber 1999 yıl.*

---

*Котлыйбыз!*

## Фәния Гайнановага 70 яшь



Фәния Гариф кызы Гайнанова 1929 елның 15 ноябрендә Арча районы Олы Әтнә авылында туа. 1946 елны Казан Дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1951 елда укуын тәмамлап, шул ук университетның фәнни китапханәсендә эшли башлый. 1952 елны Ф. Гайнанова Татарстан китап нәшриятына эшкә урнаша һәм утыз ике елдан артык гомерен матур әдәбият редакциясендә редактор һәм өлкән редактор вазифаларын башкаруга багышлый.

Фәния Гайнанова тәрҗемәсендә чит ил, рус һәм СССР халыклары язучыларының дистәдән артык китабы басылып чыкты. Алар арасында «Мисыр хикәяләре», Ж. Вернның «Капитан Грант балалары», «Серле утрау», И. Тургеневның «Язгы сулар» повесте һәм И. Гончаровның «Гыйбрәтле язмыш» романы аеруча игътибарга лаек.

Хезмәт юлындагы казанышлары өчен Фәния Гариф кызы Гайнанова «Матбугат отличнигы» исеменә лаек булды, аңа Татарстан җөмһүриятенең «Мактау грамотасы» һәм Россиянең «Атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелде.

Фәния Гайнанова 1980 елдан Язучылар Берлеге әгъзасы. Бүгенге көндә ул Татар энциклопедиясе институтында мөхәррир булып эшли.

*Иҗтимагый—мәдәни тормышыбыздан*

**ФИННАР БЕЛӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК**

Татарстан Президенты М. Шәймиев житәкләгән делегация 14-15 октябрьдә Финляндиядә булды. Финляндия Президенты Мартти Ахтисаари, Парламент Рәисе Рийтт Уосукайнен, Финляндиянең Сәүдә һәм икътисад министрлыгы житәкчеләре белән очрашу нәтижәсендә Татарстан өчен файдалы өч килешүгә кул куелды. Тәгәлрәк әйткәндә: Түбән Кама «Нефтехим» акционерлык жәмгыяте 40 млн. долларлык продукциясен Финляндиягә сатачак. Шул ук вакытта Финляндиянең кайбер технологик жиһазлары нефтехимия промышленносте предприятиеләренә кайтарылачак.

Минтимер Шәймиев һәм делегация вәкилләре Финляндия Татар жәмгыятендә дә кунакта булдылар. Татар жәмгыяте рәисе Окан Таһир әйтүенчә, бу очрашуга татарлар бөтен Финляндиядән махсус жыелганнар, алар М. Шәймиевне Татарстан Президенты итеп кенә түгел, дөнья буйлап сибелгән барлык татарларның да Президенты итеп саныйлар.

**ИНСТИТУТ ЮБИЛЕЕ**

20 октябрьдә Татарстан Дәүләт Зур концерт залында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 60 еллык юбилее билгеләп үтелде. Тантаналы утырышны ТФА Президенты М. Хәсәнов ачты. Ул гуманитар фәннәр институтының озын, гыйбрәтле, әмма нәтижәле юл үтүе, аның бай фәнни казанышлары белән дөньякүләм танылуы, мәшһүр тарихчылар, әдәбиятчыларның татар гуманитар фәнен үстерүгә зур өлеш кертүләре, бүгенге көндә татар халкының тарихын өйрәнүдә, телен саклап калуда, алфавитын торгызуда бөтен көчләрен биреп эшләүләре турында сөйләде.

Институт директоры М. Зәкиев тантанага жыелган кунакларны әлеге фән йорты үткән данлы юл белән таныштырды.

Юбилей тантанасында Татарстан Президенты М. Шәймиев тә чыгыш ясады һәм гуманитар фәннәрне үстерүгә зур өлеш керткән өчен институтка һәм бер төркем галимнәргә Татарстан республикасының Мактау грамоталарын тапшырды.

**ШУРА ЭШЛИ БАШЛАДЫ**

Татарстан Язучылар берлегендә Аксакаллар шурасы оештырылды. Аның максаты—өлкән яшьтәге язучыларга ярдәм күрсәтү. Шураның шәрәфле рәисе итеп бертавыштан аксакал язучыбыз Әмирхан Еники, төп эшләрен башкаручы рәисе итеп Мәгъсүм Гәрәев сайланды, ә составына исә Татарстанның халык язучылары Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләжев, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, фронтовик язучылар Мәгъсүм Насыйбуллин, Геннадий Паушкин, Кави Латыйп, язучылар Азат Әхмәдуллин, Мәгъсүм Хужин, Ләбибә Ихсанова, Нонна Орешина, Рабит Батулла, «Кызыл Ай» шәфкатьлелек жәмгыяте президенты, язучы Мәдинә Маликова керде.

**ЯЗУЧЫНЫ ОЛЫЛАУ**

Ш. Камал музеенда күренекле язучы Шамил Рәкыйповка 70 яшь тулуга багышланган музыкаль кичә булды. Анда артистлар Ренат Тажетдинов, Ирек Баһманов, Миңгол Галиев, Гөлзадә һәм язучының каләмдәшләре катнашты. Татар дәүләт яшьләр театры язучының «Кызлар-йолдызлар» спектаклен куйды. Алар авторның әсәрләреннән өзекләр укыдылар һәм Ш. Рәкыйпов сүзләренә ижат ителгән жырлар башкардылар.

**ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ**

Мәдәният өлкәсендәге күпьеллык нәтижәле хезмәте өчен республиканың атналык «Мәдәни жомга» газете баш мөхәррире Зиннур Мөжип улы Мансуров Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# ИҖАТКА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Күренекле татар рәссамы Искәндәр Рафиковка житмеш яшь тулды. Ярты гасыр чамасы гомерен иҗатка багышлаган рәссам өчен рәсем сәнгате яшәү мәгънәсе, аның язмышы да ул.

Һөнәри белемне ул Казан сәнгать училищесында һәм Рига сәнгать академиясендә ала. Күренекле латыш рәссамы Я. Тильберг остаханәсендә укый.

Иҗат юлы совет идеологиясе белән сугарылган чорга туры килсә дә, рәссам чын реалист булып кала алган. Искәндәр Рафиков—рәсем сәнгатенең классик традицияләренә таянып, үзенең индивидуальлеген саклап әзлекле иҗат итүче татар рәссамнарыннан. Бу өлкәдә ана тиңнәр табуы кыен. Ул, заманча яңа юнәлеш-карашларга артык игътибар бирмичә, үз мәсләгенә тугры калып, гаҗәеп үҗәтлек белән Европа реалистик мәктәбе ирешкәннәрне татар рәсем сәнгатендә дәвам иттерә. Аның хезмәтләре үзенә генә хас тирән фикерле, форма ягыннан монументаль бай эчтәлекле булулары һәм композиция төзелешенең бөтенлеге белән дә аерылып торалар. Реалистик сурәтләү манерасы, осталыгы рәссамны психологик портретлар, татар халкы тарихына, көнкүрешенә багышланган темаларны сурәтләүче зур оста итеп таныттылар. Аның беренче карашка гадәти генә тоелган «Кунакка бару», «Ана», «Кызлар» һәм башка картиналарында халкыбызның милли характеры, рухи дөньясы чиста, бай образлар аша сурәтләнә.

И. Рафиковка авыл темасы да бик якын. Гади генә тоелган әйберләрне дә—чиккән сөлгеме яки шамаилме, җепләр йомгагымы, милли киемме—картинаның композицион төзелешендә югары кимәлдә чагылыш таба, авыл көнкүрешенең җылы атмосферасын тудыра. Аның әсәрләре төсләрнең бирелеше, һәм аеруча милли төсләрнең өстенлеге белән игътибарны җәлеп итәләр.

Искәндәр Рафиковның төп иҗат идеясе татар халкының әхлакый йөзен, тыйнаклыгын һәм кыюлыгын, рух һәм иҗат потенциалын сурәтләүдән гыйбарәт. Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Гөлсем Болгарская, Мәрьям Рахманкулова, Җәүдәт Фәйзи кебек күренекле татар уллары һәм кызларына, тезүчеләргә, нефтьчеләргә, тарихи шәхесләргә һәм замандашларына багышланган портретлар сериясе менә ачык мисал.

«Җәлилчеләр» монументаль картинасын алыйк. Бу әсәр сурәтләнгән геройларның гына түгел, бәлки рәссамның да батырлыгын чагылдыра дисәм ялгышмамдыр. И. Рафиков бу әсәрне язуга гомереннең дистәдән артык елын багышлый. Архивларда казыну, эзләнүләр, сәфәр чыгулар, күпсанлы эскизлар... Татар сынлы сәнгатенең алтын фондына кергән әлеге картина сәнгаткярнең башка күп кенә әсәрләре белән бергәттән Татарстан сынлы сәнгать музеенның даими экспонатлары арасында саклана.

Соңгы елларда җәмгыятебездә булган демократик үзгәрешләр рәссамнарыбызга халкыбызның милли тарихы темасына иркенләп иҗат итү мөмкинлекләре ачты. «Сөембикә», «И туган тел...» картиналары, мәчет һәм борынгы ядкарьләр сурәтләнгән әсәрләр шуларның ачык йогынтысы.


Татарстан хөкүмәте Искәндәр Рафиков талантына һәм иҗатына зур бәя бирде. Ул—Татарстанның халык рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, исеме Зур Совет Энциклопедиясендә һәм сәнгатькә багышланган калын монографияләрдә.

Рәссам киләчәккә зур иҗат планнары белән яши, иҗат итә, мирасын тулыландыра.

Гүзәл **ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА**
*сәнгать фәннәре докторы.*

*Тышлыктагы сурәтләр:*

**Тышлыкның беренче битендә:** «И туган тел...»—Искәндәр Рафиков картинасыннан фотокүчермә.
**Тышлыкның дүртенче битендә:** әдип-тәрҗемәче Кыям Миңлебаев.



# ХУШЛАШУ СҮЗЕ

Бу елның 6 сентябрендә олуг замандашыбыз—Башкортостанның халык шагыйре, М. Горький һәм С. Юлаев исемендәге Дәүләт премияләре, шулай ук Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге бүләге лауреаты, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы, аксакал әдип Нажар Нәҗми сиксән икенче яшендә дөньядан китте. Ул татар әдәбиятының, халкыбызның сыналган, тугры дусты, Уфада яшәп тә Казан турында кайгыртып, янып яшәүче каләмдәшебез, татар һәм башкорт әдәбиятларын үстерүгә зур өлеш керткән ил агасы иде. Президентыбыз М. Шәймиевнең Башкортостан илбашы М. Рәхимовка кайгы уртаклашып җибәргән телеграммасында да бу чагылыш тапты. Әйе, шагыйрьнең зур әдәби мирасында татар халкы, теле һәм әдәбияты язмышы зур урын алып тора: атаклы «Татар теле», «Казан, Казан—татар Парижы», «Бар», «Татар бугазы» кебек шигырьләрен, «Татар каны», «Иблис» поэмаларын искә алу да җитә.


Шулай ук Г. Тукай, М. Җәлил, Х. Туфан, С. Хәким, Г. Бәширов, Ә. Еники кебек классик әдипләребезгә багышланган шигырьләре, мәкалә-эсселары күбесен үзе күреп, белеп, даими аралашып яшәгән татар әдип-шагыйрьләрен олылау, алар йөзендә татар әдәбиятына зур мәхәббәт чагылышы иде. Бу—аның үзеннән яшьрәк каләмдәшләренә ачык хатлары, багышлаунамәләрендә дә—һәм алар, югарыда саналган әсәрләр кебек үк, беренче мәртәбә журналыбыз битләре аша укучыга таралды. Әйе, татар әдәбияты, мәдәнияте, сәнгатенә табынып, яратып яшәгән шагыйрь күпләребез турында җылы сүзен әйтеп, үз чиратында үзенә карата да яхшы сүзләр ишетеп, хөкүмәтебез, киң җәмәгатьчелек тарафыннан кайгырту, ихтирам тоеп яшәде—узган ел Казанда Г. Камал театрында узган юбилей кичәсе дә шуның бер мисалы иде.

Нажар ага «Алар өчәү иде» дигән мәгълүм шигырендә дуслары—Кайсын Кулиев, Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәрне яратып яшәп, аларның дәфененә дә баруын яза, һәм «мин үлгәчтен—мине алар килер кебек җирләргә» дип тә әйткән иде. Әйе, Башкортостанның Бабичны да тудырган Дүртөйле районында, аның Минеште авылында—Агыйдел буенда, үзе васыять иткәнчә, Кандаулы тавы башына күмелгән шагыйрьгә баш иярgә бөекләрнең мәңге тере рухы да, исәннәрнең мәхәббәте дә, аны киләчәктә яд итәчәк яңа буын—яшьләр авазы да озаткандыр. Ул бит халыклар, әдәбиятлар, шагыйрьләр дуслыгы җырчысы, борынгы тамырлар, Әнкә тел—төрки Ватан хисенә ахыргача тугрылык саклаучы иде: шуңа да татар һәм башкорт халыкларының кабатланмас рухи байлыгы нәкъ менә анарда, аның иҗатында үзенең балкышын тапты.

Хуш, ак җанлы дустыбыз, Нажар ага! Урының җәннәттә булсын!

*«Казан утлары» редакциясе.*

Индекс 73210



Кыям Миңлебаев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)